4° 2014

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

КАЗАН

*Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары —
мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Мөдәррис Харис улы ВӘЛИЕВ

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), БӘДЕРТДИНОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты),
ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ Д.Р. (фәлсәфи фикер)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Г.Р. ХӘКИМОВА

## БУ САНДА:

Котлаулар ........ 5

• ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Зәкиев М.З.* Гомумиләштерүче фундаменталь лингвистик хезмәтләр төзү юлында ........ 14

*Тимерханов А.Ә.* Татар лексикографиясенең үткәне һәм киләчәккә бурычлары (кыскача күзәтү) ........ 21

*Рамазанова Д.Б.* Заман белән бергә ........ 35

*Бәширова И.Б., Миңнулин Б.К., Мирхаев Р.Ф.* Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәби теле тарихының өйрәнелеше ........ 49

• ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Исламов Р.* Әдәбият гыйлемендә эзлебез... ........ 57

*Рахмани Р.* «Татар әдәбияты тарихы»ның алты һәм сигез томлыклары хакында ........ 67

*Рәмиев З.З.* Әдәбият текстологиясе ........ 76

• ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Закирова И.Г., Урманчеев Ф.И.* Эшләре — җыр, сүзләре — дастан (халык иҗаты бүлегенең 75 еллыгы уңаеннан) ........ 80

• ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

*Әхмәтҗанов М.И.* Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар мирасханәсе тарихы ........ 89

• ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Заһидуллин И.К.* 1940—1990 елларның беренче яртысында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында тарих фәне үсеше сәхифәләре ........ 98

*Хуҗин Ф.Ш.* Тел, әдәбият һәм тарих институтында Татарстан археологиясе ........ 109

*Мусина Р.Н., Суслова С.В.* Татарстанда этнологик тикшеренүләр тарихыннан (ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 75 еллыгына) ........ 121

*Шәйдуллин Р.В., Вәлиев Р.М.* XIX гасырның икенче яртысында — XXI гасыр башында Россиядә татар милли энциклопедистиканың барлыкка килүе һәм үсеше ........ 128

**• ФӘЛСӘФИ ФИКЕР**

Халкыбызның рухи мирасы ........ 140

**• МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Хәсәнова Ф.Ф.* ТӘһСИ галимнәре дәреслек яза, яки әдәбият укытуны программалаштыру ........ 144

**• ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Абдуллина Д.М., Бәдертдинова Л.Ш.* Мөхәммәт Гайнуллин — галим һәм остаз ........ 151

*Асылгәрәев Ш.Н.* Профессор Л. Җәләй — татар орфоэпиясен нигезләүчеләрнең берсе ........ 158

*Ямалтдинов И.И.* Халык акылына сокланган, гомерен аны өйрәнүгә багышлаган галим ........ 169

**• ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Баязитова Ф.С.* Институт тарихында фәнни экспедицияләр ........ 175

**• СӘНГАТЬ**

*Арсланов М.Г.* Рухи байлык сагында ........ 182

*Солтанова Р.Р.* Тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге ........ 189


**• ЯҢА КИТАПЛАР**

*Саберова Г.Г.* А.Ә. Тимерханов, С.Ф. Гарифуллин. Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге ........ 196

*Булатова М.Р.* Д.Р. Фардеева. Национальная проза на сцене татарского государственного академического театра им. Г. Камала ........ 198

*Вәлиев М.Х.* Без — бер тамырдан = Корни наши едины = Köklerimiz ortak ........ 200

Фәнни-иҗтимагый тормышыбыздан ........ 202



**Э. Н. ФӘТТАХОВ**
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары —
Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры

**Хөрмәтле коллегалар!**

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр, дөньякүләм проблемалар һәм интеграцион процесслар бүген мәгариф системасы алдына да яңадан-яңа бурычлар куя. Аларны тиешле дәрәҗәдә хәл итү, иң беренче чиратта, яшь буынга заман таләпләренә туры килерлек белем бирүне, тормышның төрле өлкәләрендә конкурентлыкка сәләтле белгечләр әзерләүне таләп итә. Әлеге юнәлештә мәгариф оешмалары фәнни-тикшеренү институтлары белән тыгыз элемтәдә эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты — татар гуманитар фәне өлкәсендә әйдәп баручы үзәкләрнең берсе. Аның милли мәгарифне үстерүдә дә өлеше зур. Бүген Институт республиканың мәгариф һәм белем бирү оешмалары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итә. Аерым алганда, татар галимнәре, тел, әдәбият һәм сәнгать белеменең фундаменталь нигезләрен эшләү белән бергә, бу өлкәдә ирешелгән казанышларны киң җәмәгатьчелеккә таныту юнәлешендә дә зур эшчәнлек алып бара: татар теле һәм әдәбиятын укыту проблемаларына багышланган бер генә чара да институт галимнәре катнашыннан башка үтми. Бу очракта мин «Ел укытучысы» конкурсларын, мәктәпләрдә үткәрелә торган фәнни-гамәли конференцияләрне, төрле методик семинарларны, предмет олимпиадаларын, тел-әдәбият укытучыларының форумнарын һәм башка чараларны күз уңында тотам.

Институтның милли мәгариф өлкәсендәге эшчәнлегенең тагын бер тармагы — югары һәм гомуми урта белем бирү оешмалары өчен уку-укыту программалары һәм дәреслекләр язу. Л. Җәләй, Г. Халит, Х. Хәйри, Х. Ярми, М. Гайнуллин кебек олы галимнәр башлап җибәргән бу традиция бүген дә уңышлы гына дәвам итә. Институтның фәнни хезмәткәрләре тарафыннан ФГОС таләпләренә туры китереп эшләнгән яңа буын дәреслекләрнең федераль исемлеккә кертелүе — моның ачык дәлиле. Шул ук вакытта тел-әдәбият

галимнәре тарафыннан язылган академик хезмәтләр үзләре дә дәреслекләр төзү өчен нигез булып тора.

Соңгы вакытта Татарстан Республикасы хөкүмәте тарафыннан мәгариф һәм фән өлкәсенә караган мәсьәләләрне хәл итү юнәлешендә күп кенә чаралар тормышка ашырыла. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасының 2014—2020 елларга дәүләт программасының кабул ителүе — татар фәнен һәм мәгарифен үстерүдә мөһим адымнарның берсе. Аны гамәлгә куюда институт галимнәренең дә өлеше зур. Аерым алганда алар «Ана теле» онлайн-проектында актив катнашалар. Институт базасында татарча «Фәнни Татарстан» журналының чыга башлавы да моның ачык үрнәге. Әлеге журнал гуманитар фәннәр өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен киң җәмәгатьчелеккә таныту юнәлешендә үзеннән зур өлеш кертә.

75 ел, бер караганда, күп тә түгел кебек. Шул ук вакытта татар телен саклап калу һәм аны киләчәк буыннарга җиткерү юлында күпме эш эшләнгән! Бүгенге катлаулы чорда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең милли мәгариф һәм фән алдында торган бурычларны уңышлы гамәлгә ашырачагына ихластан ышанам. Сезгә сәламәтлек, эшегездә уңышлар һәм яңадан-яңа фәнни ачышлар телим!



**М. Х. СӘЛАХОВ**
Татарстан Республикасы
Фәннәр академиясе президенты

**Мөхтәрәм дуслар, коллегалар!**

Быел Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенең 75 еллыгын бәйрәм итә. XX гасырның 20—30 нчы елларында ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган Академик үзәкнең дәвамчысы буларак, институт әлеге дәвердә киң кырлы фәнни эшчәнлек алып барды. Нәтиҗәдә гуманитар фәннәр өлкәсендә бай традицияләргә нигез салынды. Л. Җәләй, В. Хангилдин, М. Гайнуллин, Х. Ярми, Г. Халит, М. Мөхәррәмов, А. Халиков, Я. Абдуллин, Ә. Кәримуллин, Н. Юзиев, Х. Курбатов, М. Зәкиев, Ф. Урманчеев, Ф. Ганиев, Х. Мәхмүтов, Н. Хисамов, М. Әхмәтҗанов һ.б. күренекле галимнәр татар фәнен дөнья масштабларында танытуга үзләреннән зур өлеш кертте. Шуның белән бергә институт башка гуманитар фәннәрнең үсешенә дә йогынты ясады. Аның нигезендә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татар энциклопедиясе институтының оешуы — моның ачык мисалы. Институт Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен оештыруда да хәлиткеч роль уйнады һәм хәзер дә аның төп структур берәмлеге санала.

Тел, әдәбият һәм сәнгать белеме өлкәләрендәге фәнни эшчәнлекне институт бүген дә уңышлы дәвам итә. Ул берничә юнәлештә алып барыла. Бердән, максатчан рәвештә билгеле бер проблемаларны чишү, яңа гыйльми ачышларга ирешү юлында үтәлә торган проектлар; икенчедән, озак еллар дәвамында иҗтимагый-сәяси вакыйгалар нәтиҗәсендә онытылып торган өлкәләргә яңадан кайту, рухи мирасыбызны барлап, өйрәнеп, аны халыкка җиткерү; өченчедән, киң җәмәгатьчелекне фәнни казанышлар белән таныштыру максатыннан академик хезмәтләрне бастырып чыгару. Болар барысы да — татарны, аның гуманитар фәнен, гомумән, милли йөзен дөньяга таныта торган гамәлләр. Халыкара масштабта уздырыла торган фәнни-гамәли конференцияләр, симпозиумнар, экспедицияләр институтның чит илләрдәге фәнни үзәкләр белән эшлекле һәм нәтиҗәле элемтәсен күрсәтеп тора.

Хәзерге глобальләшү шартларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты алдында мөһим бурычлар тора. Беренче чиратта, бу — туган телебезне, милли үзаңны һәм мәдәниятне саклау, аларны һәрьяклап үстерүдән гыйбарәт. Саф фәнни оешма кысаларын инде күптән үтеп чыккан һәм иҗтимагый әһәмияткә ия зур үзәккә әверелгән Институтның әлеге бурычларны уңышлы гамәлгә ашырачагына ышанычым зур.

Бу истәлекле көннәрдә бөтен төрки-татар дөньясы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына зур өметләр баглый. Ышанам, татар галимнәре киләчәктә дә сынатмас, гуманитар фәннәр өлкәсендәге күркәм традицияләр алга таба да дәвам итәр һәм баетылыр, илһам дәрте сүнмәс, сүрелмәс.

Институтның барлык хезмәткәрләренә саулык-сәламәтлек, яңадан-яңа иҗади казанышлар, бәрәкәтле гомер һәм бәхет телим!



**К. М. МИҢНУЛЛИН**
ТӘһСИ директоры,
ТФАның мөхбир әгъзасы,
профессор

## Милләт рухына тугъры калып

Республикабыздагы иң зур гыйлем йортларыннан берсе — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга 75 ел тулды. Ул ТАССР Халык мәгарифе комиссариатының 3050 номерлы боерыгы нигезендә 1939 елнын 7 октябрендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты исеме белән төзелә, ә 1941 елның февраленнән Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты статусын ала.

ТӘһСИ үзенең фәнни эшчәнлегендә Мәгариф халык комиссариаты каршында 1920 — 1930 нчы еллар башында эшләп килгән Академик үзәкнең традицияләрен уңышлы дәвам итә. Шунысы игътибарга лаек: штаттагы хезмәткәрләре аз булуга карамастан, Академик үзәк татар дөньясы рухи тормышының бар тармакларын да фәнни яктан иңли һәм татар дөньясын өйрәнүне күп тармаклы фән буларак формалаштырып җибәрә. Академик үзәкнең коллективы энциклопедик белемле галимнәрдән — М.Корбангалиев, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Толымбай кебек татар фәненең классикларыннан — тупланган булуы да үз нәтиҗәләрен бирә: оешма татар теле һәм әдәбияты, этнография, фольклористика, музей эше, сәнгать белеме, педагогика, нәшрият эшләре белән югары дәрәҗәдә шөгыльләнә һәм шул рәвешле ачылачак Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни структурасының фундаментына ныклы нигез сала. Бу елларда әлеге үзәк белән күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе һәм галим Галимҗан Ибраһимов та җитәкчелек итә.

Татарстан Фәннәр академиясе төзелгәнгә кадәр ТӘһСИ гуманитар һәм иҗтимагый гыйлемнәр буенча республика координация советын җитәкли, якын һәм ерак чит илләрнең (шул җөмләдән, Төркия, Финляндия, Венгрия, Алмания, Англия, АКШ һ. б.) академик оешмалары һәм тюркология үзәкләре белән тыгыз иҗади элемтәләр урнаштыра.

Институт оешканнан бирле татар гуманитар белемнәренең барлык мөһим өлкәләрендә: тел белеме, әдәбият белеме, аның текстология тармагы, фольк-

лор фәне, театр сәнгате, музыка сәнгате, сынлы сәнгать, тарих, археология, этнография, иҗтимагый фикер һәм ислам дине һ.б. буенча җитди теоретик һәм гамәли тикшеренүләр алып барыла. Бүгенге көндә Институтта милли мәдәниятебезнең ифрат бай фонды тупланды һәм иң кыйммәтлесе шул: биредә гуманитар фәннәрнең алда санап үтелгән барлык тармак һәм юнәлешләрендә нәтиҗәле эш алып барырга сәләтле бердәм хезмәт коллективы формалашты.

XX гасыр дәвамында төрле юнәлешләрдә эзләнүләр алып барган институт, XXI гасырга аяк баскач, илдәге үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Билгеле булганча, XX — XXI гасырлар чигендә илнең иҗтимагый-сәяси тормышында барган процесслар гуманитар фәннәрне дә читләтеп узмый: алар тарихларын барлап, киләчәктә яңа үсеш юлларын билгеләүгә, яңа юнәлешләрне ачыклауга дучар ителәләр.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында озак вакытлар дәвамында оешкан фәнни мохит һәм югары квалификацияле гыйльми кадрларның зур потенциалы XXI гасыр башы Республикабыз фәненең үсешендә әһәмиятле факторларның берсе булып әверелә. М.Ш. Шәймиев сүзләре белән әйтсәк, «Институт Татарстан Фәннәр академиясен төзүдә хәлиткеч рольне уйнады, ул хәзер дә аның төп таянычы булып кала. Аңардан мөстәкыйль Татар энциклопедиясе һәм Тарих институтлары аерылып чыккач, хәзер ул Тел, әдәбият һәм сәнгать институты буларак мәгълүм. [Аның] кебек югары хәзерлекле, күпкырлы, абруйлы һәм нык институтка ия булу — Җөмһүриятебез һәм халкыбыз өчен зур бәхет ул».

Бүгенге көндә Интитут гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрендә эзләнүләр алып бара. Институтның төп фәнни юнәлешләреннән татар теленең функциональ һәм структур үсеше мәсьәләләре; татар әдәбияты тарихы һәм нәзарияте; татар халык иҗаты тарихы һәм теориясе; татар әдәбияты өлкәсендә текстологик эзләнүләр һәм чыганакларны барлау; мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә дәвамлылык һәм үсеш мәсьәләләрен атап үтәргә кирәк. Әлеге юнәлешләр кысасында Институтта бүген 19 фундаменталь һәм 26 гамәли тема буенча эш алып барыла, аларның күп өлеше өр-яңа фәннитикшеренү темаларын үз эченә ала.

Хәзерге вакытта Институт алдында барлык фәнни көчләрне заман таләп иткән перспективалы тикшеренүләр тирәсенә туплау бурычы тора. Бу максатка ирешү өчен ТӘһСИ структурасында җитди үзгәртүләр үткәрелде. Әйтик, тел белеме проблемалары белән хәзер өч бүлек: лексикология һәм диалектология, лексикография, гомуми лингвистика бүлекләре шөгыльләнә. Лексикография бүлеге җәмгыятебездә төрле тип сүзлекләргә ихтыяҗның зур булуын, әлеге фәнни юнәлешнең яңа казанышларын үзебездә гамәлгә кертүнең мотлак зарурлыгын истә тотып, мөстәкыйль бүлек итеп төзелде.

Перспективалы структур үзгәрешләр әдәбият бүлекләренә дә якыннан кагылды. Мөстәкыйль Кулъязмалар һәм фәнни архив фонды бүлеге (Мирасханә) барлыкка килде. Мирасханәдә күренекле татар язучыларының, композиторларының, театр эшлеклеләренең 170 тән артык шәхси архивы

саклана. Монда тагын 7000 нән артык кулъязма китап, 3000 чамасы сирәк басма китап, берничә дистә мең аерым кулъязма тупланган. Алар гуманитар фәннәребезнең барлык юнәлешләрендә эшләүче белгечләр өчен уникаль чыганак булып тора. Арада борынгы әдәбиятыбызга гына түгел, медицинага, астрологиягә, юриспруденциягә, шул җөмләдән мөселман хокук белеменә караган чыганаклар да күп. Көнчыгыш (бигрәк тә гарәп, фарсы) телләрендәге хәзинәләр дә зур игътибарга лаек, аларның байтагы турыдан-туры татар әдәбияты һәм мәдәниятенә мөнәсәбәтле. Бүген бу бүлек «Кулъязма һәм музыкаль мирасны өйрәнү үзәге» дәрәҗәсендә халыкка, фәнгә хезмәт итә.

Институт текстологларына хәзер шулай ук мөстәкыйль бүлек статусы бирелде. Бу бүлек коллективы тарафыннан Г.Исхакыйның 15 томлыгы әзерләнде һәм нәшер ителде. Алдагы бурыч — Габдулла Тукайның 6 томлык академик басмасын (1 һәм 2 томнары дөнья күрде), Тукай энциклопедиясен тәмамлау. Ә әдәбият белеме бүлегендә татар әдәбияты тарихының яңа таләпләргә җавап бирерлек 8 томлыгын язу эше бара. Аның инде 1, 2 томнары басылып та чыкты. Гомумән, күптомлы академик хезмәтләр — Институт эшчәнлегенең характерлы бер билгесе ул. Фольклорчылар бүгенге көндә 25 томлык (татар телендә) һәм 15 томлык (рус телендә) «Татар халык иҗаты» җыелмасын төзесә, сәнгатьчеләрнең планында дүрт томлык «Татар театры тарихы», өч томлык «XX гасыр Татарстан рәссамнары» антологиясе, ике томлык «Татарстанда китап сәнгате» кебек фундаменталь хезмәтләр каралган, ә телчеләр 3 томлык «Академик лексикология», 3 томлык «Академик грамматика»ның яңа басмасын, 3 томлык «Татар әдәби теле тарихын», 6 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н, «Татарстан Республикасы топонимнарының электрон картотекасы һәм географик объект исемнәренең дәүләт каталогы»н әзерлиләр.

Фәнни бүлекләрдән тыш, институт структурасында аспирантура, Диссертация советы мөһим урын алып тора. Казан филиалында аспирантура бүлеге 1946 елдан бирле эшләп килсә, тел һәм әдәбият белгечлекләре буенча совет 1982 елдан бирле эшли. Шул вакыт дәвамында биредә башка оешмалардан килүчеләр белән бергә 265 кандидатлык диссертациясе якланды. Ә докторлык диссертацияләрен татар филологлары Мәскәү, Алматы, Баку, Ташкент шәһәрләрендә яисә, махсус рөхсәт алып, Казан университетындагы кандидатлык советында яклап килделәр. Институтның үзендә исә беренче докторлык диссертациясен «Татар фольклорының афористик жанрлары» дигән темага 1995 елда Х.Ш. Мәхмүтов яклады. Моның өчен ВАК безнең институтта бер генә мәртәбә яклау советы төзеде. Ә даими нигездә эшләүче докторлык советы 1997 елның апрелендә оештырылды. Шунысы да бик мөһим иде: аңа, тел һәм әдәбият белгечлекләреннән тыш, фольклор буенча да диссертацияләр яклату хокукы бирелде.

Институтның элгәреге казанышларына таянып һәм заман таләпләреннән чыгып билгеләнгән перспектив юнәлешләреннән берсе — Россия күләмендә тюркологик эзләнүләр үзәге буларак оешу, Халыкара төрки академия белән берлектә төрки халыклар мәдәниятен өйрәнү өлкәсендә координатор вазый-

фасын башкару. Әлеге юнәлештә эш алып барыр өчен институтның фәнни потенциалы бар: биредә Идел — Урал регионында гына түгел, ә бәлки Россия һәм якын чит илләрдә дә билгеле, профессионал буларак җитлеккән белгечләр эшли. Шул ук вакытта институт яшь галимнәрне заман таләпләренә туры китереп үстерү, аларны гуманитар фәннәр өлкәсендәге казанышлар белән таныштыру, тюркология өлкәсендә эзләнүләр алып барган фәнни структуралар һәм гыйлем йортлары белән уртак эш-максатлар булдыруга зур әһәмият бирә.

Бу өлкәдә эффектив нәтиҗәләр бирә торган чара буларак, институт җитәкчелеге халыкара конференцияләр, симпозиум, түгәрәк өстәлләр үткәрүне уңай күрә. Әлеге фәнни чаралар, бер яктан, галимнең күзаллавын киңәйтә, фәнни казанышлар белән танышырга ярдәм итә, икенче яктан, эзләнүләр алып бара торган юнәлешнең актуальлеген билгеләргә, нәтиҗәләрнең дөреслеген расларга мөмкинлек ача. Фикер төрлелеге, аралашу мөмкинлеге булганга күрә, институт республика, бөтенроссия һәм халыкара күләмдә үткәрелә торган фәнни чараларга зур игътибар бирә. Соңгы биш ел эчендә институт уздырган «Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар» (2011), «Дөньякүләм рухи мәдәният мәйданында төрки телле китап» (2012), «Галимҗан Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья» (2012), «Төрки халыклар әдәбияты һәм музыка сәнгатенең тамырлары һәм үсеше» (2014, ТҮРКСОЙ Халыкара төрки мәдәнияте белән берлектә), «Россия һәм БДБ илләрендә сәнгать белеме үсешенең актуаль мәсьәләләре» (2014) һ.б. халыкара конференцияләр, симпозиумнар моның ачык мисалы.

Бу җәһәттән институт җитәкчелеге совет заманында югалган фәнни бәйләнешләрне кире кайтару юлларын эзли. Россия территориясендә һәм якын чит илләрдә гуманитар фәннәр өлкәсендә эзләнүләр алып барган институтлар белән үзара эшчәнлек турында килешүләр төзелә, фәнни конференцияләр үткәрелә, яңа проектларда катнашу мөмкинлекләре барлана. Институт галимнәре Россия лингвистик фәннәр академиясе, Төрки академия (Астана), Төркия тел җәмгыяте, Стамбул дәүләт университеты, Гиссен университеты (Германия), Индиана, Йель университетлары белгечләре (АКШ) һәм Россия территориясендә эшләп килгән күпсанлы фәнни оешмалар белән бәйләнештә тора. 2014 елда ТӘһСИ делегациясе Алматы шәһәрендә урнашкан М. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институтында, А. Байтурсынов исем. Тел белеме институты һәм Казакъстанның башка фәнни оешмаларында булып, яңа фәнни-тикшеренү юнәлешләрен барлап кайтты.

Озак еллар дәвамында формалашкан традицияләрне истә тотып, институт экспедиция эзләнүләренә дә зур игътибар бирә. Халык мәдәниятен өйрәнә торган галимнең кабинет кысалары, китапханә фондлары белән чикләнмичә, халыкның бүгенге яшәешен, традицияләрнең үсеш-үзгәрешен өйрәнүе заман таләпләренең берсе. Соңгы елларда институтта Татарстан районнарына һәм татарлар күмәк яшәгән Курган, Төмән, Оренбург өлкәләренә, Башкортстан, Марий Эл республикалары, Пермь төбәгенә, Иран Ислам Республикасының Гөлестан провинциясенә комплекслы фәнни экспедицияләр оештырыл-

ды. Экспедицион эзләнүләр барышында җыелган материаллар «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә дөнья күрә. Әлеге язмалар XXI гасырда яшәгән татар халкының матди һәм рухи мәдәниятен бер система буларак күз алдына китерергә ярдәм итә.

Дәүләт программалары, грантлар, конкурслар да Институтны читләтеп узмый, фәнни хезмәткәрләр әлеге төр чараларда даими катнашып, тикшеренү даирәләрен киңәйтеп торалар. Зур проектлардан «Мирас» — «Наследие», «Татар халкының милли бердәмлеген саклау», «2014 — 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программаларын атап үтәргә кирәк. «Мирас — Наследие» дәүләт программасы гамәлдә булган елларда Г. Тукай энциклопедиясен, классик әдипләребезнең академик басмаларын эшләү зур җанлылык белән барды. 2014 елдан алып комплекслы фәнни экспедицияләр «Татар халкының милли бердәмлеген саклау» дәүләт программасы кысаларында оештырыла башлады. «2014 — 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы нигезендә «Татарстан Республикасы топонимнары электрон каталогы», сүзлекләрне электрон версиягә күчерү өчен махсус программа әзерләү каралган. Әлеге программа кысаларында хәзерге вакытта татар телендә «Фәнни Татарстан» журналы нәшер ителә. Гуманитар фәннәр өлкәсендә татар телендә чыга торган журнал буларак, туган телдә эзләнүләрне активлаштыруда, чит төбәкләрдә яшәп иҗат итүче татар зыялыларына, тугандаш халыкларга татар фәненең казанышларын җиткерүдә аның әһәмияте гаять зур.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бай тарихы белән беррәттән, нәтиҗәле бүгенгесе һәм өметле киләчәге бар. Югарыда әйтелгән фикерләрне тормышка ашыру, алда торган мәсьәләләрне хәл итү, әлбәттә, институт хезмәткәрләреннән күп көч һәм вакыт таләп итә. Шулай да, бүгенге көндә нык нигезле фәнни коллективның төп эш юнәлешләре билгеләнгән, дип әйтергә мөмкинлек бар. Бары тик өлкән буынның тәҗрибәсен һәм яшьләрнең энергиясен туплап, дөрес юнәлеш биреп яңадан-яңа үрләр яуларга гына кала.

УДК 811.512.145

***М.З. Зәкиев***

# ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ ФУНДАМЕНТАЛЬ ЛИНГВИСТИК ХЕЗМӘТЛӘР ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

В статье рассматриваются история и современное состояние фундаментальных исследований в татарской лингвистике. В частности, представлен общий обзор научных трудов, посвященных изучению грамматического строя татарского языка. Основное внимание уделено исследованиям в области синтаксиса.

**Ключевые слова**: татарская лингвистика, фундаментальные исследования, академическая грамматика, морфология, синтаксис.

Фундаменталь хезмәт ике яклап характерлана: беренчедән, ул әһәмиятле гыйльми юнәлешнең барлык төп проблемаларын үз эченә ала, икенчедән, гыйльми юнәлешнең аерым проблемалары буенча алып барыла торган фәнни эшкә нигез булып тора. Гомумиләштерүче фундаменталь хезмәт берничә фәнни юнәлешне колачлый. Татар лингвистикасы фәнендә мондый хезмәтләр язу күптән башланды һәм ул берничә юнәлештә бара, аларның тел гыйлемендә танылганнары: 1) академик планда татар грамматикасын төзү; 2) күп томлы татар лексикологиясен булдыру; 3) татар теленең һәм халкының формалашу тарихын язу, 4) татар әдәби теле тарихы курсын оештыру; 5) татар теленең тарихи грамматикасын төзү; 6) телебез сүзләрендәге тамыр, нигез һәм кушымчаларда тарихи фонетик үзгәрешләрне (морфонологияне) өйрәнү, моңа таянып татар этимологиясе фәнен үстерү һ.б.

Бу язмамда мин менә шушы гомуми проблемаларның берсенә — академик планда татар грамматикасын төзү, аны камилләштереп торуга тукталмакчы булдым.

Мәгълүм булганча, татар грамматикасын, дәрес кулланмасы итеп төзү, бастыру, XIX йөз башыннан алып, XX гасырның 60 нчы елларына кадәр Ибраһим Хәлфин, Иосиф Гиганов, Александр Троянский, Мирза Казимбәк, Мартиниян Иванов, Габделгалләм Фәезханов, Каюм Насыйри, Мөхәммәтгали Мәхмүдов, Әбдүш Ваһапов, Шиһаб Әхмәров, Габдрахман Сәгъди, Әхмәтһади Максуди, Гыймад Нугайбәк, Шәехгаттар Иманаев, Василий Богородицкий, Гыйбадулла Алпаров, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Мирфатыйх Зәкиев, Вәли Хангилдин һ.б. тарафыннан башкарылды.

Нәкъ менә шундый хезмәтләрнең дөнья күрүе СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында чын мәгънәсендә академик дип аталырлык грамматика төзү кирәклеге идеясен тудырды. Лексика, фонетика, орфоэпия, орфография һәм морфология бүлекләрен язуны ТӘһТИ хезмәткәрләре үз өсләренә алдылар, синтаксис бүлеген язу университет доценты чагымда миңа тапшырылды. 1963 елда Казан университеты нәшриятында «Синтаксический строй татарского языка» дигән киң күләмле докторлык монографиям (464 бит) басылып чыкты. Ул дөньякүләм синтаксис фәне казанышлары нигезендә язылган беренче академик басма буларак бәяләнде.

1965 елда ТӘһТИ академик грамматиканы — «Хәзерге татар әдәби теле. Лексика. Фонетика. Орфоэпия. Графика һәм орфография. Морфология»не (300 бит) В. Хангилдин, Х. Курбатов, Ф. Шакирова һәм К. Сабиров авторлыгында татарча чыгарды. Бу хезмәтнең II томы итеп, 1966 елда минем «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» китабым (288 бит) нәшер ителде.

Бу басмалар тюркология фәнендә уңай бәяләнгәч, ТӘһТИ планы буенча академик грамматиканы Мәскәүдә «Наука» нәшриятында русча чыгару өчен әзерлек башланды. Әлеге хезмәтнең I томы «Современный татарский литературный язык. Лексикология. Фонетика. Морфология» (380 с. Авторы: Н.Б. Бурганова, М.З. Закиев, Х.Р. Курбатов, А.М. Латыпов, Л.Т. Махмутова, К.С. Сабиров, М.А. Сагитов, Д.Г. Тумашева, В.Х. Хаков, Ф.Ю. Юсупов) дөнья күрде. Аның минем тарафтан язылган II томы — «Современный татарский литературный язык. Синтаксис» (310 с.) шул ук «Наука» нәшриятында 1971 елда чыкты. Әйтергә кирәк, татар теленең русча язылган бу академик грамматикасы күп кенә башка төрки телләрнең шундый грамматикаларын язу өчен үрнәк хезмәтен дә үтәде.

Татар теле академик грамматикасының теоретик куелышларын эшкәртүдә 1980 елда «Наука» нәшриятында дөнья күргән һәм 1982 елда СССР Дәүләт бүләгенә лаек табылган ике томлык «Русская грамматика» аеруча әһәмиятле булды.

Болар барысы да татар теленең яңа академик грамматикасын язу зарурлыгын тудырдылар. Шуны истә тотып, 80 нче еллар башында Тел, әдәбият һәм тарих институты татар теле галимнәреннән махсус төркем оештырды һәм аларга, дөнья лингвистикасы һәм татар теле фәненең казанышларын күз алдында тотып, татар теленең яңа академик грамматикасын русча язуны тапшырды. Бу коллективның җитәкчесе итеп, ул чорда Казан педагогия институты ректоры булып эшләгәндә, мине билгеләделәр. Коллектив белән бик актив һәм килешеп эшләдек һәм өч томлык татар академик грамматикасы 80 нче еллар ахырына язылып, Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел бүлегендә редакцияләнеп әзер хәлгә китерелде. Типографиягә тапшыру алдыннан бу томнарны киң катлау лингвистлар белән тагын тикшереп алдык. Бер генә автор язганлыктан III том, ягъни синтаксис томы, тиз генә карап чыгылды, һәм 1992 елда ук ул, бераз кыскартылып, 1000 данә тираж белән басылып чыкты (488 бит, авторы — М.Зәкиев). Калган ике том 1993 елның башында шулай ук 1000 әр данә тираж белән дөнья күрде. Тиражларның аз икәнен белдек, ләкин башка чара юк иде, ул чорда нәшрият кәгазь кытлыгы кичерә иде.

I томдагы (584 бит) «Сүз башы», «Кереш», «Грамматиканың төп төшенчәләре», «Морфемика» бүлекләре минем тарафтан, «Фонетика», «Фонология», «Просодика» бүлекләре — Х. Сәлимов, «Графика һәм орфография», «Орфоэпия» турындагы өлешләре — Х. Курбатов, «Морфонология» темасын — мин һәм Д. Сәлимова, «Сүзьясалыш» бүлеге Ф. Ганиев тарафыннан язылды. Исемнәр, терминнар һәм кушымчалар исемлеген Э. Кадирова төзеде.

II томдагы, ягъни морфология томындагы (397 бит) теоретик «Кереш» бүлеген — М. Зәкиев, «Исем» сүз төркеме өлешен — З. Вәлиуллина, «Сыйфат», «Алмашлык», «Фигыль юнәлешләре», «Хәл фигыль», «Рәвеш» бүлекләрен — К. Зиннәтуллина, «Зат категориясе», «Наклонение категориясе», «Фигыльнең модаль формалары һәм конструкцияләре» өлешләрен — Д. Тумашева, «Фигыльне өйрәнүнең кыскача тарихы», «Фигыльгә гому-

ми характеристика», «Сан категориясе», «Раслау һәм инкяр категориясе», «Фигыльдә эшнең үтәлү ысулын белдерү», «Инфинитив формалар», «Фигыльләрнең эш-хәрәкәт ысуллары» бүлекләрен — Ф. Ганиев, «Сыйфат фигыль» бүлеген — Ф. Хисамова, «Сан» сүз төркемен — Н. Борһанова, «Бәйлек һәм бәйлек сүзләр», «Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр» өлешләрен — С.Ибраһимов, «Хәбәрлек сүзләр», «Модаль сүзләр», «Кисәкчәләр», «Ымлыклар», «Ияртемнәр» бүлекләрен — М. Сәгыйтов, исемнәрдә, сыйфатларда, фигыльләрдә, алмашлыкларда, саннарда, рәвеш һәм ярдәмлек сүзләрдә басым турындагы материалларны Х. Сәлимов язды. Библиографияне Ф. Гаффарова белән Р. Сепперова төзеделәр.

Өч томлык академик грамматика тюркологлар арасында югары бәя алды, һәм аны төзүчеләрдән дүрт авторга Татарстан Республикасының дәүләт бүләге бирелде.

Академик «Татар грамматикасы» китапханәләргә генә бирелде. Студентлар һәм укытучылар кулына аларның берничәсе генә барып җитте. Шуңа күрә аларны репринт юлы белән яңадан күбәйтеп чыгару ихтыяҗы туды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Тел законын гамәлгә кую комитеты бу ихтыяҗны тормышка ашыру өчен финанс мөмкинлекләре тудырды. I һәм III томнар — 1995 елда, II том 1997 елда репринт юлы белән күбәйтелделәр.

Яшерен-батырын түгел, 80 нче еллар башында татар теленең өч томлык академик грамматикасын төзү турында карар кабул иткәндә, аны русча гына төзеп, СССР Фәннәр академиясенең «Наука» нәшриятында бастыру күз алдында тотылды, чөнки ул чорда һәр халыкта шул тәртип кабул ителгән иде. Үзгәртеп корулар милли мәсьәләләр өлкәсенә дә үтеп кергәч, татар теленең академик грамматикасын татарча төзеп чыгару актуаль мәсьәләгә әйләнде. Шушы максаттан чыгып, 1994 ел башында Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр бүлеге контракт нигезендә эшләүче вакытлы хезмәт коллективы төзеде һәм аңа якын елларда мөмкин кадәр тулы булган татар грамматикасын татарча язып чыгару бурычын йөкләде. Вакытлы хезмәт коллективына татар теленең академик грамматикасын русча язып чыгарган галимнәр алынды.

Бу коллектив татарча академик грамматиканы русча чыкканыннан тәрҗемә итү белән генә шөгыльләнмәскә, ә тупланган яңалыкларны исәпкә алып, һәр теманы баетып яңача язарга омтылырга тиеш булды. Татар академик грамматикасының татарчасы да, русчасы кебек үк, нигездә, тасвирый һәм норматив булсын, шуның белән бергә, кирәк урыннарда чагыштырмалы (төрки телләр белән чагыштырылган), контрастив (рус, инглиз, немец һ.б. шундый тугандаш булмаган телләр белән чагыштырылган), стилистик, диалекталь һәм тарихи да булсын, дигән бурыч куелды.

Өч томлы академик «Татар грамматикасы»ның татарчасы тиздән Мәскәүдәге «Инсан» һәм ТӘһСИдагы «Фикер» нәшриятларында басылып та чыктылар: I томы — 1998 (512 б.), II томы (448 б.) — 2002, III томы (512 б.) — 1999 елда.

Академик «Татар грамматикасы»ның русча томнары 2 шәр мең данә, татарчасы 3 әр мең данә басылдылар. Китапханәләргә тапшыргач, русчасын кайбер төрки телле республикаларга бирәр данә дә бирә алмадык. Мәсәлән, каракалпак галимнәре Казанга махсус килеп, бу хезмәтне фотога төшереп алып киттеләр. Аның татарчасы да студентлар өчен кулланма буларак файдаланылды, шуңа күрә 3000 данә чыгарылган булса да, ул бер ел эчендә таралып бетте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Телләр законнарын гамәлгә кую Советы 6 томлык академик грамматиканың яңа басмасын киң җәмәгатьчелеккә яңадан җиткерүне кирәк тапты. Атап әйткәндә, бу Совет «2014—2020 елларга ТР дәүләт телләрен һәм ТРда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР дәүләт программасы»н кабул итте. Аның 4.1.1 бүлеге «Татар филологиясе өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләр нәтиҗәләрен гамәлгә кертү» дип атала. Аның 1 нче пунктында ук әйтелгән: «Хәзерге татар теле академик грамматикасы»ның яңадан язылган һәм тулыландырылган басмасын әзерләргә һәм нәшер итәргә. Бу эш дөньякүләм филологик фәннәр дәрәҗәсендә башкарылырга тиеш.

Хәзерге көндә өч томлы татар академик грамматикасының русчасы да, татарчасы да (барлыгы 6 том) яңадан басып чыгару өчен әзерләнеп килә. I һәм III томнар әзер. II томның (морфологиянең) элекке авторлары хәзер инде исән түгел.

Мәгълүм булганча, авторлар күп булганда, тикшерелә торган объектка бер үк югары таләпләрдән якын килеп аңлату да югала. Морфологиянең (II томның) канәгатьләнерлек булмавын исәпкә алып, мин, гомуми эш җитәкчесе буларак, «Морфология»не тирәнрәк итеп язу эшен Казан дәүләт университеты профессоры Ф.М. Хисамовага тәкъдим иткән идем, чөнки аның фикерләре күп еллар буе студентларга морфология фәнен укыту барышында билгеле бер системага салынган.

Ф.М. Хисамова татар теленең морфология курсын язды, аны бергәләп карап, өйрәнгәннән соң, минем редакторлыгымда ул 2006 елда татарча басылып та чыкты. Русча томын да ул тиз язар дип ышанам.

Академик «Татар грамматикасы»ның яңадан әзерләнгән басмасына ике төрле яңа бурыч куелды: 1. Академик грамматиканың теоретик куелышлары һәм гамәли ачышлары татар тел гыйлеме өлкәсендә файдаланыламы, аларга нигезләнеп нинди хезмәтләр язылган? 2. Грамматиканың әзерләнә торган басмасына яңа фәнни ачышлар кертелгәнме?

Мәсәлән, III томның яңа басмасына «III томның татар һәм төрки синтаксисын өйрәнүгә уңай тәэсире» дигән тема өстәлде. Әйтелгәнчә, «Татар грамматикасы»ның III томы автор тарафыннан өзлексез яңартылып торылды һәм студентлар өчен дәреслек-кулланма буларак күп мәртәбәләр басылып чыкты. Мәгълүм булганча, III том беренче мәртәбә 1992 елда басылган иде, аның икенче басмасы 1995 елда чыгарылды. Әле генә әйтелгәнчә, татарча III том 2013 елда тагын дөнья күрде. Димәк, автор III томны камилләштерүне өзлексез дәвам итте.

Синтаксисның төп проблемалары буенча миңа төрле югары уку йортларында кыска-кыска гына лекцияләр дә укырга, күп кенә халыкара конференцияләрдә синтаксисның төп проблемалары турында докладларда сөйләргә туры килде.

Хәзерге татар синтаксистлары III томда яктыртылган теоретик куелышлар тәэсирендә формалаштылар. Шул теоретик карашлар нигезендә татар синтаксисы буенча күп кенә докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклānды, монографияләр, мәкаләләр җыентыклары басылып чыкты.

2000 елда Ф.С. Сафиуллина «Татар синтаксик төзелешенең үсеше» турындагы хезмәтләрен берләштереп, докторлык яклау өчен 116 биттән фәнни доклад язды һәм аны уңышлы яклады. 2002 елда аның белән автордашлыкта «Хәзерге татар әдәби теле» дигән китап әзерләдек, 2002 елда аның беренче басмасы, 2006 елда икенче басмасы дөнья күрде (408 б.).

Бу хезмәттә синтаксис проблемалары тулысынча бирелгән.

2006 елда Алабуга techинституты укытучысы Ф.Г. Галләмов «Синтаксис осложненного предложения в татарском языке» дигән монографиясен (296 б.) КДУ нәшриятында бастырды, 2007 елда ул Уфада «Структурно-семантическое осложнение простого предложения в татарском языке» дигән докторлык эшен яклады.

2011 елда тагын бер докторлык эше — А.Ә. Билялованың «Системно-функциональное описание факультативности как языкового феномена: на материале татарского, русского и английского языков» дигән монографиясе әзерләнде.

Синтаксис проблемаларына багышланган кандидатлык диссертацияләре тагын да күбрәк якланды. Алабуга techинституты укытучысы Э.Р. Ибраһимова «Парадигмы простого предложения в татарском языке (в сопоставлении с аналогичными парадигмами русского языка)» дигән темага 1999 елда кандидатлык диссертациясен яклады.

Р.К. Сәгъдиеваның «Аффиксы как средства выражения конкретизирующих отношений в татарском языке» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясе 2000 елда бертавыштан якланды.

Синтаксис проблемалары буенча тагын түбәндәге диссертацияләр әзерләнде: Г.М. Шәйхиева — 1999 елда «Коммуникативно-прагматические аспекты обращения (на материале татарского языка), Г.А. Нәбиуллина — 2002 елда «Синтаксис сложного преложения в татарских пословицах (по трехтомному сборнику Н. Исанбета «Татар халык мәкальләре»), Р.С. Барсукова — 2002 елда «Заболотный говор тоболо-иртышского диалекта татарского языка» дигән темаларга. Хәзерге көндә Р.С. Барсукова «Татар теленең диалекталь синтаксисы (гади җөмлә)» дигән фәнни-тикшеренү эше алып бара.

2004 елда синтаксис проблемалары буенча өч кандидатлык диссертациясе якланган: М.С. Азисова — «Таксис в современном татарском языке», Н.Р. Харисова — «Глагольно-глагольные словосочетания в современном татарском литературном языке», А.Ә. Билялова — «Вариантность и факультативность в татарском языке (в сопоставлении с русским и английским языками)» дигән темаларга.

2006 елда Н.Х.Шакирова «Структурно-семантические модели многочленных смешанных сложных предложений в татарском языке», 2007 елда Ф.Б. Ситдикова «Способы передачи имплицитной информации в татарском литературном языке», 2008 елда Л.А. Янсаева — «Диалектный синтаксис татарского языка (простое предложение)» дигән темаларга кандидатлык диссертацияләре якладылар.

2012 елда «Семантика и репрезентация каузативности в татарском языке» дигән темага Л.К. Вәлиева кандидатлык диссертациясен яклады. Хәзерге көндә ул ТӘһСИның лексикология һәм диалектология бүлегендә «Классификация смысловых отношений между синтаксическими единицами в татарском языке в сравнении с другими тюркскими языками» темасына монография язу эше белән мәшгуль.

ТӘһСИ аспиранткасы Г.Г. Миңнеханова татар синтаксисы өчен яңа булган «Татар телендә агенс һәм пациенсның бирелеше» темасына кандидатлык диссертациясен тәмамлады. Аның буенча күп кенә иҗади мәкаләләр бастырды.

Диалектология буенча кандидатлык диссертациясен вакытыннан алда яклаган М.Р. Булатова хәзер «Татар теленең диалекталь синтаксисы (кушма җөмлә)» дигән тема өстендә эшли башлады.

Шулай итеп академик «Татар грамматикасы»ның III томында яктыртылган теоретик куелышларга таянып, синтаксис буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якланды. Болардан тыш синтаксис буенча күп кенә фәнни мәкаләләр басылды. Аларның авторлары: С.М. Ибраһимов, М.Х. Кашапов, З.Н. Кириллова, З.В. Шәйхразиева һ.б.

Академик грамматикадагы кайбер проблемалар ничек һәм кемнәр тарафыннан үстерелде, алар нинди яңа ачышлар ясадылар? Бер мисалга аерым тукталып үтәм.

«Татар грамматикасы»ның I томында «Морфонология» дигән бер бүлек бар. Морфонология дигән лингвистик юнәлеш сүз тамырлары нигезләренең һәм кушымчаларының (бер сүз белән әйткәндә, морфемаларның) сөйләм вакытындагы авазлар үзгәрешен өйрәнә. Бу юнәлешне башлап мин үзем өйрәнгән идем, «Татар грамматикасы»на да аны шәкертем Д.Ә. Сәлимова белән мин үзем язып керттем. Кызганычка каршы, «Татар грамматикасы»на ияреп, бу теманы тагын да тирәнрәк итеп үстерүче табылмады. Бары үзем генә аның үзенчәлекләрен өйрәнеп, Астана шәһәрендә 2013 елда «Древнетюркская ономастика и ее морфонология» дигән (415 б.) китабымны бастырып чыгардым һәм анда морфонологиянең *лингвистик археология* дигән махсус юнәлешне тудыруын исбатладым. Археология фәне матди культура табылдыкларын өйрәнә, тарихка бик зур өлеш кертә. Ләкин археологик юл белән табылган шул һәйкәлләре өйрәнелә торган борынгы халыкның этносын (кайсы телдә сөйләвен) билгеләү «телсез» булып кала бирә.

Лингвистик археология борынгыдан сакланган ономастик берәмлекләрне, атап әйткәндә, антропонимиканы (кеше исемнәрен), топонимиканы (җир-су исемнәрен), зоонимиканы, космонимиканы һәм этнонимиканы (кабилә, халык исемнәрен) җентекләп өйрәнә, аларның кайсы телгә нигезләнеп ясалуларын тикшерә, этник хуҗасын билгели.

Мисалга Кара диңгез буйларының этник тарихы буенча лингвоархеологик ачышны китерәм. Европоцентристик тарих фәне: төркиләр бары безнең эра башларында Алтайда формалашканнар да Кара диңгез тирәләренә безнең эраның IV, хәтта VII, кайбер европоцентристлар фикеренчә, бары IX гасырда гына килгәннәр, дип исбатларга тырыша.

Борынгы тел материалларын морфонологик тикшерү һәм алардан лингвистик археология планында нәтиҗәләр чыгару Кара диңгез тирәләренең иң борынгы чордан ук төрки кабиләләрнең яшәгән җирләре булуы турында сөйли.

Кара диңгезнең борынгы грек чыганакларына да кереп калган исеме — *Понты*, борынгы греклар аны *Понт эвксинский* (Pontos Euxenos) дип атаганнар. Русчага бу исем «гостеприимное море» дип тәрҗемә ителә. *Понты* дигән төрки сүзнең дә мәгънәсе «ашамлыкка бай, ашамлыклы» була: *бүн/бун/пүн/пун* борынгы төркидә «ашамлык, аш, шулпа» мәгънәсен бирә, ә *ты/т* кушымчасы бездәге хәзерге *-лы/-ле* кушымчасына туры килә. Борынгы төрки телдә, казакъларда хәзер дә бу кушымча *-ты/-ды* формасында еш очрый: *Алматы* безнең әйтелештә *алмалы* булыр иде; без *Таллы курган* дибез, казакълар *Талды курган* диләр.

Кара диңгез буенда — Кырымда б.э. к. VIII—VII гасырларда *Фанагория* һәм *Пантикапей* шәһәрләре булган. Фанагория — ул Кубрат хан Болгарстанының башкаласы саналган. Болгар халкының борынгы бабалары *Һуногур* исемен йөрткәннәр. Греклар аны *фанагория* дип әйткәннәр, чөнки

аларда h авазы өрелмәле ф белән алмаштырыла торган булган.

*Понтикапей* шәһәренең исеме Понтка (Кара диңгезгә) керү-чыгу капкасы ролен үтәгән, димәк, ул төркичә *Понт капасы* (капкасы) дигән сүз. Соңрак ул шәһәрне Понтка керү урыны итеп аңлаганнар һәм аны *Кереш* (Кара диңгезгә керә торган шәһәр) дип атаганнар, соңрак ул *Керчь* исеменә үзгәргән. Димәк, Кара диңгез буйлары бик борынгы чорларда ук төркиләр дә яшәгән регион булганнар.

Мондый морфонологик, ягъни лингвистик археология материаллары «Татар грамматикасы»ның хәзер әзерләнә торган яңа басмасына да яңалык буларак кертелгәннәр.

***Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы,*** *филология фәннәре докторы, академик, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге җитәкчесе*

УДК 811.512.145

*А.Ә. Тимерханов*

# ТАТАР ЛЕКСИКОГРАФИЯСЕНЕҢ ҮТКӘНЕ ҺӘМ КИЛӘЧӘККӘ БУРЫЧЛАРЫ
## (кыскача күзәтү)

В статье рассматриваются вопросы становления и развития татарской национальной лексикографии. Представлен общий обзор более 50 лексикографических работ, датируемых XIX — XXI вв. Основное внимание уделено анализу толковых и переводных словарей татарского языка, а также справочных пособий словарного типа. При этом освещены некоторые общие и частные проблемы теоретической и прикладной лексикографии, рассмотрены достижения в области разработки и реализации татарских электронных словарей.

**Ключевые слова**: татарский язык, татарская лексикография, толковый словарь, двуязычный словарь, электронный словарь.

2013 елның азагында Республикада инде өченче тапкыр телләрне саклау программасы кабул ителде. «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы [2014—2020 елларга...] кысаларында хәзерге татар тел белеме өлкәсендә фәнни-теоретик эзләнүләргә зур урын бирелә. Билгеләнгән күптөрле бурычлар арасында гамәли характердагы хезмәтләр әзерләү, аеруча төрле типтагы татарча сүзлекләрне күпләп төзеп бастыру мәсьәләләре дә игътибар үзәгенә чыга.

Бүген лексикография юнәлешенең әһәмияте торган саен арта гына баруын ассызыкларга кирәк. Моның үзенең объектив сәбәпләре бар. Сәяси-иҗтимагый тормыш, икътисад, мәдәният, спорт һ.б. өлкәләрдәге интенсив процесслар тәэсирендә телебезгә, аеруча аның иң сизгер өлешенә — лексик системасына — һәрдаим күптөрле сүзләр, терминнар өстәлеп тора, аларның семантикасына, кулланылышына бәйле башка үзгәрешләр күзәтелә. Боларның барысын да үз вакытында күреп, ачыклап, дөрес итеп теркәү, тасвирлау ихтыяҗы үзен ныграк сиздерә. Дәүләтләр, халыклар арасында актив рәвештә урнаша барган элемтәләр, үзара тыгыз аралашу-аңлашу һ.б. уңай күренешләр киңрәк төс ала. Шуларның нәтиҗәсе буларак, тормышның төрле өлкәләрендә арта барган мәгълүмат алмашу, хезмәттәшлек итүгә бәйле ихтыяҗларны тиешле дәрәҗәдә сыйфатлы итеп канәгатьләндерүгә карата да аерым таләпләр куела. Мондый вазгыять татар лексикографиясенең, гомумән, татар тел белеменең актив рәвештә нәтиҗәле үсешенә этәргеч бирә.

Татар лексикографиясенең озак еллар дәвамында формалашып ныгыган бай традицияләре бар. Аларның нигезен, иң элек, төрле максатларда төзелгән икетелле, башлыча русча-татарча һәм татарча-русча, сүзлекләр тәшкил итә. Бу табигый да, чөнки күп гасырлар дәвамында аралашып-аңлашып яшәү нәтиҗәсендә татар һәм рус халыклары арасында тыгыз социаль-иктисади, мәдәни бәйләнешләр урнаша, элеккеге СССР һәм хәзерге Россия халыкларының уртак казанышына әйләнгән рухи-мәдәни киңлек барлыкка килә. Электән үк шундый үзара тыгыз бәйләнештә яшәү тәрҗемә сүзлекләр һәм төрле эчтәлектәге сөйләшмәлекләр эшләп чыгаруга этәрә. Еш кына андый басмалар татарча текстларны рус теленә һәм киресенчә тәрҗемә итүдә төп белешмә әсбап булып хезмәт итә.

Татар лексикографиясе үзенең тамырлары белән XVI—XVII гасырларда төзелгән кульъязма сүзлекләргә барып тоташа. Алга таба, XVIII—XIX гасырларда, аның формалашуы һәм үсүе этабындагы уңышлар үз чорының күренекле галимнәре, эшләренә тугрылыклы шәхесләре — И. Хәлфин, А. Троянский, И. Гиганов, К. Насыйри, Н. Остроумов, М. Юнысов, С. Рахманкулов һ.б.ларның исемнәре белән бәйле. Аларның күпсанлы хезмәтләре татар телен нормалаштыруда һәм тел аша киң халык массаларына аң-белем бирү, аларны агарту эшендә зур роль уйный.

В 1895—1896 елларда татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге — ике томлы *Ләхҗәи татари* исемле хезмәт нәшер ителә [Насыйри]. Сүзлекнең авторы — танылган мәгърифәтче һәм галим К. Насыйри. Ул — татар фәнни терминологиясен милли нигездә эшләүгә, аны алга таба үстерүгә бәяләп бетергесез өлеш керткән шәхес. Сүзлеккә 20 меңләп сүз теркәлгән һәм аларның мәгънәләре аңлатылган, гарәп һәм фарсы телләренә тәрҗемәләре китерелгән. Аерым очракларда мисаллар нигезендә теркәлгән сүзләрнең кулланылыш үзенчәлекләре дә ачылган.

Татар лексикографиясе тарихында Җ. Вәлиди аеруча лаеклы урын алып тора. Туган телнең сүзлек хәзинәсен лексикографик тасвирлауда катгый фәнни принципларга таянып эш итүе һәм шулай эшләргә кирәклеген тирәнтен аңлавы белән Җ. Вәлиди бу өлкәгә нык-лы нигез салып калдыра. Алга таба әтрафлы үсүе белән татар лексикографиясе нәкъ менә шушы галимгә бурычлы. Җ. Вәлиди татар лексикографиясенең теоретик нигезләрен эшләүгә зур өлеш кертә: ул сүзләрдә лексик һәм грамматик мәгънәләрне аерырга кирәклегенә игътибар итә, фигыльләрне теркәүдә *-у/-ү* исем фигыль формасын өстен күрә, шулай ук фигыльнең юнәлеш формаларын аерып карау мәсьәләсен күтәрә һ.б. Үзенең лексикография өлкәсенә караган фикер-табышларын галим *Татар теленең тулы сүзлеге*ндә (1927, 1929) [Вәлиди] чагылдырырга омтыла. Кызганыч, сүзлек өлешчә генә нәшер ителеп кала. Хезмәтнең зур өлеше юкка чыгарыла, ә автор үзе репрессия корбаны була.

Үткән гасырның 30—50 нче елларында да татарча сүзлекләр эшләп бастыру өлкәсендә җитди үзгәрешләр күзәтелә. М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев, Н. Исәнбәт, Г. Ишмөхәммәтов, Г. Нугайбәк һ.б. галимнәрнең тырышлыгы белән тагын күп кенә сүзлекләр дөнья күрә. Аларда татар теленең лексик байлыгы үз вакыты өчен шактый тулы һәм системалы рәвештә чагылыш тапкан дияргә кирәк.

Бу өлкәдәге зуррак уңышлар исә узган гасыр урталарына карый. 1955—1959 елларда дүрт томлы *Русча-татарча сүзлек*нең басылып чыгуы республикабызның мәдәни һәм гыйльми тормышында мөһим вакыйга буларак кабул ителә [Русско-татарский..., 1955—1959]. Югары бәягә лаек бу хезмәтне әзерләүдә профессор Н.К. Дмитриеваның фәнни җитәкчелегендә танылган татар галимнәре Р.С. Газизов, Ф.Г. Исхаков, Ә.М. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмутова, М. Максуд, Г.С. Әмиров, К.С. Сабировлар катнаша. Д.Н. Ушаков редакциясендәге *Рус теленең аңлатмалы сүзлеге* [Толковый словарь, 1940], С.И. Ожеговның *Рус теле сүзлеге* [Ожегов, 1949] һ.б. авторитетлы хезмәтләргә таянып әзерләнгән бу сүзлек ул вакыттагы лексикографиянең тәрҗемә сүзлекләр төзү өлкәсендә тупланган барлык уңай тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнә.

Бүген татар лексикографиясе алдында яңа мөһим бурыч тора — ике халык арасында телара, мәдәниятара бәйләнешләр киңәя, ныгый барган шартларда хәзерге аралашу ихтыяҗларына җавап бирә алырдай зур русча-татарча сүзлек булдыру.

Шуның белән бергә бу өлкәдә тупланган тәҗрибә төрле елларда татарча-русча сүзлекләр төзүдә дә зур булышлык итә. Мисал өчен, 1950 елда 20 меңгә якын сүзне эченә алган *Татарча-русча сүзлек* басыла [Татарско-русский..., 1950]. Аерым сүзләрне теге яки бу сүз төркеменә кертүдәге буталчыклык, сүзләрнең грамматик формаларын теркәү, татар теленә кагылышлы материалны чагылдыру һәм башка шундый кайбер кимчелекләр булуга карамастан, сүзлек уку-укыту максатларында да, журналистлар, тәрҗемәчеләр өчен дә көтеп алынган файдалы белешмә әсбапка әйләнеп китә.

Бу юнәлештә башкарылган уңышлы эшнең күркәм дәвамы буларак, 1966 елда тагын да яңарак, тагын да күләмлерәк *Татарча-русча сүзлек* [Татарско-русский..., 1966] дөнья күрә. Элегрәк басылган шундый төр сүзлек белән чагыштырганда, монда сүзләр саны ике мәртәбә күбрәк, ягъни 38 меңгә якын берәмлек тәшкил итә. Төзелеше ягыннан сүзлектә татар лексикасын тасвирлауда, нигездә, шул ук принциплар саклана, әмма бу сүзлекне төзүчеләр татар сүзләрен рус теленә тәрҗемә иткәндә, аларның мәгънәләрен, мәгънә төсмерләрен мөмкин кадәр киңрәк һәм төгәлрәк чагылдырырга омтылганнар. Тәрҗемә аша татар теленең фразеологик байлыгын ачуга да зур урын бирелгән.

Берничә гасыр дәвамында сүзлекләр төзүдә тупланган зур тәҗрибә алга таба лексикография өлкәсендә тагын да күләмлерәк проектларны гамәлгә ашыруда төпле нигез була алган. Совет чоры һәм аннан соңгы чор төрки-татар лексикографиясенең иң күркәм традицияләре өч томлы *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге* [Татар..., 1977—1981], *Русча-татарча сүзлек* [Русско-татарский..., 1984], *Татарча-русча сүзлек* [Татарча-русча..., 1998], икетомлы *Татарча-русча сүзлек* [Татарча-русча..., 2007], *Русча-татарча сүзлек* [Ганиев, 2009] һәм башка шундый фундаменталь басмаларда чагылыш тапты.

Хәзерге татар лексикографиясенең яңа зур уңышларыннан берсе — бертомлы *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге* басылып чыгуы [Татар..., 2005]. Сүзлекне профессор Ф.Ә. Ганиевнең фәнни җитәкчелегендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында (ТӘһСИ) эшләүче бер төркем лексикограф галимнәр төзеде. Ул озак еллар дәвамында күп көч, тырышлык куеп башкарылган зур эш нәтиҗәсе. Хезмәт әлеге төр сүзлекләрне төзүдәге барлык диярлек алдынгы тәҗрибәне исәпкә алып эшләнгән. Сүзлеккә 58 мең сүз һәм фразеологик берәмлек кертелгән. Ул татар халкының рухи-мәдәни мирасын һәм мәгълүм күләмдә бөтен төрки дөньяның милли-тел тасвирланышын чагылдырган гаять бай чыганак булып хезмәт итә.

Югарыда әйтелгән сүзлектә күпсанлы тезмә фигыльләрне төп фигыль оясында теркәү, аларның мәгънәләрен тасвирлау, иллюстратив мисаллар белән ныгыту мәсъәләләренә зур игътибар бирелгән булса, татар теленең фигыль сүз төркеменә бәйле сүзьясалыш куәте аерым хезмәттә — ике кисәктән торган *Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге*ндә ачылган [Ганиев, 2009; 2012]. Татар телендә тезмә фигыльләрне (ә аларның саны берничә йөз меңнән артып китәргә мөмкин) мөстәкыйль лексик берәмлек сыйфатында сүзлеккә теркәп тасвирлау һәм шул рәвешле телебезнең янә зур эчке байлыгын ачып бирү — милли лексикография кысаларында гына түгел, гомумтюркология югарылыгында да беренче җитди һәм уңышлы тәҗрибә буларак бәяләнергә хаклы.

Әлбәттә, бу уңыш — күп кенә галимнәрнең татар тел белеме өлкә-

сендә озак елларга сузылган фәнни тикшеренүләре, эзләнүләре, фидакяр хезмәте нәтиҗәсе. Иң зур фәнни казанышлардан исә — бүген татар тел белеменең мөстәкыйль тармагы буларак сүзьясалышы барлыкка килүедер [Ганиев, 2010]. Сүзлектә 20 меңнән артык тезмә фигыль теркәлгән. Бу лексика — туган телебезнең сүзлекләрдә чагылырга тиешле фигыль сүз төркеменә караган лексик байлыгының кечкенә бер өлеше генә. Тезмә фигыльләрнең тулы аңлатмалы сүзлеген эшләп чыгару хәзерге татар лексикографиясе алдында торган катлаулы һәм масштаблы бурычларның берсе булып кала бирә.

Шушы юнәлештә тупланган уңай тәҗрибә 2013 елда дөнья күргән *Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге*н төзүдә дә чагылыш тапты [Татар..., 2013]. Сүзлек мәктәп укучысын татар теленә өйрәтү, аның туган телне үзләштерүдә белемен тирәнәйтү бурычын күз уңында тотып эшләнде. Ул, гомумән, татар телендә мәктәп программасы күләмендә мәгълүмат алу чыганагы буларак тәкъдим ителә. Сүзлеккә кертелгән 10 меңнән артык сүз һәм фразеологик берәмлек тә нәкъ менә шуны истә тотып сайланган. Монда укучыларга сүзләрнең мәгънәләре, аларның дөрес кулланылышы, аерым грамматик формаларның ясалыш үзенчәлекләре, басымның куелышы, сүзләрнең язылышы һ.б.лар хакында тулы һәм аңлаешлы шәкелдә мәгълүмат тәкъдим ителә.

Бүген Институтта татар теленең күптомлы яңа, тагын да тулырак һәм камилрәк аңлатмалы сүзлеген төзү юнәлешендә актив эш алып барыла. Аның беренче өч томы инде төзелеп бетү алдында, калган томнарын эшләү дә дәвам иттерелә. Әлеге хезмәттә телебезнең киң палитралы лексик-фразеологик байлыгын чагылдырган 100 меңләп берәмлек теркәлер дип көтелә.

Бу хезмәтнең моңа кадәр чыккан аңлатмалы сүзлекләрдән аерып торачак якларының берсе — төрки телләрнең табигатенә хас, аеруча морфология һәм сүзьясалышында киң чагылыш тапкан аналитизм күренешенә зур урын бирелүендәдер. Билгеле, бу күренешне эзлекле рәвештә теркәү сүзлек төзүчеләрнең татар тел белеме, шул җөмләдән татар лексикографиясе, һәм, гомумән, тюркологиянең соңгы ярты гасыр эчендә ирешелгән барлык диярлек уңышларын исәпкә алып, аңлап эш итүләренә дә бәйле. Моңа кадәр аналитизм күренеше тиешле дәрәҗәдә һәм канәгатьләндерерлек күләмдә лексикографик яктан максатчан рәвештә тасвирланмаган иде әле. Шунлыктан, телебездә кулланылышы ягыннан актив булган лексик катламның зур бер өлеше сүзлекләрдә чагылмый кала килде. Бу өлкәдә телчеләрнең, аеруча профессор Ф.Ә. Ганиевнең [кара: Ганиев, 2010], күп еллар дәвамында алып барган тикшеренү нәтиҗәләренә караганда, татар телендә тезмә фигыльләрнең саны берничә йөз меңнән артып китәргә мөмкин. Мисал өчен, **ачу** ‘открывать’ фигыленнән 6—7 тезмә фигыль ясарга мөмкин: *ача тору, ача төшү, ачып алу, ачып бирү, ачып җибәрү, ачып кую, ачып салу*. Аларның барысы да бүгенге сөйләмдә актив кулланыла. Шуның белән бергә телебездә шактый күләмдә формаль-семантик күрсәткечләре белән мөстәкыйль лексик берәмлек статусына дәгъва кылган тезмә исемнәр, исемнән торган конструкцияләр кулланыла. Мәсәлән: *башакка утыру, баш кысу, бәпкә үләне, дала мәчесе* һ.б. Мондый берәмлекләрне эзлекле һәм системалы рәвештә аңлатмалы сүзлектә теркәү фундаменталь лексикографик хезмәт әзерләүчеләрнең алдында торган мөһим фәнни һәм гамәли бурычлардан санала.

1990 еллар башыннан алып татар теленең тармак терминологи-

ясен өйрәнү өлкәсендә дә шактый эшләр башкарылды. Әйтик, бүгенге көнгә кадәр монографик планда татар теленең 30 лап тармак лексикасы тикшерелгән. Алар арасында үсемлек, балык, кош, бөҗәк атамалары, умартачылык, агач архитектурасы, җир эшкәртү, нефть сәнәгате лексикасы, хәрби лексика, медицина, физика, химия терминологиясе һ.б.

Бу фактлар артында күпсанлы лингвистларның конкрет өлкәләргә караган лексиканы барлау, җыю, туплау, теркәү, терминнарның мәгънәләрен ачыклау, яңа терминнар ясау һ.б.ш. зур түземлек һәм тырышлык таләп итә торган максатчан күпьеллык эшчәнлеге тора.

Телнең тулы һәм сыйфатлы кулланылышын, аның үсешен тәэмин итүдә терминологик сүзлекләр эшләп чыгару әһәмиятле урын алып тора. Соңгы 20—25 ел эчендә татар телендә 40 тан артык махсус тәрҗемә һәм аңлатмалы терминологик сүзлек нәшер ителде. Шундый хезмәтләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *Русча-татарча, татарча-русча физика терминнары сүзлеге* [Русча-татарча…, 1996], *Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге* [Агрохимия…, 2003]; *Медицина терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге* [Медицина…, 2004]; *Агроэкология терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге* [Агроэкология…, 2008]; *Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек* [Тасвири…, 2011] һ.б. Шулай да татар лексикографиясендә тармак терминологиясен өйрәнү юнәлешендә әлегә бушлыклар да юк түгел. Соңгы берничә ел дәвамында Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ аспирантларының кандидатлык диссертацияләре темаларыкысаларында ат асраучылык, спорт, урман хуҗалыгы, музыка һ.б. өлкәләргә караган махсус лексиканың өйрәнелүе дә билгеле бер дәрәҗәдә әлеге бушлыкны тутырыр дип ышанабыз.

Аерым тармаклар буенча тәртипкә салынып тикшерелгән бай лексик материал соңгы вакытта нәшер ителгән гомуми характердагы лексикографик хезмәтләрдә дә, икетелле махсус аңлатмалы терминологик сүзлекләрдә дә чагылыш тапты. Шуңа да карамастан, бу юнәлештә киеренке эш дәвам иттерелә. Якын киләчәктә тукучылык лексикасы, хәрби терминология, ихтионимнар, орнитонимнар, фитонимнарның икетелле аңлатмалы терминологик сүзлекләре дә укучыга барып ирешер дип көтелә. Лексиканың аерым тематик төркемнәренә бәйләп сүзьясалышы сүзлекләрен эшләп чыгару да көн тәртибендә тора.

Рус һәм татар халкы арасындагы күптәннән килә торган тыгыз тарихи багланышларны чагылдырган традицион икетелле сүзлекләрдән тыш, төрле чорларда чит телләргә, башлыча, инглиз, гарәп, фарсы, төрек телләренә бәйләп икетелле, күптелле сүзлекләр дә эшләнгән. Билгеле, андый хезмәтләр күп булмаган. Мисал өчен, безгә 15 ләп татарча-гарәпчә, гарәпчә-татарча сүзлек барлыгы мәгълүм. Бу нисбәттән Г. Ишмөхәммәтовның зур булмаган күптелле хезмәтен — *Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә*сен [Ишмөхәммәтов, 1954] атарга була.

Мондый төр күләмлерәк сүзлекләрнең эшләнүе XX йөзнең икенче яртысына һәм хәзерге заманга карый. Биредә, һичшиксез, 1965 елда дөнья күргән [Гарәпчә-татарча-русча..., 1965] һәм 1993 елда кабаттан нәшер ителгән *Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге*н [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993] телгә алырга кирәк. Әлеге хезмәт татар теленең XX йөз башына кадәр киң кулланылышта булып, аннан соңгы чорларда, баш-

лыча милли мәдәниятләрне гомумсоветлаштыру процессы тәэсирендә, татарның үз сүзләре, рус яки рус теле аша кергән интернациональ сүзләр белән алыштырылып, өлешчә пассив катламга күчкән яки тулысынча кысрыклап чыгарылган кабатланмас лексик байлыгын чагылдыра. Гарәп-фарсы сүзләрен татар һәм рус телләренә төгәл тәрҗемә итеп бирү, аерым аңлатмалар теркәү, төрле чыганаклардан мисаллар китерү, өстәвенә, кушымта итеп, гарәп грамматикасы хакында кыскача белешмә тәкъдим итү — барысы бергә хезмәтне әлегә бердәнбер шундый кыйммәтле фәнни чыганак һәм гамәли кулланма буларак күзалларга мөмкинлек бирә.

Соңгы елларда татар һәм гарәп телләре материалы нигезендә күләме белән зур булмаган терминологик сүзлекләр дә басыла тора. Мисал өчен, 2005 елда *Мөселман терминологиясе сүзлеге* басылып чыкты [Сафиуллина, 2005]. Татар халкы үзенең үткән тарихи юлын барлап, милли асылына кайтырга, телен, мәдәниятен, динен сакларга һәм үстерергә омтылган шартларда, башлыча гарәп чыгышлы мөселман терминологиясенең бер өлеше татар телендә кабат актуальләшә һәм сүзлек составында үз урынын ныгытып калырга дәгъва кыла. Икенче бер төркем сүзләр исә, алга таба өйрәнелеп, сүзлекләрдә теркәлергә тиеш. Мондый төр сүзлекләр эшләп чыгару, гәрчә алар, аерым тар максаттан чыгып, тел материалын тулы күләмдә чагылдыру бурычын үтәмәсәләр дә, хәзерге татар лексикографиясе үсешендә мөһим бер юнәлеш тәшкил итә. Татар теленә бәйле башка икетелле сүзлекләрдән татар һәм төрек галимнәренең уртак тырышлыгы белән төзелгән шактый күләмле *Татарча-төрекчә сүзлек* [Татарча-төрекчә..., 1997] һәм *Төрекчә-татарча сүзлек* [Төрекчә-татарча..., 1998] игътибарга лаек. Аларда тупланган лексик материал уртак тарихи тамырларыбызны һәм Татарстан белән Төркия арасындагы социаль-икътисади, мәдәни һ.б. өлкәләргә караган бүгенге хезмәттәшлекнең югары үсеш дәрәҗәсен чагылдыра.

Бүген, фән һәм техника өлкәсендә күзәтелгән сизелерлек үсеш нәтиҗәсендә, тел системасында да, аеруча аның сүзлек составында, күптөрле үзгәрешләр барлыкка килә: тел үзенең эчке мөмкинлекләре исәбенә берникадәр үсә-үзгәрә, неологизмнар пәйда була, алынмалар саны арта бара, сүзләрнең семантик структурасы үзгәрә, яңа мәгънәләр, мәгънә төсмерләре теркәлә һ.б. Бу шартларда татар теле һәм башка телләрнең хәзерге кулланылышүсеш дәрәҗәсенә җавап бирердәй һәм традицион, һәм электрон форматта яңа буын лексикографик продукция эшләп чыгару ихтыяҗы үзен ачык сиздерә. Бу исә тулысы белән татарча-төрекчә сүзлекләргә дә кагыла. Әлеге юнәлештә билгеле күләмдә эш башкарыла да инде [Öner Mustafa, 2009].

Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән халыкара хезмәттәшлекне җәелдерә баруы аралашуга карата да яңа таләпләр куя. Мондый вазгыять татар телен чит телләргә бәйләп, икетелле һәм күптелле зуррак сүзлекләр эшләп чыгару ихтыяҗын алга сөрә. Глобальләшү һәм халыкара багланышларның аеруча тиз үсеш алуы шартларында мөстәкыйль дәүләтләр югарылыгында да, Россиянең аерым төбәкләре дәрәҗәсендә дә тормыш һәм яшәешнең төрле өлкәләрендә белгечләр арасында тәҗрибә уртаклашу арта бара. Галимнәр, мәдәният хезмәткәрләре, бизнес вәкилләре, спортчыларның халыкара конгрессلар һәм симпозиумнарда, сәяси һәм икътисади чараларда, төрле спорт ярышларында катнашуы киңрәк төс ала, чит ил компанияләре белән хезмәттәшлек итү өчен яңа мөмкинлекләр ачы-

ла. Күпчелек очракта мондый бәйләнешләрдә төп аралашу чарасы булып инглиз теле хезмәт итә. Галимнәр фикеренчә, бүген Җир шарында миллиард ярымнан артык кеше аралашу һәм мәгълүмат алмашу максатында нәкъ менә шушы телдән файдалана. Сәясәт, икътисад өлкәсендә күзәтелә торган глобаль процесслар, югары технологияләрнең гаять тиз үсеш алуы, Интернет челтәренең актив, хәтта агрессив рәвештә кулланылыш даирәсе киңәю — барысы да, ул телдә сөйләшүче илләрдән саналган Бөекбритания, АКШ, Канада, Австралия һ.б. лар белән генә чикләнмичә, инглиз теленең таралыш мәйданын күпкә арттыра. Шул рәвешле инглиз теле глобаль аралашу чарасына әйләнеп бара. Киләчәккә йөз тотып эш иткәндә, инглиз телен белү заманча карашлы кешенең профессиональ эшчәнлегенә дә сизелерлек йогынты ясарлык, алыштыргысыз гамәли бер сыйфат булып торачак. Шушы үсеш юнәлешләрен исәпкә алып, халыкара лексикография өлкәсендә милли (татар) һәм чит (инглиз) телләр нигезендә сүзлекләр эшләүгә күбрәк игътибар ителә башлады. Башка чаралар белән беррәттән, андый алым, халыкның лингвоэтник үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, төрле мәдәният вәкилләренә гомумдөнья күләмендәге лингвистик процесслар агымына кушылу мөмкинлеген бирә. Моннан тыш, телара элемтәләр милли тел системасын баету һәм үстерү өчен генә түгел, ә бәлки шул телләрдә сөйләшүчеләргә бер-берсенең мәдәниятләрен дөрес һәм тулы аңлау өчен дә уңай бер нигез булып тора.

Шул ук вакытта, классик һәм хәзерге татар әдәбияты үрнәкләрен дөньякүләм укучыга җиткерү максатында, татар язучыларының әсәрләрен инглиз теленә һәм киң таралган башка телләргә дә тәрҗемә итү кирәклеге торган саен үзен ачыграк сиздерә бара. Бу өлкәдә лексикографик эшчәнлек төп юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Шунлыктан, татар һәм инглиз телләре материалы нигезендә икетелле сүзлекләр булдыруның әһәмияте бүген тагын да арта төшә.

Хәзерге вакытта мәктәпләр, югары уку йортлары өчен төзелгән икетелле, күптелле сүзлекләр бар. Күләме ягыннан артык зур булмаган андый сүзлекләр арасында түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *Инглизчә-русча-татарча тематик сүзлек* [Апакова, 1994], *Инглизчә-русча-татарча физика терминнары* [Даутов, 1996], *Инглизчә-татарча-русча уку-укыту гомумтөзелеш лексикасы сүзлеге* [Кафиатуллина, 1996], *Немецчә-татарча-русча уку-укыту гомумтөзелеш лексикасы сүзлеге* [Кафиатуллина, 1996], *Инглизчә-татарча-русча уку-укыту минимумы сүзлеге* [Арсланова, 1999], *Информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары: инглизчә-татарча-русча аңлатмалы сүзлек* [Термины..., 2006], *Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек* [Татарча-русча-инглизчә ..., 2010], *Французча-русча-татарча мәктәп укучылары сүзлеге* [Васильева, 2013] һ. б.

Төрки дәүләтләрдә һәм чит илләрдә инглиз теленә бәйле башка икетелле сүзлекләрне дә очратырга мөмкин. Андыйлар рәтендә 1989 елда Германиядә басылган шактый күләмле *Татарча-немецчә сүзлек*не [Dawleschin, 1989] күрсәтеп була. 1994 елда АКШта С.Шакмаев тарафыннан төзелгән *Татарча-инглизчә, инглизчә-татарча сүзлек* нәшер ителә [Tatar-English..., 1994]. Сүзлекнең кулланучы өчен аеруча уңай сыйфаты — татар өлешенең — латинда, ә инглиз өлеше кириллдагы транскрипциядә бирелүендә. Дөрес, татар сүзләренең транслитерация аша әйтелешен билгеләүдә кимчелекләр дә юк түгел. Татар өлеше латинда булган тагын бер *инглизчә-татарча сүзлек һәм сөйләшлек*не үз эченә алган китап 2009 елда Лондонда басыла [Nichalos..., 2009].

Башка төрки телләргә мөнәсәбәтле шундый ук сүзлекләрне алып карaганда, төрекчә-инглизчә һәм инглизчә-төрекчә сүзлекләр тел материалын этрафлырак һәм тулырак чагылдырулары белән аерылып торалар.

Татарча-русча икетеллелек шартларында исә инглиз теленә өйрәтү, башлыча, рус теле аша алып барылганлыктан, мондый төр уку-укыту сүзлекләрен арадашчы тел саналган рус теленнән башка төзү күпчелек укучылар өчен алардан файдалануда аерым кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Шунысын да искәртергә кирәк: соңгы дистә елда чит телләргә өйрәткәндә, туган телгә, татар теленә таянып укыту юнәлеше дә үсеш алып килә. Безнең фикеребезчә, өчтелле сүзлекләр нигезендә эшләнгән икетелле сүзлекләр тулырак һәм төгәлрәк булулары белән аерылып тора. Шуны исәпкә алып, киләчәктә күләмлерәк татарча-инглизчә һәм инглизчә-татарча сүзлекләр төзү юнәлешендә беренче тәҗрибә буларак, агымдагы елда Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ белгечләре тарафыннан төзелгән *Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге* [Татарча-русча-инглизчә..., 2014] дөнья күрде. Сүзлекнең күләме 30 басма табак тәшкил итә. Ул укучыга яхшы таныш булган *Татарча-русча уку-укыту сүзлеге*нең [Татарча-русча..., 1993] сүзлекчәсенә һәм аның төп лексикографик принципларына таянып төзелде.

Сүзлекнең максаты — татар сүзләренең рус һәм инглиз телләрендә мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү иде. Сүзлеккә 12 меңгә якын сүз һәм сүзтезмә кертелде, шул исәптән 1000 ләп актуаль булган фразеологик берәмлек һәм аларның рус, инглиз телләрендә төгәл тәңгәлләре, ә андыйлар булмаган очракта — тасвирлама вариантлары бирелде. Сүзлектә татар теленең хәзерге чордагы үсешенә хас үзенчәлекләр, аның лексик составында яңа барлыкка килгән яисә башка телләрдән кереп үзләштерелгән берәмлекләр дә теркәлде. Бу исә сүзлекнең татарча лөгатьлеген берникадәр яңартуга китерде.

Сүзлекнең аны башкалардан аерып торган отышлы ягы — кушымта итеп, инглиз теле грамматикасы турында татарча кыскача белешмә бирелүендә. Әлеге белешмә чит тел кагыйдәләрен аңларга, аларны үзләштерергә ярдәм итәр һәм туган тел аша чит телне өйрәнү процессын җиңеләйтер дигән максаттан чыгып эшләнде.

Татарстанда һәм аннан читтәге югары уку йортларында, төрле фәнни учреждениеләрдә эшләүче укытучылар, тел галимнәренең нәтиҗәле хезмәттәшлек итүе өлкәләренең берсе — икетелле, күптелле тематик сөйләшмәлекләр эшләп чыгару. Әлеге эшчәнлек һәр як өчен дә аеруча әһәмиятле, чөнки ул Республикада яшәүче төрле халык вәкилләренә аралашу-аңлашу, дәүләт теле статусына ия булган татар теле белән беррәттән, үз туган телләрен өйрәнү, үстерү өчен уңайлы шартлар тудыруга булышлык итә. Республикада зур халыкара спорт, мәдәният чаралары һ.б. вакыйгаларның әледән-әле үткәрелеп торуын исәпкә алганда, туган телне пропагандалау, аның абруен күтәрү максатларында мондый эшчәнлекне киңрәк һәм нәтиҗәлерәк итеп тә оештырырга булыр иде.

Әлбәттә, соңгы берничә ел дәвамында шундый гамәли кулланмаларның укучыга барып ирешүе бик тә куанычлы күренеш. Мисал өчен, *Татарча-удмуртча сөйләүлек* [Татарско-русско-удмуртский..., 2012], *Татарча-русча-чувашча сөйләүлек* [Татарско-русско-чувашский..., 2012], *Татарча-русча-марича сөйләүлек* [Татарско-русско-марийский..., 2012], *Татарча-русча-мокша-эрзәнчә сөйләүлек* [Татарско-русско-мокшанско-эрзянский..., 2012], *Татарча-русча-инглизчә сөйләүлек*ләр [Та-

тарча-русча-инглизчә..., 2012] нәшер ителде. Тагын берничә шундый хезмәт әзерләнә тора, шул җөмләдән, арадашчы тел буларак рус телен дә кертеп, *Татарча-инглизчә, инглизчә-татарча сөйләшмәлек*. Кулланманың аермалы ягы шунда: һәр ике телдә дә сүзләрнең, гыйбарәләрнең латин һәм кириллда транслитерациясе бирелә. Мондый алым, сүзлек төзүчеләр фикеренчә, татар яки инглиз телен бөтенләй белмәгән очракта да, файдаланучыга аралашу мөмкинлеген бирә.

Телләр турындагы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында татар телен кытай, испан, гарәп, алман, француз телләре кебек дөньяда киң таралган телләр янәшәсенә куеп та сөйләшмәлекләр һәм билгеле күләмдә сүзлекләр эшләү күз уңында тотыла.

Хәзерге заманда төбәкара, илләр арасындагы багланышларның һәм, гомумән, халыкара хезмәттәшлекнең киңәя баруын исәпкә алып, Республиканың төрле юнәлешләрдә эзлекле үсешен тәэмин итү, аны чагылдырган хезмәтләрне чит телләргә тәрҗемә итү аша бай рухи-мәдәни мирасыбыз белән башка халыкларны да таныштыру, казанышларыбызны дөнья күләмендә актив рәвештә пропагандалау кирәклеген тулысы белән аңлап эш иткән очракта, татар телен чит телләргә бәйләп, лексикографик хезмәтләр, сөйләшмәлекләр, башка шундый кулланмалар әзерләү, татар классик әдәбияты һәм хәзерге чор әдәби әсәрләрнең тәрҗемә үрнәкләрен булдыруга бәйле эшчәнлекнең әһәмияте торган саен артачак кына.

Көннән-көн үзгәрә-камилләшә барган техника, компьютер технологияләре, Интернет мөмкинлекләре татар электрон лексикографиясе үсешенә дә этәргеч бирә. Бүген татарча электрон интерактив, күпфункцияле сүзлекләр эшләү юнәлешендә, бигрәк тә соңгы берничә елда, шактый активлык күзәтелә. Бу эшкә аерым кешеләр дә, махсус фәнни тикшеренү лабораторияләренә берләшеп эшләүче галим-белгечләр дә үзләреннән өлеш кертәләр. Интернет киңлекләрендә, аерым сәхифәләрдә күрсәтелгән мәгълүматка караганда, сүз саны 2 000 нән алып 70 000 гә җиткән ике дистәләп төрле типтагы татарча электрон сүзлек табып була. Шундый электрон эшләнмәләр арасында түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *Кыскача русча-татарча сүзлек* (2000 сүз) [Русско-татарский краткий словарь. URL: http://radugaslov.ru], *Зур татарча-русча сүзлек* (15 000 ләп сүз) [Татарско-русский большой словарь. URL: http://tatar.com.ru], *Татарча-русча һәм русча-татарча электрон сүзлек* (һәр өлешендә 70 000 сүз) [Электронный татарско-русский и русско-татарский словарь. URL: http://tatar.com.ru], *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге* [URL: http://tatarca-text.narod.ru], онлайн режимында файдаланып була торган Г. Тукай сүзлеге [Габдулла Тукай шигърияте теле. URL: http:// http://www.klf.kpfu.ru] h.б.

Бу сүзлекләрнең нигезен, башлыча, төрле елларда Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ хезмәткәрләре тарафыннан эшләнеп басылган сүзлекләр тәшкил итә.

Казан федераль университетының гамәли лингвистика кафедрасында дистә елдан артык татар теленә мөнәсәбәтле һәртөрле сүзлек, белешмә, кулланмаларның электрон фондын булдыру, яңа төр сүзлекләр (аеруча электрон форматта) эшләү юнәлешендә җитди тикшеренүләр алып барыла. Бу эшкә проф. К.Р. Галиуллин җитәкчелек итә. Кафедра хезмәткәрләре тарафыннан эшләнеп, Интернетка урнаштырылган ике сүзлекне — *Габдулла Тукай шигърияте теле: интернет-сүзлеге* [URL: http:// http://www.klf.kpfu.ru] белән *Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» теле: интернет-сүзлеге*н [URL: http://

http://www.klf.kpfu.ru] — татар телендә язучылар теле лексикографиясенә нигез салган беренче җитди хезмәтләр буларак бәяләргә мөмкиндер. Укучы Г. Тукай сүзлегенең традицион кәгазь вариантыннан да файдалана ала [Галиуллин, 2009]. Әлеге сүзлекләрнең электрон форматта эшләнеше аларда тупланган тел материалын төрле лингвистик тикшеренүләрдә файдалану өчен дә зур мөмкинлекләр бирә.

Моннан берничә ел элек гамәли лингвистика кафедрасында тагын бер зур теоретик хезмәт әзерләнде [Татарская..., 2011]. Бу хезмәттә XX гасырның икенче яртысы — XXI гасыр башы (1951—2008 еллар) арасында Россиядә басылган 317 татар сүзлеге, татар теленә мөнәсәбәтле төрле эчтәлектәге белешмә, кулланмалар, бер системага китерелеп, лингвографик планда анализланган. Чынлыкта мондагы материал татар теленең, нигездә, икетелле сүзлекләрдән торган төп сүзлек фондын чагылдыра. Биредә телгә алынган һәрбер сүзлек аның макро- һәм микроструктурасы, лексикасының никадәр тулы һәм эзлекле чагылганлыгы, сүзләрне теркәп тасвирлау параметрларының никадәр дөрес бирелгәнлеге һ.б. мөһим күрсәткечләрне исәпкә алып, җентекләп тикшерелгән. Мондый тикшеренүнең әһәмиятле ягы тагын шунда: аның нәтиҗәләре басылган һәм басмага әзерләнә торган татар сүзлекләренең типологиясен ачык күзалларга, телнең бүгенге кулланылышына бәйле рәвештә барлыкка килгән ихтыяҗларны исәпкә алып, максатчан рәвештә лексикографик бушлыкларны тутыра барырга, гомумән, татар лексикографиясенең алга таба үсешен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, әлеге фондка гаять зур күләмдәге тел материаллары тупланган. Алар, һичшиксез, татар электрон лексикографиясе өлкәсендә дә, беренче чиратта, татар теленең зур электрон сүзлеген төзегәндә, компьютер ярдәмендә тәрҗемә итү, сөйләмне танып белү, аны текстка әйләндерү, мәгълүмат эзләү кебек һ.б.ш. махсус программалар әзерләгәндә дә тулысы белән эшкә җигелергә, телебезне саклау, ныгыту, үстерү мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиеш.

Мәскәүдәге «Инсан» нәшрияты белгечләре тарафыннан татар лексикографиясендә әлегә күзәтелмәгән икетелле мультимедияле интерактив сүзлек эшләнә. Аның эксперименталь үрнәгеннән аңлашылганча, *Русча-татарча сүзлек*кә 40 меңнән артыграк сүз кергән. Өстәвенә, татарча яхшы белгән профессиональ диктор башкаруында һәр сүзнең аудиоверсиясе теркәлгән, сүзнең татарча әйтелешен, аның яңгырашын үзләштерү өчен, махсус программасы да эшләнгән. Әлеге заманча лексикографик продуктны яңарту, киңәйтү һәм камилләштерү мөмкинлекләре дә программага салынган. Сүзлекнең эчтәлегенә бәйле барлык үзгәрешләр, өстәмә-төзәтмәләрне Интернет аша онлайн режимында алып тору мөмкинлеге булу әлеге сүзлектән файдалануны уңайлаштыра. Андый мәгълүматны кулланучы үзе дә тәкъдим итә ала.

Төрле елларда Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ хезмәткәрләре төзегән икетомлы *Татарча-русча* һәм *Русча-татарча сүзлек*ләрнең гади электрон версияләре дөньякүләм билгеле ABBYY компаниясенең күптелле лексикографик проектында — *ABBYY Lingvo сүзлеге*ндә чагылыш тапкан.

Татар теленең төрле чорларда һәм төрле максат белән төзелгән 50 ләп аңлатмалы, икетелле һәм башка сүзлекләренә кыскача күзәтү ясау татар лексикографиясенең бай тарихы, озак еллар, хәтта гасырлар дәвамында формалашып шомарган, ныгыган фәнни традицияләре, гомумән, бәяләп бетергесез мирасы барлыгын исбатлый.

Ул мирас төрле тарихи чорларда, төрле шартларда күпсанлы галимнәр, тикшеренүчеләрнең, татар теленә, татар мәдәниятенә, татарның тарихына битараф булмаган, үз милли асылын белергә, аны өйрәнергә омтылган затларның тырышлыгы, эчкерсез фидакяр хезмәте белән булдырылган. Милли лексикографиянең хәзерге урыны һәм әтрафлы үсүе әнә шул мираска һәм аерата соңгы чирек гасыр эчендә төрки-татар тел белеме, шул җөмләдән татар лексикографиясе өлкәсендәге уңышларга, фундаменталь һәм гамәли хезмәтләр белән салынган ныклы нигез булуына бәйле.

Шуның белән бергә бүген тормышның бар өлкәләренә дә диярлек тиз адымнар белән фән-техника казанышлары үтеп керә. Гомумкомпьютерлаштыру, электрон мәгълүмат базалары, һәртөрле белешмә каталоглар, мәгълүмат туплау, саклау, эзләү ресурслары булдыру, шулар өстенә, тәрҗемә итү, тавышны танып белү, аны текстка салу һәм, киресенчә, кәгазьдәге текстны «тавыш» форматына күчерү кебек катлаулы гамәлләр башкара алырдай компьютер программаларын эшләп, кулланылышка кертү ихтыяҗы үскән саен, профессиональ нигезгә корылган лексикографик эшчәнлекнең әһәмияте дә күп тапкыр арта. Һичшиксез, мондый эшчәнлек кысаларында өстенлек лексикография өлкәсендә яңа буын продуктларына — кирәкле мәгълүматны тиз арада, аз көч сарыф итеп, мөмкин кадәр киңрәк күләмдә һәм тиешле тасвирланышында табып алу мөмкинлеген бирә торган күпмаксатлы, күпфункцияле интерактив электрон сүзлекләр эшләүгә бирелергә тиеш. Уңайлылыгы, күптөрле заманча гаджетлар (электрон җиһазлар) ярдәмендә киң куллану мөмкинлекләре булуы белән электрон сүзлекләр, аларның традицион форматлы «агайлары» белән чагыштырганда, күпкә отышлырак булып чыга. Гәрчә мондый вазгыять алга таба традицион лексикографиянең үсүенә дә киртәләр куймый.

Бүген милли лексикография өлкәсендә, шул исәптән электрон сүзлекләр төзү юнәлешендә җитди адымнар ясалу якын киләчәктә телне, тел берәмлекләренең семантикасын лексикографик тасвирлау алымнарын камилләштерү, яңа төр сүзлекләр төзү мәсьәләләрендә сизелерлек алга китеш булыр дип әйтергә нигез бирә. Тупланган тәҗрибә шуны күрсәтә: моңа ирешүнең иң нәтиҗәле юлы ул — төрле тармак белгечләренең, иң элек телчеләр, компьютер программаларын төзүчеләрнең берләшеп эшләве, алай гына да түгел, әлеге гаять катлаулы, шул ук вакытта кызыклы да, файдалы да лексикографик «авантюра»га — сүзлекләр төзүгә — киң катлау файдаланучыларны җәлеп итү.

Ничек кенә булмасын, шунысы бәхәссез: бу процессларның үзәгендә һәрвакыт Кеше дигән акыл иясе торачак, чөнки машиналарның кеше акылыннан өстен булулары, аларның кеше фикер йөрткән дәрәҗәдә уйлау-аңлау сәләтенә ия булулары турында сүз куерту әлегә иртәрәктер, гәрчә хәзерге чордагы фәнни-техник алгарышның кайбер җимешләре безне, ирексездән, киләчәктә моның чынбарлыкка ашу ихтималы югары булганлыгына ышанырга этәрсә дә.

**Әдәбият**

2014—2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү: дәүләт програмасы. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге № 794 карары белән расланган. URL: http://tel.tatar.ru/tt/дәүләт-программасы-турында (мөрәҗәгать ителде: 15.10.2014)

ABBYY Lingvo x5 20 языков Профессиональная версия. URL: http://www.lingvo.ru/download (дата обращения: 15.10.2014).

*Dawletschin T., Dawletschin I., Semih T.* Tatarisch-deutsches Wőrterbuch = Татарча-алманча сүзлек. Wiesbaden: Harrassowitz, 1989. 365 S.

*Nicholas Awde & Gulnaz Valeeva.* Tatar Phrasebook. London: Bennet & Bloom. 2009. 183 p.

*Őner Mustafa.* Kazan-Tatar Tűrkçesi Sőzlüğü. Ankara: Tűrk Dil Kurumu, 2009. 358 s.

Tatar-English / English-Tatar Dictionary / Sergey Shakmaev. New York: Hippocrene Books, 1994. 200 p.

Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / төз. М. Ю. Гыйлаҗев, С. Г. Мортазина, Ф.Ф. Гаффарова. Казан: Мәгариф, 2003.

Агроэкология терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / төз.: М.Ю. Гыйләҗев, С.Г. Мортазина, Ф.Ф. Гаффарова һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 191 б.

*Апакова Л.Я.* Англо-русско-татарский тематический словарь (соматическая фразеология). Казань: Иман, 1994. 82 с.

*Арсланова Г.А., Сафиуллина Ф.С.* Учебный англо-татарско-русский словарь-минимум. Казань: Хэтер, 1999. 134 с.

*Васильева В.Н., Низамиева Л.Р., Харисов Ф.Ф.* Французско-русско-татарский словарь для школьников. Казань: ХӘТЕР, 2013. 159 с.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең тулы сүзлеге: 2 кисәктә. Казан, 1927, 1929.

Габдулла Тукай шигърияте теле: интернет-сүзлек / төз.: К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина; программистлар: Н.А. Обносова, Е.В. Фёдоров, И.Л. Александрова. URL: http:// http://www.klf.kpfu.ru/tukay/indext.php (мөрәҗәгать ителде: 19.10.2014).

*Галиуллин К.Р., Каримуллина Р.Н.* Габдулла Тукай: язык поэзии: словарь: в 2 кн. Казань: Магариф, 2009. (1 кн. — 503 с.; 2 кн. — 527 с.; на русском и татарском языках).

*Ганиев Ф.А.* Русско-татарский словарь: Русча-татарча сүзлек. Казань: Раннур, 2009. 632 с.

*Ганиев Ф.Ә.* Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге: ике кисәктә. Беренче кисәк (А—К). Казан: Мәгариф, 2009, 375 б.; икенче кисәк (Л—Я). Казан: Паравитта, 2012. 537 б.

*Ганиев Ф.А.* Избранные статьи / сост. А.А. Тимерханов, М.Р. Ахметзянов. Казань: Паравитта, 2010. 335 с.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре: М.И. Мәхмүтов төзегән гарәп теле грамматикасы белешмәсе кушымта итеп бирелде) / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин; ред.: Р.С. Газизов, М.Г. Гыймадиев, И.Г. Гыйльфанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 855 б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре: М.И. Мәхмүтов төзегән гарәп теле грамматикасы белешмәсе кушымта итеп бирелде): 2 томда / М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин; ред.: Р.С. Газизов, М.Г. Гыймадиев, И.Г. Гыйльфанов. Казан: Иман, 1993. 448 б.

*Даутов Г.Ю.* Англо-русско-татарский словарь физических терминов: ок. 1000 слов / Г.Ю. Даутов, З.М. Вагизова, О. Аслан; под ред. Г.Ю. Даутова. Казань: Тан-Заря, 1996. 28 с.

*Ишмөхәммәтов Г.* Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә: 2 600 сүз / җаваплы ред. Х.У. Усманов, Л. Яфаров. Казан, 1954. 100 б.

*Кафиатуллина В.И.* Англо-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики / науч. ред.: Ф.Ш. Фатхуллин, Р.А. Шакирзянов, Р.Н. Куряева. Казань: Изд-во Казан. архит.-строит. акад., 1996. Вып. 1. 84 с.

*Кафиатуллина В.И.* Немецко-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики: ок. 5 000 слов / науч. ред.: Ф.Ш. Фатхуллин, Р.А. Шакирзянов. Казань: Изд-во Казан. архит.-строит. акад., 1996. 90 с.

Медицина терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / төз. Р.Р. Шәмсетдинова. Казан: Мәгариф, 2004. 351 б.

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» теле: интернет-сүзлек / төз.: К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина, Л.С. Минһаҗева; программистлар: Н.А. Обносова, Е.В., Фёдоров. URL: http://www.klf.kpfu.ru/jalil/indext.php (мөрәҗәгать ителде: 16.10.2014).

*Насыйри К.* Ләһҗәи татари: 2 томда. Казан: Ун-т типолитогр., 1895. 226 б.; 1896. 226 б.

*Ожегов С.И.* Словарь русского языка / гл. ред. С. П. Обнорский. М.: Гос. изд. иностр. и нац. словарей, 1949. 968 с.

Русско-татарский краткий словарь. URL: http://radugaslov.ru/tatar2.htm (дата обращения: 20.02.2014).

Русско-татарский словарь / сост.: Э.М. Ахунзянов, Р.С. Газизов, Ф.А. Ганиев; под ред. Ф.А. Ганиева. М.: Рус. яз., 1984. 734 с.

Русско-татарский словарь: в 4-х томах / под ред.Н.К. Дмитриева. Казань: Таткнигоиздат, 1955—1959.

Русча-татарча физика терминнары сүзлеге. Татарча-русча физика терминнары сүзлеге / төз. Г.Ю. Даутов, Д.Г. Галимов, З.М. Вагыйзова; Г.Ю. Даутов ред. Казан: Таң-Заря, 1996. 200 б.

*Сафиуллина Р.Р.* Мөселман терминологиясе сүзлеге. Словарь мусульманской терминологии. Казань: Алма-Лит, 2006. 124 с.

Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек / төз. Ф.Г. Ваһапова; Р.Т. Сәфәров ред. Казан: Мәгариф—Вакыт, 2011.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / баш редакторы Ф.Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. URL: http://tatarca-text.narod.ru (мөрәҗәгать ителде: 10.09.2014).

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: т. I—III / редкол.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров h.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге / фәнни ред. Ф.Ф. Гаффарова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

Татарская лингвография: словари татарского языка 1951—2008 годов: библиографический справочник / сост. Р.Н. Каримуллина; науч. ред. К.Р. Галиуллин. Казань, 2011 536 с.

Татарско-русский большой словарь. URL: http://tatar.com.ru/dict/aa.php (дата обращения: 03.03.2014).

Татарско-русский словарь / сост. Р. Газизов, Н. Исанбет, Г. Ишмухаметов. Казань: Татгосиздат, 1950.

Татарско-русский словарь: ок. 38000 слов. М.: Сов. энциклопедия, 1966. 863 с.

Татарско-русско-марийский разговорник / сост.: Ф.Ф. Гаффарова, А.Н. Куклин. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 215 с.

Татарско-русско-мокшанско-эрзянский разговорник / сост.: Ф.Ф. Гаффарова, А.Н. Келина, Л.А. Гурьянова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 375 с.

Татарско-русско-удмуртский разговорник / сост.: Ф.Ф. Гаффарова, И.В. Тараканов, В.В. Вежеева. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 215 с.

Татарско-русско-чувашский разговорник / сост.: Ф.Ф. Гаффарова, Е.Ф. Васильева. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 212 с.

Татарча-русча сүзлек: 2 томда. Т. 1 (А—Л), 726 б. Т.2 (М—Я), 726 б. Казан: Мәгариф, 2007.

Татарча-русча сүзлек: 25 000 чамасы сүзне эченә ала [= Татарско-русский словарь: ок. 25000 слов] / төз.: И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев һ.б.; Ф.Ә. Ганиев ред. 3 нче басма. Казан: Татар. китап нәшр., 1998. 464 б. [1-е изд. — 1988]

Татарча-русча уку-укыту сүзлеге: 10 000 сүз чамасында = Татарско-русский учебный словарь: ок. 10 000 слов / Ф.А. Ганиев, И.А. Абдуллин, Р.Г. Гатауллина һ.б.; Ф.Ә. Ганиев редакциясендә. М.: Рус теле, Дигора. 1993. 416 б.

Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге / төз. А.Ә. Тимерханов, С.Ф. Гарифуллин; фәнни ред., кереш мәкалә, кушымта авторы А.Ә. Тимерханов. Казан: Мәгариф—Вакыт, 2014. 512 б.

Татарча-русча-инглизчә сөйләүлек = Татарско-русско-английский разговорник = Tatar-russian-english phrasebook / төз-авт. : К.С. Фатхуллова, Х.Г. Фәйзрахманова, Ф.Р. Шәйхиева һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр, 2012. 175 б.

Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек / төз.-авторы С.Ф. Гарифуллин. Казан: ХӘТЕР, 2010. 296 б.

Татарча-төрекчә сүзлек / төз. Ф. Ганиев, Р. Әхмәтьянов, Х. Ачыкгөз; фәнни мөх. Х. Ачыкгөз, А. Рәхимова. Казан—Мәскәү: Инсан, 1997. 496 с.

Термины информатики и информационных технологий: англо-татарско-русский толковый словарь / Д.Ш. Сулейманов, А.Ф. Галимьянов, М.Х. Валеев. Казань: Магариф, 2006. 384 с.

Толковый словарь русского языка: в 4 т. / под ред. Д.Н. Ушакова. М.: Сов. энцикл.: ОГИЗ, 1935 —1940.

Төрекчә-татарча сүзлек / төз. Р. Әхмәтьянов, Р. Мөхәммәтдинов, Ф. Нуриева һ.б. М.: Инсан, 1998. 560 б.

Электронный татарско-русский и русско-татарский словарь. URL: http://tatar.com.ru/e-slovar.php (дата обращения: 28.02.2014).

***Тимерханов Айнур Әхәт улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге җитәкчесе*

УДК 811.512.145

*Д.Б. Рамазанова*

## ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ

В статье прослеживается развитие татарской диалектологической науки за 75 лет существования ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова; зарождение и становление таких направлений диалектологии, как диалектная лексикография, региональная лексикология, лингвогеография, ареалогия и др., усовершенствование методов изучения говоров начиная со способа анкетирования до проведения комплексных экспедиций.

**Ключевые слова:** татарская диалектологическая наука, диалектологические экспедиции, визуальные наблюдения подготовленными специалистами, сбор материала, объективный подход при анализе и интерпретации, лингвистический атлас.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты төзелүенең башлангыч чорыннан ук диалектология фәне төп юнәлешләрнең берсе булып китә. Моның, нигездә, ике сәбәбе бар.

Фәндә билгеле булганча, татар диалектларына игътибар XVIII гасырда ук туа. Татар теленең җирле сөйләшләреннән материаллар Г.Ф. Миллер, П.С. Паллас, И.И. Лепехин, С. Хәлфин, И. Гиганов, Н.Б. Атнометов, О. Бётлинк, И.И. Золотницкий, В.А. Казаринов, Е.А. Малов, Н.Ф. Катанов, Г. Әхмәров, С.Е. Малов, Х. Паасонен, Р. Пелисьер, Л.З. Будагов, В.В. Радлов, Дамаскин кебек күренекле шәхесләрнең, галимнәр һәм ориенталистларның хез-мәтләрендә урын алалар, XVIII—XX гасыр башларында төзелгән икетелле сүзлекләрдә [Юсупова, 2008] чагылыш табалар. Шуны искәртү кирәк: әлеге мәкаләдә телгә алынган авторларның, хезмәтләрнең исемнәрен бүгенге көнгә шактый тулы итеп төзелгән «Татар диалектологиясе буенча библиография»дән карарга мөмкин [Татар..., 2009, б. 813—839].

Татар диалектологиясен фән буларак башлап җибәрүчеләрдән берсе А.Г. Бессонов була. Ул Урал төбәгендә халык арасында эшләгән чакта андагы сөйләшләр буенча материаллар туплаган һәм шуларны файдаланып «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» дигән хезмәтен чыгара [Бессонов, 1881]. Л. Җәләй һәм Л.Т. Мәхмүтова А.Г. Бессоновны, татар диалектологиясенә нигез салучы, дип атыйлар. Бу хезмәттә А.Г. Бессонов Урал төбәге татар сөйләшләрен беренче мәртәбә хәзерге урта һәм көнбатыш диалект сөйләшләре белән чагыштырма планда анализлый, аларны төркемли, татар теленә бик якын икәнлеген ассызыклап күрсәтә. Авторның фикерләре алга таба уздырылган тикшеренүләр белән расландылар.

Октябрь вакыйгаларыннан соң татар диалектларын фәнни өйрәнү югарырак баскычка күтәрелә, бу чорда Ж. Вәлиди һәм Л. Җәләйнең эшчәнлеге төп урынны тота, алар татар сөйләшләрен анкета һәм экспедиция уздыру ысуллары белән өйрәнү, сөйләшләрне төркемләү критерийларын билгеләү тәҗрибәсен уздыралар.

Икенчедән, Тел, әдәбият һәм тарих институты оешкач, диалектология фәненең төп юнәлешләрнең берсе буларак кабул ителүенә институтта инде байтак тәҗрибә туплаган Л. Җәләйнең эшләве дә төп этәргеч була.

Тел, әдәбият һәм тарих институты үзенең эшчәнлеген Мәскәүдәге Тел белеме институты җитәкчелегендә алып бара. Бу бергәлек, институтларның исеме үзгәреп торса да, хәзергә кадәр дәвам итә, дияргә мөмкин.

Диалектология юнәлеше исә СССР Фәннәр академиясенең барлык бүлекләрендә һәм, Казан филиалында гына түгел, барлык башка филиалларында да эшләп килде. Шушы ук традиция хәзер дә дәвам итә. Мәсәлән, Чувашстандагы пединститутта Чуваш диалектологиясе лабораториясе, Удмурт дәүләт университетында Лингвистик карталар төзү лабораториясе, Россия Фәннәр академиясендә диалектология һәм лингвистик география бүлеге эшләп килә; Идел буе социаль-гуманитар дәүләт академиясендә Самара төбәге сөйләшләренең лексик атласы төзелеп ята. Якутларның (2 томда), башкортларның (1 томда), удмуртларның (3 томда) диалектологик атласлары басылып чыкты. Күргәнебезчә, диалектология өлкәсендә актив эшчәнлек дәвам итә, юнәлешләр дә арта бара. Хәзерге көндә чуваш сөйләшләре атласын төзү эше бара. Европа илләрендә лингвистик атласлар төзү XIX гасырда башлана, 1930 елларга Европа илләренең күбесендә атласлар инде төзелеп беткән һәм басылып чыккан. Гомумән, лингвистик атласлар төзү һәм чыгару цивилизацияле илләрдә абруйлы проект буларак карала, халыкның югары мәдәниятлелеге билгесе булып санала. Казан университетының конференцияләр залында «Информацион технологияләр һәм лингвистик тикшеренүләр» дигән темага уздырылган конференциягә илебезнең төрле почмакларыннан галимнәр җыелган иде. Татар сөйләшләре атласының электрон версиясен югары бәяләп чыгыш ясаучы затлар арасында Мәскәү, Санкт-Петербург галимнәре генә түгел, Балкан дәүләтләре һәм башка илләрдән дә вәкилләр булды.

40 нчы елларда татар сөйләшләрен өйрәнү тагын да җанлана төшә. Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер — сәнгать) институты тарафыннан сугыш алды елларында ук Себер якларына экспедицияләр уздырыла. Бу экспедиция материалларын С. Әмиров (1941) эшкәртеп, гомумиләштереп «Көнбатыш Себердәге татарларның сөйләш үзенчәлекләре (бараба, тары, тевриз һәм тобол татарлары буенча)» дигән хезмәтен яза. Кызганыч, ул кулъязма хәлендә кала, автор сугышта һәлак була.

Бу елларда татар диалектологиясе өлкәсендә Л. Җәләй зур эшчәнлек алып бара. Галимнең башлангыч чор хезмәтләрендә дә мишәр диалектына хас үзенчәлекләр (аеруча морфологик) шактый күрсәтелә: нәтиҗәле үткән заманның *-ыпмын* формасы, боерык фигыльнең *-гын* кушымчасы (1938). Ул анкеталар таратып җаваплар алу юлы һәм сораулыклар тутыртту алымы белән, экспедицияләр уздырып, татар диалектлары буенча шактый бай материал туплый, аларны фәнни эшкәртә. Л. Җәләй, татар диалектологиясендә беренчеләрдән булып, тел үзенчәлекләрен картага төшереп карый, ягъни лингвистик география методын куллана.

Шушы казанышлар Л. Җәләйнең «Татар диалектологиясе» [Җәләй, 1947] дигән дәреслек-китабында чагылыш таба. Бу хезмәттә Татарстанда гына түгел, аннан читтәге өлкәләрдә һәм республикаларда (Рязань, Мордовия, Пермь, Түбән Новгород, Башкортстан, Себер) таралган сөйләшләр буенча да мәгълүматлар китерелә, татар диалектларын төркемләү шактый ачыклана. Л. Җәләй аларны, территориаль-лингвистик принципка нигезләнеп, көнбатыш, урта һәм көнчыгыш диалектларга аера. Җ. Вәлиди тарафыннан себер диалектлары белән берлектә урал-уфа диалекты составында каралган Урал алды сөйләшләренең (минзәлә, пермь һ.б.) урыны Л. Җәләй классификациясендә дөрес билгеләнә һәм алар урта диалектка кертеләләр. Л. Җәләй төркемләве нигезле, чынбарлыкка туры килә торган классификация булды һәм ул бүген дә яшәештә.

Бик күп сөйләшләр (аеруча урта диалект сөйләшләре) индивидуаль-монографик ысул белән тикшерелә. Өйрәнү географиясе киңәя: Пермь крае, Рязань, Киров өлкәләре, Удмуртия, Мари Эл, Башкортстан республикалары; Түбән Новгород өлкәсендәге һәм Татарстандагы мишәр сөйләшләре, Себердәге татар сөйләшләре индивидуаль-монографик планда өйрәнелә башлый. Татар диалектологлары Л.Җ.Җәләй (1947), Н.Б.Борһанова (1953; 1955; 1962 һ.б.), Г.К.Якупова (1953; 1960; 1961; 1962) белән бергә бу эштә Мәскәү, Петербург, Казан югары уку йортларындагы аспирантлар да катнаша. Нәтиҗәдә, күп кенә диссертацияләр әзерләнеп яклана: Д.М.Сарманаева (1949), А.А.Юлдашев (1952), Р.Ф.Шакирова (1950), Л.Т.Мәхмүтова (1952), Н.Б.Борһанова (1953), Д.Г.Тумашева (1952) һ.б. Шушы ук төркемгә бераз соңрак якланган кандидатлык диссертацияләрен дә өстәргә кирәк: Ә.Ш.Әфләтунов (1961), Р.Р.Мингулова (1963), С.М.Исхакова (1970) һ.б. Л.Җ.Җәләй татар теленең урта диалектына багышланган монография яза һәм аның нигезендә, татар тел белемендә беренчеләрдән булып, докторлык диссертациясе яклый (1954). Соңга таба диалектларны өйрәнүдә ирешкән казанышларны гомумиләштереп, Себер татарлары диалектлары буенча Г.Х.Әхәтов (1965), Д.Г.Тумашева (1969) тарафыннан докторлык диссертацияләре яклана.

50 нче елларга кадәр Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар диалектологиясе тармагы, нигездә, бер юнәлештә бара: урыннарга экспедицияләр оештырып, сөйләшләрне индивидуаль-монографик ысул белән тасвирлау. 50 нче еллар азагында экспедицияләр дәвамында туплана килгән диалекталь сүзләрне эшкәртү, сүзлекләр төзеп аларны фәнни әйләнешкә кертү өчен зур эшләр башкарыла, диалектологик сүзлекләр дөнья күрә [1948; 1953; 1958]. Шулай итеп, диалектология фәненең әһәмиятле юнәлеше — диалекталь лексикография үсеш ала башлый [Рамазанова, 2002, б. 101—106].

Бу елларда татар диалектологиясенең тагын бер әһәмиятле юнәлеше көн тәртибенә куела. Татар диалектларының төрле юнәлешләрдә үсеш-үзгәреш алуы, диалектлар буенча тупланган бай мәгълүматлар, бастырып чыгарылган монографияләр, җыентыклар һәм күп санлы мәкаләләр — Л.Җәләйнең докторлык диссертациясендә лингвистик география методы белән ясалган беренче адымнар татар диалектологларына югарырак максатлар куярга, катлаулырак проблемалар күтәреп чыгарга мөмкинлек бирде, татар сөйләшләрен лингвогеографик аспектта өйрәнә башларга нигез булды. Кайбер монографияләр аспирантлар тарафыннан, диссертация буларак әзерләнеп, уңышлы якланганнар иде: Л.Ш. Арсланов (1966), Д.Б. Рамазанова (1970), Ф.С. Баязитова (1972), Ф.Й. Йосыпов (1972), Р.С.Барсукова (2004), Т.Х. Хәйретдинова (1980), З.Р. Садыйкова (1986). Шулай итеп, татар диалектларын өйрәнү буенча аеруча әһәмиятле булган бурычларны башкару белән бергә, кадрлар әзерләү мәсьәләсе дә хәл ителде, Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Г.К. Якупова кебек татар диалектологиясенең әзерлекле, бай тәҗрибәле галимнәре — укытучыларыбыз сафына бертөркем яшь хезмәткәрләр дә кушылды.

1959—1985 еллар татар диалектологиясе үсеш-үзгәрешенең иң уңышлы чоры. Бу этапта Идел—Урал регионы татар сөйләшләренең Атласын төзү һәм аны матбугатка әзерләү көнүзәк мәсьәлә булып тора. Татар сөйләшләрен лингвогеографик һәм монографик планда өйрәнү, карталар төзү, кадрлар әзерләү кебек катлаулы

һәм күп көч сорый торган мәсьәләләр хәл ителә.

Идел — Урал регионындагы татар сөйләшләренең Диалектологик атласын булдыру максатыннан чыгып, татарлар яши торган барлык өлкәләргә экспедицияләр оештырырга, меңләп (Атласның I—II томнарында 845 авыл чагылган) авылның сөйләшен әзерлекле белгечләр тарафыннан тикшереп чыгарга кирәк була. Өйрәнү «Татар теле диалектологик атласын төзү өчен материал җыйнау программасы» [Казан, 1959] нигезендә башкарыла. Әйтергә кирәк, бу чорда материалны туплауда анкета һәм индивидуаль өйрәнү методлары кулланылмый. Татар сөйләшләрен лингвистик география методы белән өйрәнү — гаять зур масштабтагы эш. Атласны төзүчеләрдән тыш, материал җыюда Л.Ш. Арсланов, Р.Р. Шәмгунова, Ф.Й. Йосыпов, Г.К. Якупова, И.Б. Бәширова, С.Б. Вахитова, З.Ә. Исхакова, Р.Р. Абдуллина һәм Р. Фарисовалар да катнашты.

Татарлар гаять зур территориядә (Рязань — Кемерово — Киров — Әстерхан) яшәгәнгә күрә, карталар төзүне практик җиңеләйтү өчен, Атласны өч томга (биредә географик киңлек күздә тотыла) бүләргә туры килде (I том: Рязань — Вятка; II том: Вятка — Урал аръягы; III том: Көнбатыш Себер). Координацион план нигезендә I—II томнарны Тел, әдәбият һәм тарих институты, III томны Казан дәүләт университеты төзи, дип килешенгән була.

Атлас төзү барышында диалектологлар тарафыннан гаять зур һәм әһәмиятле эшләр башкарылды. Атлас 1985 елда тәмамланды һәм матбугатка тәкъдим ителде. Институт директоры М.З. Зәкиев һәм Ш.Н. Асылгәрәевләрнең зур тырышлыгы белән ул 1989 елда 2 томда «Татар теленең Урта Идел һәм Урал төбәге сөйләшләре атласы» исеме астында басылып чыкты. Аның фәнни җитәкчеләре һәм мөхәррирләре Н.Б. Борһанова белән Л.Т. Мәхмүтова булды. Төзүчеләр: Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова (I том), Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдинова (II том).

Татар диалектлары буенча гаять бай материал тупланды, бик күп диалекталь күренешләр табылды, чагыштырмача аз өйрәнелгән сөйләшләр махсус тикшерелде, яңа сөйләшләр ачылды, аларның формалашу тарихын ачыклаганда, күп санлы архив документлары барланды һәм фәнгә кертелде, гаять күп сөйләү үрнәкләре, легендалар, йолалар, риваятьләр, авыл, халык тарихларын чагылдырган текстлар, халык авыз иҗаты әсәрләре (бер өлеше магнитофон тасмасына) язып алынды. Тупланган текстларда тел үзенчәлекләре генә түгел, бәлки татар халкының рухи һәм матди мәдәнияте буенча да чиксез бай мәгълүмат чагыла. Алдагы этапларда туган яңа юнәлешләр интенсив рәвештә һәм югары дәрәҗәдә үстерелә.

1969 елда татар теленең диалектологик сүзлеге чыга. Ул 1958 — 67 елларда урта һәм мишәр диалектларына караган сөйләшләрдән тупланган диалекталь сүзләр һәм сүзтезмәләрне эченә ала, анда шулай ук 1948, 1953 1958 елларда чыккан диалектологик сүзлекләрдәге материаллар да, әлбәттә, тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, исәпкә алына.

Элек чыгарылган сүзлекләрдән аермалы буларак, яңа сүзлектә диалекталь сүзләрнең мәгънәләре һәм татар, һәм рус телләрендә аңлатыла, иллюстратив материал буларак, күп санлы мисаллар китерелә, сөйләшләрдәге үсемлек атамалары аерым сүзлекчә итеп (Н. Борһанова) бирелә, азакта татар сөйләшләре турында кыскача белешмәлек урнаштырыла. Мондый ике телле диалектологик сүзлек фән дөньясында зур яңалык була. Татар тел белемендә генә түгел,

гомумтюркологиядә дә бу сүзлекнең принципларына (Л. Мәхмүтова) югары бәя бирелә, аны, яңа типтагы диалектологик сүзлек, дип атыйлар.

1993 елда бу зур сүзлекнең дәвамы — 2 нче китабы дөнья күрә. Ул да шул ук принциплар нигезендә төзелә. Анда төп урынны татар теленең Урал тирәсендәге сөйләшләре буенча тупланган диалекталь сүзләр һәм сүзтезмәләр алып тора, азакта китерелгән татар сөйләшләре турындагы белешмәлек (Д.Б. Рамазанова) тә өстәмә материаллар, өстәмә күзәтүләр рәвешендә төзелә; татар диалектологиясе буенча библиография (Л.Т. Мәхмүтова) урнаштырыла.

Атлас өчен материал җыю турында сүз барганда, тагын бер әһәмиятле мәсьәләне истә тотарга кирәк. Диалектологлар бай һәм уникаль тел фактларын туплап, фәнгә кертеп калдырырга өлгерделәр. Чөнки аеруча соңгы еллардагы иҗтимагый-сәяси үсеш-үзгәрешләр, интенсив урбанизация, әдәби телнең, башка телләрнең көчле тәэсире татар халкының уникаль рухи мирасы булган сөйләшләрдәге үзенчәлекләрнең, борынгы күренешләрнең, тарихи формаларның юкка чыга баруына китерде.

Материал җыю белән беррәттән, аны фонетик, морфологик һәм шулай ук, лексик, синтаксик яктан фәнни эшкәртү буенча да җитди эш алып барылды. Татар сөйләшләренең зур күпчелеге тасвирланды, аларның формалашу тарихлары ачыкланды. Шунысы әһәмиятле, тел материалларын эшкәрткәндә комплекслы якын килү ысулына аеруча зур игътибар ителде, ягъни, тел күренешләрен аңлатканда, сөйләш вәкилләренең тарихы, этнографиясе буенча мәгълүматлар һәм махсус тупланган архив материалары да файдаланылды.

Тупланган һәм шулай төрле яклап ачыкланган, эшкәртелгән гаять зур материалны, нәтиҗәләрне, ачышларны фәнгә кертеп җибәрү — диалектологлар эшчәнлегенең тагын бер бик әһәмиятле юнәлеше булды: «Татар диалектологиясе буенча материаллар»ның — 9, татар теленең тарихи диалектологиясе буенча тикшеренүләрнең — 3, диалектологик сүзлекнең 2 чыгарылышы нәшер ителде. Л.Т. Мәхмүтованың (1978); Ф.Й. Йосыповның (1979, 1985, 1986, 2003, 2006); Л.Ш. Арслановның (1982); Ф.С. Баязитованың (1986, 1992, 1997, 2001, 2002, 2003, 2006, 2007, 2010, 2011, 2012, 2013); З.А. Мухаеваның (2005, 2011); А.Р. Рәхимованың (2001); Д.З. Мәхмүтшинаның (2002); Р.С. Барсукованың (2004); Г.М. Сөнгатовның (1991); Т.Х. Хәйретдинованың (1980, 1985, 1993, 2000, 2004); Д.Б. Рамазанованың (1984, 1996, 1997, 2001, 2002, 2007, 2011, 2012, 2013, 2014); З.Р. Садыйкованың (1985, 1986, 1994, 2003); Х.Ч. Алишинаның (1992, 1994, 1999); Д.Г. Тумашеваның (1961, 1968, 1969, 1977) монографияләре дөнья күрде, тематик җыентыкларда, журналларда күп санлы фәнни мәкаләләр басылып чыкты.

70 нче елларда Л.Ш. Арсланов тарафыннан Әстерхан һәм Волгоград өлкәләрендә таралган татар сөйләшләре өйрәнелә, аларның атласы төзелә, монографияләр чыгарыла (1983; 1995; 2009 һ.б.), докторлык диссертациясе яклана [Арсланов, 1982].

Диалектологик атласны төзү барышында тупланган бай фактик материал фәнни-теоретик яктан тирәнәйтелгән, гомумиләштерүләргә нигезләнгән хезмәтләр иҗат итәргә ышанычлы база булды. Мәсәлән, аерым темаларны эшләү, системалы һәм синхрон алым белән, диахроник күзәтүләрне дә кертеп, чагыштырма-тарихи интерпретацияләү юнәлешендә җитди хезмәтләр әзерләнде һәм шулар нигезендә бертөркем докторлык диссертацияләре яклaнды: Л.Ш. Арсланов (1982), Ф.Й. Йосыпов (1988),

Д.Б. Рамазанова (1998), Ф.С. Баязитова (1998).

Ике томлык «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы»н һәм аңа «Комментарийлар»ны (1989) төзү һәм чыгару барышында гаять зур эшләр татар диалектологиясе фәнен яңадан бер баскычка югары күтәрделәр, ул гомумтюркологик масштабта да күренекле урын алды. Атлас — татар диалектологиясе фәненең зур казанышы. Ул татар сөйләшләрен объектив һәм фәнни нигездә төркемләргә, сөйләшләрнең таралышын, чикләрен билгеләргә, тел тарихы күзлегеннән караганда, бик әһәмиятле булган күп кенә тел күренешләренең ареалын ачыкларга, күпчелек сөйләшләрнең һәм шул сөйләш вәкилләренең формалашу тарихын ачарга, татар халкының Идел—Урал ареалындагы тугандаш һәм башка халыклар белән күп гасырлар буе килгән бәйләнешләренең асылын һәм нәтиҗәләрен күзалларга ярдәм итә.

Планлы чагыштырулар һәм комплекслы өйрәнү, лингвистик география методын файдалану татар сөйләшләренең барлыкка килүен, нинди үсеш-үзгәреш кичерүләрен, шулар аша татар халкы этногенезының кайбер мәсьәләләрен ачыкларга мөмкинлекләр тудырды. Атласның чикләре татар халкының тарихи Ватанын чагылдыра. Татарстаннан читтәге яңа ачылган сөйләшләрнең формалашуында төп рольне уйнаган лингвистик һәм экстралингвистик факторлар билгеләнде. Урал тирәсендәге сөйләшләрнең нигезендә казан арты сөйләшләре белән борынгыдан ук килә торган уртаклык ятканы ачыкланды, аларның якынлыгы турында революциягә кадәр үк әйтелгән фикерләр нигезле фактлар, архив документлары белән тагын бер кабат расланды.

Шушы ук чорда себер диалектларын махсус фәнни өйрәнү буенча да җитди эш башкарыла. Бу диалектлар аеруча Д.Г. Тумашева тарафыннан җентекле тикшерелгән. Ул, күп санлы экспедицияләр уздырып, әлеге җирле сөйләшләрнең байлыкларын шактый бөтен хәлдә саклап, гаять бай материал туплауга ирешә; себер диалектларының формалашу тарихын, үзенчәлекләр системасын фәнни-нәзари яктан югары дәрәҗәдә анализлый, аларның әдәби телгә мөнәсәбәттәге составын, төрки телләр системасында тоткан урынын билгеле. Себер татарлары сөйләм теленең тубыл-иртыш, бараба, том диалектларына бүленүен, татар диалектлары системасындагы урынын, бай фактик материалга таянып, дәлилле исбат итә (1961, 1968, 1977, 1992).

Соңга таба себер татарлары диалектлары белән бәйле аерым мәсьәләләр Г.М. Сөнгатов, Х.Ч. Алишина, А.Р. Рәхимова, А.Х. Насыйбуллина, Р.С. Барсукова тарафыннан өйрәнелде, аларның монографияләре һәм сүзлекләре дөнья күрде. Татар диалектологлары Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова Т.Х. Хәйретдиновалар да Себер якларына күп санлы экспедицияләр уздырдылар һәм төрле юнәлештә фәнни тикшеренүләр алып бардылар.

Атлас өчен материал туплау һәм ул материалларны фәнгә кертү татар диалектологиясе фәнендә тагын бер әһәмиятле юнәлешнең көчәюенә, конкрет формалашып җитүенә китерде, диалекталь лексикология (фәндә аны региональ лексикология дип тә атыйлар) дигән әһәмиятле юнәлеш тупланган диалекталь лексиканы төрле (чагыштырма, тасвирый, тарихи, этимологик, стратиграфик һ.б.) аспектларда тикшерүне үстереп җибәрде. Бу өлкәдә эшләгән кайбер галимнәрне атап үтик: Х.Ч. Алишина (1990, 1991); Л.Ш. Арсланов, (1976, 1978, 2001); Р.С. Барсукова (2000, 2002, 2004); Ф.С. Баязитова (1985, 1988, 1993,

1995, 2001, 2006, 2010); М.Р. Булатова (2012); Н.Б. Борһанова (1955, 1973, 1985); С.М. Исхакова (1983); Ф.Й. Йосыпов (1982, 1985, 2004, 2011 һ.б.); А.Г. Казыйханова (2006); Л.Т. Мәхмутова (1974, 1979, 1987); Д.З. Мәхмүтшина (2001); Г.Ф. Мөхәммәтова (2006); А.Х. Насибуллина (1998, 1999); И.С. Насипов (1992, 1998); Д.Б. Рамазанова (1979, 1984, 1985, 1987, 1988, 1990 1991, 1993, 1999, 2002, 2004, 2008, 2010 һ.б.); А.Р. Рәхимова (1995); З.Р. Садыйкова (1989 һ.б.); Д.Г. Тумашева (1972, 1973 һ.б.); Т.Х. Хәйретдинова (1976, 1979, 1985, 1989, 1998, 2004, 2007 һ.б.); И.Р. Һидиятов (2003, 2004 һ.б.).

Бу юнәлешнең кайбер үрнәкләре 60—70 нче елларда ук башлана. Аның буенча Л.Т. Мәхмүтова (1955; 1957; 1958; 1962; 1974 һ.б.), Н.Б. Борһанова (1953; 1955; 1962; 1967 һ.б.), Ф.Й. Йосыпов (1969 һ.б.) Д.Б. Рамазанова (1969; 1970 һ.б.), Ф.С. Баязитова (1972; 1977 һ.б.), Л.Ш. Арсланов (1965 һ.б.), Г.К. Якупова (1955; 1960—1962 һ.б.), Д.Г. Тумашева (1960, 1968, 1969 һ.б.), Т.Х. Хәйретдинова (1971, 1972 һ.б.), бик актив эшлиләр. Лексикологиягә багышланган күпсанлы махсус җыентыклар дөнья күрделәр: «Вопросы тюркологии» (1970); «Исследования по татарскому языкознанию» (1984); «Нормативность и вариативность в татарском языке» (1987); «Проблемы лексикологии и терминологии в татарском языке» (1993); «Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка» (1976); «Источниковедение и история тюркских языков» (1976); «Исследования по диалектологии и истории татарского языка» (1982) һ.б.

Институт диалектологлары татар сөйләшләрен монографик планда да өйрәнүләрне дәвам иттеләр. Монографияләрнең кайберләре диссертация итеп әзерләнделәр һәм уңышлы яклandылар. Алар арасында яшь буын аспирантлар да, үзлегеннән эшләүчеләр дә бар иде: Р.С. Барсукова (2002), Г.Ф. Мөхәммәтова (2007), А.Г. Казыйханова (2011), М.Р. Булатова (2012), Г.Х. Хәйбуллина (2013). Шул рәвешле, татар диалектологиясенең аеруча әһәмиятле фәнни бурычларын хәл итү белән бергә, яшь буын диалектологлар әзерләү мәсьәләләре дә хәл ителеп килә.

Бу этапта язылган хезмәтләрдә дә сөйләшләрне чагыштырып өйрәнү традицияләре дәвам иттерелде генә түгел, шактый күпкә баетылды: әдәби тел, башка сөйләшләр яки төрки телләр, борынгы язма истәлекләр белән системалы рәвештә чагыштыруга һәм шул юл белән теге яки бу үзенчәлекләрнең килеп чыгу тарихын ачыклау буенча да байтак эшләр башкарылды, күп хезмәтләр язылды.

Чагыштырма-тарихи ысулны куллану, тарихи фактларны, архив чыганакларын файдалану, лингвистик география ысулына таяну нәтиҗәсендә күп кенә татар сөйләшләренең, аеруча соңгырак чорларда, күчеп утырулар белән бәйле рәвештә барлыкка килгәннәренең формалашу тарихларын ачыкларга мөмкин булды. Аларның татар әдәби теленә бик якын икәнлеге (әйтик, Урал төбәге татар сөйләшләренең Идел буе татар теле белән тыгыз бәйләнгән булуы) раслана килде. Бу мәсьәләләр Д.Б. Рамазанованың 1978—2010 елларда басылып килгән мәкаләләрендә һәм монографияләрендә (1984, 1996, 2001 һ.б.), Ф.С. Баязитованың (1982, 1989, 1995, 2000), Т.Х. Хәйретдинованың (1979, 1980, 1985), Ф.Й. Йосыповның (1972, 1979, 2003), З.Р. Садыйкованың (1985) хезмәтләрендә аеруча актив һәм дәлилле итеп, тирәнтен тикшерелделәр.

Шушы ук чорда татар диалектологиясендә тагын бер юнәлеш көчәеп китте. Бу — татар диалектларыннан тарихи-этнографик характердагы сөйләм үрнәкләре туплау, халык авыз иҗаты һәм музыкаль фольклор

әсәрләрен язып алу. Мондый материаллар «Татар диалектологиясеннән материаллар» дигән, инде 10 чыгарылышка җиткән китапларда (1962 елдан бирле), аерым авторлар хезмәтләрендә (Ф.С. Баязитова, 1995, 1997, 2001—2003, 2006, 2007, 2010 һ.б.; Д.Б. Рамазанова 1997, 2002, 2001, 2011, 2013 һ.б.) һәм башка басмаларда басылып чыкты. Шуның белән бергә, әлеге язмаларның зур өлеше кулъязма хәлендә кала килә.

80 нче елларның урталарыннан төп эшчәнлек диалекталь лексиканы өйрәнү, төрле лексик-семантик төркемнәрнең фонетик-грамматик һәм семантик үсеш-үзгәрешен синхроник һәм диахроник, ареаль һәм генетик аспектларда тикшерүгә юнәлтелде. Бу исә, татар теленең тарихи лексикологиясе, тарихи диалектологиясе мәсьәләләрен тагын да үстерү, дигән сүз. Туганлык атамалары, кием-салым, кешегә бәйләнешле лексика, йолалар, аш-су, көнкүреш, үсемлекләр дөньясы, хайваннар дөньясы, йорт кирәк-яраклары, хуҗалык һәм инвентарь белән бәйле лексик-семантик төркемнәр турында хезмәтләр дөнья күрде.

Диалекталь лексикология юнәлешенең аерым мисаллары А.Г. Бессонов (1881), Г. Әхмәров (1907) Л. Җәләй (1954) һ.б. хезмәтләрдә чагылыш тапкан. Диалекталь лексикология диалектизмнарның матур әдәбият телендә (Л.Т. Мәхмүтова, 1969), иске татар язма истәлекләрдә (Д.Б. Рамазанова, 2004) чагылышы, татар сөйләшләрендә алынма сүзләр (Н.Б. Борһанова, 1967; Л.Т. Мәхмүтова, 1976; Л.Ш. Арсланов, 1985; Д.Б. Рамазанова, 1990, 1991; 1999; 2000; 2007 һ.б.), диалектлар һәм борынгы язма истәлекләр (Н.Б. Борһанова, 1969; И.А. Абдуллин, 1974; Л.Т. Мәхмүтова, 1982, 1985; Д.Б. Рамазанова, 1988, 1992; Р.С. Барсукова, 2004) диалектлар һәм фольклор (Л.Ш. Арсланов, 1991; Ф.С. Баязитова, 1992, 2006 һ.б.; Д.Б. Рамазанова, 2003, 2014), рухи мәдәният элементларының чагылышы буларак диалекталь лексика (Ф.С. Баязитова бу өлкәдә зур эшчәнлек алып бара, 20 гә якын сүзлек-китаплар чыгарды) һ.б. юнәлешләрдә үсеп килә.

Диалекталь лексикология мәсьәләләре аерым лексик-семантик төркемнәрне өйрәнү белән үзара нык бәйләнгән һәм бу ике тармак татар диалектологиясендә еш кына бергә бәйләп үстерелә. Туган тел һәм аның язмышы белән бәйле рәвештә сүзлек составы, сүз ясау, татарча терминологияне камилләштерү кирәк булганга күрә, диалекталь лексиканы системага салу ихтыяҗы туа. Нәтиҗәдә, «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (88,2 басма табак) дөнья күрә һәм шулай итеп татар диалектларының лексик байлыгыннан тагын зур бер өлеш фәнни әйләнешкә кертелә.

XX гасыр азагы — XXI гасыр башы тагын бер зур эш башкарылу белән әһәмиятле. 1990 еллар азагында М.З. Зәкиев һәм Д.Б. Рамазанова җитәкчелегендә татар халык сөйләшләре атласының III томын төзү башлана. Ул ике төбәкне эченә ала: Түбән Идел буе һәм Себер. Авылларны барлау, нигез-картаны төзү, материал җыйнау буенча Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова, Р.С. Барсукова күп көч куйдылар.

Себер ареалы татар диалектларын лингвографик һәм лексикологик максатларда өйрәнү башланды, 60 тан артык экспедиция уздырып, урыннарда бай фактик материал тупланды, себер татарларының рухи һәм матди мәдәниятен [Тумашева, 2002; Баязитова, 2001; Рамазанова, 1997; 2000; 2001; 2013], телен (Рамазанова, 2007; Насыйбуллина, 2001; Рәхимова, 2001; Барсукова, 2004) тикшерүгә багышланган монографияләр һәм

төрле башка китаплар басылып чыкты. Д.Б. Рамазанова «Татар теленең көнчыгыш диалектлары» дигән хезмәтен 36 экспедиция вакытында халык авызыннан үзе язып алган материаллар нигезендә яза һәм Д.Г. Тумашеваның Себер татарлары теленең 3 диалектка бүленү турындагы нәтиҗәләренең хаклы булуын раслый. Шушы ук авторлар һәм Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова тарафыннан язылган күпсанлы мәкаләләр аша да Себер ареалы татар сөйләшләре турында мәгълүматлар фәнгә кертелде, ул ареалда уздырылган төрле конференцияләрдә 30 дан артык фәнни докладлар укылды.

Нәтиҗәдә барлык татар сөйләшләрен эченә алган «Татар халык сөйләшләре атласы» (3 томда) эшләнде. Аның электрон версиясен Интернет челтәрендә карарга мөмкин, ул Ф.И. Сәлимов җитәкчелегендә һәм мөхәррирлегендә, Д.Б. Рамазанова (мөхәррир), Р.С. Барсукова, М.Е. Пилюгин, Р.Ф. Сәлимовлар тарафыннан эшләнде (URL: http://antat.atlas.ru).

Татар тел белемендә генә түгел, гомумтюркологик масштабта да беренче тапкыр «Татар халык сөйләшләре» [Татар..., 2008] исемендә барлык татар сөйләшләренең тасвирламасын эченә алган хезмәт дөнья күрде һәм җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды. Д.Б. Рамазанова тарафыннан бу хезмәткә (ул диалектологиядән дәреслек буларак та тәкъдим ителгән иде) хрестоматия итеп «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре» (2010), 2013 елда «Татар диалектларыннан тезмә текст үрнәкләре» бастырып чыгарылды. Шулай итеп, сөйләшләрдән җыеп-язып алынган диалекталь үзенчәлекләр, уникаль күренешләр бер тупланмага җыелды, халкыбызның тел байлыгын теркәп калдырырга зур мөмкинлек тудырылды.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Халык сөйләшләренең тулы тасвирламасы әлеге күренешнең татар әдәби теленә бик якын торуына тагын бер дәлил булды. Барлык сөйләшләр татар әдәби теле белән чагыштырма планда яктыртылды һәм шуңа күрә әлеге тасвирламаларны 2 китапка сыйдырырга мөмкин булды. «Татар халык сөйләшләре» китабы татар сөйләшләрендә табыла торган, ләкин теге яки бу сәбәпләр белән әдәби тел грамматикаларына керми калган күренешләр җыелмасы.

Соңгы еллардагы юнәлешләрнең берсе — тупланган бай фактларга нигезләнеп, ирешелгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, ягъни татар диалектологиясенең бөтен казанышын базис итеп, яңа, гомумиләштерү рәвешендәге тикшеренүләргә керешү.

Хәзерге көндә, Атлас материалларына таянып, татар диалектларын географик аспектта өйрәнүне тирәнәйтергә, ареалогия дигән тармакны үстереп җибәрергә мөмкинлекләр бар. Аның башлангыч тәҗрибәләре дә башкарылды. Л.Т. Мәхмүтова үзенең «Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка» [Махмутова, 1978, с. 261] дигән хезмәтендә татар сөйләшләренең көнбатыш зонасын ачты. Бу зонага кергән мишәр һәм урта диалект сөйләшләрендә нугай теле йогынтысында аларның үзләренә генә уртак булган күренешләр барлыкка килгән. Д.Б. Рамазанованың «Историко-лингвистический анализ формирования и функционирования западноприуральского ареала татарского языка» дигән хезмәтендә [Рамазанова, 1998] исә татар диалект теленең Урал алды ареалы тасвирлана. Бу ареалдагы урта һәм мишәр диалектлары сөйләшләре башкорт теле йогынтысына дучар булганнар. Нәтиҗәдә, алар бер төркем уртак диалекталь үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр һәм шул ук вакытта татар теленең башка төбәкләрдәге сөйләшләреннән берникадәр аеры-

лалар. Соңгы елларда бу юнәлештә башка хезмәтләр дә башкарылды. Д.З. Мәхмүтшина тарафыннан «Урал арты ареалы татар сөйләшләренең морфологик системасы» (2004), М.Р. Саттарова (Хәбибуллина) тарафыннан «*а* авазы һәм аның фонетик вариантларының таралыш ареаллары», М.Р. Булатова тарафыннан «Көньяк Башкортстан ареалындагы татар сөйләшләренең морфологиясе» (2013) дигән хезмәтләр ареалогик пландагы тикшеренүләрне баеттылар.

Сөйләшләр алар җанлы сөйләм теле, анда һәрвакыт үсеш-үзгәреш бара, яңа күренешләр, яңа сүзләр туа, аларны өйрәнү ысуллары да үзгәреп тора. Мәгълүматлар арта барган саен яңача караш белән аңлату да кирәк була.

Татар сөйләшләрен өйрәнү методологиясе дә бер урында гына тормый, тормыш яңа таләпләр куя, халкыбыз тарихын, күп гасырлар буе сакланып килгән милли традицияләрен һәм үзенчәлекле рухи мәдәниятен тирәнрәк аңлау/аңлату өчен төрле яңа ысуллар табыла. Институтыбыз директоры К.М. Миңнуллин инициативасы белән көн тәртибенә куелган яңа алымнарның берсе — Институтта төрле төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыру. Аларда, диалектологлардан тыш, фольклорчылар, археографлар, сәнгать һәм музыка белгечләре дә катнаша. Шул рәвешле, әлеге төбәк берьюлы төрле яклап өйрәнелә, бербөтен мәдәни сыйфатлау рәвешендә фәнгә кертелә, халыкка җиткерелә. Диалектологлар катнашлыгында шундый экспедицияләр Татарстанның Актаныш, Апас, Кукмара, Чүпрәле, Мамадыш районнарына, Пермь краена, Түбән Новгород, Курган, Омск, Самара өлкәләренә, Мари Эл, Удмуртия республикаларына оештырылды һәм бай материал тупланып, алардан төзелгән китаплар да дөнья күрә башлады. Киләчәктә дә бу ысул белән сөйләшләрне өйрәнү дәвам итәчәк.

Шунысын күрсәтеп үтәргә кирәк, халык теле — төпсез дәрья, дигән сүзнең хак сүз икәнлегенә һаман инана торабыз, чөнки яңа материаллар да, яңа энҗеләр дә өстәлә тора.

Соңгы елларда гомуми тел белеме өлкәсендә тагын бер яңа юнәлеш туды: ул — теге яки бу телләрдә иҗат ителгән текстларның тулы корпусларын булдыру. Институт диалектологлары (Д.Б. Рамазанова, М.Р. Булатова), Казан (Идел буе) федераль университеты белгечләре белән берлектә, татар диалект теле корпусын төзүдә дә катнашалар.

Татар тел белемендә диалектология фәненең үсеш-алгарышы күренешләрне объектив шәрехләү, чагыштырма-тарихи методка нигезләнеп анализлау, нәтиҗәләрне билгеләгәндә төрле эргәдәш фәннәрдәге фактларны да исәпкә ала белү кебек дөрес методология белән алшартланган иде. Бу киң колачлы эш барышында диалект, сөйләш терминнарына билгеләмә бирү [Җәләй, 1947; Заляй, 1958, с. 36—50 һ.б.], диалект һәм сөйләшләрнең формалашуында эчке һәм тышкы лингвистик факторларның әһәмияте, үзәктәге, периферияләге, аерым чолганыштагы сөйләшләрнең формалашу закончалыклары, телнең билгеле территориаль яссылыкларының формалашуына китерә торган тарихи-лингвистик шартлар һ.б.ш. нәзари (теоретик) мәсьәләләр һәрвакыт үстерелә һәм тиешле югарылыкта хәл ителә килде.

Татар диалектологиясенең казанышлары гомумтюркология үсешенә дә зур өлеш кертте [Бурганова, Махмутова, Рамазанова, 2010, с. 321—384], чит илләрдәге тюркологик үзәкләрдә дә танылды. Безнең хезмәтләргә Германия, Финляндия, Америка, Венгрия, Болгария, Румыния, Төркия һ.б. илләрдә дә ихтыяҗ булуы ачыкланды.

Бүгенге көндә татар диалектологиясе каршында түбәндәге бурычлар тора: диалекталь лексиканы синхроник, диахроник һәм ареаль аспектларда өйрәнүне дәвам итү, диалекталь синтаксис проблемаларын тикшерүне җәелдерү, ареалогик тикшеренүләрне үстерү, диалектологик сүзлек төзүне дәвам итү һ.б. Татар сөйләшләренең тугандаш һәм тугандаш булмаган телләрнең диалектлары белән үзара тәэсир итешү мәсьәләләрен тикшерү, Идел — Урал регионыннан читтәге өлкәләрдә яшәүче татарларның сөйләшләрен өйрәнү фән өчен шулай ук бик әһәмиятле.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар диалектологлары, яуланган казанышлар, уңышлар белән канәгатьләнеп калмыйча, яңа планнар корып, монументаль характердагы хезмәтләр әзерләүгә омтылып иҗат итәләр.

Комплекслы экспедицияләрдә диалектологлар даими катнашып киләләр һәм яңа материал, бай тәҗрибә нигезендә, «Татар халык сөйләшләре атласы»ндагы фактларны да күздә тотып, үзләренең мәкаләләрендә яңадан-яңа фикер-нәтиҗәләрне чагылдыралар.

**Әдәбият**

*Алишина Х.Ч.* Ономастикон сибирских татар: в 2-х частях. Тюмень: Изд-во ТюмГУ, 1999. Ч. I. 240 с; Ч. II. 216 с.

*Арсланов Л.Ш.* Формирование и развитие островных языков и диалектов (на материале тюркских языков и диалектов Волгоградской, Астраханской областей, Ставропольского края и Калмыцкой АССР): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алма-Ата, 1982. 39 с.

Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / науч. ред.: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова. Казань, 1989.

*Ахмаров Г.Н.* Тептяри и их происхождение. Казань, 1907. 27 с.

*Барсукова Р.С.* Заболотный говор тоболо-иртышского диалекта татарского языка в сравнительном освещении: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 23 с.

*Баязитова Ф. С.* Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: Дом печати, 2007. 480 б.

*Баязитова Ф.С.* Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе. Казан, 2002. 300 б.

*Баязитова Ф. С.* Керәшеннәр: тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 б.

*Баязитова Ф.С.* Мишәр диалекты. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе. Саранск, 2003. 280 б.

*Баязитова Ф. С.* Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе. Казан, 2001. 300 б.

*Баязитова Ф.С.* Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 158 б.

*Баязитова Ф.С.* Татарские говоры Нижнего Прикамья: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1973. 29 с.

*Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе, фольклор. Казан, 2002. 432 б.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан: Алма-Лит, 2012. 331 б.

*Баязитова Ф.С., Хайбуллина Г.Х.* Язык и культура: этнолингвистические и этноконфессиональные особенности татарских говоров Западного Закамья Татарстана. Казань, 2013. 400 с.

*Баязитова Ф.С., Мухаметова Г.Ф.* Язык и культура: этнолингвистические исследования по татарским говорам региона юго-восточного Закамья Татарстана (чистопольский, мензелинский, крещено-татарские говоры). Казань: Алма-Лит, 2008. 285 с.

*Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 26 с.

*Бурганова Н. Б.* Нагорный говор татарского языка // Материалы по диалектологии. Казань, 1955. С. 28—69.

*Бурганова Н. Б.* О формировании татарских говоров Заказанья // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1985. С. 3—31.

*Бурганова Н. Б.* Языковые особенности каринских и глазовских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1953. 16 с.

*Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т., Рамазанова Д.Б.* Диалекты татарского языка // Диалекты тюркских языков: очерки. М.: Восточная литература, 2010. С. 321—384.

*Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. Казан, 1947. 136 б.

*Заляй (Залялетдинов) Л.З.* Опорный диалект в формировании татарского языка // Вопросы диалектологии тюркских языков. Баку, 1958. С. 36—50.

Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1976.

*Исхакова С.М., Валеев Ф.Т.* Таджикский компонент в народно-разговорном языке западносибирских татар // Советская тюркология. 1978. № 4. С. 31—39.

*Йосыпов Ф.Й.* Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. Казан, 1979. 184 б.

*Йосыпов Ф.Й.* Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. Казан, 2006. 607 б.

*Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казанском ун-те. Казань, 1884. Т. IV. С. 9—10.

*Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиций 1954—1957 гг.) // МТД. Вып. 2. Казань, 1962. С. 57—85.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М.: Наука, 1978. 271 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнетюркскому памятнику «Codex Cumanicus» по данным лексики (краткий анализ и приложение) // ИИДТЯ. Казань, 1982. Вып. 2. С. 68—153.

*Махмутшина Д.З.* Морфологическая система татарских говоров Уральского ареала: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2002. 19 с.

*Мингулова Р.Р.* Особенности чистопольского говора татарского языка: автореф. дис. … канд. филол.наук. Казань, 1963. 19 с.

*Мухаева З.А.* Топонимия территории распространения пермского говора. Пермь, 2005. 131 с.

*Мухаева З.А.* Топонимия территории пермского говора татарского языка (юга Пермской области): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2003. 21 с.

*Мухаметова Г.Ф.* Этнолингвистические исследования татарских говоров региона юго-восточного Закамья Татарстана: автореф. дис. …канд. филол. наук. Казань, 2007. 23 с.

*Насибуллина А.Х.* Лексика тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (в семантическом и генетическом аспектах): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 22 с.

*Рамазанова Д.Б.* К вопросу о формировании белебеевского подговора мензелинского говора среднего диалекта татарского языка // ИИДТЯ. Казань, 1979. С. 4—43.

*Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. 191 с.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования татарских говоров северозападной Башкирии (по данным архивных и исторических источников) // ИИДТЯ. Вып. 3. Казань, 1985. С. 5—36.

*Рахимова А.Р.* Сибирско-татарские и монгольские лексические параллели (на материале хозяйственно-промысловой лексики) // Интеграция археологических и этнографических исследований: материалы III Всероссийского научного семинара. Омск, 1995. Ч. 2. С. 80—85.

*Рамазанова Д.Б.* Туйлар, туйлар... Казан, 1997. 104 б.

*Рамазанова Д.Б.* Историко-лингвистические особенности формирования и функционирования западноприуральского ареала татарского языка: дис. в виде научного доклада... д-ра филол. наук. Казань, 1998. 100 с.

*Рамазанова Д.Б.* Себер татарларының мәдәнияте һәм теле буенча материаллар. Төмән: ТОГИРРО, 2000. 123 б.

*Рамазанова Д.Б.* Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора. Казань: Магариф, 2001. 208 с.

*Рамазанова Д.Б.* Вопросы татарской диалектологии. Казань: Алма-Лит, 2008. 272 с.

*Рамазанова Д.Б.* Западноприуральский ареал татарского диалектного языка // Вопросы татарской диалектологии. Казань, 2008. С. 5—105.

*Рамазанова Д.Б.* Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 565 б.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан, 2013. 364 б.

*Рамазанова Д.Б.* Атамаларда гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләре. Казан: Татар. кит. нәшр.; 2014. 290 б.

*Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань, 1985.— 160 с.

*Садыкова З.Р.* Зоонимическая лексика татарского языка. Казань: Татар. книж. изд-во, 1994. 130 с.

*Садыкова З.Р.* Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. Казань: Фикер, 2003. 211 с.

*Сарманаева Д.М.* Диалектные особенности языка среднеуральских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1949. 22 с.

*Саттаров Г.Ф.* Сопоставительный анализ звукового состава татарского литературного языка и диалектов // Вопросы татарского языкознания. Кн. 2-я. Казань: КГУ, 1965. С. 120—146.

*Сунгатов Г.М.* Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 23 с.

Татар теле диалектологик атласын төзү өчен материал җыйнау программасы / төз. Н.Б. Борһанова. Казан, 1959. 43 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар.кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре. 2 китапта. Казан: Мәгариф, 2008.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во КГУ, 1977. 295 с.

*Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле (грамматик очерк һәм сүзлек). Казан, 1961. 240 б.

*Тумашева Д.Г.* Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992. 255 с.

*Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар. Часть вторая. Казань: Изд-во КГУ, 1968. 182 с.

*Тумашева Д.Г., Насибуллина А.Х.* Словарь диалектной лексики татарских говоров Тюменской области. Тюмень: ТОГИРРО, 2002. 110 с.

*Хабибуллина М.Р.* Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвистическом пространстве: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 25 с.

*Хайрутдинова Т.Х.* Бытовая лексика татарского языка. Казань: Фикер, 2000. 124 с.

*Хайрутдинова Т.Х.* Говор златоустовских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1980. 20 с.

*Хайрутдинова* Т.Х. Названия пищи в татарском языке. Казань, 1993. 140 с.

*Хайрутдинова Т.Х.* Народные названия растений в татарском языке. Казань: Фикер, 2004. 224 с.

*Хайрутдинова Т.Х.* Словообразовательная структура названий растений в татарском языке // Аспекты гуманитарных исследований: Материалы итоговой конференции Татарского гуманитарного института за 1997 год. Казань: Изд-во Татар. гум. ин-та, 1998. С. 83—88.

*Хидиятов И.Р.* Язык письменных памятников периода Казанского ханства (XVI в.) и татарские говоры в сравнительном аспекте: морфология. Казань, 2013. 163 с.

*Юсупов Ф.Ю.* Изучение татарского глагола. Казань: Татар. книж. изд-во, 1986. 287 с.

*Юсупов Ф.Ю.* Татарские говоры Южного Урала и Зауралья (Челябинской и Курганской областей): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 42 с.

*Юсупов Ф.Ю.* Татарский глагол в ареальном освещении: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алма-Ата, 1988.— 35 с.

*Юсупова А.Ш.* Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. Казань: Казан. ун-т, 2008. 410 с.

***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***И.Б. Бәширова, Б.К. Миңнуллин, Р.Ф. Мирхаев***

# Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ТАРИХЫНЫҢ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

Статья посвящена истории и научно-теоретическим аспектам изучения татарского литературного языка. Дается описание историографии и основных дифференциальных признаков старотатарского литературного языка.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, старотатарский литературный язык, литературно-письменная традиция, вариативность нормы, функционально-стилистическая вариативность.

XX гасырның 50 нче еллары ахырында Татарстаннан читтәге һәм Казандагы кайбер татар мәктәпләрендә ана телендә укыту гамәлдән чыгарылып, татар теле һәм әдәбияты аерым предмет буларак кына калдырыла. Шул ук вакытларда СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты тел секторы мөдире Л. Җәләй тарафыннан Казан дәүләт университетының татар филологиясе студентларына «Татар әдәби теле тарихы», «Әдәби телнең стильләре» дигән курслар буенча лекцияләр уку дәвам итетелә. Үз вакытында, Җ. Вәлиди, Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, Н. Хәким, А.Н. Самойлович, Х. Бәдигый һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә әдәби телнең тарихын чорларга бүлеп карарга мөмкин, дигән фаразлар билгеле бер дәрәҗәдә гомумиләштерелә һәм әдәби телнең функциональ вазыйфасы булуына игътибар көчәйтелә.

«Татар әдәби теленең стильләре» дигән лекциясендә профессор Л. Җәләй: «...формалашып җиткән әдәби тел биш стильгә бүленә, аларның һәрберсенең тарихы бар», — дип, санап күрсәтә. Л. Җәләй хезмәтләре нигезендә татар теле гыйлемендә, әдәби тел тарихы һәм әдәби телнең стильләрен тикшерү күздә тотыла торган, стилистика дигән яңа фән тармагы барлыкка килә, аның максат-бурычлары, ысул-методлары билгеләнә.

Татар әдәби теленең Л. Җәләй тарафыннан күтәрелгән бу катлаулы мәсьәләләре алга таба Ф.С. Фасиев, М.З. Зәкиев, В.Х. Хаков, Х.Р. Курбатов кебек талантлы шәкертләре тарафыннан дәвам иттерелә, һәрьяклап җентекләп тикшерелә, әлеге теманы өйрәнүне объектив фәнни юнәлештә алып бару өчен ныклы нигез салына.

Ф.С. Фасиев һәм М.З. Зәкиев хезмәтләрендә, татар әдәби теленең үсеш баскычлары, төрки кабиләләренең үзара мөнәсәбәте яктылыгында, татар халкын, татар милләтен барлыкка китерә торган тарихи шартлар белән берлектә өйрәнелә [Закиев, 1965, с. 5—37; 1993, с. 25—43; Фасеев, 1966, с. 809—810; 1982, с. 57—62]. Әлеге тикшеренүләр барышында, гомумтөрки тарих тәфсилләнә: М.З. Зәкиевнең «Төрки-татар этногенезы» хезмәтендә егерме өч төрки этнонимга этимологик, семантик һәм функциональ күзәтү ясала. Үзенең әдәби тел тарихын язуга керешкәндә, теләсә кайсы төрки халык менә шушы күзәтүгә нигезләнә. Татар әдәби теленең традициясе-дәвамчанлыгы турында сүз башлаганда, Түрк этнонимына карата бирелгән этимологик, семантик һәм функциональ аңлатуга нигезләнәбез [Зәкиев, 1998, б. 235—321].

Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков хезмәтләрендә татар әдәби теленең функциональ стильләре ныклы бер системага салына

һәм тарихи планда өйрәнелә [Курбатов, 1971; Хаков, 1972, 1993].

ТӘһСИдә аспирантура узган В.Х. Хаков озак еллар буена Казан дәүләт университетында татар әдәби теле тарихын укыта, аның программасын төзи, кулланма һәм монографияләр яза, аспирантлар җитәкли һәм болай дип белдерә: «...Татар тел гыйлеменең бер тармагы буларак, татар әдәби теле тарихы фәне XX гасырның 60—70 нче елларында формалаша» [Хаков, 2003, б. 5].

Шушы ук вакытларда Институтның тел белеме бүлеге мөдире танылган диалектолог Л.Т. Мәхмүтова, Л. Җәләйнең фикерен куәтләп, әдәби телнең формалашуында диалектларның роле зур булуына, аларның үзара мөнәсәбәтен төрле яклап, шул исәптән, тарихи планда өйрәнергә кирәклегенә басым ясый [Махмутова, 1960], әлеге мәсьәләгә һәрдаим игътибар итә. Аның хәер фатихасы белән Ф.С. Фасиев Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын, Я.С. Әхмәтгалиева «Кисекбаш китабы»н, И.А. Абдуллин Г. Камал драмаларының, М.Г. Мөхәммәдиев Ш. Камал прозасының телен-стилен тикшерә башлый. Бу юнәлештә эшләү өчен аспирантурага Ф.Х. Хәкимҗанов, М.И. Әхмәтҗанов, М.М. Нигъмәтуллов, Ә.Х. Исхакова (Алиева), З.А. Хисамиева (Казыйханова), Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Вафина (Кадирова) һ.б. кабул ителә. Яшь галимнәрнең күпчелеге үзләренең тикшеренүләрен академик Э.Р. Тенишев җитәкчелегендә алып бара, мәкаләләре тупланган җыентыклар дөнья күрә башлый.

Бу вакытларда Н. Юзиев җитәкчелегендә «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы языла башлый. 1 нче томның беренче битендә үк язма ядкярларның теле-язылышы үз вакытындагыча саклануы турында мәгълүмат бирелә. Бу хезмәтнең 1 нче һәм 2 нче томнарында IX гасырдан башлап, XX йөзнең башына кадәрге чордагы төрки-татар әдәбияты турында Х. Күроглы, Ш. Абилов, Г. Таһирҗанов, М. Гайнуллин, Ә. Кәримуллин, Я. Абдуллин, М. Гайнетдинов, Н. Хисамов, М. Әхмәтҗанов, Х. Мәхмүтов, Х. Миңнегулов, Ф. Мусин кебек танылган галимнәрнең мәкаләләре урын ала. Аларның хезмәтләрендә, иҗтимагыйтарихи вакыйга-хәлләр һәм әдәбимәдәни тормыш хәрәкәте яктыртылу белән бергә, һәр әдипнең һәр әсәре тикшерелгәндә, шул әсәрнең теленә дә игътибар ителә.

Шуның белән бергә, язма әдәбиятны халыкка кайтару юнәлешендә безнең текстологлар төркеме зур эш башкара. Алар тырышлыгы белән кулъязма хәлендә сакланып калган текстлар бүгенге укучылар да укый алырлык хәлгә китерелә. «XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» дигән җыентыкны төзүче М. Әхмәтҗанов белдерүенчә, «...әдәбиятыбыз буенча чыганаклар хәзерләп чыгаруда татар текстологиясе соңгы илле ел дәвамында зур тәҗрибә туплады һәм алдына куелган бурычларны хәл итә бара». Казан дәүләт университетында М. Госманов татар телендәге тарихи истәлекләрнең (1972, 1979), Ф. Хисамова рәсми документларның телен өйрәнә (1981, 1999).

Әдәбиятчылар, тарихчылар һәм телчеләр тарафыннан алып барыла торган эшчәнлеккә нигезләнеп, төркитатар язма истәлекләренең моңа кадәр өйрәнелгәннәрен бер системага салу, әлегә кадәр кул тимәгән чыганакларны барлау, тикшерүнең ысулын замана таләпләренә туры китереп төгәлрәк күзаллау максатында, Институт директоры һәм тел белеме бүлегенең җитәкчесе М.З. Зәкиев Х.Р. Курбатов һәм И.А. Абдуллинга татар әдәби теле тарихын өйрәнү өчен бердәм Программа төзергә тәкъдим итә.

Х.Р. Курбатов тарафыннан төзелгән Программа, Мәскәү тюркологлары белән берлектә, 1987 елның 5 маенда Институтта тикшерелә. Төрле

фикерләр әйтелә. Тикшеренүчеләр тарафыннан, «Татар әдәби тел тарихы»н чорларга бүлеп язарга кирәкми, дигән уртак фикер дә яңгырый.

И.А. Абдуллин тарафыннан төзелгән программа тикшерелми һәм бу программалар рәсми рәвештә кабул ителә алмыйча кала. Әмма татар әдәби телен тикшерү эшенә карата игътибар кимеми. Язма текстларны өйрәнеп язылган мәкаләләр тупланган җыентыклар Х.Р. Курбатов редакциясендә ел саен чыга килә. Әлеге мәкаләләрдән күренгәнчә, әдәби тел тарихын тикшерү, асылда, телнең фонетика һәм морфология тармакларына нигезләнеп бара. Авторларның күбесе, үзләре тикшерә торган текстлардагы фонетик, морфологик үзенчәлекләрнең татар халкының аерым сөйләшләре яисә хәзерге әдәби теле белән уртак булган якларына ныклап игътибар итәләр, ягъни язма истәлекнең татар халкына да мөнәсәбәте барлыгын ассызыклыйсылары килә; истәлек язылган яисә басылган чордагы язма телгә кыскача характеристика ясала, тел берәмлекләренең аерым жанр таләпләренә туры китерелеп кулланылышы турында да кайбер мәгълүматлар бирелә.

«Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка» дигән җыентыкта Х.Р. Курбатов һәм И.А. Абдуллинның программа буларак төзелеп тә кабул ителмичә калган фикерләре урын ала, иң мөһиме, әлеге мәкаләләрдә татар әдәби теленең тарихын өйрәнүдә алдагы бурычлар күзаллана. И.А. Абдуллин «Әдәби тел тарихын һәм чыганаклар өйрәнүнең төп концепцияләре» дигән күләмле мәкаләсендә: «...теге яки бу чорның әдәби телен һәм гомумән әдәби тел тарихының, лексик-семантик һәм грамматик нормалары үсеш-үзгәрешен язма истәлекләрне алдан килешенгән методика һәм тотрыклы схема буенча өйрәнгәндә генә күз алдына китереп бастырырга мөмкин. ...Татар әдәби телен шундый җитди, ышанычлы өйрәнү өчен аерым язма чыганаклар, әдипләр, жанр стильләре, чорлар буенча монографияләр, диссертацияләр язуның, кадрлар әзерләүнең максатчан һәм анык бер программасы зарур. Мондый программа әлегә юк» — дип нәтиҗә ясый [Абдуллин, 1992, б. 8—20].

Ел саен басылып килгән җыентыкларның барысы да Институтның директоры һәм тел гыйлеме бүлеге мөдире М.З. Зәкиевнең кереш мәкаләсе белән ачыла. Авторның «Татарская лингвистика в системе тюркологии» дигән кереш мәкаләсендә әдәби тел тарихы турында болай дип белдерелә: «...50—60 годах XX века начала формироваться как самостоятельная научная дисциплина история татарского литературного языка на уровнях лексики, фонетики, грамматики и стилистики, но, к сожалению, она не получила интенсивного развития. Пока мы имеем лишь книги по истории формирования литературных стилей на уровне вузовских учебников» [Закиев, 1992, с. 6].

Бу җыентыкларда басылган мәкаләләрнең авторлары тарафыннан алга таба язма истәлекләрнең телен өйрәнеп язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана, аларның монографияләре дөнья күрә: иске татар әдәби теленең матур әдәбият, эш кәгазьләре, публицистика һәм фәнни, дини әдәбиятка караган язма текстлар барлана һәм тикшерелә.

Шуның белән бергә, Н. Хисамов хаклы рәвештә ассызыклаганча, «...гарәп әлифбасы нигезендә иҗат ителгән әдәби-шигъри текстларны хәзерге әлифба нигезендә яктыртуның күп кенә кыенлыклары килеп чыга. Күзгә күренеп торган тупас хаталар да ясала» [Хисамов, 2006, б. 4].

Әлеге мәсьәләне әдәби тел тарихын өйрәнүче галимнәр дә һәрдаим истә тота, шуңа күрә дә әдәби тел тарихын объектив-фәнни югарылыкта,

яңача өйрәнергә кирәклегенә басым ясыйлар.

Бу эшчәнлекнең мөһимлеген ассызыклап, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелеге «Татар әдәби тел тарихы»ның рус телендә берничә томлы басмасын әзерләү мөмкинлеген күздә тота. Хезмәт җаваплы мөхәррир Х.Р. Курбатов тарафыннан язылган «Сүз башы» һәм «Йомгак урынына», В.Х. Хаков тарафыннан язылган күләмле кереш мәкалә белән бер томлы булып дөнья күрә [История..., 2003].

Китап төрки-татар әдәби теленең XIII, XIV, XV—XVII, XVII—XIX гасырларны һәм XX гасырның беренче чиреген колачлаган чорларны нигез итеп алган дүрт бүлектән гыйбарәт. Бу бүлекләрдә, асылда, күрсәтелгән чорларда иҗат ителгән текстларны тикшереп язган аерым авторларның (Х. Кузьмина, Ф. Нуриева, Х. Курбатов, Ә. Нәҗип, Ф. Хисамова, Э. Кадирова, А. Алиева, Л. Гыймадиева һ.б.) басылып чыккан хезмәтләреннән сайлап алынган өзекләр урын ала. Тикшеренүләрнең нәтиҗәсе гомумиләштерелеп, китапның аннотация өлешендә бирелә: «Эта коллективная монография (авторами которой являются московские и казанские ученые-тюркологи) посвящена исследованию особенностей татарского письменного литературного языка. В работе тщательному анализу подвергнуты наиболее важные письменные памятники прошлых столетий (эпические и лирические произведения, деловые памятники, дидактика и т.д.).

В результате выяснилось, что единого письменно-литературного языка, начиная с XIII до первой четверти XX вв., не было. Оказалось, что язык у каждого автора был своеобразен, в зависимости от того, в каких странах и тюркоязычных краях он получил образование, к какому диалекту (или говору) татарского языка принадлежал. Единый татарский стандартный литературный язык установился лишь в 20—30-х годах XX века.

Исследование же татарского разговорного литературного языка ждет особого исследования» [История ..., 2003, с. 4].

Аңлашылганча, XШ гасырдан алып XX гасырның беренче чирегенә кадәр дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигате һәм вазыйфасы, үзенең дәвереннән аерылып, хәзерге бердәм стандартлашкан әдәби тел яктылыгына куеп бәяләнә. Бу фонда караганда, чыннан да һәр авторның теле «своеобразен» булып күренергә мөмкин, чөнки иске татар телендә бер үк сүзләрнең төрлечә языла алуы, телчеләр билгеләгәнчә, әсәр теленең «смешанный» булуы мәгълүм: бар — вар, була — ула, төрле — дөрле, тау — таг һ.б.

Әмма бу хәл XIII гасырдан Идел буе төркие, XV йөздән иске татар теле, XIX гасырның икенче яртысыннан татар милли әдәби теле дип йөртелә торган тел белән язылган әдәби әсәрләрнең телендә билгеле бер эзлеклелек-дәвамчанлык, ягъни әдәби телнең статусын билгели торган төп үзенчәлеге — аның традициясе булмаган, дигән фикер әйтергә мөмкинлек бирәме? Әгәр дә шулай дип аңласак, татар әдәби теле фәкать XX йөзнең 30 нчы елларында гына, ягъни язмачылыгы 1917 елдан соң гына барлыкка килгән, «младописьменные языки» дип йөртелә торган телләрдән дә соңрак формалашкан булып чыга.

XX гасырның соңгы чирегендә, бер уңайдан менә шушы сорауларга да җавап бирү юнәлешендә, әдәби телләрнең тарихын тикшерү ысулының яңарырга тиешлеге аңлашыла. Ә.Р. Тенишев хезмәтләрендә, әдәби телнең табигатен барлыкка китерә һәм аның вазыйфасын билгели торган төп билге-шартларын күрә белергә тиешлек ассызыклана, әмма бу ысул белән бер генә төрки халыкның әдәби теле өйрәнелмәве әйтелә. Әдәби телнең

асыл табигатен барлыкка китерә торган төп шартлары дигәндә, 1) әдәби телнең билгеле бер дәрәҗәдә эшкәртелгән — шомартылган булуы, 2) функциональ-стилистик вариантлылыкка һәм 3) норма вариантлылыгына ия булуы, 4) диалектларыннан өстен һәм 5) традициясе — дәвамчанлыгы булуы истә тотыла (Тенишев, 1988, с. 68 — 78). Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2007 елда төзелгән гомуми лингвистика бүлегендә, бер төркем хезмәткәрләр тарафыннан татар әдәби теле тарихы менә шушы юнәлештә тикшерелә башлады.

Классик иске татар әдәби телен яңача өйрәнү «2004 — 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы»нда расланган «...татар халкының рухи мирасы буларак, татар телен төрле яклап һәм тирәнтен, шул исәптән яңа лингвистик караш һәм дөньякүләм телләр үсеше тәҗрибәсе күзлегеннән чыгып, фәнни тикшерү» максатын [Закон..., 2005, с. 26] тормышка ашыру юнәлеше иде.

Татар әдәби тел тарихын бу юнәлештә тикшерә башлагач та, гасырлар дәвамында иҗат ителеп килә торган язма истәлекләрдә билгеле бер эзлеклелек-дәвамчанлык саклана алганмы? Танылган тюркологлар тарафыннан Идел буе төркие, классик иске татар теле дип тикшерелә торган язма тел нинди традицияләргә нигезләнгән? Тотрыклы язма норма дип санала торган үзенчәлекләре булганмы, әллә һәр автор фәкать үзенчә генә язганмы? дигән сорауларга җавап бирергә кирәклек мәсьәләсе күтәрелде.

Бу сорауларга җавап бирү өчен, беренчедән, әдәби телнең табигатен һәм вазыйфасын барлыкка китерә торган төп билге-шартларның татар филологиясендә ничек итеп өйрәнелешен күзәтеп чыгарга; икенчедән, татар язма истәлекләренең телен анализлап язылган хезмәтләрдә, телнең фонетика, морфология тармакларына, шулай ук графика һәм орфография мәсьәләләренә мөнәсәбәтле әйтелгән фикерләрне гомумиләштереп бирергә кирәк булды.

Шушы нигездә, XIII гасырдан алып, XX йөзнең башына кадәр дөнья күргән язма текстларның, чыннан да, билгеле бер эзлеклелекне саклап, дәвамчанлыкка нигезләнеп иҗат ителүен аңлата торган теориясен эшләргә, бу юнәлештәге максат-бурычны, ысул-методны билгеләргә кирәк булды.

Әлеге мәсьәлә, бигрәк тә фонетика тармагын тикшергәндә, бик тә авыр эш булып чыкты. Чөнки язма ядкярләрнең телен өйрәнүчеләр каршына әдәби нормага мөнәсәбәтле рәвештә фикер әйтү мәсьәләсе куелмый, аларның барысында да гарәп графемалары ярдәмендә кайсы авазларның язуда ничек чагылышы (мәсәлән, мәдсез әлиф белән а, ә, и, ы, э авазлары языла) күрсәтелә иде. Аңлату барышында, мисал рәвешендә гарәп-фарсы алынмалары да, төрки-татар сүзләре дә китерелә, аларның язылышы, әлбәттә инде, төрлечә булып чыга: исем дигәндә сүз аерым әлиф белән, иген дигәндә әлиф йай белән язылган. Моны, русча әйткәндә, «смешанность» дип саный алабызмы? Бу мәсьәлә соңгы елларда Ф. Хәкимҗанов (1991), Ф. Хисамова, И. Бәширова, Ф. Нуриева хезмәтләрендә тикшерелә башлады һәм язма телдәге төрлелекнең норма фонында гына билгеләнә алуы аңлатылды.

Әлеге хезмәтләргә нигезләнеп, иске татар теленең гасырлар буена билгеле бер эзлеклелекне — традицияне саклап дәвам итеп килүен раслау өчен, барлык чорлардагы язма ядкярләрне тикшерүне бер метод-нигезгә утыртып карарга мөмкин булды. Бу уңайдан, әдәби язма телнең фонетика тармагында һәм графика, орфографиясендә чагыла торган эзлеклелек-традиция мәсьәләсе билгеләнгәндә, түбәндәге үзенчәлекләр истә тотылды: берен-

чедән, тикшеренүләрдән күренгәнчә, гарәп-фарсы алынмалары катгый рәвештә үз чыганак телендәгечә, ягъни гарәп теле кагыйдәләре буенча язылганлыгы искә төшерелде. Иске татар телендәге сүзләрнең 60—70% ы гарәп-фарсы алынмаларыннан гыйбарәт булуы мәгълүм, димәк бу өлкәдә ныклы язма норма дәвам иткәнлеге күренә. Икенчедән, галимнәр ассызыклаганча, төрки-татар сүзләренең язылышында да, Идел буе төркие, иске татар теленең йөзе билгеләнерлек дәрәҗәдә кабул ителгән тәртип булганлыгы мәгълүм [Фасеев, 1982, с. 48—51]. Димәк, иске татар телендә билгеле бер дәвамчанлыкның булуын күрер өчен, беренче чиратта, гарәп-фарсы алынмаларының язылышын төрки-татар сүзләренең язылышыннан катгый рәвештә аерып алып карарга кирәк булуы аңлашылды.

Болай итеп эшләгәндә, гарәп-фарсы алынмалары белән төрки-татар сүзләренең язылышындагы туры килмәүләрне һичничек тә «смешанность» — вариантлылык дип санарга мөмкин булмавы күренә, чөнки алар ике мөстәкыйль гаилә тел берәмлекләре буларак, графика бер үк булса да, үз телләренең таләпләренә туры китерелеп язылган. Шулай булгач, аларның берсен икенчесе белән чагыштырганда күзәтелә торган туры килмәүләрне язма телдәге «смешанность» — вариантлылык дип түгел, бәлки бер орфографик норманың икенчесенә тәңгәл килмәвен белдерә торган күренеш кенә, дип әйтә алабыз.

Язма истәлекләрнең теле «смешанный» дип белдерелгән вакытта, бер үк телдәге төрлечә язылышны гына истә тотарга тиеш булабыз, мәсәлән, Аллаһ — Иллях, яисә Иман дигән сүз гарәп теле кагыйдәсе буенча бер әлиф белән генә башланырга тиеш, әмма ул әлиф йай булып та языла һ.б.

Бу төрдәге вариантлылык, гарәп теленә караганда, төрки-татар сүзләренең язылышында, әлбәттә, ешрак очрый, нигездә гомумтөркидән килә торган традицион шәкел белән әсәр языла торган җирле-төбәк әйтелеше чагылган форманың туры килмәве истә тотыла.

Боларның күбесе угыз һәм кыпчак төркеме телләренә хас булган аермалыкларның язудагы чагылышына карый. Әмма бу үзенчәлекне ике яктан килеп аңлый-аңлата алабыз: а) бер үк гомумтөрки телгә хас булган вариантлылык, дип әйтә алабыз, чөнки болар бер үк гаилә теленә караган аерымлану хасил итә, әмма, шул ук вакытта аларны: ә) гомумтөрки эчендәге ике төрле телнең һәрберсенә хас булган норманың чагылышы, дип тә әйтә алабыз.

Язма истәлекләрнең телендәге төрлечә язылыш, татар телендәге ун сузыкны язуда чагылдыру өчен, гарәп теленең өч кенә графемасы булуы, шул ук вакытта, татар телендәге /г/, /з/, /с/, /т/, /х/ тартык авазларын белдерү өчен, гарәп теленең ике-өч-дүрт хәрефе булуы нәтиҗәсендә дә барлыкка килгән.

Шулай итеп, язма әдәби телнең «смешаный» — вариантлы булуы, төрки-татар теле һәм гарәп теле үзенчәлекләренең үзара мөнәсәбәтендә, һәм бер үк гомумтөрки гаиләгә караган тел төркемнәренең үзенчәлекле әйтелеше-язылышына нигезләнеп барлыкка килгән. Әмма әлеге вариантлылыклар билге бер норма-традиция яктылыгында күренә алган. Димәк, норма вариантлылыгы дип әйтелгәндә, иң беренче чиратта, язма телнең нормасы булуын истә тотарга кирәк була.

Әлеге метод-ысулга нигезләнеп тикшерү VII йөзләрдән башлап XX гасырның беренче чирегенә кадәр дәвам итә һәм төрле исемнәр белән атала торган төркидә иҗат ителә килгән язма текстларның тел үзенчәлеген, һәр истәлекне үз дәвереннән аермыйча өйрәнергә мөмкинлек бирә. Моның өчен һәр текст теленең структур-төзелешенә хас булган «смешанность»,

ягъни вариантлы булуын күрсәтү белән бергә, ул берәмлекләрнең функциональ кулланылышын билгеләргә тиеш булабыз, тел берәмлекләренең төзелеше белән, аларның аерым бер текст эчендә үзенчәлекле кулланылышын бергә караганда гына билгеле бер эзлеклелекнең ничек итеп дәвам ителүе күренә ала. Әдәби телне бу ысул белән тикшергән вакытта, «...единого письменно-литературного языка, начиная с XIII до первой четверти XX вв., не было...» дигән фикернең чынбарлыкка туры килмәгәнлеге аңлашыла.

Димәк, әдәби язма текстларда традицион норма дигәндә, тел берәмлекләренең, хәзерге хәле белән чагыштырылып, төзелеш-структурасын билгеләү белән бергә, аларның билгеле бер чордагы аерым текстта ничек итеп кулланылуына — функциональ үзенчәлегенә дә игътибар итәргә кирәк була.

Төрки-татар әдәби язма норманың эзлекле булып дәвам итүен билгеләү юнәлешендә, тикшерүне гарәп графемаларын түгел, бәлки хәзерге вакытта татар теле авазларын белдерә торган рус-кирилл хәрефләрен нигез итеп алып, аларның язуда гарәп теле графемалары белән ничек итеп чагылышын һәм вариантлылыкның нинди сәбәпләр белән барлыкка килүен күзәтергә кирәк булуы аңлашылды. Тикшерү гарәп графемаларына нигезләнеп барганда, татар теленең үзенчәлегеннән бигрәк, гарәп теленең мөмкинлеге күбрәк чагыла иде.

Татар әдәби теленең «Фонетика, графика, орфография: әдәби норма һәм вариантлылык» дигән беренче томын язу барышында, авторларга менә шундый бердәм яңа метод-ысуллар белән эшләргә туры килде.

«Татар әдәби теле тарихы»ның «Морфология: грамматик категорияләрдә әдәби норма һәм вариантлылык» дигән икенче томын язганда да, сүз төркемнәренең тәртибен билгеләгәндә һәм аларга хас булган грамматик формалар белән белдерелә торган мәгънәләр тикшерелгәндә аларның хәзерге әдәби телдәге рәвешләре нигез итеп алына.

Төрле чорда иҗат ителгән язма текстларның сүз — лексема байлыгын тикшерү эше әлеге тармакның хосусый табигатен билгеләү юнәлешендә барачак. Сүзнең номинатив мөмкинлегенә нигезләнә торган тематик төркемнәрне барлау белән бергә, иң мөһиме, аларның функциональ колачын күзалларга, ягъни лексик-семантик категорияләренең үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтен объектив яктырта белергә кирәк булачак.

Йомгаклап әйткәндә, борынгы төрки (VI—VIII), иске төрки (XI—XIV) язма әдәби телләр нигезендә XV—XVI гасырларда классик иске татар теле булып формалашкан, XIX гасырның икенче яртысыннан гамәлдә булган татар милли әдәби теле бүгенге көндә дә кулланылышын дәвам итә.

**Әдәбият**

*Абдуллин И.А.* Әдәби тел тарихын һәм чыганаклар өйрәнүнең төп концепцияләре // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. Казань, 1992. С. 4—20.

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры — XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык. Казан: КДТУ нәшр., 1999. 576 б.

Закон РТ О государственных языках РТ и других языках в РТ. Казань, 2005. 68 с.

*Закиев М.З.* Некоторые вопросы развития татарского литературного языка // Вопросы татарского языкознания / КГУ. Кафедра татарского языка. Казань, 1965. Кн. 2. С. 5—37.

*Закиев М.З.* Введение: Татарская лингвистика в системе тюркологии // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1992. С. 3—8.

*Закиев М.З.* Введение // Татарская грамматика: в трех томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. I. С. 10—53.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. Казан: Фикер; М.: Инсан, 1998. 624 б.

История татарского литературного языка (XIII — первая четверть XX в.). Казань: Фикер, 2003. 656 с.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең стилистик системасы. Казан: Татар. кит. нәшр, 1971. 193 б.

*Махмутова Л.Т.* Современный татарский литературный язык и диалекты // Вопросы татарского языка и литературы. Казань, 1960. Кн. 4. С. 26—34.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Казан. ун-т, 2004. 376 с.

*Тенишев Э.Р.* Принципы составления исторических грамматик и историй литературных тюркских языков // Советская Тюркология. Баку, 1988. № 1. С. 68—78.

*Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII—XVIII вв. Казань: Изд-во КГУ, 1972. 222 с.

*Усманов М.А.* Жалованные акты Джучиева Улуса XIV—XVI вв. Казань: Изд-во КГУ, 1979. 318 с.

*Фасеев Ф. С.* Краткий грамматический справочник татарского языка // Татарско-русский словарь. М.: Советская энциклопедия, 1966. С. 807—863.

*Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII века. Казань: ИЯЛИ, 1982. 170 с.

*Хакимзянов Ф.С.* Варианты реализации поволжского литературного языка // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. Казань, 1991. С. 28—37.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 221 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. Казан: КДУ нәшр., 1993. 323 б.

*Хаков В.Х.* Тел — тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Хисамов Н.Ш.* Классик әдәбиятны нәшер итүнең кайбер принципиаль аспектлары // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар — XX йөз башы). Казан, 2006. Б. 4—8.

*Хисамова Ф.М.* XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. Казан: КДУ нәшр., 1981. 161 б.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии (XVI — нач. XIX в.). Казань: Мастер Лайн, 1999. 408 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,*** *филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре;*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге җитәкчесе,*

***Мирхаев Рифат Фирдинат улы,*** *филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ф.К. Бәширов***

## ИНСТИТУТТА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ БҮЛЕГЕ

В данной статье рассматривается история функционирования отдела литературоведения в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, персоналия, теория литературы, текстология.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1939 елгы 27 август карары нигезендә 7 октябрьдә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты оештырылган көннәрдә үк, аерым сектор буларак, барлыкка килә. Аның беренче җитәкчесе итеп Я.Х. Агишев билгеләнә һәм әлеге вазифаны 1941 елга кадәр башкара. Секторның беренче хезмәткәрләре В.Х. Хаҗиев, М.Х. Гайнуллин, Г.Х. Хисмәтуллин (Хәй Хисмәтуллин) була. 1940—1950 елларда анда А.Х. Камский, Г.М. Халитов (Гали Халит) (1942—1953 елларда мөдир), Б.А. Яфаров, М.В. Галиев (Мөхәммәт Гали), М.С. Кәшшафетдинов (Гази Кашшаф) эшли.

40 нчы елларда әдәбиятчылар, нигездә, әдәби чыганакларны җыйнау-туплау, аерым язучыларның иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Акрынлап борынгы, урта гасырлар, XIX йөз һәм XX гасыр башы татар әдәбияты проблемаларын өйрәнү буенча план-проспектлар төзелә, ләкин, Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, аларны гамәлгә ашыруда зур авырлыклар туа. Шулай да тикшеренү эшләре тукталып калмый. Бу елларда Г. Халитнең «Халык шагыйре Габдулла Тукай» (1939), «Мәҗид Гафури иҗаты (критик очерклар)» (1941), М. Галинең «Г. Камал: тормышы, иҗаты, татар әдәбиятындагы һәм гомумән татар культурасында тоткан урыны» (1941), Х. Хәйри һәм С. Фәйзуллин тарафыннан М. Фәйзинең әсәрләре (1941), Я. Агишевнең «Габдулла Тукай — патриот» (1942), М. Гайнуллинның «Горький и татарская литература» (1944), татар һәм рус телләрендә «Каюм Насыйри: тууына 120 ел тулу уңае белән», «Каюм Насыри. Его научная и просветительская деятельность» дип аталган хезмәтләре (1945), М. Гафуриның «Балалар күңеле» дигән шигырьләр, мәсәлләр һәм хикәяләр тупланмасы (1944), әдип әсәрләренең җыелмасы (Г. Халит, 1949), Г. Тукайның «Сайланма әсәрләр»е һәм «Күңелле сәхифәләр» дип исемләнгән китабы (Г. Халит һәм Х. Хисмәтуллин, 1946), Һ. Такташның «Сайланма әсәрләр»е (төзүчесе Х. Хәйри, 1947), Х. Хәйринең «Һади Такташ (Тормыш һәм иҗат юлы)» (1949) монографиясе дөнья күрә, Г. Халитнең теоретик характердагы «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре (критик очерклар)» (1948) дигән китабы басылып чыга.

Я. Агишев һәм Х. Хисмәтуллин китапханәләрдә, архив фондларында Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗат мирасына кагылышлы материалларны барлау-туплау юнәлешендә эзләнү эшләре алып барып, 1943—1948 елларда шагыйрь әсәрләренең ике томлы академик басмасын нәшер итәләр. Әлеге хезмәткәрләрнең бу эшчәнлеге

Институтта башланган фәнни текстология тармагының иң әүвәлге үрнәге булып тора. Г. Тукайның тууына алтмыш ел тулу уңаеннан гыйльми сессия үткәрелә һәм әлеге фәнни чараның материаллары аерым җыентык булып басылып та чыга.

Институт, шул исәптән әдәбият секторы да, үз вакытында рәсми идеологиянең ныклы контроле астында эшли. Шуңа күрә әлеге оешманың өстендә «кара болытлар» куерган вакытлар да булгалап тора. Мәсәлән, 1944 елның 6 октябрендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросында Институтның эшчәнлеге тикшерелә. Бу мәсьәлә буенча чакырылган егерме биш кеше арасында, директор Х. Ярми (Х.Х. Ярмөхәммәтов) белән бергә, фәнни хезмәткәрләрдән Б. Яфаров һәм Г. Халит тә була. Биш кешелек комиссия тарафыннан имзаланган бәяләмәдә һәм бюроның карарында Институт эшендә шактый җитди хаталар җибәрелгәнлеге әйтелә. Әдәбиятчылардан Б. Яфаров, Г. Халит, Я. Агишев, Х. Хисмәтуллин хезмәтләре кискен тәнкыйтьләнә. Нәтиҗәдә Х. Ярми җитәкчелектән алына һәм аңа кисәтү ясала.

1946 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы төзелгәч, әдәбият секторы 1961 елга кадәр фольклор секторы белән берләштерелә. Тикшеренүләрнең тематикасы һәм проблематикасы киңәйтелә: галимнәргә татар әдәбияты тарихының актуаль проблемаларын эшкәртү, милли әдәбият тарихын язу, урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен уку әсбаплары төзү, татар әдәбияты классикларының әсәрләрен туплау һәм аларны бастырып чыгару бурычы йөкләнелә.

Мәгариф системасы тарафыннан алып барылган эшләргә Я. Агишев, В. Хаҗиев, М. Гайнуллин, Б. Яфаров, Х. Хәйри, Г. Кашшаф һ.б. җәлеп ителә һәм алар, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләр, югары уку йортлары өчен, әдәбияттан дәреслек-хрестоматияләр төзеп бастыралар.

Институтта урта гасыр татар әдәбиятын өйренеп тикшерүне, беренчеләрдән булып, Б. Яфаров башлап җибәрә. Ул XIV йөздә яшәп иҗат иткән Мәхмүд Гали әл-Болгаринең «Нәһҗел-фәрадис», Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур», Габдерәхим Утыз Имәнинең (XVIII) һәм башка әдипләрнең иҗади мирасларын өйрәнә. Әмма аның әлеге бибәһа тикшеренүләре вульгар-социологизм тарафдарлары ягыннан нигезсез һәм рәхимсез тәнкыйтькә дучар ителә. Үзенә карата барлыкка китерелгән түзә алмаслык шартлар нәтиҗәсендә галим бу өлкәдә эзләнүләрен бөтенләй туктатырга һәм 1952 елда Институттан китәргә мәҗбүр була.

Шушы чорда сектор хезмәткәрләре Я. Агишев («Общественно-политические мотивы в творчестве татарского народного поэта Г. Тукая», 1946), М. Гайнуллин («Исследование по татарской литературе XIX и начала XX века», 1946), Г. Халит («Дооктябрьская творческая эволюция Маджита Гафури», 1947), Х. Хисмәтуллин («Драмутургия Г. Камала (дооктябрьский период)», 1949), Б. Яфаров («Литература Камско-Волжских булгар в X—XIV веках и «Нахдж-ал-Фарадис», 1949) диссертацияләр яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алалар.

Хезмәткәрләр күмәк хезмәтләр язу белән дә шөгыльләнәләр. Г. Халит, Х. Хисмәтуллин, Б. Гыйззәт тарафыннан башкарылган «XX йөз башында татар әдәбияты: очерклар» (1954) — әнә шуларның берсе. Әлеге китап илленче еллар әдәбият гыйлеменең күркәм бер казанышы буларак кабул ителә, күрсәтелгән чордагы татар әдәбияты үсешенең тенденцияләрен тикшерү, идея-эстетик байлыкны

ачыклау, әдәби хәрәкәткә зур өлеш керткән әдипләрнең иҗади эшчәнлеген бәяләү юнәлешендә беренче тәҗрибә була. Авторлар чор идеологиясе таләпләренә ярашлы рәвештә әдәбиятны социологияләштерү белән генә чикләнеп калмыйлар, ә әсәрләрнең сәнгати эшләнеше ягына да зур игътибар бирәләр. Г. Тукай һәм М. Гафури (Г. Халит), Г. Камал һәм Ш. Камал (Х. Хисмәтуллин), Г. Коләхмәтовның (Б. Гыйззәт) иҗат портретларында язучыларның һәм аларның әсәрләрендә чагылыш тапкан геройларның сәнгати дөньяларын характерлый торган күп кенә шәхси үзенчәлекләрен табарга мөмкин. Шунысын да билгеләп үтү лязим: партияле әдәбият принциплары нигезендә әдәбиятны өйрәнү монографиядә дә үзенең чагылышын тапмый калмый, әлбәттә. Аерым язучылар, шагыйрьләрнең (мәсәлән, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Н. Думави) әдәби процесстагы рольләре шактый түбәнәйтелеп күрсәтелә.

50 нче һәм 60 нчы елларның беренче яртысында әдәби тикшеренүләрнең тематикасы һәм проблематикасы киңәйтелә төшелә. Төп игътибар урта гасыр татар әдәбиятына юнәлтелә. Әлеге өлкәдә аеруча киң эрудицияле галим, язучы М. Гали актив һәм нәтиҗәле шөгыльләнә. Ул беренче татар мәгърифәтчеләре И. Хәлфин, Ш. Мәрҗани, шагыйрьләр Өмми Камал, Акмулла, педагог һәм хаттат (каллиграф) Гали Мәхмүдев турында этрафлы мәкаләләр бастыра, К. Насыйриның киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган кульъязмаларына, Г. Тукайның Уральскида яшәгән чорына караган кызыклы күзәтүләр ясый. Соңгысы турында ул «Шагыйрь баскан эзләрдән» (1957) дигән китап та бастырып чыгара. Болар белән берләттән, аның әдәбият белемендә саллы казанышлары булып XVIII гасыр һәм XIX йөз башы татар әдәбиятының яңа сәхифәләрен ачыклау исәпләнелә. Мәсәлән: «XVIII һәм XIX йөз татар әдәбиятында Пугачев хәрәкәтенең чагылышы», «XVIII йөз татар әдәбияты тарихы буенча кыскача очерклар», «XVIII йөз азагы — XIX йөз башы мәгърифәтчеләре», «XVIII йөз һәм XIX йөз татар әдәбияты тарихы буенча проспект» һәм башка хезмәтләре. Алар нәшер ителми калган булсалар да, хәзерге вакытта да үзләренең актуальлекләрен җуймыйлар.

1950—1960 елларда секторда М. Гайнуллин (1953—1956 елларда мөдир), Х. Хисмәтуллин, Г. Халит, Р. Башкуров, С. Исәнбаев, Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт (Ф. Гыйззәтуллин), Х. Хәйри (Х. Хәйруллин) (1956—1958 елларда мөдир), В. Воздвиженский, Ш. Абилов эшлиләр.

Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институтындагы татар филологиясе бүлекләрендә белем алучы студентларның, анда эшләүче укытучыларның XIII—XVIII гасырлар әдәбиятын яктыртучы материалларга булган ихтыяҗларын истә тотып, секторда хрестоматик характерда «Борынгы татар әдәбияты» дигән китапны төзү эше башлана. М. Гайнуллин җитәкчелегендә тупланган галимнәр Х. Мөхәммәтов, Х. Хисмәтуллин, Ш. Абилов, С. Исәнбаев, Оренбург педагогия институты доценты Ү. Беляева бинаһая көч куеп башкарган әлеге хезмәт 1963 елда нәшер ителә.

Бу китап бай эчтәлекле һәм күп яңалыклары белән үзенчәлекле. Галимнәр эш барышында татарларның этногенезы мәсьәләсендә соңгы тарихи казанышларга нигезләнәләр. Татар әдәбияты тарихы Идел буе Болгар дәүләте чорыннан (IX—XIII) башлап тикшерелә. Төп игътибар язма әдәби мираска юнәлтелә: Кол Галинең иҗаты беренче тапкыр татар әдәбиятының табигый өлеше буларак тикшерелә, Харәзми, Хөсам Кятиб, Мәхмүд Гали

әл-Болгари (XIV), Мөхәммәдьяр (XVI) әсәрләренең текстлары, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе-Болгария» (XVI), Мәүла Колый (XVII), Габдерәхим Утыз Имәни (XVIII) иҗатларыннан үрнәкләр китерелә һәм анализлана.

Әдипләрнең әсәрләрен текстологик яктан эшкәртеп бастыру юнәлешендә эш уңышлы дәвам иттерелә. Элгәрге тәҗрибәләрне нәтиҗәле файдаланып башкарылган Г. Камал әсәрләренең икетомлыгы (М. Гали, 1950—1951), К. Насыйриның «Сайланма әсәрләр»е (1956, М. Гайнуллин редакциясендә); М. Гафуриның ике томда «Сайланма әсәрләр»е (1953—1954, төзүчеләре Г. Кашшаф, Г. Халит); Ш. Мөхәммәдевнең «Сайланма әсәрләр»е (1956, төзүчесе М. Гайнуллин); Г. Тукай әсәрләренең дүрт томлы академик басмасы (Я. Агишев, Х. Хисмәтуллин, 1955—1956), Г. Ибраһимовның өч томлы «Сайланма әсәрләр»е (1956—1957), З. Һадиның «Сайланма әсәрләр»е (М. Гайнуллин, 1957), Ф. Әмирханның ике томда «Сайланма әсәрләр»е (1958, төзүчесе һәм текстны әзерләүче Х. Хисмәтуллин), К. Нәҗми әсәрләре җыентыгының дүрт томы (Н. Гыйззәтуллин һәм С. Әдһәмова, 1959—1960) дөнья күрә. Шулай ук классикларның иҗат мирасларын теоретик планда өйрәнү дә уңышлы башкарыла. Мәсәлән, М. Гайнуллин «Каюм Насыри и просветительское движение среди татар» (1955), Р. Башкуров «Переводы Тукая из русской литературы» (1957), «Тукай һәм рус әдәбияты. Шагыйрьнең тәрҗемәләре турында» (1958), Г. Халит «Тукай и татарское литературное движение начала XX в.» (1956), «Тукай үткән юл: Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк» (1962), «Тукай и его современники» (1966) дигән хезмәтләр язалар. С. Исәнбаев тарафыннан төзелеп, 1960 елда дөнья күргән «Тукай турында замандашлары: истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы» Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗат мирасын өйрәнүдә кыйммәтле чыганакларның берсе була. Галим 1966 елда олуг шагыйрьгә багышланган фотоальбом да бастыра.

Шул елларда сектор хезмәткәрләре М. Гайнуллин, Г. Халит, Б. Гыйззәт, Х. Хисмәтуллин, Н. Гыйззәтуллин, Х. Мөхәммәтев татар совет әдәбияты тарихы буенча гомумиләштерүче хезмәт язу белән турыдан-туры шөгыльләнәләр. Ул «Татар совет әдәбияты» исеме белән 1960 елда бастырып чыгарыла.

Х. Хәйринең теоретик характерда булган «Әдәбият һәм тормыш» (1953), «Советская татарская литература. Очерки» (1957), «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1960) хезмәтләре, К. Насыйриның «Сайланма әсәрләр»е (1953, икенче басмасы — 1956), «XX йөз башы татар әдәбияты: очерклар» (1954) дигән коллектив хезмәт дөнья күрә. М. Гайнуллин, Х. Мөхәммәтев, Х. Ярми тарафыннан «Татар поэзиясе антологиясе» (1956) төзелә. Шулай ук аерым язучыларның, мәсәлән, З. Һадиның (1957), Ш. Мөхәммәдевнең (1958) «Сайланма әсәрләр»е (төзүчесе М. Гайнуллин) нәшер ителә.

Аерым язучыларның әдәби портретларына, социалистик реализм проблемаларына багышланган китаплар да басыла. Мәсәлән, Ф. Гыйззәтуллинның «Драматург Таҗи Гыйззәт» (1957), Н. Гыйззәтуллинның татар һәм рус телләрендә «Кави Нәҗми. Тәнкыйть-биографик очерк» (1956), «Кави Наджми. Критико-биографический очерк» (1957), З. Усманованың «Гадел Кутуй» (1957), Х. Хәйринең «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1960) дигән хезмәтләре шулар җөмләсеннән. Совет чорында, беренче буларак, 450 терминны эченә алган татар те-

лендә «Әдәбият белеме сүзлеге» (Н. Гыйззәтуллин. 1958) нәшер ителә.

Әлеге чорда секторда һәм татар әдәбияты белемендә гомумән беренче булып М. Гайнуллин («Татарская литература и публицистика в период первой русской революции», 1958) фән докторы булып җитешә, ә Б. Гыйззәт («Гафур Коләхмәтов иҗаты», 1951), Н. Гыйззәтуллин («Кави Нәҗми прозасы», 1952), Х. Мөхәммәтев («XIX йөзнең соңгы чирегендә татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре», 1953), Р. Башкуров («Переводы Г. Тукая из русской литературы», 1958), Ш. Абилов («XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр иҗаты», 1960) кандидатлык диссертацияләре яклыйлар.

1960—1970 елларда бүлектә М. Гайнуллин, Г. Хисмәтуллин, Г. Халит (1960—1966 елларда мөдир), Х. Хәйри (1966—1973 елларда мөдир), Р. Башкуров, Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт, В. Воздвиженский, Ш. Абилов, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, Р. Сверигин, Ф. Ибраһимова, Р. Гайнанов, М. Йосыпов, М. Маннурова, М. Гайнетдинов, Л. Гайнанова, Н. Хисамов, К. Дәүләтшин эшлиләр.

Аерым әдипләрнең иҗатларын өйрәнүгә багышланган Х. Хисмәтуллинның «Фатих Әмирхан (тормышы һәм иҗаты турында кыскача популяр очерк. Тууына 75 ел тулу уңае белән)» (1961), «Галиәсгар Камал (Критик-биографик очерк)» (1969), Р. Башкуров һәм В. Воздвиженскийнең «Һәрвакыт халык йөрәгендә (Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлы)» (1966); Г. Халитнең «Тукай үткән юл (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк)» (1962), «Тукай и его современники» (1966); А. Әхмәдуллинның «Фәтхи Бурнаш» (1967) дигән хезмәтләре; татар әдәбиятында герой, иҗат методы, традиция, новаторлык мәсьәләләре турында теоретик характердагы «Герои, рожденные революцией. К проблеме героя и метода татарской советской литературы» (1967), «Шагыйрь, чор, герой (Һади Такташ иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән)» (1971) (Г. Халит) басылып чыга. Х. Хисмәтуллин тарафыннан әзерләнеп, Ф. Сәйфи-Казанлының «Сайланма әсәрләр»е (1960) нәшер ителә. М. Гайнуллинның «Татарская литература и публицистика начала XX века» (1960, 1966), «Татар әдәбияты: XIX йөз. Тулыландырылган икенче басма: югары уку йортлары өчен» (1968) дигән хезмәтләре дөнья күрә.

60 нче еллар уртасыннан әдәбиятчылар эшчәнлегендә яңа этап башлана. СССР Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятлары институты һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән берлектә, 1965 елда Мәскәүдә рус телендә нәшер ителгән «История татарской советской литературы» — моның ачык чагылышы булып тора. Әлеге басмада авторларның идея-тематик анализ кысаларыннан чыгарга омтылышлары күренә. Бу хезмәт Мәскәүдә дөнья күргән милли совет әдәбиятларының беренче үрнәге була.

1966 елда Ш. Абилов Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» дигән поэмаларын текстологик яктан эшкәртеп, аларны искәрмәләр һәм сүзлек белән тулыландырып бастырып чыгара. Әйтергә кирәк, ул әлеге юнәлештә эшне лаеклы ялга киткәч тә уңышлы дәвам иттерде. Нәтиҗәдә, урта гасыр шагыйре әсәрләренең яңа тәнкыйди нөсхәсе барлыкка килде (1997).

Бүлек хезмәткәрләре Г. Халит («Проблема творческого метода в татарской литературе» (1905—1932 гг., 1968 г.) — фән докторы, В. Воздвиженский («Моабитские тетради» М. Джалиля и их место в советской

литературе военных лет», 1968), Ф. Ибраһимова («Сугыштан соңгы елларда татар балалар прозасы (1945—1966 еллар)» (1969), Ф. Мусин («Алтмышынчы еллардагы татар прозасында уңай герой проблемасы», 1969) фән кандидатлары булып җитешәләр.

1970 — 1980 елларда бүлектә Н. Юзиев, М. Гайнуллин, Г. Халит, Н. Гыйззәтуллин, В. Воздвиженский, Ф. Гыйззәтуллин, Х. Хәйри, Ш. Абилов, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, Р. Свеlinks, Ф. Ибраһимова, Р. Гайнанов, М. Маннурова, М. Гайнетдинов, Л. Гайнанова, Н. Хисамов, К. Дәүләтшин, З. Рәмиев, Ә. Шәрипов, М. Йосыпов, С. Шәйдуллин, Н. Ханзафаров, Н. Садыйкова, Ф. Макаев, Р. Әхмәтов, Ә. Алиева, М. Хәйруллин, М. Хәбибуллин, Н. Исмәгыйлев эшлиләр.

Татар әдәбиятчыларының эшчәнлегендә аларның Бөтенсоюз фәнни-тикшеренүләрдә актив катнашуларын билгеләп үтү зарур. СССР Фәннәр академиясе М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятлары институты тарафыннан нәшер ителгән күпмилләтле совет әдәбияты тарихының фундаменталь күптомлылыгын (1970—1974) язуда Г. Халитов, Р. Башкуров, Б. Гыйззәтуллин, В. Воздвиженский, Н. Гыйззәтуллин, Н. Юзиев, Х. Хәйруллин, А. Әхмәдуллин, Р. Сверигин шактый көч куялар һәм әлеге гамәл сектор галимнәре өчен зур академик мәктәп узу була.

Ул елларда Г. Халитнең «Шагыйрь, чор, герой: Һади Такташ иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән» (1971), М. Гайнуллинның «Дуслыкта — көч. Публицистик мәкаләләр, әдәби очерклар» (1973), татар һәм рус телләрендә «Каюм Насыйри. Тормыш һәм иҗат юлы. Тууына 150 ел тулу уңае белән», «Каюм Насыри. Очерк жизни и творчества» (1975), «Галиәсгар Камал (1879 — 1933). Тормышы һәм иҗат юлы (тууына 100 ел тулу уңае белән)» (1978), «Галиасгар Камал (1879 — 1933). Очерк жизни и творчество» (1978), Ф.И. Ибраһимованың «Заман белән бергә (Ватан сугышыннан соңгы елларда татар балалар прозасы)» (1971); Н. Хисамовның «Поэма «Кысса-и Йусуф Кул Али» (М., 1979) дигән тикшеренүләре аерым монографияләр булып дөнья күрә. М. Гайнетдинов тарафыннан әзерләнеп, күренекле шагыйрь Х. Туфанның «Давыллы еллар лирикасы» (1974), «Сайланма әсәрләр»енең икетомлыгы (1974—1975) бастырыла.

1976 елда дөнья күргән «Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917—1973)» (А. Әхмәдуллин (баш редактор), Н. Гыйззәтуллин, Х. Хәйри) илле алты ел эчендә татар әдәби һәм мәдәни тормышында булган истәлекле вакыйгаларны чагылдырган һәм фактик материалга бай чыганакларның берсе булып тора.

Татар әдәбияты тарихы һәм теориясенең актуаль проблемалары буенча аерым монографияләр язу да планлаштырыла. Аны гамәлгә ашыру юнәлешендә башкарылган хезмәтләрдән М. Гайнуллинның «Татарская литература начала XX века» (1975), «Татарская литература XIX в.» (1975), «Татар әдипләре: иҗат портретлары» (1978), «Татар мәгърифәтчелек әдәбияты» (1979) китапларын билгеләргә кирәк. Галимнәр әдәбиятны теоретик планда өйрәнүгә игътибарны арттыра төшәләр, иҗат методы, герой, жанр, стиль проблемаларын тикшерә башлыйлар. Аның үрнәкләрен Г. Халитнең «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән (әдәби-тәнкыйть мәкаләләре)» (1975), «Яңа гасыр поэзиясе. Егерменче йөз башы (1905—1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре» (1979); Ф. Мусинның «Связь времен» (1979); Н. Ханзафаровның «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» (1982), А. Әх-

мәдуллинның «Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма» (М., 1983) дигән хезмәтләре тәшкил итә.

1975—1977 елларда Р. Гайнанов тарафыннан Г. Тукайның дүрт томлык «Әсәрләр»е нәшер ителә. Ул шулай ук Г. Ибраһимов сигезтомлыгының беренче — бишенче томнарын (1974 — 1976) төзеп чыгаруда турыдан-туры катнаша. Н. Гыйззәтуллин 1976 елда әдип К. Нәҗминең әдәбипублицистик мәкаләләрен туплап, «Әдәбият дөньясында» дигән китап бастырып чыгара.

Ул елларда хезмәткәрләрдән Н. Юзиев («Татар совет поэзиясе», 1974) — докторлык, К. Дәүләтшин («XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колый», 1971), М. Маннурова («Интернациональные идеи и образы в татарском историко-революционном романе (Изображение русского революционера в романах Г. Ибрагимова, К. Наджми, И. Гази)», 1971), Р. Сверигин («Фатыйх Хөсни иҗатында герой проблемасы һәм әдәби осталык», 1971), М. Гайнетдинов («Хәсән Туфан иҗаты», 1972), З. Рәмиев («Сибгат Хәким поэзиясе», 1973), Н. Ханзафаров («Нәкый Исәнбәт драматургиясе (Жанр, конфликт һәм герой)», 1975), Н. Хисамов («Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Гали (Анализ источников сюжета и авторского творчества)», 1979) кандидатлык диссертацияләре яклыйлар.

1980—1990 еллар — секторда булган җитди үзгәрешләр белән характерлы. 1986 елда ул әдәбият белеме лабораториясе итеп үзгәртелә һәм 1987 елның февралендә аннан кульъязмалар һәм текстология лабораториясе бүленеп чыга. Әдәбият белеме лабораториясендә Ф. Мусин (мөдир), Г. Халит, Н. Гыйззәтуллин, Н. Ханзафаров, М. Гайнетдинов, Л. Гайнанова, Р. Әхмәтов, Ф. Бәширов эшлиләр.

Аерым язучыларның иҗат мирасларын туплап чыгаруга да зур игътибар бирелә. Н. Гыйззәтуллин, танылган язучы К. Нәҗминең улы Тансык Нәҗметдинов белән берлектә, әдип «Әсәрләр»енең дүрттомлыгын кабат бастырып чыгара (1981—1984). Ф. Ибраһимова, Н. Садыйкова, З. Рәмиев, М. Әхмәтҗанов тарафыннан Ф. Әмирхан «Әсәрләр»енең дүрттомлыгы (1984), Һ. Такташ «Әсәрләр»енең өчтомлыгы (1980—1983, төзүчеләре — Н. Садыйкова, М. Әхмәтҗанов, З. Рәмиев, Л. Гайнанова), М. Гафури «Әсәрләр»енең дүрттомлыгы (1980—1981, төзүчеләре — З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова) нәшер ителә.

1971 елдан әдәбиятчылар алты томлык фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы»н төзү эшенә керешәләр. Эшнең җитдилеген һәм күләмлелеген аңлап, аны башкаруда Казан, Ленинград, Уфа, Оренбург филолог-галимнәре дә җәлеп ителәләр.

Классикларның тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнүне уңышлы дәвам иттереп, Г. Халит «Тормыш һәм ирек җырчысы: Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турында очерк» (1980), «Поэзия дерзаний: творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов» (1980) дигән монографияләр язды.

Бүлектә эшләгәндә мин үзем дә «Формирование нового татарского романа. Конец XIX — начала XX в.» дигән темага (1989) кандидатлык диссертациямне якладым.

Татар әдәбияты тарихының актуаль мәсьәләләре буенча башка байтак китаплар һәм фәнни җыентыклар дөнья күрә. Алар арасында, мәсәлән, язма әдәбиятыбызга нигез салган урта гасырның мәшһүр шагыйре Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган «Поэт-гуманист Кул Али» (1987), аз өйрәнелгән проблемаларга багышланган «Урта гасырлар татар әдәбияты тарихыннан» (1982)

дигән фәнни мәкаләләр җыентыклары, Н.Ш. Хисамовның «Бөек язмышлы әсәр» (1984) монографиясе бар.

XIX йөз татар әдәбияты тарихы да кызыклы гына тикшеренүләр белән баетыла барды. Әйтик, шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың тууына 150 ел тулуга багышланган «Поэт-просветитель Акмулла» (1984) дигән фәнни җыентык моның ачык мисалы.

XX йөз классиклары турында Г.Халит тарафыннан язылган «Портреты и проблемы» (1985) хезмәте шулай ук кызыклы. Авторы М.В.Гайнетдинов булган «Давылларда, җилләрдә...» (1989) дигән китап күренекле шагыйрь Х. Туфанның тормыш юлы һәм иҗатына багышлана. Шул ук галим тарафыннан классикның «Лирик шигырьләр» (1986), «Стихотворения» дигән русча (Мәскәү, 1988), «Гүзәл гамь» (1990) шигырь җыентыклары әзерләнеп бастырыла. Муса Җәлил (1978), Габдулла Тукай (1979, 1997), Галимҗан Ибраһимов (1980), Галиәсгар Камал (1981), Мәҗит Гафури (1981), Гафур Коләхмәтов (1986), Һади Такташка (1983) багышлап нәшер ителгән тематик җыентыклар әлеге әдипләрнең тормыш юлын һәм әдәби эшчәнлекләрен өйрәнү юнәлешендә тагын бер адым булып тора.

1990—2000 елларда бүлек хезмәткәрләре Н.Г.Ханзафаров («Татарская комедия: истоки и развитие») (1996), Н.Ш.Хисамов («Сюжет Йусуфа и Зулейхи в средневековой тюрко-татарской поэзии XIII—XV вв. (Проблемы версий)», 1996), Ә.Г.Мәхмүтов («Формирование и развитие литературно-эстетической мысли татарского народа в конце XIX — начале XX веков», 1999) — докторлык, Р.Ф.Исламов («Төрки «Шаһнамә» (Тарихи-типологик анализ», 1992), Д.Э.Ибәтуллина («Поэтика прозы Амирхана Еники», 1993), Р.С.Зарипова («Атилла Расих иҗаты», 1998) кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Үткән гасырның азаклары татар әдәбиятындагы «ак тапларны» бетерү юнәлешендә максатчан эшләр башлану белән дә характерлы. Бу, барыннан да элек, күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы Гаяз Исхакыйның (1878—1954) әдәби мирасын яңадан кайтару белән бәйле. Л.Р. Гайнанова тарафыннан әдипнең сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре «Зиндан» исеме белән аерым китап булып басылып чыкты (1991), унбиш том күләмгә исәпләнгән «Әсәрләр»енең 1899—1908 елларда иҗат ителгән повестьләре һәм хикәяләре тупланган беренче томы (1998) нәшер ителде. (2014 елда бу хезмәт төгәлләнде. — *Ред*.). Ф.М. Мусин фактик бай архив материаллары нигезендә язучының тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеген өйрәнүгә «Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге)» дигән махсус монография багышлады (1998).

Урта гасыр һәм яңа татар әдәбияты циклы буларак күптән уйланылган һәм тиешле вакытында тәмамланган рус телендәге «Средневековая татарская литература (VIII—XVIII вв.)» (авторлар коллективы җитәкчесе һәм фәнни мөхәррире Н.Ш. Хисамов) 1999 елда басылып чыкты. Ул материалларны концептуаль анализлауга һәм тасвирлауга омтылыш белән язылган. Анда ун гасырлык төрки-татар әдәбияты һәм сәнгати мәдәнияте тулы күзаллана. Китапта шулай ук халык эпосы «Идегәй», урта гасырның монументаль ядкәре булган төрки «Шаһнамә», Казан ханлыгы чоры проза әсәре «Сиражел-колүб», Өмми Камал иҗаты һәм «Кәлилә вә Димнә» хикәятләре турында яңа очерклар да урын алган.

Урта гасыр төрки, төрки-татар язма мирасны өйрәнү юнәлешендә эш нәтиҗәле дәвам иттерелде. Р.Ф.Исламов татар әдәбияты тарихында аз билгеле булган мәмлүкләр чоры ядкәрләрен тикшерү белән

шөгыльләнеп, «Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар» (1998), «Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се (Текст һәм чыганаклар. Шигырь төзелеше һәм стиль)» (2001) дигән монографияләр бастырып чыгарды. Бу басмаларда әйтелгән җирлектә барлыкка килгән язма истәлекләр барлана, аларның ориенталистикада һәм тюркологиядә өйрәнелү, ике дәүләт арасындагы мәдәни багланышлар мәсьәләсе карала; төрки «Шаһнамә»нең чыганаклары, әсәрнең сәнгати эшләнеше ачыклана һәм ул Алтын Урда әдәбияты контекстында чагыштырма планда тикшерелә.

М.В. Гайнетдинов репрессия еллары корбаннарыннан берсе булган, бай әдәби мирас калдырган, танылган мәгърифәтче Фатыйх Кәриминең әсәрләрен туплап, бай кереш белән «Морза кызы Фатыйма»ны (1996), үзенең күп кенә мәкаләләрен, рецензияләрен һәм әдәби портретларын «Хакыйкать юлыннан (әдәби тәнкыйть)» (2001) дигән аерым китап итеп бастырып чыгарды.

Ф.К. Бәшировның «XX йөз башы татар прозасы» (2002) исемле хезмәте әйтелгән чор татар прозасының үсеш этапларын һәм шул дәвер әдәби хәрәкәтнең катлаулы халәтен ачыклауга юнәлтелгән.

«История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX в.)» (авторлар коллективы җитәкчесе һәм фәнни мөхәррире Г. Халитов) хезмәте элеккеге идеологик стереотиплардан мөмкин кадәр арыну, билгеләнгән дәверләрдәге әдәбиятны яңача фикерләү нигезендә бәяләү максатында башкарылган. Анда XIX йөз — XX йөз башы татар әдәбияты үсешенә һәрьяклы һәм тулы анализ ясала; традиция һәм новаторлык, иҗади индивидуальлек, жанр төрлелеге мәсьәләләре өйрәнелә.

Яшь галим З. Гыйлаҗевнең рус телендә басылып чыккан «Татарская литература начала XX века в книжных изданиях» (2005) дигән тикшеренүе гасыр башында иң популяр булган татар язучыларын һәм аларның китап булып нәшер ителгән әсәрләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Хезмәттә 1901—1917 елларда дөнья күргән басмаларның исемлеге дә урнаштырылган.

Бу чорда М. Гайнетдинов («Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы)», 2000), Р. Исламов («Алтын Урда һәм кыпчак-мәмлүк әдәбияты контекстында Шәрифнең «Шаһнамә»се (Чыганаклар. Поэтика)», 2002), Ф. Бәширов («Этапы развития татарской прозы начала XX века», 2002) — докторлык, Л. Гарәпшина («Сатирическое творчество Фатыха Амирхана (эпоха и герой)», 2004), З. Гыйләҗев («Татарская литература начала XX века в книжных изданиях» (2003), Ф. Миңнуллина («Юныс Сафиуллинның драматургиясе (иҗат эволюциясе)», 2004) кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Төрле гыйльми чаралар үткәрү һәм аларда катнашу — фәнни эшчәнлекнең мөһим тармакларыннан берсе. Әйтик, төрле елларда бүлекнең турыдан-туры катнашлыгында татар әдәбиятының күренекле классиклары Кол Гали (1983), Габдерәхим Утыз Имәни (1994, 2004), Мифтахетдин Акмулла (2007), Ризаэддин Фәхретдинов (1989), Габдулла Тукай (1996, 2006), Мәҗит Гафури (1980), Һади Такташ (1981, 1991), Кәрим Тинчурин (1987), Шамил Усманов (1988), Нәҗип Думави (2003), Галиәсгар Камал (2004), Шәехзадә Бабич (2005), Галимҗан Ибраһимов (1997, 2002, 2007), Гаяз Исхакый (1992, 1993, 2008), Фатих Кәрим (2009), казакъ халкының бөек әдибе һәм фикер иясе Абай Конанбаев (1995) һәм башкаларның юбилейлары

уңаеннан фәнни конференцияләр уздырылды.

Бүлек хезмәткәрләре Татарстан Фәннәр академиясе, Институт, Республика, Бөтенроссия, чит илләр күләмендә һәм төрле югары уку йортлары, фәнни оешмалар тарафыннан үткәрелгән конференцияләрдә, семинарларда, симпозиумнарда актив чыгыш ясыйлар, андый форумнарны әзерләүдә һәм үткәрүдә коллектив еш кына үзе дә катнаша. Шулай ук матбугат битләре, радио-телевидение аша киң җәмәгатьчелекне үзләренең казанышлары белән даими таныштырып баралар. Бүлек Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең төрле төбәкләре өчен дә белгечләр әзерләү белән нәтиҗәле шөгыльләнә.

Әдәбият белеме бүлегендә мөдир вазифасын, Я. Агишев, Х. Хәйри, Г. Халит, М. Гайнуллиннан соң, Н. Юзиев (1973 — 1986 еллар), Ф. Мусин (1986 — 1999; вакытлыча 2001 — 2002 еллар), Н. Ханзафаров (вакытлыча 1999 — 2001 еллар), Р. Исламов (2002 — 2006 еллар), Р. Рахман башкардылар. (Хәзерге вакытта әдәбият белеме бүлеген Ф.Ф. Хәсәнова җитәкли. — *Ред.*)

*Мәкалә Ф. Бәширов архивыннан алынды.*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Рахмани***

# «ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ»НЫҢ АЛТЫ ҺӘМ СИГЕЗ ТОМЛЫКЛАРЫ ХАКЫНДА

В статье рассматривается история создания «Истории татарской литературы» в шести и восьми томах. Вкратце приведены также содержания этих изданий, некоторые сведения об авторах статей.

**Ключевые слова:** теория литературы, история татарской литературы, «История татарской литературы» в шести и восьми томах.

Татар әдәбият белеменең соңгы кырык ел эчендәге үсеш дәрәҗәсе аның системалы һәм коллектив иҗат казанышы булган күптомлыклары — «Татар әдәбияты тарихы»ның алты һәм сигез томлык басмаларында турыдан-туры чагылыш таба. Иң элек шунысын ассызыклап үтәргә кирәк, бу ике басманың да язылуына төп этәргеч булып халкыбыз рухи дөньясында мөһим роль уйнаган тарихи вазгыять тора. Аның беренчесе ил тормышына килеп кергән Хрущев җепшеклеге елларында, ягъни җитмешенче еллар башында ук әзерләнә башлап (1979 елда аның Баш редколлегиясе һәм том редколлегияләре оештырыла), 1984 елда беренче, 1985 елда икенче томнары нәшриятта басылып чыга. Сигезтомлык исә турыдан-туры үзгәртеп кору елларындагы вазгыять алышыну — илдә урнашкан демократик сәясәт, ирекле культура үсеше тенденцияләре белән бәйле. Алтытомлык басма — әдәби казанышларыбызны әлегә күрелмәгәнчә колачлавы, аны бер система буларак күзалларга омтылуы белән уникаль хезмәт. Аны әзерләүдә татар совет әдәбият белеменең дистәләгән иң танылган белгеч-галимнәре катнашты. Биредә том җитәкчеләре итеп Ш. Абилов, М. Гайнуллин, Г. Халитов, Н. Юзиев, Н. Гыйззәтуллин, Ф. Мусин кебек абруйлы шәхесләрнең билгеләнүе генә дә күп нәрсә сөйли булса кирәк. Шул ук вакытта аларның чын совет идеологиясендә тәрбияләнеп чыныгу алган белгеч булуларын да истән чыгарырга ярамый. Әлеге басманың бишенче томы дөнья күргәч (1989), эшнең кинәт тукталып калуы һәм алтынчы томның 2001 елда гына нәшер ителүе дә һич очраклы түгел, әлбәттә. Бу совет чоры һәм үзгәртеп кору идеологиясенең бер-берсенә һич туры килмәве, ә чынлыкта, бер-берсенә капма-каршы позициядә торуы белән дә бәйле иде. Табигый ки, алдагы томнарның совет чоры идеяләре белән сугарылуы, өстәвенә, соңгы томга, алдагыларының «логик дәвамы» булуга да карамастан, икенчерәк рухтагы фикерләрнең үтеп керүе әлеге басманың әһәмиятен һәм бөтенлеген шактый төшерә. Бу хакта алда конкрет мисаллар җирлегендә киңрәк тукталырбыз, ә биредә шунысын әйтергә тиешбез: алтытомлык нинди генә сәяси кысалар эчендә өлгермәсен, ул әдәбиятыбыз мирасын барлауда һәм өйрәнүдә — егерменче гасырда дөнья күргән иң тулы, иң системалы хезмәтләрнең күренеклесе саналырга лаеклы. Ә инде моннан соң әзерләнгән сигезтомлыкка килсәк, ул — шушы беренче иҗат җимешенең кыйммәтле тәҗрибәсенә таянып, яңа заманда — егерме беренче гасыр шартларында туган хезмәт. Шуңа ул алдагы басмага күпмедер охшаш та, аңардан шактый гына аерыла да... Миңа 1998 елда алтытомлык басманың бишенче томында автор буларак катнашырга туры килгән иде, әлеге сигезтомлыкта да томнарның проект авторы, төзүчесе

һәм фәнни редакторы сыйфатында, шөкер, уртасында торып эш итәргә насыйп булды. Әлбәттә, чагыштырыр нәрсәләр шактый. Шулай да мин укучыларыбызның төп игътибарын яңа басманың иң мөһим ачкычына — аның идеологик яңа көйләнешенә юнәлтәсем килә.

Татар әдәбияты — ерак тарих төпкеленнән күтәрелгән халык авыз иҗаты һәм ике мең еллык язма мәдәниятккә нигезләнеп үскән, бүгенге дөнья сүз сәнгатендә үзенчәлекле урын биләгән күп авазлы, күпкырлы, авыр язмышлы, әмма һәрвакыт иң зур вакыйгалар уртасында яшәп килгән сизгер, тере, көрәшче әдәбиятларның берсе. Бабаларыбыз аны үзләренең рухи үсеш дәверендә биштән артык әлифба, ягъни язу төре (рун, уйгур, гарәп, латин, кириллица һ.б.) алмаштырып; берничә дәүләт (һун/хун дәүләти берәмлекләре, Төрки каганатлар, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы) корып, соңгы дәвердә исә башка милләтләр тарафыннан төзелгән дәүләт структураларына тартылып; мәдәни казанышларын төрле кыйтга (Азия, Европа, Африка), төрле тарихи, социаль, культура катламнары белән баетып, бүгенге көнгә гаҗәеп үзенчәлекле, кабатланмас бер милли хәзинә буларак китереп җиткерә алган.

Әдәбият тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә авторларның үз халыклары үткәнен, үз милли-мәдәни мирасларын мөмкин кадәр матуррак, баерак һәм борынгырак итеп күрергә теләүләре күзгә ташлана. Рухи тамырлары үсешен тирәнрәк тарихи катламнарга бәйләп аңлатырга омтылу — табигый хәл әлбәттә. Һәм һәрбер милләт моңа күпмедер лаеклы да. Бит, ахыр чиктә, дини тәгълимат өйрәткәнчә әйтсәк, бар халыкларның нәсел очы атабыз Адәм галәйһиссәлам белән анабыз Һаувага барып тоташа… Шул ук вакытта, фәнни күзлектән чыгып караганда, һәр милләтнең үзенә генә хас үсеш чоры, үсеш үзенчәлекләре барлыгын, әдәбиятларының да байлык һәм зурлык ягыннан гына түгел, язмышлары белән дә тәңгәл түгеллеген онытырга һич ярамый; сәнгать әсәрләре төрле объектив-тарихи шартларда, төрле иҗтимагый яшәеш вазифалары алып, тел, психология, фәлсәфә, эстетик аң катламнарындагы дистәләрчә компонентлар берлеге буларак оеша. Милли мәдәният һәм әдәбият үсеше турында сүз барганда, дәлилсез коры сүз, теләк, хис-эмоция, сәяси омтылышлар белән генә ерак китеп булмый — әйтелгән фикерләрнең реаль чынбарлык белән раслануы да соралып тора.

Сәнгать төре булган әдәбиятның материалы — тел, һәм аның үсү-үзгәрү хасиятләре тел тарихы белән турыдан-туры бәйләнештә тора. Белүебезчә, кеше аралашуының иң гади аваз һәм бер иҗекле сүзләрдән башланып китүе — бик табигый хәл. Аларның, мәгънә белдергән сүз берәмлекләре булып, тел арсеналында ныгып-утырып сакланып калулары да очраклы түгел. Әлеге күренеш төрле сөйләм һәм тел системалары оешуда нигез роль уйный. Бу уңайдан төрки кавем вәкиле булган татарларның аваздан мәгънәви сүз-сөйләмгә күчү рәвешен саклаучы беренче яшәеш, аралашу-аңлашу даирәсенә күз салыйк. Аның эволюцион чагылышы, тарихи эзе бүгенге телебездә дә ачык сизелеп тора.

Көндәлек тормышыбызда актив кулланылган ул сүзләр телебезнең башлангыч этапта оешкан тулы бер системасын тәшкил итә. Менә бабаларыбызның сөйләмдәге тирәяк мохитне күзаллавы: *тау, күл, кыр, саз, чүл, юл;* аларның яшәеш-хәрәкәт кыйбласы: *ас, өс, ал, арт, уң, сул;* вакыт үлчәмнәре: *ай, ел, көн, төн, таң, кич;* ел фасыллары: *җәй, көз, кыш яз;* үз-үзен танып белүе, әгъзалары: *баш, чәч, ми, төк, бит, йөз, каш, күз, тел, теш, миң, иң, кул, уч, эч, сын,*

*бил, тез һ.б.;* иң еш кулланган ризык атамалары: *ит, сөт, он, тоз һ.б.;* эчке халәте: *рух, дәрт, хис, шик, моң, уй;* фәлсәфи уйланулары: *тән, җан, кан, аң;* табигать фәлсәфәсенең нигез төшенчәләре: *җир, су, күк, ут...* Бу мисаллар күзаллавыбызны узган эраның тирән катламнарына илтеп тоташтыра һәм телебез, кавемебезнең башлангыч чоры, милли культура һәм телавыз иҗаты, әдәбиятлар үсеше турында уйланганда, һичшиксез, мәсьәләгә шактый яктылык өсти. Әлеге сүзләрне өлкәнлеккә дәгъва белдергән аерым милләтләрнең сүзләре белән янәшә куеп, аваздан мәгънәгә күчү чорларын борынгылык аспектында чагыштырып карасак, монда бик кызык һәм гыйбрәтле күренешкә тап булабыз... Һәрхәлдә, бу очракта ул телләрнең кешелек үсешендә шактый соң өлгергән тарихи катламнарда оешканлыгын һәм чагыштыруның кем файдасына сөйләвен абайлау авыр түгел. Нәтиҗә ачык: җитлеккән цивилизацияләрнең үткән культурасын таный белү, санлый белү бүгенге көндә илдә гадел, демократик милли сәясәт корылышы урнаштыруда гаять файдалы булыр иде.

Сүз сәнгатенең туу һәм үсүендә, татар халкының милли әдәбияты формалашуында мөһим роль уйнаган башка факторлар — мәдәниятебезнең фәлсәфи, психологик, эстетик компонентлары турында да, әлбәттә, киңәебрәк сөйләргә мөмкин, әмма томлыкларга алып керүче, аларга карата гомуми сүз әйтүне генә максат иткән бу мәкаләдә милләтнең татар әдәбиятына ачкыч ролен үтәгән төп парадоксаль хәл-сыйфатын билгеләп үтү белән чикләнергә туры килә: бу — аның шундый зур традицияле потенциаль кодрәткә ия булып та, ничә гасырлар дәвамында табигый саналырлык хокукларга да ирешмәве, хәтта үзгәртеп корудан соңрак чорда язма хәреф системасын камилләштерүне генә дә үз кулына ала алмавы, мәктәпләрендә ана телендә укытуны кискен чикләгән сәясәт кысаларыннан чыгарга чара тапмавы. Шушы каршылыкны ачык күзаллау гына татарның кыршауланган рухи дөньясын, әдәбиятының да зурлыгын һәм чикләнгәнлеген дөрес аңлауга мөмкинлек бирә.

Татарның дәүләтчелек тарихын искә-исәпкә алмау яисә аңа кагылышлы фактларны тискәре яктан яктырту, бу халыкның Россиягә дәүләт төзешүдә катнашуын урап үтү, реаль тарихи вакыйгаларны сәясәткә бәйле төстә берьяклы яктырту, кызганыч ки, һаман да дәвам итә, һәм ул билгеле бер дәрәҗәдә әдәбият тарихын яктыртуга да үз тәэсирен ясамый калмый. Шулай да җәмгыятебездәге үзгәртеп корулар татар әдәбиятының соңгы дистә еллардагы яңарышын гына түгел, ерак гасырлардан килгән тотрыклы мирасыбызны өйрәнү белән шөгыльләнүче әдәбият белеме фәне үсешен дә — аның тоткан кыйбласын, эш юнәлешен, структурасын тамырыннан үзгәртеп ташлады. Яңа караш әлеге фәннең төп өйрәнү сферасына заман яшәешен, заман сулышын алып керде, бүгенге мәдәни-идеологик омтылышлар белән кушылып, әдәби мирасны өйрәнү-анализлау, аны бәяләү методларын да үзенә көйләп-яраклаштырып, үзгәртеп куйды. Соңгы елларда илебездә барган тетрәнүле үзгәрешләр эзсез генә узмады, үткәнебезгә генә түгел, киләчәгебезгә дә ул өр-яңа күз белән карау һәм яшәү көчен җуеп бетермәгән милләтләргә яңа чорда яңача уйлау, хәрәкәт итү кирәклеген искәртте.

Моннан алда зур фәнни потенциалны эшкә җигеп язылган, үз вакытында биниһая кыйммәткә ия булган, гасыр дәвамында тупланган фәнни ачышларны үз эченә алган алты томлы «Татар әдәбияты тарихы» бүген инде гамәли кулланышка бәйле за-

ман ихтыяҗларын канәгатьләндерми башлады. 1984 елда чыга башлап та, соңгы томы 2001 елда гына дөнья күргән бу басманың бербөтен фәнни концепциягә нигезләнмәве укучыда шактый гына фикер таркаулыгы тудыра, чөнки соңгы берничә дистә ел эчендә чынбарлык безнең анда шактый зур үзгәрешләр дулкыны кузгаткан иде. Узган гасыр азагында чыккан әлеге китапларда бөтенләй башка формациягә яраклаштырылган идеология, күп кенә акланмаган, искергән идея-фикерләр капма-каршы якка борылган бүгенге яшәешебезгә, киләчәккә барышыбызга ныклы ориентир биреп бетерә алмый. Яңа социаль шартларда тәрбияләнгән яшь буын инде башка үлчәмнәр белән эш итә. Әлбәттә, моңа кадәр кире кагылган кыйммәтләр белән яшәүчеләр дә җитәрлек. Шуңа күрә, бер яктан, үсеп килгән буыннарның игътибарын милләтебезнең мең ел тупланган асыл рухи хәзинәсенә юнәлтү, әдәбиятыбызга бүгенге фән югарылыгыннан торып бәя бирү һәм, икенче яктан, әлеге кыйммәтләр янәшәсенә яңа заман тудырганнарын кушу, рухи мирасыбызны бөтен тулылыгында күрсәтү кичектергесез бурыч булып көн тәртибенә басты. Димәк ки, татар әдәбиятының яңартылган тарихын язу бүгенге көндә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әдәбият бүлеге галимнәренең дә чорыбыз таләп иткән мөһим бер вазифасына әверелде. Үзгәртеп коруның әдәбият фәнендәге чагылышы барыннан да бигрәк шушы җитди хезмәтне басмага әзерләү дәвамында тагын да ачыклана төште.

Рус яисә кайбер башка алдынгы халыкларныкы белән чагыштырып караганда, татар әдәбияты фаҗигалерәк һәм гыйбрәтлерәк язмышлы әдәбият сыйфатында күзаллана. Ничәмә гасырларга сузылган данлы юл узып та, әдәбиятыбыз киштәсендә әле XXI йөздә дә моңарчы үз бәяләрен алып бетермәгән яисә, чор шаукымына ияреп, урынсыз рәвештә тискәре бәяләнгән рухи җәүһәрләребез табыла тора. Шуларны тиешенчә барларга, гасырдан гасырга күчеп, дөньяның төрле архивларында чәчелеп-сибелеп калган ядкарьләрне эзләп табып, вакыты-вакыты белән өзелеп киткән әдәби барышыбыз чылбырын ялгарга тиешбез. Белүебезчә, махсус яндырылу-юк итүләр, язма культураның кысрыклануы һәм дәүләтчелексез биш йөз ел яшәү олы мирасыбызны җентекләп максатчан өйрәнү эшенә киртә куеп килгән. Совет чорында да вульгар социологизм, сыйнфый һәм атеистик идеология тәэсирендә әдәби казанышларыбызның шактый өлеше тиешле һәм лаеклы бәясен ала алмады, эмиграциядәге язучыларның иҗаты кире кагылды. Ләкин милли һәм сыйнфый изелү дәверендә дә, шулай ук сәяси эзәрлекләнү, цензура чикләүләре вакытында да татар әдипләре үз тавышларын халыкка ишеттерделәр, киләчәк буыннарга бай әдәби мирас калдырдылар. Эш әле дә, еш кына, чын энтузиастлар тарафыннан башкарылып килсә дә, милли мирас фондыбыз гаять интенсив төстә үзгәрә-тулылана. Әлеге зур байлыкны системага салу, аны җентекләп өйрәнү эше, һичшиксез, галимнәр алдына яңа җитди бурычлар куя.

Шунысы сөенечле, яңа табылган материаллар белән берлектә, милләтнең үз мирасын барлауда үрнәк һәм гыйбрәт алырлык тәҗрибәсе булу, укучыларына үз әдәби байлыгына мөнәсәбәтен кабат чагыштырып, төзәтеп, камилләштереп бирү мөмкинлегенә ирешүе фәнни культурабызның югары үсеш дәрәҗәсенә күтәрелүе хакында сөйли. Билгеле бер күләмдә ирек тоеп яшәгән соңгы ике дистә ел эчендә генә дә илебездә яңалыклар шактый җыелып

өлгерде. Күбесе — принципиаль һәм милли-мәдәни үсешнең кыйбласын билгеләгән, әдәбиятыбызның нигез ташларын тагын да тирәнгәрәк төшереп салырга ярдәм иткән яңалыклар. Аларны яңа «Татар әдәбияты тарихы»нда чагылдыру — бүгенге көннең объектив таләбе.

Әйтеп үтелгән яңалыкларның тәүгесе аерым төшенчәләргә замана салган мәгънә төсмерләре белән бәйле. Әйтик, «Татар әдәбияты тарихы» атамасындагы беренче «татар» сүзе үк инде үзенә яңа фәнни карашлардан чыгып якын килүне сорый. Белүебезчә, соңгы берничә дистә ел эчендә аның тарихи мәгънәсе дә, бүгенге тормышыбыздагы тоткан урыны да, киләчәк перспективасы да шактый яңарды. Элек, социалистик җәмгыять идеологиясе күзлегеннән караганда, милли идея, милли дәүләт фикер-төшенчәсе белдерелгән һәр язма, һәр китапка «милләтчелек» һәм аның авторына «милләтче» тамгасы сугылып килде. Ерак китәсе юк — дөнья күргән алты томлыкта, заманның иҗтимагый-сәяси шартларына бәйле рәвештә, рухи ядкарьләребезнең йөзек кашына тиң «Идегәй» дастаны турында да бер тискәре җөмлә әйтеп китү белән генә чикләнергә мәҗбүр булдык. Классик әдибебез, күренекле рухи лидерыбыз Гаяз Исхакый кебек шәхесләрнең дә иҗади һәм иҗтимагый ролен милләт үсеше тарихыннан бөтенләй сызып ташлап, дөньяда яшәгәнлекләрен кимсетүле ике җөмлә аша бәяләүдән ары уза алмадык. Бүген исә объектив чынбарлык таләбе булган милли проблема кире кагыла алмый.

«Татар әдәбияты тарихы» атамасындагы «әдәбият» төшенчәсе дә хәзер моңа кадәр зур күпчелеккә таныш булмаган бик күп ядкарьләрне сыйдыра башлады, аны сан һәм сыйфат ноктасыннан күзаллавыбызга өр-яңа үзгәрешләр өстәлде. Фәлсәфи яктан материалистик, атеистик, большевистик идеологиягә хезмәт иткән әсәрләрне генә алга чыгарып, психологик тирәнлекләргә төшмичә, әдәби әсәрләрне барлауда, нигездә, штамп фикергә иллюстрация эзләү белән чикләнеп, без аң һәм җан яшәешен, эстетик үсешебезне таш диварга китереп терәдек, чөнки ике меңьеллык әдәби ядкарьләребез, асылда — тулаем ачык иманлы, дини карашлар белән камил керешкән югары сәнгатьле рухи хәзинә. Аларның эчтәлеген бозып, берьяклы гына аңлау, матур әдәбият әсәрләрен, нигездә, атеистик тәнкыйди ноктадан чыгып анализларга һәм бәяләргә маташу әдәбият фәне өчен зур хилафлык иде. Мондый «фәнни» мөнәсәбәтнең сәнгать-әдәбият белемендә ясалма нәтиҗәләргә китергәнлеге бер дә гаҗәп түгел.

Әдәбиятка психологик һәм эстетик карашлар яктылыгыннан чыгып якын килү исә әдәбият белемен яңарту, камилләштерү ихтыяҗын тагын да арттыра төшә. Замандаш әдипләребезнең иҗаты гына түгел, классикларыбызның, шул исәптән яңа әдәбиятыбызның нигез ташларын салган даһи Тукаебызның мирасы да җентекле фәнни анализ, яңача бәяләүне көтә. Шагыйрь әсәрләренең 1946 елда Мәскәүдә «Библиотека поэта» сериясенең кечкенә форматлы китабы рәвешендә басылып чыгуы үзе үк безгә күп нәрсә хакында сөйли. Монда хикмәт кемнәрнеңдер аны олы шагыйрь буларак кабул итәргә әзерлеге җитмәүдә генә түгел… Безгә бүген, иң әүвәл, шагыйрьне рус телле укучыга үз бөеклеге дәрәҗәсендә илтеп җиткерә алу җаваплылыгын өстебезгә алу сорала. Тукайны ил һәм дөнья күләмендә бөек итеп күрсәтә белү өчен, әлбәттә, иң беренче чиратта, оригиналга лаек булган әдәби тәрҗемә һәм сәнгати-иҗат процессыннан аерылмаган, теоретик һәм методик яктан камил булган әдәби анализ кирәк.

Күптомлыкның исем-атамасына чыгарылган «тарих» сүзе шулай ук бу хезмәткә алынган галимнәргә гаять зур җаваплылык йөкли. Соңгы берничә дистә ел эчендә әдәби мирасыбыз вакыт чикләрен шактый киңәйтте: ерак һәм якын тарихи мохиттә без белмәгән дистәләрчә яңа исемнәр ачылды, тыелган, йә булмаса, милләттәшләребезнең чит республикалар мирасханәсендә адашып калган иҗаты кабат үз урынына кайтты.

Әдәбиятыбызга, фән дөньябызга соңгы егерме елда йөзләгән яшь көчләр килеп өстәлде. 1958 елда, ягъни ярты гасыр элек чыккан язучылар белешмәлегендә — 78 кеше, 1986 елда басылган белешмәлектә 350 әдип теркәлсә, 2009 елда дөнья күргән «Әдипләребез» икетомлыгында бу сан 700 гә җитә. Димәк, ярты гасыр эчендә генә дә профессиональ дәрәҗәле авторларыбызның саны ун тапкырга арткан. Табигый ки, татар әдәбияты үсешендәге мондый сан һәм сыйфат үзгәрешләре яңа фәнни басманың төп үзенчәлекләрен билгеләүче фактор булып тора.

Мәдәният һәм милли аң үсешендә тирән эз калдырган, аның билгеле бер үсеш этабын барлыкка китергән, бер яки берничә жанрда үзенең яңа сәнгати сүзен әйтү югарылыгына күтәрелгән, укучылары арасында камил, үзенчәлекле әсәрләре белән зур уңыш казанган әдипләребезнең томлыкларда аерым иҗат портретлары бирелә. Әлеге классикларыбыз иҗаты милли әдәбият гөмбәзендә төп үсеш офыкларын яктырткан якты йолдызлар вазифасын үти.

Теге яки бу чорның үзенчәлекле казанышларын, хасиятләрен үз иҗатларында ачуга ирешкән, аерым әсәрләре белән томнарның рухи йөзен билгеләргә ярдәм иткән әдипләребез иҗаты да, һичшиксез, басмада теге яки бу чорга караган күзәтү мәкаләләрендә лаеклы үз урынын алды.

Инде әйтеп үтелгәнчә, татар әдәбиятының без бүген күзаллаган ике меңьеллык үсеш тарихы укучыларыбызга бу яңа басмада һәркайсы аерым үсеш баскычын чагылдырган сигез том-китап буларак тәкъдим ителә.

*Беренче том* татар сүз сәнгатенең, безнең эрага кадәрге иң борынгы төрки чорларыннан алып, милли әдәбиятыбыз тәмам ачылып-формалашып беткәнчегә кадәрге булган иң зур вакыт аралыгын — XV гасырга чаклы дәверне үз эченә ала. Алдагы алты томлыкта Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын чагылдыруга беренче томның (1984) яртысыннан да кимрәк өлеше генә бирелгән иде. Биредә исә ул заманга караган материаллар мөстәкыйль томга әверелде; анда төрки-татар әдәбиятының калыплашкан башлангыч чор мирасы үзенең күпкырлы спектрында, дистәләрчә яңа әсәр-чыганаклар җирлегендә ачылып, тагын да тулылана, киңәя, тирәнәя төште. Бу басмада аерым төрки авторлар һәм аларның иҗат хасияте генә түгел, ул әдипләр иҗатындагы бүгенге милли әдәбиятыбызда чагылыш тапкан төп кыйблага, төп сәнгати сыйфатларга, тел-стиль үзенчәлекләренә, аларны барлыкка китергән социаль шартларга да аерым игътибар бирелде. Кыскасы, халкыбызның, бер тарихи яшәеш тореннән икенчесенә күчә-күчә, эчке рухи үсеш агымына әверелгән гомум милли хасиятен, фәлсәфи-психологик-эстетик карашларының әдәбияттаербөтен уртак чылбырга тезелү рәвешен укучыларыбыз күз алдына тулырак китерү максаты куелды.

Татар халкына, милләт буларак оешу өчен, төрле субэтник төркемнәрнең һәм этнокультураларның үзара кушылуы, яңадан-яңа катлаулы һәм сынаулы тарихи үсеш юлын үтү кирәк булган. XV—XVI гасырларда күпмедер дәрәҗәдә бер үзәккә тупланган зур кыпчак-татар иле, аерым ханлыклар-

га (Казан, Себер, Касыйм, Хаҗитархан, Кырым, Нугай) аерылып, тормышын дәвам итә. Казан ханлыгы юк ителгәннән соң, халыкның шактый өлеше, кыйпылчыклар рәвешендә, төрле якларга таралып яшәргә мәҗбүр була. Шушы кырыс тарихи вакыйгаларны чагылдырган *икенче том*ның төрле төбәкләрдә сибелеп калган әдәби ядкарьләрне барлау-җыйнаудан башлануы да һич очраклы түгел. Мондый фаҗигале тарихи катаклизмнар, әлбәттә, мәдәни алгарышта да чагылыш тапмый калмаган, әдәби үсеш тоткарлана, милли тәрәккыят һәм язма культура үзәге булган шәһәр мәдәнияте яшәүдән туктый. Бөтен бер халыкны, чоңгылга убылгандай, үзе тудырган матди һәм рухи кыйммәтләрдән аерган бу хәтәр елларны, ягъни ике гасырга сузылган бушлыкны исән-имин кичеп, җирдә үзенең барлыгын раслаган һәм әдәби традицияләрен дә саклап кала алган милләтебезнең каһарманлыгы горурлык хисләрен көчәйтә. Ул гына да түгел, аңа исән калырлык кодрәт, үлемсезлек даруы биргән көч тә нәкъ менә шул иманлы, кыйблалы әдәбият булганлыгына төшенәсең. Киләчәккә миллионлаган милләттәшләрен югалтып, иреген җуеп, кан елгалары аша кичеп атлаган милләт инде беркайчан да, сәясәт таләп итә дип кенә, империягә «үзе теләп кушыла» һәм үзбилгеләнү хокукыннан ваз кичә алмый. Аның йөрәгендә вөҗдан сакчысы, дипломатия үрнәге буларак даһи Тукае әйткән «тел, лөгать, әхлак алмашу...» «уртак ватанда шактый ук хаклы» булу тойгысы яши. Күрәбез, фаҗигале көннәрне шагыйрь монда бер дә шомартмаган, аңлар кешегә аңларлык итеп әйтеп калдырган. Бу томлык — хәтәр һәм хәвефле чорларда да үзен, телен, динен, милли йөзен саклап калган, шул исәптән әдәбиятын, мәдәниятен һәм андагы традицияләрне дә яшәтә алган милләтебез каһарманлыгына үлемсез сәнгати һәйкәл ул.

Күптомлыкның *өченче китаб*ында, өзлексез дәвам иткән канкоюлы яулардан соң, хөкүмәтнең, христианлаштыру һәм «инородец»ларны ассимиляцияләштерү сәясәтенең перспективасыз икәненә инанып, кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр булуы, шул ук вакытта Европа демократик карашларының Россиягә дә үтеп керә башлавы нәтиҗәсендә илдә беркадәр уңай сәяси-иҗтимагый шартлар туу белән бәйле чагыштырмача хәвефхәтәрсез узган елларда калкып чыккан XIX йөз татар әдәбияты үсеше яктыртыла. Ул — милләтебезнең, җан җәрәхәтләреннән арына башлап, ахирәттә һәм дөньялыкта дөрес яшәр өчен, кыйбласын актив рәвештә раслаpayларга керешкән дәвере.

Бу дәвер, зур мәдәниятнең өзелгән сабакларыннан кабат ялганып бөреләнгән үсентесе буларак, әдәби җимешләре, казанышлары әле дөньякүләм дәрәҗәдә яңгыраш тапмаса да, тамырларындагы яшәү дәрте, иман ныклыгы, үткәндәге традицияләргә, кыйбласына тугрылыгы ягыннан ул хәтта үзеннән соң килгән — мәдәниятебезнең «алтын чоры» саналган XX йөз башы әдәбиятына караганда да күбрәк сокландыра. Аның һәр әсәре сулышыннан тыелгысыз эчке яшәү энергиясе бөркелеп тора. Ул — татар рухының, олы милләтләргә генә хас булганча, дөньялыкта үзенчәлекле яңа әдәбият, яңа милли фәлсәфә булып өлгереп җитүе [Юзеев, с. 46]. Бу — татар акылының фән өлкәсендә һәр ике дөньяны үзләштерүдә нәзаригамәли сикереш ясавы, татар эстетик зәвыгының, мең еллык традиция-тамырларына табигый тоташып, өр-яңа заман нәфис әдәбияты үрнәкләрен бирүгә сәләтлелеген күрсәтүе. Бу чор милли аң формалашуда XX йөз башы татар әдәбиятына үткәннәрдән ныклы күпер хезмәтен үти. Һәрхәлдә, бу ике гасыр әдәбияты психологик эчке көйләнештә бөтенлек хасил итә, шуңа

аларны инде формаль гасыр чикләре белән генә бүлеп каравы да кыенлаша.

XIX йөз татар әдәбияты ул — Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәгърифәтчелегенең уртак төрки көрәш мәйданында үзара керешүе, дөньявилык һәм илаһилыкның бергә кушылуы, кешелек-гуманизм идеяләренең тагын да баеп, көчәеп, яктыга үрелүе; шул ук вакытта шигъри шартлылык нигезенә корылган, синкретик табигатьле бу күркәм гөл кәүсәсенең, тармакланып, тулы комплекслы әдәби жанрлар системасын барлыкка китерүе дә.

*Дүртенче том*га тупланган XX йөз башы татар әдәбияты мирасын халкыбызның һәм әдипләребезнең потенциаль иҗат мөмкинлекләрен аеруча тулы һәм калку итеп ачкан чор казанышы дип кабул итәргә кирәк. Аң-белемгә, демократиягә, милләтара тигезлеккә, милли яңарыш һәм милли азатлыкка омтылуны тоткарлаган ничәмә гасырлык богауларның беркадәр йомшаруы, «хөррият диңгезләре»нең ерылып китүе, дистә ярым ел эчендә заман таләпләренә җавап биргән күпкырлы, күп авазлы милли матбугат, югары уку йортларына тиң мәдрәсәләр барлыкка килүе һәм, иң әһәмиятлесе, шәрекъ һәм гареб культурасы казанышларын бер дәрәҗәдә үзләштереп, дөнья әдәбияты үсеше югарылыгына күтәрелгән, бөтен төрки халыкларның рухи әйдаманы дәрәҗәсенә ирешкән дистәләгән бөек классикларыбыз үсеп чыгу — болар барысы да XX йөз башы татар иҗтимагый хәрәкәтенең һәм, әлбәттә, татар мәдәнияте, татар әдәбиятының чын-чынлап бер могҗизасы булып саналырга хаклы.

*Бишенче том* Октябрь инкыйлабыннан соңгы, ягъни XX йөзнең 20—50 нчы елларында үсеш алган татар совет әдәбияты казанышларын чагылдыра. Биредә милли азатлык, тигезлек вәгъдә иткән 1917 елгы социалистик революциянең киң халык массалары арасында уяткан күтәренке энтузиазмы, эмоциональ шигъри очкыны һәм милли өметләрнең, күп тә үтми, бер-бер артлы юкка чыгарылуы — әдәбиятның рәхимсез кызыл диктатура кулына төшеп, социальсәяси идеология корбанына әверелүе һәм аның аянычлы нәтиҗәләре, шул заманның фаҗигале сәхифәләре рәвешендә, бергә үреп күрсәтелә. Бу чорда талантлы әдип, туры сүзле, намуслы гражданин булу авторларга аеруча кыйммәткә төшә, болар өчен аларның күбесе газиз гомерләре белән түләгән.

Бөек Ватан сугышы милләт һәм әдипләр алдына өстәмә яңа сынаулар куя. Каләм ияләребез фронтта үткен сүз белән дә, кулларына мылтык алып та көрәшә, шактые батырларча һәлак була. Татар әдәбияты хәвефле һәм дәһшәтле чорның иң кырыс сынауларыннан да, зур каһарманлыклар кылып, югары вөҗданын саклап кала алган хәлдә, исән-имин чыга.

*Алтынчы том* татар совет әдәбиятына 1960 нчы еллар китергән үзенчәлекле сыйфат-казанышларны анализлаган мәкаләләрдән тора. Монда, барыннан да элек, сугыш афәтләреннән берникадәр арынып, яңа, тулы канлы тормыш белән яшәргә керешкән яшь буынның, ил күләмендә килеп туган сәяси «җепшеклек» шартларында, рус һәм башка милләт шагыйрьләре йогынтысында (Е.Евтушенко, А.Вознесенский, В.Высоцкий, Р.Кутуй, О.Сулейменов һ.б. иҗатын искә төшерик), догматик идеология һәм кыршауланган норматив иҗат методы кысаларын тарсынып, иҗат ирегенә омтылуларын башлыча эстетик күзаллау, форма өлкәләренә күчереп чагылдырган эксперимент-казанышлары, иҗатларында сурәтле тасвирга күчеп, поэтик фикерләүләрендә яңача, иркен сулыш алулары күзгә ташлана.

*Җиденче том*да XX йөзнең 70—80 нче еллары татар әдәбияты

һәм аның мәдәни традицияләребезгә керткән новаторлыгы үзәккә куеп тикшерелә. Торгынлыкка каршы кабынып киткән көрәш уты — эчке ризасызлык һәм бунтның акрынлап эчтәлеккә таба, ягъни яшәештәге иҗтимагый фикер-идеяне белдерүгә борылуы, совет идеологиясенең төрле кысуларына конкрет реакция рәвешендә җавап бирү омтылышының көннән-көн көчәя баруы бу чорда үзен шактый нык сиздерә. Милли чикләүләрне тарсынып аваз биргән бер төркем шагыйрьләр иҗаты, әдәбиятка милли тарихи романнарның, тарихи публицистик әдәбиятның актив килеп керүе, үткен юмор-сатира жанрының кабат зур сәнгати югарылыкка ирешүе шул хакта сөйли. Тормышыбызда да камил әхлак нормаларының, хөр фикернең җәелә баруы әдипләребез иҗатына яңа үсеш мөмкинлекләре ача.

*Сигезенче том* ике гасыр аралыгын берләштергән яңа сыйфатлы әдәби барышны анализлауга, ягъни илдәге «Үзгәртеп кору»дан соң үзен чагыштырмача иркле тоткан әдәбиятны барлауга багышлана. Бу әдәбият, бүгенге тормышның үзе кебек үк, шактый тулы канлы, күпкырлы, күп сулышлы, каршылыклы. Шул ук вакытта ул башка чорларны да уртак бер идеякыйбла тирәсенә берләштерә, тоташтыра торган гомум бер әдәби юнәлеш рәвешендә күзалларга да мөмкинлек бирә. Сигезтомлык үзе дә шушы чор тудырган демократик шартларның бер конкрет җимеше дип бәяләнә ала.

Әлеге күптомлык басма нигездә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әдәбият белеме бүлеге коллективы тарафыннан әзерләнде. Билгеле, мондый зур фундаменталь хезмәтне дүрт-биш ел эчендә кечкенә бер бүлек хезмәткәрләре генә башкарып чыга алмас иде. Ярдәмгә, төп иҗат юнәлешләрен исәпкә алып, Казан (Идел буе) федераль университеты, Мәскәү, Уфа югары уку йортлары укытучы-галимнәре — кыскасы, соңгы егерме ел эчендә татар әдәбият белеме өлкәсенә зур өлеш керткән белгечләр тартылды.

Китап югары уку йорты студентлары, урта һәм махсус белем бирү мәктәбе укытучылары, аспирантлар, әдипләр, гомумән, әдәбиятыбыз тарихы белән якыннан кызыксынган киң катлам зыялы укучыларыбызга тәкъдим ителә. Әлеге басма, тирән ышануыбызча, татар әдәбият тарихын барлауда һәм өйрәнүдә татар әдәбият белеменең соңгы елларда ирешкән казанышларын тагын да тулырак һәм төгәлрәк чагылдырачак.

**Әдәбият**

*Юзеев А.* Философская мысль татарского народа. Казань, 2007.

***Рахмани Равил Фәйзрахман улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*З.З. Рәмиев*

# ӘДӘБИЯТ ТЕКСТОЛОГИЯСЕ

В статье рассматривается история текстологических исследований, проводимых с первых годов существования Института до сегодняшнего дня.

**Ключевые слова**: текстология, академическое издание, научное издание, Г.Тукай, Г.Исхаки, М.Джалиль, Г.Ибрагимов, Г.Камал, Ф.Амирхан, Х.Такташ, К.Насыри, Ф.Халиди.

1989 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «50 лет поисков и открытий» исемле коллектив монографиянең «Литературоведение и археография» дигән бүлегендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 1939 елдан башлап уздырылган текстологик тикшеренүләрнең тарихы шактый тулы чагылыш тапкан иде. Аның авторы — күренекле әдәбият галиме Нил Юзиев — Институтта Тукай әсәрләренең ике томдагы академик басмасы (1943;1948), дүртәр томлы «Әсәрләр»е (ике басмада: 1955—1956; 1975—1976) һәм биш томлы «Әсәрләр»е (1985—1986) мисалында (барысы да Татарстан китап нәшриятында чыкты) бөек шагыйребез иҗатының халкыбыз игътибарына басмадан-басмага тулылана төшеп тәкъдим ителүен әйтә. Н. Юзиев Ф. Әмирханның ике һәм дүрт томлы (1957—1958; 1984—1989), Г. Ибраһимовның сигез томлы (1974—1987), М. Гафуриның дүрт томлы (1980—1983), Г. Камалның ике һәм өч томлы (1950—1951; 1978—1981), Һ. Такташның өч томлы (1980—1983), К. Насыйриның ике томлы (1974—1975), М. Җәлилнең дүрт томлы (1975—1976) «Әсәрләр»ен 50 ел дәвамында Институтта башкарылган текстологик эзләнүләрнең, шулай ук, уңышлы нәтиҗәсе итеп саный. Болардан тыш, 1963 елда «Борынгы татар әдәбияты» дәреслек-хрестоматиясе, 1983 елда, ниһаять, болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы да (тәнкыйди тексты) дөнья күрә. Югарыда телгә алынган текстологик басмаларны төрле елларда матбугатка әзерләүгә катнашкан гыйльми хезмәткәрләрнең исемнәрен хөрмәт белән атап китү гаеп эш саналмас. Болар — Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев, Г. Халит, М. Гали, М. Гайнуллин, Н. Юзиев, Б. Гыйззәт, Ш. Абилов, Р. Гайнанов, Ф. Ибраһимова, Ф. Фасиев, Х. Мәхмүтев, С. Алишев, А. Әхмәдуллин, М. Әхмәтҗанов, Л. Гайнанова, Н. Ханзафаров...

Билгеле ки, 1939—1989 елларда текстологлар тоталитар совет режимы шартларында эш алып барды: классикларыбызның кайбер текстлары томнардан читләштереп килде, барыннан да бигрәк, ислам диненә мөнәсәбәтле мотивларны да чагылдырган әсәрләр басмаларга кертелмәде яисә кыскартылып урнаштырылды; аңлатмалар һәм искәрмәләрдә (комментарийларда) автор телгә алган реаль шәхесләр эшчәнлеге совет идеологиясе таләп иткәнчә генә интерпретацияләнергә тиеш булды һ.б. Еш кына текстологик эшне әдипләребезнең юбилейларына туры китереп, шактый дәрәҗәдә ашыгып эшләргә дә туры килә иде. Әйтергә кирәк, Институт җитәкчелеге текстологик тикшеренүләрне оештыру мәсьәләләрен һәрчак күз уңында тотты, вакыт-вакыт аларны гыйльми совет утырышларына чыгарды. Ә 1976 елның маенда татар әдәби мирасын

текстологик аспектта өйрәнүне заман таләпләренә туры китереп җайга салу уе белән бик мөһим бер адым ясалды: әдәбият бүлеге составында 6 фәнни хезмәткәрне эченә алган махсус структур берәмлек булдырды — текстологик төркем төзеде. Болар инде бары тик әдәбият текстологиясе белән генә шөгыльләнергә тиеш булдылар (аңа кадәр, аерым очракларда, әдәбиятчылар гына түгел, тарихчылар да, телчеләр дә, фольклорчылар да текстологик эшкә тартыла иде)...

1980 еллар ахырында СССРда коммунистик идеологиядән баш тарту нәтиҗәсендә меӊ еллык татар әдәбияты тарихын да бернинди дә чикләүләрсез өйрәнү мөмкинлеге ачылды. Октябрь революциясеннән соң мөһаҗирлектә гомер кичерергә мәҗбүр булган татар әдипләренең, зыялыларының язма мирасын барлау һәм халыкка кайтару юлында да чаралар күрелә башлады. Заманында солтангалиевчелектә гаепләнгән шәхесләрнең исемнәреннән кара тамга алынды. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар белән бер чорда яңа татар әдәбиятының нигез ташларын салган классик әдибебез, прозаик, драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның бай иҗат мирасын барлау һәм җентекләп тикшерү исә текстологик төркем хезмәткәрләре алдына кичектергесез һәм төп бурыч рәвешендә килеп басты... 1993 елның 26 апрелендә Татарстан хөкүмәте кабул иткән карарда аның әсәрләрен 15 томда әзерләү турында әйтелгән иде. Җитмеш ел буе бу бөек әдипнең әсәрләре, публицистик эшчәнлеге туган илендә өйрәнелмәде, хәтта исемен дә телгә алырга ярамады, алынган очракларда да ак эмигрант, совет хакимиятенең дошманы сыйфатында гына гәүдәләнә иде. Текстологик төркем (2007 елдан: текстология бүлеге) хезмәткәрләренең хөкүмәтебез карарын тормышка ашыру барышында күптөрле кыенлыклар белән очрашуын да әйтергә кирәк. Иӊ зарур нәрсә — Г.Исхакый каләменнән чыккан, төрле-төрле жанрларга караган әдәби һәм публицистик текстларның, аның турындагы әдәбиятның фәнни библиографиясе төзелмәгән иде (хәер, бу эшкә Һәнүз Мәхмүтов алынган да иде, әмма кинәт вафат булды, дәвам иттерүче табылмады). Чынында, текстологик тикшеренүләргә керешкәнче, әдипләр иҗаты буенча библиографик эзләнүләр инде уздырылган булырга тиешле. Әмма моны эшләрдәй фәнни көчләр, кызганычка каршы, Институт штатында каралмаган. Кыскасы, әлеге карарны әзерләгәндә пәйда булган ике битле план-проспектка туры китереп, бу томнарны (бигрәк тә, 6 нчы — 15 нче томнарын) төзү өчен Г. Исхакый текстларын күптөрле чыганаклар (китаби басмалар, газета һәм журналлар, архив материаллары) буенча эзләүгә, барлап чыгуга — «кулга төшерүгә» ифрат күп вакыт сарыф ителде. Монда әле авторлык мәсьәләсе дә алга килеп баса: публицист-журналист буларак, ул дистәдән артык псевдоним да кулланган («Татар энциклопедиясе»ндә 16 сы аталган). Г.Тукай белән янәшәдә хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы итеп Г.Исхакыйны да атыйлар. Бу — дөрес. Тик аның меӊ еллар буенча гамәлдә булган гарәп графикалы татар язуындагы текстларын бүгенге укучыга кириллицада юллаганда бәхәсле моментлар очрап тора: сүзләрне ничек язарга (әдип кулланганчамы, әллә хәзергечәме?), совет чорында читләтелгән гарәп-фарсы алынмаларына сүзлекчәләр кирәклек, дини төшенчәләрне шәрехләү һ.б. Кыскасы, басмада иҗатчының (авторның) ирек-ихтыяры (творческая воля) мөмкин кадәр тулы сакланырга, бозылмаска тиеш иде. Текстологларның аеруча да күп көчен, энергиясен сорый торган гамәл — текстларның

эчтәлеге укучыга дөрес барып җитсен өчен аларны аңлатма-комментарийлар белән тәэмин итү. Әмма Институтның текстология бүлеге галим-галимәләре, шөкер, эзләнүләрдән туктамадылар, көннән-көн аларның текстологик тәҗрибәләре артты. Бүген инде горурланып әйтергә ярый: булдырдылар. Быелгы җәйдә Татарстан китап нәшриятында Г. Исхакый «Әсәрләр»енең иң соңгы — 15 нче томы да басылып чыкты. Моңа кадәр әле бер генә татар әдибенең дә язма мирасы шушы күләмдә, шушы рәвештә киң катлау укучыларга тәкъдим ителгәне юк иде. Бу урында исә аларны төзүгә катнашканнарны «фаш итәргә» дә телим. Болар — Лена Гайнанова, Фатыйма Ибраһимова, Зөфәр Мөхәммәтшин, Гөлназ Хөснетдинова, Элмера Галимҗанова, Фәния Фәйзуллина, Гөлчирә Ханнанова, Рәшит Кадыйров (һәм мин үзем). Форсаттан файдаланып, Татарстан китап нәшрияты редакторларының да томнарны «кондициягә» китерүгә күп көч куюларын билгеләп үтәсем килә.

Соңгы 25 елда Институт текстологлары әзерләгән һәм нәшер ителгән әдәби мирас басмалары Г. Исхакый томнары белән генә чикләнми. Бу урында аларның һәрберсенә дә бәя бирергә мөмкин түгел. Әмма кайберләре, һичшиксез, аталырга тиешле. Мәсәлән, Марсель Әхмәтҗанов җитәкчелегендә ике томлы хрестоматия — «XVIII гасыр татар әдәбияты» төзелде һәм басылып чыкты. Алар белән танышканда моннан өч-дүрт гасыр әүвәле дә, нинди авыр шартларда да татар халкының әдәби иҗаттан аерылмаганына инанасың. З. Мөхәммәтшин Көнчыгышның атаклы «Мең дә бер кичә»се үрнәгендә Ф.Халиди иҗат иткән (тәмамлап өлгермәгән) «Мең дә бер сәхәр»не (311 сәхәрен) матбугатка әзерләде. Язучы «Мең дә бер кичә»нең үзен дә тәрҗемә иткән. Аны Әнисә Алиева өйрәнде (әле нәшер ителмәгән). Бу юлларның авторы да хәл кадәри хезмәт күрсәтте: ул С. Сүнчәләй, Г. Сөнгати, Г. Чыгтай бер томлыклары, «Татар шигърияте. XX гасыр башы» дигән җыентык-хрестоматиядә (антология дияргә дә ярыйдыр) китапларны төзүче, текстларны басмага әзерләүче, искәрмә һәм аңлатмалар авторы итеп күрсәтелә. Бер төркем текстологларыбыз исә, уртак тырышлык куеп, халкыбызның горурлыгы — патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең 100 еллык юбилеена (2006) биштомлы «Әсәрләре»н төзеп өлгерттеләр.

Яшерен-батырын түгел, 75 ел дәвамында Институт текстологлары әзерләп чыгарган том-том басмаларның барысы да — фәнни басмалар, әмма алар эчтәлекләре ягыннан да, текстларның һәм комментарийларның бирелеше ягыннан да фәнни басмаларның иң югары тибына — академик басмаларга куела торган барлык таләпләрне канәгатьләндереп җиткермәделәр. Нил Юзиев Тукайның 1943 һәм 1948 елларда нәшер ителгән, «академик басма» дип аталган ике томлыгын «Институт галимнәре өчен әһәмиятле казаныш» дип санаса да, аның «гадәти фәнни басма дәрәҗәсендә» калганлыгын» искәрткән иде. 1929—1931 елларда чыккан Тукай әсәрләренең өчтомлыгын әзерләгән Ф. Сәйфи-Казанлы беренче томда аны академик басма дип тәкъдим итеп караган иде дә, башкаларында ул сүзләрдән баш тартты. Кемнең-кемнең, әмма сөекле Тукаебызның мирасы академик басмада яшәүгә лаек, билгеле. Бу турыда матбугатта да әйтелеп килено (мәсәлән, 1955 елда Р.И. Нәфыйков язды). Һәм менә, ниһаять, текстологлар, Институт җитәкчелеге тәкъдиме белән, бу эшкә дә алынырга җөрьәт иттеләр. Алты томлы итеп планлаштырылган «Габдулла Тукай. Академик басма»ның 1нче томы Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшиннар, 2 нче томы З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөс-

нетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиевләр тарафыннан әзерләнеп, могтәбәр галимнәребездән гыйбарәт редколлегиядә һәм Институтның гыйльми советында тикшерелеп, матбугатка тапшырылды һәм шагыйребезнең 125 еллык юбилеена басылып чыкты (тиражы гына азрак булды кебек). 3 нче һәм 4 нче томнары да Татарстан китап нәшриятына тапшырылган. Калган ике томы буенча да төзү эшләре төгәлләнеп килә.

Институт 1967 елның декабреннән бирле Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә. Бу күренекле язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесенең иҗат мирасы моннан утыз еллар элек, совет чорында сигез томлы басмада чыгарылган иде. Әмма ул тулы түгел, текстлары да урыны-урыны белән кыскартылып бирелгән, аңлатма-комментарийларына да җентеклелек җитми. Г.Ибраһимов әсәрләренең дә тулы басмасын булдыру зарурияте күптән өлгергән. Шуны искә алып, текстология бүлеге хезмәткәрләре 2012 елда аның иҗатын 12 томда төзү эшенә керештеләр.

Институтта әдәби мирасны өйрәнүнең, текстологиянең нәзари аспектларын тикшергән хезмәтләр дә язылa. Алар XX гасыр ахырында «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш» (1987), «Әдәби мирасның яңа катламнары» (1990), «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» (1990), «Әдәби мирас: эзләнүләр һәм табышлар» (1991), «Әдәбият чыганаклары һәм текстология» (1992) исемле тематик җыентыкларда басылып чыкты. Н. Юзиевнең «Әдәбият чыганаклары белеме» (1998), З. Рәмиевнең «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре» (2000), «Текстология татарской литературы начала XX века» (2008) исемле китап-монографияләрендә дә татар әдәбияты текстологиясенә караган күптөрле актуаль мәсьәләләр үзәккә куеп тикшерелә. Соңгы елларда башлыча текстология бүлеге галимнәре хезмәтләрен эченә алган «Әдәби мирас һәм текстология» исемле җыентыклар чыгару традициясе дә туды, аларның ике чыгарылышы инде басылды да...

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,*** *филология фәннәре докторы, профессор,*
*Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***И.Г. Закирова, Ф.И. Урманчеев***

## ЭШЛӘРЕ — ҖЫР, СҮЗЛӘРЕ — ДАСТАН
## (халык иҗаты бүлегенең 75 еллыгы уңаеннан)

Статья посвящена анализу научной и научно-организационной деятельности отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Рассматриваются этапы становления и развития Казанской фольклорной школы.

**Ключевые слова:** сектор фольклора, отдел народного творчества, экспедиция, фольклорный свод, научное исследование.

Бер үк вакытта гади дә (аны күпмедер дәрәҗәдә бөтен кеше белә, фикерен белдерә ала), әмма шул ук вакытта гаятъ катлаулы да (ул әдәбият, тарих, фәлсәфә, музыка, театр, мантыйк, дин, эзотерика һәм башка фән һәм күренешләрнең катлаулы синтезын тәшкил итә, аларның күбесенең чишмә башы булып тора) фән бар. Бу — фольклор фәне. Бүген сүзебез татар фольклоры, аны өйрәнә торган фольклористика фәне һәм фольклорчылар турында. Бер сүз белән әйткәндә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һән сәнгать институтының Казан фольклор мәктәбен барлыкка китергән халык иҗаты бүлеге турында. Аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында.

Татар фольклор фәненең тарихын ике өлешкә бүлеп торган дата бар. Бу — 1939 ел.

Төрки-татар фольклор әсәрләре теркәлгән борынгы һәм урта гасырларга караган чыганаклар шактый. Татар халык иҗатына да, төрки-татар фольклорына да турыдан-туры мөнәсәбәте булган аерым сюжетларны, мотивларны, образ-персонажларның һәм әдәби алымнарның кайбер төсмерләрен ташка яки кәгазьгә теркәп калдыру VI гасырлардан башлана. Мәсәлән, шул чордан безнең көннәргә хәтле килеп җиткән Орхон-Енисей ташъязмаларында төрки-татар дастаннарының төзелеш-композициясенә бик якын торган сюжет-мотивлар, әдәби алымнар шактый киң чагылыш таба. Мәхмүт Кашгариның 1072—1074 елларда төзегән «Диване лөгатет-төрк» сүзлеге дә төрки-татар фольклорын өйрәнү өчен бай материал бирә.

Безнең көннәргә якынрак килсәк, академик В.В. Радловның (1837—1918) Себер татарлары фольклорын җыюга керткән өлешен әйтми калу мөмкин түгел. 1872 елда галимнең татар фольклоры өчен хәзерге көнгә кадәр иң әһәмиятле чыганакларның берсе булган хезмәте — «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» унтомлыгы дөнья күрә. Аның «Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар» дип аталган дүртенче томында себер татарларыннан 19 авылда җыелган йөз унбер әсәр урнаштырылган.

Татар фольклористикасының фән буларак тулысынча оешуы бөек мәгърифәтче, энциклопедист-галим Каюм Насыйри (1825—1902) эшчәнлеге белән бәйләнгән. XX гасыр башына татар фольклор фәне шактый бай тәҗрибә туплаган, гуманитар фәннәрнең тулысынча формалашкан бик тә мөһим бер юнәлеше буларак килеп җитә. Табигый ки, бу фәннең алга таба үсешендә бөек әдипләр Габ-

дулла Тукай (1886—1913), Галимҗан Ибраһимов (1887—1938), Фатих Әмирхан (1886—1926), шул чорларда ук киң танылган галимнәрдән әдәбиятчы һәм фольклорчы-теоретик Гали Рәхим (1892— 1943), Хуҗа Бәдигый (1887—1940), Фазыл Туйкин (1887—1938) һәм соңыннан олы галим, шагыйрь һәм драматург буларак танылган Нәкый Исәнбәт (1899—1992) исемнәре дә зур роль уйный.

Күпме генә эш эшләнмәсен, XX гасырның утызынчы еллары ахырына хәтле татар фольклор әсәрләрен халыктан җыю, аларны туплап бастырып чыгару, ягъни яңадан халыкка кайтару һәм фәнни нигездә өйрәнү, башлыча, стихиячел юнәлештә алып барыла.

XX гасырның беренче яртысында татар фольклористикасы тарихының икенче өлеше башлана.

1939 елда Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты ачыла, Габделхәмит Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми) үзен шунда эшкә билгеләүләрен үтенеп ВПК(б) га мөрәҗәгать итә. Шул елның декабреннән Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институтында үзе ачкан фольклор секторының мөдире булып эшли башлый. Секторның төп эш юнәлешләрен билгели. Татар фольклор фәненең олпат галиме Хәмит Ярми үзенең «Татар халкының поэтик иҗаты» дигән хезмәтендә бу вакыйганы түбәндәгечә терки: «1939 елда Казанда, Татарстан Мәгариф Халык Комиссаритаты карамагында Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылды. Бу институт янында аерым фольклор секторының оештырылуы татар халык поэзиясен билгеле бер план нигезендә һәм системалы рәвештә өйрәнүне башлап җибәрергә мөмкинлек бирде. Институтның фольклор секторы халык авыз иҗаты өлкәсендә эшләүче кадрларны үз тирәсенә туплау эшенә кереште. Махсус экспедицияләр оештыру һәм урыннардагы культура көчләрен тарту юлы белән, институт янында махсус фольклор фондын булдыру сектор тарафыннан беренче чиратта эшләнергә тиешле бер эш итеп куелды» (76 бит).

Шушы елларда фольклорчы-галим буларак формалашкан Хәмит Ярми, баштан ук әлеге секторның төп эш юнәлешләрен билгели: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен махсус экспедицияләр оештыру; аңа хәтле басылып чыккан җыентыкларда, китапханәләрдә, архивларда сакланган, бигрәк тә регуляр оештырылып килгән экспедицияләрдә җыелган фольклор текстларын басмага әзерләү һәм татар халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү.

Әнә шул юнәлешләрнең беренчесен тормышка ашыру буенча 1940 елда ук сектор мөдире Х.Ярми җитәкчелегендә Себергә академик В.В. Радлов эзләреннән махсус экспедиция оештырыла. Бу беренче экспедициянең иң җитди нәтиҗәләреннән берсе, дип, мәшһүр «Идегәй» дастанының аерым вариантларын язып алуны ассызыклап үтәргә кирәк.

1945—1955 елларда сектор оештырган фольклор экспедицияләре Татарстанның барлык районнарында йөреп, искиткеч бай материал туплый. Шуннан соң инде экспедицияләр татарлар күпләп яши торган күрше Киров, Пенза, Рязань һ.б. өлкәләргә, Мари Эл, Чувашстан, Мордовия, Удмуртия республикаларына — җәмгысы 13 өлкәгә һәм 4 республикага оештырылып, тагын да баерак, үзенчәлеклерәк материаллар туплана.

Татарстан һәм күрше өлкә-республикалардагы татар авылларын тулысынча йөреп чыкканнан соң, Хәмит Ярми сектор галимнәренең төп игътибарын Татарстаннан ераграк төбәкләрдә яшәүче татарлар иҗатын өйрәнүгә юнәлтә. Галимнең бу эше

әйтеп бетергесез мөһим һәм перспективалы булып чыга. Чөнки татар халкының дүрттән өч өлеше Татарстаннан читтә яши. Академик В.В. Радловтан соң бер гасыр вакыт узгач, татар фольклорчылары алдында халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен бөтенләй диярлек күтәрелмәгән һәм бик тә уңдырышлы «чирәм җирләр» ачыла: 1967 елдан башлап, Хәмит Ярми җитәкчелегендә киң Себер якларына фольклор экспедицияләре оештырылып, ифрат та бай һәм бик тә үзенчәлекле әсәрләр язып алына. Хәтта әйтергә мөмкин, күпсанлы экспедицияләр нәтиҗәсендә татар фольклорчыларының татар халык иҗаты, аның байлыгы, жанр төрләре, яшәү шартлары турындагы карашлары принципиаль үзгәрешләр кичерә: татар халык эпосы (Себер татарлары), бәетләр, туй-йола җырлары (Себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр), тарихи җырлар (Себер татарлары һәм мишәрләр) кебек фундаменталь фольклор төрләре җыелып, аларны өйрәнеп тикшеренүне яңа фәнни югарылыкка күтәрү мөмкинлеге туа.

Тулаем алганда, Хәмит Ярми 1940 елдан 1972 елга хәтле, ягъни 32 ел дәвамында, татар халык иҗаты секторы оештырган күпсанлы экспедицияләрнең җитәкчесе буларак, бик зур тәҗрибә туплый. Шул экспедицияләрдә катнашкан, шушы өлкәдәге хезмәтләре белән профессор дәрәҗәсен яулаган Ф.И. Урманчеев ул чорларны болай дип искә төшерә: «Хәмит Ярми оештырган экспедицияләргә әзерлек гадәттә 2—3 ай элек башланып, экспедиция үзе зур бер бәйрәм кебек оештырыла иде. Ел саен экспедицияләрдә 10—12 кеше катнашып, июнь-июль айларында, бер ай буена йөреп, халыкның көндәлек тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен, поэтик әсәрләрен җыеп, авыллар тормышында да актив катнашып, төрле лекция-докладлар, концертлар оештырып, авылларны шаулатып китә торган идек. Һәм әлеге экспедицияләрнең шулай матур һәм нәтиҗәле узуының төп сәбәпләреннән берсе — экспедиция җитәкчесенең әби-бабайлар, урта буын һәм яшьләр белән сөйләшә белүе һәм аларны сөйләтә алуы, һәрвакыт «кесәсендә тылсымлы тел ачкычы йөртүче», гомумән, кешелекле, мәрхәмәтле, җор һәм үткен телле Хәмит абый Ярми булуы иде».

Фольклор секторының икенче эш юнәлеше тупланган материаллардан киң катлам укучылар, мәктәпләр, студентлар өчен фольклор җыентыклары чыгару була. Шул ук вакытта мәсьәләнең тагын бер мөһим ягын истән чыгармаска кирәк: җитди фольклор җыентыгы чыгару өчен, барыннан да элек, конкрет материалны фәнни яктан тирәнтен өйрәнеп чыгу таләп ителә. Хәмит Ярми җитәкчелегендә эшләүче сектор галимнәре эшне бик тирәннән һәм зурдан башлый. Дөресен әйткәндә, академик В.В. Радлов, Габор Балинт, Хейкки Паасонен хезмәтләреннән соң 1940 елларга хәтле татар фольклорыннан зур күләмле һәм чын мәгънәсендәге фәнни җыентык-антология дөнья күргәне булмаган. 1940—1941 елларда Хәмит Ярми, үзенең халык алдында зур абруй казанып өлгергән бер төркем каләмдәшләре белән «Татар халык иҗаты» дип аталган 40 табак күләмендәге антология төзеп, бастырып чыгарырга әзерли.

1940 елда «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында татар халкының олы галиме Нәкый Исәнбәт татар халык эпосының йөзек кашы булган «Идегәй» дастанының җыелма версиясен бастырып чыгара. Сектор галимнәре дә бу изге эштән читтә калмый: дастанны аерым китап итеп чыгару өчен Х. Ярми җитәкчелегендә махсус комиссия төзелә, аның составына Н. Исәнбәт һәм Ш. Маннур кертелә.

Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, басмага тулысынча әзерләнгән әлеге мөһим китапларның берсе дә дөнья күрми кала...

1940 еллар уртасында ук Х. Ярми белән Г. Бәширов икетомлык «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын басмага әзерләп бетерәләр, 1946 елда ул нәшер ителә. 1956 елда шул икетомлыкның икенче китабы дөнья күрә. Әлеге басмалар татар фольклористикасында зур әһәмияткә ия принципиаль яңа төр җыентыклар булып, үзләренең фәнни әһәмиятләрен әле бүген дә югалтканнары юк. Бөек Ватан сугышыннан соң берничә ел узгач, Хәмит Ярми «Татар халык иҗаты» антологиясенә яңадан әйләнеп кайта. 1951 елда ул басылып чыга. Һәм бу адым татар фольклористикасында, әле безнең көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаган вакыйга булды, дип бәяләнергә тиеш. Китапта Хәмит Ярминең тулаем татар халык иҗатына багышланган зур күләмле монографик мәкаләсе урын алган. Аның беренче өлеше татар халык иҗатын өйрәнүгә — фольклористика тарихына багышланган. Аннан соң кереш мәкалә авторы татар фольклорының төп жанрларының һәркайсына: әкият, бәет, җыр, мәкальәйтемнәр, табышмакларга, Совет чоры фольклоры кебек катлаулы, тиешенчә өйрәнелмәгән проблемага тәфсилле фәнни анализ ясый. 1940 елдан башлап, сектор галимнәре татар фольклорының төрле жанрларына багышланган күпсанлы җыентыкларны даими рәвештә бастыра башлыйлар, халык иҗаты әсәрләреннән торган махсус һәм саллы җыентыклар чыгару эше алга таба да эзлекле һәм нәтиҗәле дәвам итә.

Сектор эшчәнлегенең өченче юнәлеше — җыелган материалларны фәнни яктан өйрәнү һәм анализлау була. Үзенең күп гомерен татар халык иҗаты әсәрләрен даими җыю, бастыру һәм фәнни өйрәнүгә багышлаган Хәмит Ярминең фәнни яктан иң мөһим хезмәте — «Татар халкының поэтик иҗаты» дип аталган зур күләмле монографиясе — 1967 елда басылып чыга.

Хәмит Ярми фәнни эшчәнлегенең тагын бер мөһим үзенчәлеге шунда — еллар үткән саен аның тикшеренүләренең эчтәлеге-мәгънәсе тирәнрәк ачыла бара. 60—70 нчы елларда Совет фольклор фәнендә ифрат җитди бер юнәлеш ачылып, төрле халыклар авыз иҗатының күптомлыкларын чыгару эше башлана. Казакъ, үзбәк, кыргыз, мордва һ.б. халыкларда шул юнәлештә беренче җитди адымнар ясала. Хәмит абый да әлеге идеяне күтәреп, күптомлыкның проспектын төзүне 1972 елдан халык иҗаты секторы мөдире итеп билгеләнгән фольклорчы-галим Илбарис Надировка тапшыра. Тиз арада татар фольклорының 12 томлык җыелмасының тәфсилле һәм чын фәнни нигездә әзерләнгән проспекты төзелеп бетә һәм сектор галимнәре күптомлыкны төзү эшенә керешә. Аның кыска җырларга багышланган беренче томы И. Надиров тарафыннан төзелеп, 1976 елда ук басылып та чыга. Өч китаптан торган әкият томнарының беренче икесен Х. Ярми һәм Х. Гатина төзиләр.

Фольклор секторы 90 нчы еллар башына тулысынча җитлеккән фәнни бүлек булып формалаша һәм Хәмит Ярми башлаган эшләрне уңышлы дәвам итеп килә. И. Надиров сектор мөдире булган елларда «Татар халык иҗаты» күптомлыгы басылып бетә. 1989 елда бу фундаменталь басманы әзерләүдә турыдан-туры катнашкан бер төркем галимнәр: Х. Ярми (үлгәннән соң), И. Надиров, Х. Мәхмүтев, Л. Жамалетдинов һәм Ф. Әхмәтова Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаеклы дип табылалар. Бу үзе бик күп нәрсә турында сөйли: күрсәтелгән күптомлык хәзер дә, киләчәктә дә ха-

лык иҗаты белән кызыксынучылар, аны өйрәнүчеләр өчен мөһим фәнни чыганак булып хезмәт итәчәк.

Хәмит Ярминең җитәкче буларак тагын бер күркәм сыйфатын әйтеп үтми мөмкин түгел: ул, халык иҗаты секторын җитәкли башлаган еллардан ук, фольклор фәненең киләчәге турында кайгыртучанлык күрсәтеп, секторга аспирантлар ала башлый. Ул җитәкләгән аспирантларның барысы да тормышларын фән белән бәйли. Алар арасында 1972—1990 елларда, ягъни 18 ел буена сектор мөдире булган филология фәннәре кандидаты И. Надиров, танылган язучы һәм фольклорчы Э. Касыймов, фән докторлары, күренекле галимнәр Т. Галиуллин һәм Ф. Урманчеев бар.

Татар халкының танылган һәм күренекле галиме, татар фольклористикасы тарихында беренче фән докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүлеге лауреаты, кеше буларак бик тә мөлаем, мәрхәмәтле, һәрвакыт киң күңелле зыялы Хәмит Ярминең (1904—1981) фундаменталь фәнни тикшеренүләре, ул төзегән күпсанлы фольклор җыентыклары, аларда урын алган саллы-саллы фәнни мәкаләләре, комментарий-искәрмәләре бүген дә фән өчен кыйммәтле чыганак булып тора. Бу хезмәтләр Хәмит Ярминең ни дәрәҗәдә киң колачлы галим булуын бик тә ачык күрсәтә.

Татар халык иҗаты бүлегенең тарихын күзәткәндә, бик тә үзенчәлекле бер фактка тап буласың — 75 ел дәвамында бу бүлекне нибары алты галим җитәкләгән: 1939—1972 елларда Хәмит Ярми, 1972—1990 елларда Илбарис Надиров. И. Надировтан соң бу вазыйфага Хуҗиәхмәт Мәхмүтев билгеләнә, әмма ул монда вакытлыча эшләп тору шарты белән генә риза була. 1992—2009 елларда Фатих Урманчеев. 2009—2010 елларда бүлек мөдире вазыйфаларын вакытлыча К.М. Миңнуллин башкара. Һәм 2011 елдан бүлекне җитәкләргә яшь, әмма перспективалы егет Илмир Ямалтдинов билгеләнә.

Фатих Урманчеев бүлекне үзе җитәкләгән чор турында болай дип искә төшерә: «Мәсьәләнең иң җитдие — күп еллар буена төзелеп һәм нығытылып килгән ышанычлы нигез булуда иде. Шул 90 нчы еллар башында бүлек алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе — фәнни кадрлар мәсьәләсе булып чыкты. Чөнки бүлек шактый «олыгайган». Анда нибары өч фән кандидаты эшли. Бер генә аспирант та, бер генә фән докторы да юк... Чын күңелдән эшкә керешкәч, мәсьәләнең бу ягы да шактый тиз хәл ителде: чөнки элек-электән бүлекнең фәнни потенциалы бик нык һәм зур иде».

Ф.И. Урманчеев бүлек җитәкчесе буларак эшчәнлеген фәнни кадрлар әзерләүдән башлап җибәрә. Шул ук вакытта бүлек хезмәткәрләре «Татар халкының этник тарихы» дигән темага фәнни-тикшеренү эшләрен башлап җибәрәләр, бүлектә эшләүче галимнәр кайсы кандидатлык, кайсы докторлык диссертацияләрен тәмамлый. Берничә ел эчендә фольклористика белгечлеге буенча Хуҗиәхмәт Мәхмүтев — докторлык, Айсылу Садыйкова, Рәшит Ягъфәров, Ленар Җамалетдинов кандидатлык диссертацияләре яклый. Шул рәвешле бүлек фәнни яктан әзерлекле, җитлеккән галимнәр белән ныгый башлый.

Бүлеккә аспирантлар кабул итү, яшь кадрлар әзерләү дә шушы ук елларда башланып китә. Халык иҗаты бүлегендә аспирантура узып, К.М. Миңнуллин 1996 елда «Татар поэзиясендә җыр жанры», Л.Ә. Кариева 2000 елда «Татар мифологиясе: тарихи-чагыштырма һәм типологик аспектта» дигән темаларга кандидат лык диссертацияләре яклыйлар. Башка

регионнарда яшәгән галимнәр белән дә хезмәттәшлек башлана. Бүлектә Төмәннән килеп В.И. Хәйруллина аспирантура уза һәм 1999 елда «Идегәй» эпосы һәм аның тарихи нигезләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

1995 елдан бүлеккә аспирантлар кабул итү планлы рәвештә алып барыла, ел саен яңа аспирантлар укырга килә, диссертациясен тәмамлаган яшь галимнәр яклауга чыга. Ф.И. Урманчеев бүлекне яшь кадрлар белән ныгыту эшен дә алып бара. 1998 елдан бүлеккә, Ф.И. Урманчеев җитәкчелегендә диссертацияләребезне яклап, Лилия Мөхәммәтҗанова белән мин дә килеп кушылдык. Бу елларда дистәләгән кеше кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый, фәнгә җитлеккән белгечләр әзерләнә. 2001 елда татар фольклоры буенча ике диссертация яклана: К.М. Миңнуллин «Сүз сәнгате буларак җыр», А.Х. Садыйкова «Ислам идеологиясе һәм татар халык иҗаты» дигән темаларга диссертацияләр яклап, филология фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗә алалар. Бүлектә шулкадәр доктор булгач, Институтның Диссертация советында фольклористика буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау мөмкинлеге дә ачыла. Ел саен Фольклористика шифры (10.01.09) буенча күп санлы диссертацияләр яклана башлый.

Фатих Урманчеев үзе берничә фәнни юнәлештә эшли. Алар — татар һәм, гомумән, төрки эпосны фәнни яктан өйрәнеп һәм анализлау, татар мифларын беренчеләрдән булып тикшерү, әдәбият белән фольклор бәйләнешләрен өйрәнү.

Ф.И. Урманчеев Омск өлкәсеннән 1962 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторына аспирантурага керү максаты белән Казанга килә. Аспирантураны уңышлы тәмамлап, 1968 елда Хәмит Ярми җитәкчелегендә «Совет чоры татар халык иҗаты жанрларының үсеш юллары» дигән темага диссертация яклап, Институтта эштә кала. Шул еллардан Фатих Урманчеевның фән дөньясында эшчәнлеге башлана. Башта ул ун ел чамасы Алабуга педагогика институтында проректор вазифасын башкара, 1980 елдан дүрт ел дәвамында Венгриянең Эгер шәһәрендә студентларга рус әдәбияты курсыннан лекцияләр укый. Галим бу елларда да фольклор фәненнән читләшми. Венгриягә китәр алдыннан монографик планда эшләнгән «Татар халкының героик эпосы» дигән зур хезмәтен нәшриятка тапшыра. Татар фольклорын бөтен Советлар иленә таныткан әлеге хезмәт 1984 елда дөнья күрә. Шул көннән ул татар фольклорчыларының гына түгел, азәрбайҗан, кыргыз, казакъ, үзбәк, нугай һәм башка халык галимнәренең дә өстәл китабына әйләнә. Төрле өлкәләрдән Казанга килгән галимнәр беренче эш итеп шул китапны үзендә булдырырга омтыла. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, галимнең соңрак чыккан хезмәтләрен дә шул ук язмыш көтә.

Ф.И. Урманчеевның татар эпосына багышланган «По следам белого волка» (1994), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999) дигән монографияләре дә дөнья күрде; «Ак Күбек», «Җир Төшлек», «Түләк», «Алпамыш», «Җик Мәргән», «Кузы Көрпәч һәм Баян-Сылу», «Алтаин Саин Сүмә» һәм башка дастаннарны тикшерүгә багышланган күп санлы фәнни мәкаләләре «Советская тюркология», «Советская этнография» журналларында басылып чыкты. Галим татар фольклорының дастан жанрын беренче булып тикшереп чыга. Ф.И. Урманчеевның 2002 елда «Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслег»е дә

вакытлы матбугат битләрендә югары бәя алды. Берничә елдан бу дәреслек белән эшләр өчен төзелгән хрестоматия да басылып чыга.

Фатих Урманчеевның соңгы елларда дөнья күргән өч томлык «Татар мифлары» дигән энциклопедик характердагы хезмәте янәдән бер тапкыр аның фәндә беренчеләрдән булуын исбатлый. Басмада татар эпосының аерым сюжетлары, мотивлар, эпик геройлар турында бай мәгълүмат бирелә. Бу хезмәт тә күпчелек төрки халыклар өчен өстәл китабына әйләнде. Хәзерге вакытта ул рус телендә басмага әзерләнә.

Алдарак әйтелгәнчә, Фатих Урманчеев җитәкче булып килү белән бүлек төп игътибарын татар халык иҗатын теоретик яктан өйрәнүгә юнәлтә. Бу елларда бүлек хезмәткәрләре зур һәм әлегә кадәр өйрәнелмәгән теоретик мәсьәләләрне тикшерүгә зур хезмәт куя.

Хуҗиәхмәт Мәхмүтев татар халкының паремияләрен тикшерә. Галимнең шушы өлкәгә багышланган «Борынгылар әйткән сүзләр (VIII—XVII йөз төрки-татар ядкярләрендә афоризмнар)» (2002), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008), «Изге китаплар кайтавазы» (2012) һ.б. монографияләре, күп санлы хезмәтләре дөнья күрә.

Ким Миңнуллин татар халык җырларын халык авыз иҗатының әдәбият һәм тел белән бәйләнеше яссылыгында тикшерә. Аларда сүзнең сихри көче белән бәйле хасиятне ача. Галимнең халык җырларының жанр үзенчәлекләренә багышланган, аларның тылсымлы табигатен укучыга җиткерүгә корылган «Шигърият һәм җыр», «Агыйделкәй», «Җырларның шигъри табигате», «Басма сүз һәм татар җырлары», «Һәр чорның үз җыры» һәм башка монографияләрен һәм җыентыкларын галимнәр генә түгел, халык та яратып кабул итә.

Айсылу Садыйкова бу чорда татар фольклор фәне өчен өр-яңа «Татар халык иҗаты һәм ислам» дигән тема өстендә эшли. Тикшеренү нәтиҗәләре буларак, аның берничә монографиясе, күп санлы фәнни мәкаләләре, фольклор җыентыклары дөнья күрә. Галимә 2001 елда «Татар халык иҗатында ислам идеологиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Айсылу Садыйкованың «Ислам һәм татар халык иҗаты» (2005), «Исламская идеология и татарское народное творчество» (2000) дигән хезмәтләрен халык яратып кабул итә, хезмәт берничә тапкыр басыла. 2014 елда шушы теманы дәвам иткән «XII—XX гасыр татар әдәбиятында дини фольклор» дигән монография дөнья күрде.

Бу чорда Ленар Җамалетдинов татар халык әкиятләрен, Рәшит Ягъфәров балалар фольклорын, Илбарис Надиров татар халык җырларын, Сәлим Гыйләҗетдинов риваять һәм легендаларны, Флора Әхмәтова дастаннарны тикшерү буенча зур эш башкара, аларның үзләре өйрәнгән жанрларны туплаган җыентыклары, фәнни монографияләре, күп санлы мәкаләләре басыла.

Табигый ки, элегрәк дөнья күргән «Татар халык иҗаты» томлыгының хәзер инде бер генә томын да һәм беркаян да табып булмый. Татар халык иҗаты җыентыкларына көннән-көн арта барган ихтыяҗны истә тотып, халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре 2000—2005 елларда татар фольклорының аерым жанрларыннан торган җыентыкларын һәм «Энҗе чәчтем — энҗе җыям» дип аталган китаплар сериясен әзерләп бастыралар.

Халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре «Татар халык иҗаты» җыелмасының 25 томлыгын әзерли башлый. Татар халык иҗаты әсәрләренең русча күптомлыгын чыгару эше башлана. Бу күптомлыкның 4 томы инде басылып чыкты.

2011 елдан бүлек җитәкчесе вазыйфалары яшь галим Илмир Ямалтдиновка йөкләнә. Шушы бүлектә аспирантурада укыган, биредә фольклор мәктәбе узган И. Ямалтдинов та бүлекнең традицион эш юнәлешләрен белеп, татар фольклор фәненең киләчәген күреп эш итә. Бу табигый да, Илмирның фәнни юнәлеше татар фольклористикасы тарихын, халык иҗаты бүлегенең эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган.

Бүлекнең соңгы еллардагы эш юнәлешләре бүгенге фольклор фәненең бөтен таләпләрен истә тотып оештырыла. Алар — экспедицияләргә чыгу, фәнни тикшеренү эшләре, конференцияләр оештыру, аларда катнашып чыгыш ясау, татар халык иҗатын пропагандалау, яшь кадрлар әзерләү, фольклор җыентыклары чыгару...

Институтның халык иҗаты бүлеге Россиянең төрле регионнарында яшәгән галимнәргә олы фән юлына чыгарга фатиха бирә торган бүлек булып та формалашты. Институтның Диссертация советына фольклористика белгечлеге буенча диссертация якларга килүчеләр биредә тикшерү узып, яклауга чыгалар. Соңгы елларда гына халык иҗаты бүлегендә тикшерү узып Новосибирскидан Н.Р. Ойноткинова, Уфадан Г.З. Имаева — докторлык, Ижевскидан Т.В. Окунева, Саранскидан С.В. Пивкина, Уфадан С.М. Кагарманова, Р.Р. Антынбаев, И.В. Имаева, Ф.Ф. Гайсина һәм башкалар кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Шунысын да искә алып үтәсе килә, бездә диссертация яклап киткән фән кандидатлары, фән докторлары хәзер үзләренең шәкертләрен дә халык иҗаты бүлегенә алып килә.

Бүлек соңгы 5 ел эчендә халык иҗатына багышланган 2 халыкара конференция оештырды. Бу конференцияләрдә чит илләрдән һәм Россиянең төрле өлкә һәм милли республикаларыннан килгән галимнәр чыгыш ясады. Ә үзебезнең галимнәребез татар фольклорының актуаль мәсьәләләренә багышланган чыгышлары белән Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайжан, Белорусия һәм Россиядә үткән Халыкара конгрессларда, симпозиумнарда актив катнашалар. Төрек, казакъ, алтай, якут, кыргыз, үзбәк, мордва, башкорт, чуваш, удмурт һәм башка галимнәр белән фәнни элемтәләр булдырып, аралашып яшиләр.

Халык иҗаты бүлеге тикшереп өйрәнү өчен материалны үзе эзләп таба торган бүлек. Сүз экспедицияләр турында бара. Халык иҗаты әсәрләре бары экспедицияләр вакытында, халыктан гына язып алынырга мөмкин.

Татар халкының бай рухи мирасын, шул исәптән халык иҗатын җыйнау эшендә яңа этап Институт директоры К.М. Миңнуллин инициативасы белән 2009 елдан башланды. Сүлпәнләнеп калган экспедицияләр, ул җитәкчелек итә башлагач, җанланып китте. Комплекслы итеп уздырыла торган бу экспедицияләрдә бүлек актив катнаша башлады. Тупланган материал аерым регион яки район җыентыкларында гына түгел, күптомлык фольклор җыентыкларын төзүдә дә файдаланыла.

Шулай да соңгы елларда бүлек алдында торган иң зур бурыч — ул әһәмияте турында күптәннән сөйләнеп килгән «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын әзерләп тапшыру. Бу эшне үз өстенә алганда бүлекнең яшь җитәкчесенә табигый рәвештә килеп туган проблемаларны хәл итәргә дә туры килде. 25 томлыкны әзерләп тапшыру өчен яңа состав тупланды. Бүлеккә яңа хезмәткәрләр алынды, аерым томнарны, заман таләпләренә яраклаштырып, өр-яңадан башларга туры килде. Хәзерге вакытта томнарны әзерләүдә бөтен бүлек катнаша, һәм, шунысы куанычлы, күпчелек томнарның бу жанрны белеп-яратып эшли торган «иясе» бар.

25 том булып әзерләнә торган туплама татар халык иҗатының барлык жанрларын эченә алган бай чыганак булачак. Бу җыелма әкиятләр, дастаннар, җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, табышмаклар, мифлар, мәкаль һәм әйтемнәр, балалар фольклоры, уен фольклоры, риваятьләр, легендалар һәм йола фольклоры томнарыннан торачак. Һәрбер том архив, соңгы елларда уздырылган экспедицияләр материалларыннан, әлегә кадәр киң катлау укучыга мәгълүм булмаган җыентыклардан тупланып, яңартылып төзелә.

Шул ук вакытта бүлек «Татар халык иҗаты»н рус телендә 15 томлык итеп бастырырга әзерли. Рус телендә «Әкиятләр»нең 3 томы, «Табышмаклар» томы басылып чыкты. «Риваятьләр» һәм «Мәкальләр» томнары редакцияләнә.

Бүлек хезмәткәрләре киләчәккә йөз тотып, киләчәк буыннар өчен дә тиңе булмаган әлеге кыйммәтле, искиткеч зур хезмәт таләп иткән тупланмаларны әзерли. Аларны бастырып чыгару безнең халкыбызның рухи мирасына һәйкәл булачак. Халык иҗаты атабабаларыбызның әйтер сүзе, акылы, тәҗрибәсе булып киләчәккә тапшырылачак.

Әйтеп үтелгәнчә, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең зур тырышлыгы, югары профессиональ әзерлеге, фидакяр фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә оештырылган һәм нык үсеп киткән халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре үзләренең остазларының бәрәкәтле традицияләрен бүген дә тырышып дәвам итәләр. Бүлек үзенең 75 еллык юбилеен бәйрәм итә. Бүлекнең фәнни потенциалы ышанычлы. Димәк, бүлекнең ныклы нигезгә корылган әлеге традицияләре алга таба да уңышлы дәвам итәр, дигән өмет бар.

Хәзерге вакытта халык иҗаты бүлеге зур булмаган, әмма тырыш, эшлекле һәм фәнни перспективалы, галим буларак фәндә үзләренең сүзен әйтә торган иҗади төркем булып формалашты. Әкиятле, дастанлы, җырлы фәнгә хезмәт итә торган төркем бу.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,*** *филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре;*

***Урманчеев Фатих Ибраһим улы,*** *филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 930.25:930.27

*М.И. Әхмәтҗанов*

# Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ КУЛЪЯЗМАЛАР МИРАСХАНӘСЕ ТАРИХЫ

В статье рассмотрена история Центра письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ.

**Ключевые слова:** история Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, татарская археография, татарская литература.

Археография борынгы язма истәлекләрне өйрәнә торган фән ул. Һәр цивилизацияле, борынгыдан язма мәдәнияткә ия булган халыкта археография фәне, аның язма мирасын төрле аспектларда өйрәнү туктап тормый. Язу текстологиясе, материалы, табылу, саклану тарихлары, кулъязма күчермәләре, кәгазь материалга язылган булса, аның материалының физик халәте, биологик чирләре, кулъязмаларга соңрак теркәлгән очраклы язмалар, язу каралары составы — бар да археография фәне буенча эшләүчеләргә мөһим тематика тәшкил итәләр.

Һәр борынгы язулы халыкның безнең заманда мәдәният тарихы буларак археография юнәлеше эшләп килә. Әлбәттә, бу эшчәнлекнең күләме милләтнең дәүләтчелеге һәм мәдәниятенең ни дәрәҗәдә үскән булуы белән бәйле.

Татар язма мирасының традицияләре безнең эрага хәтле күп гасырлар элек башланган һун-руник язуларына барып тоташа. Ләкин безнең руник язмалардагы темаларга беркетелеп калган мирасыбыз әлегә башлангыч археографияне генә тәшкил итә, без аны, әлеге мираска якынаюга кереш, дип кенә саный алабыз. Чөнки аның күләме әлегә бары югары уку йортларында борынгы язуга өйрәткән фәннең дәреслеген предмет буларак өйрәнүгә кайтып кала килде [Курбатов, б. 13—24; Нуриева, 2002; Нуриева, 2007].

Татар халкы язма мирасы археографларның игътибарын XIX йөзнең беренче чирегеннән генә җәлеп итә. Ул Ибраһим Хәлфин һәм академик Х. Френ тарафыннан 1825 елларда XVIII гасыр татар кулъязмалары буенча Әбелгази Баһадир ханның «Шәҗәрә-и төрки» һәм «Дәфтәри Чыңгызнамә» исемле ике кыйммәтле әсәрен бастырып чыгарудан башлана. Әлбәттә, Казан наширләре, XIX йөзгә кергәч, инде милләтебезнең йөзләгән дини, фәнни, әдәби китапларын бастырып чыгарып өлгерәләр һәм шул эшләре белән татар археографиясенә карата кызыксыну уяталар. Әйтик, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэддин бине Фәхретдин, Фатих Халиди, Галимҗан Баруди, Хөсәен һәм Габделгалләм Фәезхановлар, Нигъмәтулла Кармышев, Йосыф Акчурин, Рәхмәтулла Әмирхан улы, Йосыф Дибердиев һ.б. татар кулъязмаларыннан коллекцияләр туплый башлыйлар.

XX йөз башыннан татардан беренче булып профессиональ археографлар — Сәед Вахиди кебек белгечләр күренә башлый. Бу дәвергә кадәр булган археографлар, нигездә, үз аңнары белән милли хәзинәләребезне саклап калу юлында йөрделәр. Россиядә 1925 елга кадәр татар археографиясе белән дәүләт кызыксынуы булмаган. Бары

1921—1933 елларда Татарстан АССР Халык Мәгарифе комиссариаты каршында оештырылган фәнни Академик үзәктә Галимҗан Ибраһимов иҗтиһады белән татар археографик материаллары 1927 елга кадәр кабул ителә (мәсәлән, Шәехзадә Бабич архивы һәм татар халык иҗаты материаллары тупланмалары һ.б.).

Беренче профессиональ археограф С. Вахиди 1919 елда археографик экспедицияләр өчен методик анкета — кулланма әзерли. Ул үзе, 1912—1925 елларда татар авылларында укыту эшләре белән йөргәндә, 230 берәмлек борынгы кулъязма туплый һәм аларны 1925 елда Татарстан Дәүләт музеена тапшыра [Әхмәтҗан, 2009].

1929 елда Татарстанны өйрәнү җәмгыяте Минзәлә кантонына беренче фәнни археографик экспедиция оештыра [шунда ук]. Бу эштә С. Вахиди дә актив катнаша. Экспедиция бик уңышлы, нәтиҗәле булып, күп кыйммәтле фәнни археографик мәгълүматлар белән баеп кайта [шунда ук]. Нәтиҗәләре матбугатта кыскача гына мәкалә рәвешендә басыла, ләкин бүгенге көндә экспедициянең табышлары язмышы билгесез.

Әлеге еллардан соң СССРда фән һәм мәдәният хезмәткәрләренә, әдәбият-сәнгать әһелләренә карата рухи террор хөкем сөрә башлый. Бары тик 1960 еллардан соң гына акрынлап хөррият юлына аяк басабыз. Казанда яшь тарихчы М. Госманов шул елларда беренче мәртәбә, археографик экспедиция уздыру максаты белән, Себергә барып, андагы татар сөйләшләрен өйрәнеп, тарихи темага язылган бер татар кулъязмасы табып, экспедициядән бик дәртләнеп кайта. М. Госмановның диссертация җитәкчесе, аның хисабын тыңлап, киләчәктә үзенә дә археографик экспедицияләр оештыру идеясе бирә. Яшь галим бу идеяне кабул итеп, 1962 елда Волгоград шәһәре тирәсендә археографик экспедиция оештыра. Шул елдан соң М. Госманов җитәкчелегендә Казан университетының татар археографиясе төркеме Россиянең Касыйм, Оренбург, Волгоград, Себер якларындагы татар районнарына ел саен археографик экспедицияләр белән чыгып, йөзләгән кулъязма китап алып кайта башлый [Госманов, б. 34]. Аның бу экспедицияләр турындагы хисаплары академикның соңрак бастырып чыгарган калын-калын китапларында тасвир ителгәннәр. Галимнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казан федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең татар кулъязма китаплары фондында сакланучы кулъязмалар саны 12 мең берәмлектән артып китте, тик, ни кызганыч, бу зур хәзинәне тасвирлаучы затлар гына күренми.

ТӘТИ оештырылу белән үк анда милли әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә кагылышлы документлар туплана башлый. Алар 1946 елның гыйнварыннан 1949 елның 10 декабренә кадәр, керү тәртибе буенча бер дәфтәргә теркәлә барганнар. Дәфтәрдә кабул ителгән 479 исемдәге документ Институтның кулъязмалар фондын, Институтта оештырылган фәнни китапханәнең нигезен тәшкил иткәннәр. Тик, кызганыч ки, аларның сакланышына гына гарантия булмаган, шунлыктан исемлектәге күп документлар югалганнар.

Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институтында оештырылган археографик экспедицияләр һәм аларның йомгаклары хакындагы хәлләргә килгәндә, Институтның 1972 елның ахырына кадәр археографик материал туплый торган даими ышанычлы урыны да булмады. Материаллар археографларның үзләрендә сакландылар. Бары 1973 елның II кварталында гына Институтка археографик материалларны, фәнни оешманың архивларын саклау өчен СССР Фәннәр

академиясе президиумы тарафыннан аерым бүлек ачарга күрсәтмә бирелде. Архив бүлегенең җитәкчесе итеп СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Физика-техника институты фәнни хезмәткәре, профессиональ архив әзерлеге булган Хава Габдулла кызы Сайманова күчерелде. Хава ханым Физика-техника институтындагы архивта татар мәдәниятенә кагылышлы материалларны күп еллар дәвамында беренче эшкәртүче булып танылган хезмәткәр булды. Ул татар һәм рус телләрен камил белә һәм гарәп графикасындагы татар текстларын үзе укый иде. Туган телне оста белүе, кешеләргә итагатьле мөгамәләсе бу ханымга күпләрнең хөрмәтен яуларга ярдәм итте.

Ул ханым яңа урынга җитәкче булып килгәч, Физика-техника институты архив бүлегендә сакланучы безнең гуманитар юнәлештәге архив материалларыннан формалаштырылган документлар фондларыннан яңа архивка эшкәртелгән 41 фонд, 75 тасвирлама, 5843 саклану берәмлеге һәм тасвирланган фондларга кагылышлы 41 эш тапшырыла. Бу соңгысы һәр фонд эчендә барган үзгәрешләр, файдалану яки куллану ешлыгы турында төгәл мәгълүматларга бай булуы белән кыйммәтле.

Моннан тыш, әүвәл фондка кереп сакланып та, ләкин эшкәртелүгә чират көтеп яткан 30 фонд та яңа бүлеккә күчерелә. Димәк Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архив фондында, ачылган вакытта, 71 фонд һәм коллекция тупланган була инде. Бу материалларның абсолют күпчелеге татар мәдәниятенең алтын фондын тәшкил иттеләр. Шулай ук Г. Тукай, М. Җәлил, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Кәрими, Ш. Мәрҗани, Г. Рәхим, К. Насыйри, Г. Коләхмәтов, Г. Шәрәф, К. Нәҗми, Л. Җәләй, И. Рәмиев, Н. Катанов, С. Сүнчәләй, К. Тинчурин, С. Вахиди, С. Габәши, Г. Кутуй, М. Гали, Ф. Бурнаш, Һ. Йосыпов һ.б. да үз мирасларының фондларын барлыкка китерделәр. Соңыннан кергән 31 коллекция материаллары, милләтебезнең шундый ук кыйммәтле хәзинәләре булярак, эшкәртелеп тасвирландылар. 2009 елның апреленә анда инде фонд номеры куелган 1—192 фонд һәм коллекция хисаплана иде.

Хава ханым, яңа архивта эшнең күплеген күреп, анда эшләр өчен бер лаборант берәмлеге дә булдырды. Бу эшкә үзенең бөтен калган гомерен багышлаган, архив эше нечкәлекләрен тирәнтен үзләштергән Әдибә ханым Сабирова килде. Хава ханым аңа, үзенең күп еллык тәҗрибәсе белән уртаклашып, архив эше нечкәлекләрен өйрәтте.

Хәзер фондта коллекцияләр саны 210 берәмлек тәшкил итә. Ләкин аларның мирасханәгә керү ешлыгы нык кимеде. Бу кимүнең сәбәпләрен аерым көн тәртибенә куеп ачыклау кирәктер, чөнки аларның берничә төр-ле булуы мөмкин, бәлки кайсыларын безнең үтәү мөмкинлекләребез дә юктыр. Ләкин татарның Миргазиян Юныс кебек зур, киң карашлы, үзенчәлекле, кабатланмас сүз осталарының мирасын аның әдәбиятыбыз тарихында басылып чыккан хезмәтләре аша гына тулы итеп күз алдына китерә алмабыздыр. Чөнки аның кебек сүз һәм фикер остасы бүгенге көндә Россиядә фәкать рус әдәбияты дөньясында гына балкырга мөмкин.

Шулай ук Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт кебек шагыйрьләребезнең мирас язмышлары, Туфан Миңнуллин кебек классик драматургыбыз мирасларының язмышы Язучылар берлеге кысаларында гына хәл ителүе бик шөбһәле.

Ниһаять, 1986 елны Институт җитәкчелеге архив бүлекчәсен әдәбият бүлегенә кушып куйды, ләкин аннан ни файда?.. Шул елны әлеге архив

төркеме җитәкчесе вазифаларын миңа йөкләделәр.

Мин, бу эшкә алынгач та, интенсив рәвештә таралып, югалып бара торган фонд һәм коллекцияләр хәзинәләрен туплауга керештем. Хәтта Казакъстанда яшәүче татар язучысы Ибраһим Салаховның да кулъязма мирасын кайтарту идеясен күтәрдем. Бу идеяне мәрхүм җитәкчебез Нил Гафур улы Юзиев тә хуплады һәм әдипнең кулъязмаларын үзебезнең мирасханәгә кайтарту чарасын күрде. Бу архив бик зур һәм бай иде, аны алырга бүлектән аспирант Зөфәр Мөхәммәтшин җибәрелеп, ул бу эшне җиренә җиткереп башкарып чыкты, И. Салахов мирасы Казанга кайтты һәм аны фәнни эшкәртү башланып, әлегә төгәлләнми тора. Шулай ук без Петербург шәһәреннән профессор Габдрахман Таһирҗанов, Әлмәттән Саҗидә Сөләйманова, Яшел Үзәннән Мәхмүт Хәсәнов һ.б.ларның архив хәзинәләрен Мирасханәгә кайтаруга ирештек. Ләкин бу дәвердә көтелмәгән яңа кыенлыкка тап булдык. Мирасханәбез ике кечкенә бүлмәдән гыйбарәт булып, архив материалларын куярлык урын калмады.

1988 елда Институтка җитәкче булып академик Мирфатыйх Зәкиев килде. Ул Мирасханәнең мәйданын 140 $м^2$ чамасы киңәйтүгә иреште.

Якындагы ун елда без ул мәйданны, архив материалларын интенсив туплый барып, тутырдык та.

Әлбәттә, кергән материалларны эшкәрткәч аның барысы да фән өчен кабул итәрлек булмый, алардагы кабатлаулар, каралама кәгазьләр текстларын кыйммәтләре ягыннан карап чыгу мәҗбүрият санала.

Инде бу тупланган, эшкәртелгән мирасның татар әдәбият белеме фәне өчен нәрсәләр биргәнлегенә күз йөртеп чыгыйк.

Бу җәһәттән иң зур кыйммәтне татар әдәбияты классикларының күптомлы академик басмаларын булдыру юлындагы чаралар икәнлеген күрсәтеп үтү фарыздыр.

Институт нигезләнеп бер ел үтүгә (1940 елның 9 маенда) аның фәнни китапханәсенә Г.Тукайның хат үрнәкләре кабул ителгән. Шул ук елда шагыйрьнең басылмаган шигырьләре гранкасы, Шәриф Хәйрулла улы Каюмовның Тукай турындагы хатирәләре (1903—1904 елларга карый) һ.б. документлар кергәнлеккә дәлилләр бар.

Болардан тыш, Каюм Насыйри, Галиәсгар Камал, Миргазиз Укмасый, Кәрим Әмир, Мәҗит Гафурига, Сәгыйть Рәмиевкә һ.б.ларга кагылышлы кыйммәтле документлар кабул итеп алынган.

Кергән документлар арасында татар әдәбиятының алтын дәвереннән генә түгел, урта гасырлардан калган уникаль кулъязма китаплар булган. Мәсәлән, 1946 елның 14 апрелендә 446 нчы номерлы эш булып фарсы шагыйре Фирдәүсинең борынгы татар телендәге «Шаһнамә» исемле җыентыгы булганлыгы теркәлгән. Минемчә, бу кулъязманың Фирдәүси әсәре тәэсирендә язылган башка татар авторынныкы булуы ихтималы да зур. Аның Институтта эшләүче, борынгы әсәрләр белән шөгыльләнүче Латыйф Җәләй, Мөхәммәт Гайнуллин, Якуб Агишев, Хәй Хисмәтуллин кебек затлар китапханәләренә кереп калуы да мөмкин. Ник дигәндә, 1941 елда бүгенге графикада Мәскәүдә чыгырылырга әзерләнгән «Татар поэзиясе антологиясе» тупламасында Алтын Урда дәвере татар шагыйрьләренең дә фәндә мәгълүмнәре текстологик эшкәртелеп, бүгенге графикадагы корректурада чагылыш тапкан иде.

Әлбәттә, Г.Тукай әсәрләренең Ватан сугышы дәверендә әзерләнгән томнарында Мирасханәгә кергән документлар урын алмаганнар. Ләкин шагыйрьнең сугыштан соңгы дүрт томлыгында, соңрак Рашат Гайнанов тара-

фыннан әзерләнгән биштомлыгында аларга игътибар нык арткан иде.

Мәҗит Гафуриның XX гасырның 70 нче елларында төзелеп, басылып чыккан дүрттомлыгында (1980—1981), Галиәсгар Камалның өчтомлыгында (1978—1981 елларда), Фатих Әмирханның дүрттомлыгында (1984—1989) һ.б. басмаларда Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының мирас хәзинәләре киң файдаланылган. Алар узган гасырның 80 нче елларында басылган татар әдәбиятының алты томлык тарихы сәхифәләрендә (аеруча аның I—III томнарында) дә үзләренә лаеклы урынны алдылар.

Шулай ук татар фольклорының узган гасырда дөнья күргән 12 томлык басмасы Мирасханә хәзинәләренә таянып эшләнгән. Алда торган 25 томлык татар фольклоры басмасы өчен дә бездә материаллар җитәрлек, тик хәзер алар белән эшли алучы белгечләргә генә ихтыяҗ үсә бара. Бүгенге көндә татар фольклорының гүзәл үрнәкләрен Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы Фольклор үзәге хезмәткәрләре тарафыннан кварталга бер мәртәбә нәшер ителә торган «Түгәрәк уен» альманахы уңышлы пропагандалап килә. Татар фольклорына рухи ихтыяҗ Татарстаннан читтәге татар регионнарында аеруча зур.

Безнең заманда Татарстанда татар фольклор-уен сәнгатенә халыклар дуслыгы эчтәлеге салырга теләп, алардан катнаш тамашалар чыгару тенденциясе белән мавыгу бар. Ләкин бу метод дөреслектән ерак тора. Һәр халыкның фольклор сәнгатен мөстәкыйль итеп, аның үз зәвыгында уздыру кирәк. Бу безнең Татарстанда гына шулай. Кайда соң миллион ярым татар яшәгән Уфа ягының тавышы? Әллә аны кичәге угырлардан булган башкортларга сатып бетерделәрме, аңлашылмый. Мәскәү шәһәрендә 2—3 миллион татар яши, кайда аларның сәнгате? Нигә Мәскәү хакимияте аларга ярдәм итми? Бездә «Каравон»ны бик зурлап уздыралар бит әле. Халыклар дуслыгы дигән чаршау аларның сәнгате үсешен томалау чарасы булырга тиеш түгел. Дуслык ул үз дәүләтеңдәге һәр милләткә җылы караш булса гына көчле яңгырый.

Бездә соңгы берничә елда төрле регионнардагы татарлар арасына фәнни экспедицияләр уздыру традициясе җанланып китте. Бу экспедицияләр нәтиҗәләренә багышланган бай эчтәлекле басмалар чыгарылды. Мәсәлән, Түбән Новгород, Мари Элның Бәрәңге, үзебезнең Апас, Актаныш һәм Удмуртия татарларының фольклор, сәнгать, археологик табышлары киң яктыртылды. Моны Институт җитәкчелегенең бик уңышлы казанышы дип бәяләргә кирәк. Мондый экспедицияләр Кукмара, Мамадыш, Чүпрәле, Пермь краеның Барда, Әстерхан, Омск, Самара, Курган өлкәләрендәге татар районнары буенча да уздырылган иде. Инде хәзер аларның да күңел энҗеләрен, рухи хәзинәләрен күрәсе, ишетәсе килә. Һәр төбәкнең үзенә генә хас, кабатланмас бизәге була бит, аларның һәркайсы гомумтатар милли мәдәниятен үстерүгә көч бирә торган үзәкләр.

Узган гасырлардагы язма әдәбиятыбызны, мирасыбызны без борынгы кулъязма китаплар буенча өйрәнеп килдек. Хәзер археографик экспедицияләрдә кулъязма мирасыбыз өлгеләрен табу кыенлашканнан-кыенлаша бара. Башта аларны татар дошманнары «порнография», «контрреволюция», «панисламизм», «пантюркизм», «русофобия» дигән ярлыклар белән тамгалап, әзерләкләп килделәр. Алардан туплап картоннар, түбә ябу материаллары ясадылар. Аларны саклаган кешеләр каты җәзаларга тартылдылар. Ләкин болар барысы татар мәдәниятеннән көнләшеп, аны дошман күреп яшәүчеләрнең явыз эшләре икәнлеге күптән ачылды инде.

Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләренең археография өлкәсендә беренче хәрәкәтләре 1972 елдан башлана. Аңа хәтле борынгы археографик материаллар фәнни фондка очраклы бүләк итүләр, яки сатып алулар юлы белән тупланып килгән. Рәсми мәгълүматларга караганда 1972 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына 137 кулъязма күчерелә [Әхмәтҗан, 2005, б. 55].

Мирасханәгә беренче экспедиция хисабы 1969 елның җәендә Ульяновск өлкәсе, Кулаткы төбәгендәге авылларда тупланган археографик материалларны тасвирлап тапшырудан гыйбарәт. Ул хисап буенча мирасханәгә 23 берәмлек кулъязма кабул ителгән. Аларны экспедиция әгъзаларыннан фәннәр кандидатлары Мөнир Йосыпов белән Камил Дәүләтшин табып, тасвирлап саклауга тапшырганнар. Алар тапкан материаллар арасында сирәк һәм кыйммәтле кулъязмалардан XVIII гасырда күчерелгән «Мөхәммәдия», «Коръән тәфсире», «Нәһҗел-фәрадис» кебек атаклы әсәрләр бар. Ләкин, кызганычка каршы, аларның соңгысын профессор Ф. Нуриева ялгыш шифр белән күрсәткән булырга охшый...

1970 елларда шулай ук археографик экспедицияләргә әдәбиятчы Ш.Абилов та йөргән, ләкин Мирасханә хисапларында аның табышлары бу елларда күрсәтелми.

1972 елның көзендә аспирантурага кабул ителгәч, диссертация җитәкчем Ф.С.Фасиев белән Татарстанның Яшел Үзән авылларына археографик экспедициягә чыгып киттек. Башта без Казан артындагы Карагуҗа, Күлбаш, Кармыш, Синтәк, Кече Карагужа, Бишнә һ.б. авылларда эзләнүләр алып бардык. Нәтиҗәдә кызыклы шәҗәрәләр, зур күләмле «Мөхәммәдия» китабы һәм башка кулъязмалар таптык. Аннан соң маршрутыбызны Иделнең Тау ягындагы авылларга үзгәрттек. Берникадәр табышлар белән Казанга кайткач, тупланган кулъязмаларга беренче тасвирлама да төзеп, аны яңа Мирасханәгә беренче булып тапшырдык. Аларның гомуми саны йөз ун берәмлек чамасында булды.

Бу елларда Казанда атаклы татар библиофилы Мәһҗән ага Шәфигуллин яши иде. Аның фатиры Казанның хәзерге Татарстан урамында урнашкан булып, без аның белән шактый еш аралаша идек. Ул борынгы басма һәм кулъязма китаплар туплау эше белән шөгыльләнде. Бу шәхеснең мәдәниятебез тарихында тоткан күренекле урыны булганы мәгълүм. Мәһҗан ага атаклы татар сынчысы, рәссам Бакый Урманчены мәдрәсәдә укытып, аның танылган остазы булган. Бакый ага Мәһҗан хәлфәнең гүзәл портретын ясаган (1971 ел). Әлеге портрет бөек рәссамнең 90 еллык юбилеена багышланган иҗади эшләре каталогына да кертелгән иде [Баки Урманче, с. 16]. Институт җитәкчелеге бу библиофилдан 103 кулъязмасын сатып алды. Алар хәзерге көндә 39 коллекциядә 340—442 нче номерлы шифрлар белән билгеләнделәр. Аларны филология фәннәре кандидаты (хәзер фәннәр докторы) Әнвәр Шәрипов 1974 елның 8 апрелендә, тасвирлап, Мирасханәгә тапшырган.

Моннан тыш, Казан артындагы Дөбъяз авылында күренекле библиограф Касыйм Әхмәтшин яшәде, ул да бөтен СССР белән диярлек бәйләнештә булып, кызыклы татар басма һәм кулъязма китапларын туплап, файдалы эш эшләде.

1970 елларда Институтка аспирантурага укырга кергән Мәсгуд Гайнетдинов, Рәфис Әхмәтов, Әнвәр Шәрипов, Илдар Ваһапов һ.б. 1990 елларга кадәр азмы-күпме археографик материаллар белән кызыксынып, беркадәр җанлылык күрсәттеләр.

Ләкин 1990 еллардан соң археографик экспедицияләргә чыгу сүлпәнләнде. Ул миңа гына йөкләнгән эш кебек калды. Бу елларда мирас хатирәләрен туплау психологиясе, безнең Мирасханәдә урын тарлыгы һәм кадрлар кытлыгы белән дә бәйле иде. Шулай да бер көтелмәгән уңыш та насыйп булды. Бүлегебез җитәкчесе профессор Н.Г. Юзиев Казан университетында укыткан елларында бер төркем студентлары белән Пермь өлкәсендәге (хәзер — крае) татар районнарына археографик экспедиция (1963 елда) оештырып, 4251—4362 номерлы шифр белән тамгаланган кульъязмаларны 1992 елларда Мирасханәгә бүләк итеп тапшырды (барысы 112 берәмлек кульъязма) [Ахметзянов, 2013, с. 104—150].

Археографлардан алынган археографик материал татар җәмәгатьчелеген кызыксындыра иде, читтә андый кульъязма табышларга юлыксалар, безнең белән телефон аша, хат аша элемтәгә керәләр, киңәш, табыш итәләр. Ләкин, икенче яктан, Татарстаннан читтәге өлкәләрдә яхшы сыйфатлы кульъязмаларны, китапларны кеше мәчетләргә тапшыра, ә тегеләре чит-ят илләрдән, аеруча Кавказдан килгән мөселманнарга сатып, акча эшләү юлына да бастылар.

Соңгы елларда кульъязма мирасыбыздан аеруча шәҗәрәләр халык күңелендә урын алды. Шәҗәрә — нәсел язулары, татарның борынгыдан килгән мәдәни традициясе, һәркем үзенең ерак бабалары турында мәгълүмат белергә тели. Шунлыктан минем тарафтан туплап, текстологик эшкәртелеп чыгарылган китап-җыентыклар халык арасында популяр булып китте. Авылларда җирле тарихчылар кызыксынып, архивлардан эзләп табып, шәҗәрәләр төзеп, йөзләгән китаплар бастырып чыгардылар.

Хәтта укучы балалар арасында мәктәпләрдә шәҗәрә конкурслары оештырып, Республикада ике мәртәбә шәҗәрәләр конкурсы уздырдылар. Җиңүчеләргә бүләкләр бирелде. Татар шәҗәрәләренә кызыксыну үсү күршедәге халыкларның да генеалогиягә игътибарын арттырды.

Шәҗәрәләрнең этник тарихыбызны барлауда да ярдәме зур.

Борынгы кульъязмалар язмышы СССР Фәннәр Академиясенең игътибар үзәгендә булды. Шуңа күрә 1980 елларда Мәскәүдә һәм Ленинградта археографик конкурслар уздыру, фәнни конференцияләр оештыру активлашып китте. Минем үземә, 1987 елның май—июнь айларында Мәскәүдә уздырылган күргәзмәгә җибәргән материалларым өчен, РСФСР Министрлар Советы Баш архив идарәсенең Мактау грамотасы бирелде. «Кыйсса-и Йосыф» кульъязмасы да Союзда табылган материаллар арасында икенче дәрәҗәдәге кыйммәткә лаек дип табылды. Мирасханәнең эшчәнлеге чит илләрдә басылган фәнни әдәбиятта да танылу ала. Мәсәлән, аның хәзинәләренә немец һәм инглиз телләрендә чыккан, татар рухи тормышын өйрәнүгә багышланган капиталь моноргафик хезмәтләр дәлил булып торалар [Кемпер, с. 144, 541, 459; Франк, с. 11].

Әлбәттә, әлеге хезмәтләрдә татар халкының XVII — XIX йөзләрдә башыннан кичкән авыр, хәсрәтле заманнар милләтебезнең дини карашлары яктылыгында чагыла. Татар галимнәренең дөньяви тешенчәләргә багышланган фикерләре дә дини пәрдәләргә төрелеп бирелә, чөнки, XIX гасырда гына түгел, XX йөзнең беренче чирегендә әле татар менталитеты ислам идеологиясеннән азат булмый. Бу фикерне без XX йөзнең икенче яртысында да әле җитәрлек дәрәҗәдә сакланып калган археографик материалларга таянып әйтәбез. Аларда дөньяви фикерләү, ислам идеологиясе кысаларыннан бик аз аерыла һәм денсезлек зәхмәте төсмерендә чагыла. Гасырлар буе формалашкан этик норма-

ларны бер сугуда гына юк итәргә һич мөмкин түгел. Ул борынгы әхлакый һәм рухи бәяләрне эзлекле мантыйк кысаларында анализларга өйрәнергә тиешбез. Мәсәлән, XX гасыр татар укымышлысының дини карашлардан йөз процент азат булган менталитеты турында сөйли алмыйбыз.

Нәрсә өчен кирәк соң мондый катлаулы фәлсәфи карашларны өйрәнү?! Алар, беренче чиратта, мең еллар буе үсә килгән фикри камиллекне тану өчен кирәк, чөнки татар теле дә, гасырлар буе чарланып, теләсә нинди фәнни фикерне формалаштырып җәмгыятькә җиткерә алган. Аның нинди чуар, буталчык заманнардан да югалмыйча 400 еллар аша килүен алман галимнәре бик дөрес тотып ала.

Археографик эзләнүләребез нәтиҗәсендә әдәбият тарихыбыз, XX йөзнең соңгы чирегенә караганда, күп яңа чыганакларга баеды. Аеруча Казан ханлыгы дәвере әдәбияты яңа чыганакларга — Кол Шәрифнең, Атнаш хафиз, Мөхәммәд Әмин хан, Үтәмеш хаҗиның һ.б. электә бу контекстта билгеле булмаган авторларның әсәрләре хисабына тулыландылар.

Шулай ук XVII — XVIII йөз әдәбиятыбызда яңа ачылган чыганаклар әйләнешкә керәләр. Бу җәһәттән татар халык язма әдәбияты үрнәкләренә әйләнгән «Таһир—Зөһрә», «Ләйлә-Мәҗнүн», «Хурнуга һәм Һәмра», «Чура батыр», «Ана белән угыл», «Кыйсса-и Сәкам», «Кыйсса-и Авык», суфичылык әхлакый тәрбия мәктәбе булган Һәмдәми (Мулла Мамай) поэзиясе һ.б. әсәрләр борынгы әдәбият репертуарыбызны гаҗәеп баеталар.

XXI гасырга кергәч татар археографиясендә борынгы кульязмаларга тасвирламалар язу процессы активлашты. Бу дәвердә мин үзем дә 3400 берәмлек кульязмага тасвирлама төзедем, шуларның 3000 берәмлеге биш китап булып басылып чыкты. Фарсы телендәге кульязмалар тасвирламасының өч җыентыгы, С.М. Гыйләҗетдинов тарафыннан төзелеп, басылып таралдылар.

Борынгы әдәби язма мирасыбызга, археографиягә игътибар арту Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршында соңгы елларда шагыйрь Г.Утыз Имәнигә, «Коръән» кульязмаларын һәм еллык эш йомгакларын өйрәнүгә багышланган фәнни конференцияләр уздыруда да күренә.

Бу җәһәттән шулай ук урта гасырларда яшәгән Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, Мәүла Колый кебек поэзия осталарының биографияләренә кагылышлы конкрет фактларның әйләнешкә керүләре зур әһәмияткә ия.

XXI гасыр башларына кергәндә татар археографиясенең яңа уңышларын җәмәгатьчелеккә күрсәтергә мөмкин булды. Бу дәвердә татар кульязма хәзинәләреннән шәҗәрәләр һәм кульязма әдәбиятыбыз турында минем үземнең ике монографик хезмәтем фәндә яңалык булып басылып чыктылар [Ахметзянов, 1991; Әхмәтҗанов, 2000]. Шулай ук татар мифологик әдәбиятын тәртипкә китергән беренче фәнни җыентыгым нәшер ителде [Әхмәтҗанов, 2000]. Археографик экспедицияләр алып бару процессында табылган йөзләрчә шәҗәрә текстлары басылып чыктылар [Әхмәтҗанов, 1995; Әхмәтҗанов, 2002; Әхмәтҗанов, 2009; Әхмәтҗанов, 2012]. XVIII йөздә иҗат иткән утыздан артык каләм осталарыбызның мираслары тәкъдим ителгән, иҗатлары һәм исемнәре беренче мәртәбә табылып, текстологик эшкәртелгән хезмәтләрем дә укучы кулына барып иреште.

Узган гасырның соңгы елларында татар археографиясен үстерүдә кыенлыклар да күп булды. Аеруча авыры — кульязма мирасны саклау урыннары җитмәү иде. Ләкин бу проблема Татарстан Республикасы президенты М.Ш. Шәймиев катнашлыгында уңай хәл ителде.

Минем үземә археография юнәлешенә специальләшкән биш аспирант әзерләп, аларның фән кандидатлары булуларын күрергә насыйп булды.

Татар археографиясе фәне ул Г. Тукайга тиң меңләгән шагыйрьләребез язмышын колачлый. Тел юнәлешендә ничә эш төркемнәре оештырылганда, нигә әдәбиятка да шундый мөмкинлек тудырмаска. Татар әдәбиятын өйрәнү өчен 120—130 белгечтән торган Фәнни-тикшеренү институты төзеп тотканда да күп булмас иде.

Иң үкенечлесе — Тукай үлгәнгә күптән йөз ел тулып узса да, әлегәчә бөек шагыйребезне реаль тану бездә юк әле. Тукай иҗатына аның әсәрләрен механик уку белән генә кереп булмый, ул яшәгән ситуацияләрне кичереп, күңелеңнән уздыру фарыз.

**Әдәбият**

*Ахметзянов М.* Татарская археография. Описи рукописей, собранных во время археографических экспедиций (1972—2012 гг.). Ч. 3. Казань, 2013.

*Ахметзянов М.* Татарские шеджере. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991.

*Әхмәтҗан М.* Мәгариф, археографик эзләнүләр. Казан, 2009.

*Әхмәтҗанов М.* Татар кульязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.

*Әхмәтҗанов М*. Татар археографиясе. Казан: Татар. кит. нәшр. 2000.

*Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Әхмәтҗанов М.* Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: Мәгариф, 2002. Беренче китап.

*Әхмәтҗанов М.* Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Икенче китап.

*Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. I том.

*Әхмәтҗанов М.* XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006.

*Әхмәтҗанов М.* XVIII йөз татар әдәбияты. Проза. Казан, 2012.

*Әхмәтҗанов М.И.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан, 2005.

Баки Урманче: Каталог юбилейный художественной выставки. Казань. 1987.

*Госманов М*. Каурый каләм эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

*Кемпер М.* Суфии и ученые в Татарстане и Башкортстане. Исламский дискурс под русским господством. Казань, 2008.

*Курбатов Х.* Татар теленең алфавит һәм археография тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Нуриева Ф*. Борынгы төрки рун язмалары: Күлтәгин һәм Төньюкук ташлары // История татар с древнейших времен. Казань, 2002. Том. I.

*Нуриева Ф.Ш.* Борынгы төрки тел. Орхон-Енисей язмалары теле (VII—XIII гасырлар). Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007.

*Франк А.* Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России. Казань: РИУ, 2008.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

***И.К. Заһидуллин***

# 1940—1990 ЕЛЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА ТАРИХ ФӘНЕ ҮСЕШЕ СӘХИФӘЛӘРЕ

Статья посвящена основным вехам развития исторической науки в ИЯЛИ им.Г. Ибрагимова на примере деятельности сотрудников отдела истории.

**Ключевые слова:** ИЯЛИ им.Г. Ибрагимова, история Татарстана, история татарского народа.

1917 елгы октябрь инкыйлабы, аңа кушылып киткән гражданнар сугышы һәм интервенция еллары Казан губернасында һәм гомумән Россиядә гуманитар фәннәр үсешенә нык тискәре йогынты ясый. Шушы болганчык чорда бер төркем татар галимнәре (Г. Баттал, С. Максуди һ.б.), ватаннарын калдырып, чит илләргә китеп сыенырга мәҗбүр була.

Фәкать 1920 елда, Татарстан автономияле республика булып оешкач, туктап калган тарихи эзләнүләр җанланып китә. Бу юнәлештә 1921 елда ТАССРның Халык мәгарифе халык комиссариаты каршында ачылган Академик үзәк зур тырышлык куя. Фәнни эзләнүләрнең эзлекле юнәлешен билгели, яңа фәнни оешмалар, структуралар булдыра, монографияләр һәм татар мәктәпләре өчен дәреслекләр язу һәм бастыруга Мәскәү һәм Ленинградның олуг галимнәрен җәлеп итә, җирле фәнни кадрлар әзерләүне башлап җибәрә.

Шул ук елны Казанда Көнчыгыш академия һәм аның каршында «Көнчыгышны өйрәнү фәнни җәмгыяте» оеша, ул 1923 елда исемен һәм концепциясен алыштыра. — «Татарны өйрәнү фәнни җәмгыяте» (1923—1931) канаты астында күпсанлы галимнәрне һәм җәмәгать эшлеклеләрен берләштереп, эшен Академик үзәк җитәкчелегендә алып бара. Әйтергә кирәк, бу җәмгыять тиз арада үз тарафдарларын туплый: анда әгъза булып 98 галим тора, шул исәптән 14 шәрәфле әгъза, 74 хакыйкый әгъза, 10 хезмәткәр була. Җәмгыять төрле төбәкләр белән элемтәләр урнаштырып, СССРның 120 фәнни оешмасы белән элемтәдә тора. 1920 еллар азагында ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары нигезендә Татарстанны өйрәнү үзәге оештырыла, ул Татарстанның табигатен, халкын, аның тормыш-көнкүрешен, тарихын, мәдәниятен, җитештерү көчләрен һәрьяклап өйрәнүне максат итеп куя. Шулай итеп, татар халкының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү, ТАССРның гына түгел, элеккеге Казан губернасы чикләрен иңләргә тиеш, дип ассызыклана.

1920 еллар башында татар тарихын һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнү юнәлешләрдә Г. Ибраһимов, М. Худяков, В.Ф. Смолин, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Сәгъди, Ж. Вәлиди, Н.И. Воробьев һ.б. ларның хезмәтләре языла, дөнья күрә. Шулар арасында Г. Гобәйдуллинның «Татар тарихы» [Татар..., 1922] исемле хезмәтен — татар халкы тарихын беренче тапкыр Европа тарих фәне традицияләренә нигезләнеп язу вакыйгасын, шулай ук М. Худяковның «Очерки по истории

Казанского ханства» [Худяков, 1923] китабын махсус билгеләп үтү урынлы булыр. Г. Гобәйдуллин һәм Г. Рәхим авторлыгында татар әдәбиятының күпгасырлык тарихын колачлаган фундаменталь хезмәт татар мәдәниятен өйрәнүдә алгарыш буларак бәяләнергә лаек [Татар әдәбияты тарихы; Татар..., 1922].

Ләкин 1930 елларда илдә башланган репрессияләр нәтиҗәсендә күп кенә галимнәр эш урыннарыннан алынып, зинданнарга ябыла, сөргенгә җибәрелә, юк ителә. Икенче бер төркем галимнәр (Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин), эзәрлекләүләрдән качып, илнең башка төбәкләренә, республикаларга күченеп китә гыйльми эшчәнлекләрен яңа урында дәвам итәләр.

Мәгълүм булганча, 1939 елда ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары белән ачылган Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты алдында совет хакимиятенең канлы репрессияләреннән соң туздырылган, бушап калган фән мәйданын тергезеп җибәрү бурычы куела. 1941 елдан Татар тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты исеме астында эшләүче бу оешма составында тарих секторы пәйда була. Бөек Ватан сугышының беренче елында секторда бер хезмәткәр — мөдир А.А. Тарасов кына исәпләнә. Шуңа күрә тарих бүлегенең чын мәгънәсендә эшләп китүе 1944 елдан башлана: эшкә Е.И. Чернышев, А.Н. Григорьев, Х.Г. Гыймади чакырыла.

1945 елда кыска гына вакытка аерым этнография секторы оешып ала [Файзрахманов, 1989, с.103].

Җиң сызганып эш башлаган тарих бүлеге хезмәткәрләре арасында 1943 елда әле 7 фәнни хезмәткәрнең берсе генә тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була.

1946—1959 елларда сектор белән Хәйри Гыймади җитәкчелек итә. (1961 елда тарих секторыннан археология һәм этнография секторы аерылып чыга.) Сугыштан соң узган егерме елда тарих бүлеге нинди темалар белән шөгыльләнгән, нинди уңышларга ирешкән соң?

Сугыштан соң биредә Х.Г. Гыймади, А.Н. Григорьев (секторның беренче мөдире), Е.И. Чернышев, А.А. Тарасов, археолог Н.Ф. Калинин, этнограф Н.И. Воробьев гыйльми эшчәнлекләрен дәвам итәләр. Читтән торып эшләргә Е.И. Устюгов һәм И.М. Климов чакырыла.

1946 елның апрелендә ТӘТИ ның киләчәк үсеш юнәлешләре КПСС Өлкә комитеты бюросында тикшерелә. Шул ук елны Татарстан тарихын язу өчен редакция комиссиясе төзелә, аспирантура ачыла.

Коллектив, фәнни хезмәт язуда беренче нәтиҗәле тәҗрибә буларак, борынгы заманнан алып, 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәрге чорны колачлаган һәм 1948 елда дөнья күргән «Материалы по истории Татарии» дигән мәкаләләр җыентыгын әзерләп бастыра.

Шундый ук вакыт аралыгын үз эченә алган «Татарстан АССР тарихы»ның 1 нче томы исә 1951 елда дөнья күрә. Ул гаять катлаулы шартларда, Коммунистлар партиянең көчле цензурасы астында языла: ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 ел, 9 август карарында, ТӘТИ галимнәренең «Идегәй» дастынын өйрәнү мисалында, Институт та, фикер ияләре дә, хаксыз рәвештә, Алтын Урда тарихын идеаллаштыруда, милләтчелектә гаепләнә. Китап басылгач, КПСС өлкә комитеты газетасы «Красная Татария»да дөнья күргән беренче томга каршы катгый тәнкыйть мәкаләсе китапның 10 мең данәсен юк итүгә китерә [Файзрахманов, 1989, с.111]. Хезмәтнең «төзәтелгән» варианты 1955 елда гына кабат дөнья күрә [История..., 1955]. Биредә татар тарихының барлык чор-

лары да яктыртыла диярлек, дөрес, материал «кыскартылган» рәвештә бирелә. Әйтик, борынгы община чорыннан соң борынгы төрки чор «сикертеп үтелә» һәм вакыйгалар Идел буе Болгар дәүләтендә дәвам итә. Алтын Урда чоры «Болгар дәүләте халыклары Алтын Урда изүе астында» исеме белән шәрехләнә, аннан соңгы төрки-татар дәүләтләре тарихын бер Казан ханлыгы алыштыра. Бу «калып» совет елларында басылган башка күмәк монографияләрдә дәвам иттерелә. «Татарстан АССР тарихы»нда болгарлар һәм хәзерге Казан татарлары арасында генетик бердәмлек турында языла, монголлар — басып алучылар, төбәк халыкларын изүчеләр буларак тасвирлана, аларның үсешенә зыян салучылар кебек бәян ителә.

Шунысы кызык, Алтын Урда чорын археолог Н.Ф. Калинин яза. Китапны әзерләүдә, шулай ук Мәскәү тарихчылары Б.Д. Греков (борынгы община җәмгыяте чоры, Н.Ф. Калинин белән бергә) һәм Л.В. Черепнин катнашалар. Аннан соңгы басмаларда авторлар исемлеге Казан галимнәре белән генә чикләнә.

Коллектив хезмәтнең 2 нче томын әзерләгәндә бер тапкыр «авызы пешкән» Институт җитәкчелеге бик сак эш итә: 1956 елда 500 битлек китапны «Материалы для обсуждения» грифы белән бастыра. Укучы кулына барып ирешкән китап исә Х.Г. Гыймади, М.К. Мөхәррәмов һәм Х.Х. Хәсәнов редакциясендә 1960 елда дөнья күрә [История..., 1960].

Партиянең милли сәясәте ике томны да татарчага тәрҗемә итеп бастырырга мөмкинлек бирә.

Ике томлыкка бәя биреп, бу елларда күп чыганакларның һәм темаларның әле өйрәнелмәгән булуын, иң мөһиме — әзерлекле кадрлар җитмәвен атап үтәргә кирәк. Бер генә мисал: «Татария в период социалистической индустриализации и коллективизации сельского хозяйства (1917—1934 гг.)» дигән бүлекне этнограф Г.М. Хисаметдинов, ә «Татария в период Великой Отечественной войны (1941—1945 гг.)» дигән бүлекне урта гасырлар тарихы буенча галим Х.Г. Гыймади яза [Указатель..., 1987]. Бу — зур-зур тарихи чорлар белән шөгыльләнүче белгечләрнең бөтенләй булмавы хакында сөйли.

Коллектив алдында ТАССР тарихын язу бурычы куелганны да онытырга ярамый. Ул вакытта автономияле статуска ия милли республикаларның тарих язуга хокуклары союздаш республикаларныкына караганда кимрәк була. 1950 елларда ике томлык тарих китабын язу ТӘТИ галимнәренең фәнни батырлыгы буларак бәяләнергә лаек. Үземнең фикеремне дәлилләп, күрше республикаларда мондый хезмәтләр бер томлык булып кына һәм күпкә соңрак дөнья күрүен һәм 1980 елларга кадәр мондый масштаблы хезмәт язу бурычы куелмавын әйтергә кирәк [Закиев, 2010, с.6—7]. Чыннан да, 1968—1980 елларда бастырылган күмәк хезмәтләр [История..., 1968; 1970; 1973; 1980] бер томлык кына булып, аларда методологик һәм тарихны яктырту буенча концептуаль яктан үзгәрешләр күзгә ташланмый, соңгы монографик хезмәтләрдә чагылыш тапкан яңалыклар тиешле дәрәҗәдә яктыртылмый.

1945—1966 елларда фәнни хезмәткәр булган Е.И. Чернышевның эзләнүләре игътибарга лаек. Баштарак аның шөгыльләнү өлкәләре секторда әзерләнә торган күмәк хезмәт белән турыдан-туры бәйле була. «Материалы по истории Татарии. Вып.1» җыентыгында ул вакыты ягыннан XVIII—XIX гасырларга караган 12 басма табак материал бастыра, «Татарстан АССР тарихы»ның беренче томында XIX гасырның беренче яртысы буенча 8 табак күләмендәге хезмәте белән катнаша һәм 1954 ел-

да «Соцально-экономические очерки по истории Казанского края в 19 веке (дореформенный период)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый, Идел — Кама төбәгенең урта гасыр тарихи географиясен өйрәнүдә зур уңышларга ирешә: XVI гасырның икенче яртысы — XVII гасыр татар авыллары турында күләмле мәкалә яза [Чернышев, 1963, с.174—183] һәм, теркәү кенәгәләре нигезендә, Казан ханлыгы чоры авылларын барлап, исемлек төзи [Чернышев, 1971, с. 272—292].

Шушы елларда ирешелгән уңышларның берсе Ш.Ф. Мөхәммәдьяров эзләнүләре белән бәйле. Аспирант егет 1951 елда Мәскәүдә «Социально-экономический и политический строй Казанского ханства в XV — первой половине XVI вв.» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Совет җәмгыятендә һәм гуманитар фәндә ханлык тарихына тенденциоз караш яшәү сәбәпле, диссертация аерым китап булып басылмый кала, ул фәкать 2012 елда гына дөнья күрде [Мухамедьяров, 2012]). Казан ханлыгының хуҗалыгын, феодаль җирбиләүчелек системасын, игенчеләрнең хокукый һәм социаль хәләтен, дәүләттә һөнәрчелек һәм сәүдә үсешен яктырткан диссертация бүгенге көнгә кадәр бу тема буенча иң әтрафлы хезмәт булып тора.

1960 елларда, Хрущев заманындагы «җепшеклек» ТӘТИда милли тарихны өйрәнүгә артык зур йогынты ясамый диярлек.

Татарстан җирләре борынгы төрки дөньяның чик өлешен тәшкил итә, бу чор белән Ленинград һәм Мәскәү фәнни оешмалары гына шөгыльләнә. Алтын Урда чоры тарихчылар өчен ябык тема булып кала бирә. Казан ханлыгы тарихын өйрәнү дә, Институттан 1952 елда Ш.Ф. Мөхәммәдьяров киткәч, тукталып кала, дисәк, ялгыш булмас, чөнки ул да «уңайсыз» тема булып санала. Нәтиҗәдә, урта гасыр татар дәүләтчелеген өйрәнү үзеннән-үзе археологлар кулына «күчә». ТӘТИда алар тулысынча бу темаларны үз кулларына алалар. Яңа күренешнең нигезендә автономияле республикаларда милли темаларны һәм җирле халыкларның Урта гасыр дәүләтчелеген өйрәнүне читкә тибәрү сәясәте ята. Археологлар исә шушы чорларга караган табылдыкларны тасвирлыйлар, иң мөһиме, ТАССР төбәкләре буенча археологик карта төзү, аларны ачыклау, барлау һәм системага салу барышында язма чыганакларны җентекләп өйрәнәләр һәм югары квалификацияле белгечләргә әйләнәләр.

Шулай да тарих бүлегендә урта гасырлар темасы бөтенләй тикшерелми дип тә әйтеп булмый. Бу өлкә белән ТӘТИда 1965—1968 елларда тарих бүлегендә аспирантурада укып, 1969 елда «Булгаро-татарская денежная система в XIII—XV вв.» исемле темага уңышлы диссертация яклаган һәм 1970 елга кадәр Институтта фәнни хезмәткәр булган А.Г. Мөхәммәдиев һәм 1968—1993 елларда тарих бүлегендә эшләгән археолог Р.Г. Фәхретдинов (кандидатлык диссертациясе темасы: «Территория Волжско-Камской Булгарии домонгольского и золотоордынского времени») шөгыльләнә [Фахрутдинов, 1984].

Казан ханлыгы тарихының тыелган булуы Россиядә татарларның Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашуларын өйрәнгән монографиясе белән танылу алган С.Х Алишевның «Присоединение Среднего Поволжья к русскому государству» дигән темага докторлык диссертациясен Мәскәүдә 1978 елда Тарих институтында тикшерү вакытында тагын бер кат ачыклана. Казан ханлыгын яулап алу турындагы фикерләр ялгыш дип табыла, шуннан

соң галим икенче тема алып, «XVI—XIX гасырның беренче яртысында Урта Идел буе» дигән яңа диссертация яза, аны 1990 елда яклый [Алишев, 1990]. Беренче диссертациясенең тексты үзгәртеп кору елларында гына басылып чыга [Алишев, 1995].

Ике томлык «Казан тарихы»н эшләгәндә С.Х. Алишев ханлык заманы һәм XVI—XVIII гасырлар тарихы буенча үзен зур белгеч итеп таныта. Галим, шулай ук, XVI—XIX гасырларда татар крестьяннарының хакимияткә каршы чыгышларын өйрәнеп, бу еллардагы татар милли хәрәкәтенең яңа битләрен язды [Алишев, 1976; Алишев, 1999].

1960—1980 елларда XVIII—XX гасырларларда булган вакыйгаларны өйрәнүгә ихтыяҗ арта. Кайсыдыр мизгелдән төп игътибар Совет чорына күчә, бу үзгәреш, еш кына, Урта гасырлар һәм, гомумән, XX гасырга кадәрге чорларны өйрәнүгә хилафлык китерү хисабына да башкарыла, дип әйтергә мөмкин.

1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәрге чорга караган һәм башкарылган кайбер яңа фәнни темаларны атап узыйк.

С.Х. Алишев, телчеләр, әдәбиятчылар, фәлсәфәчеләр белән берлектә, Г. Ибраһимовның, К. Насыйриның хезмәтләрен бастырып чыгаруда актив катнашты.

Х.Х. Хәсәнов Татарстанда беренче рус революциясе турында ике монография язып бастыра, инкыйлабның милли хәрәкәт белән кисешү нокталарын билгеләргә омтыла. Бүгенге көн югарылыгыннан караганда, аның «Татар буржуаз милләте формалашу» («Формирование татарской буржуазной нации») дип аталган монографиясе игътибарга лаек. Биредә автор милли буржуазия, аның мануфактуралары һәм алыш-биреш итүе турындагы мәгълүматларны, бигрәк тә XVIII гасыр азагы архив чыганакларын фәнни әйләнешкә кертә, татар буржуазиясе һәм татар милләте формалашуның этапларын аерып чыгара, бу процесска йогынты ясаган факторларны билгели.

Р.Г. Әмирхановның фәнни эшчәнлеге тарих фәнендә яңа юнәлешне формалаштыруда мөһим роль уйный. XX гасыр башында татар милли вакытлы матбугаты барлыкка килү сәбәпләрен, алшартларын, газета-журналларның идеологик юнәлешләрен, демократик матбугатның иҗтимагый фикергә тәэсирен яктыртып, ул бу чор тарихына яңа караш булдыруга катнаша. [Амирханов, 1988; Амирханов, 2002].

Е. Устюжанинның 1940 елларда башлаган «Казан губернасында XIX гасырның икенче яртысында крестьяннар хәрәкәте» темасын, Урта Идел җирлегендә киңәйтеп, Ю.И. Смыков дәвам итә [Смыков, 1973] һәм 1984 елда төбәктә крестьян хуҗалыкларында капитализм үсеше мәсьәләләренә багышланган докторлык диссертациясен уңышлы яклый [Смыков, 1984].

Н.С. Хәмитбаева максатчан рәвештә Урта Идел төбәге халыкларының демографиясе, аңа хуҗалык һәм икътисад үсешенең тәэсире мәсьәләләрен тикшерә. И.А. Гыйләҗев бу теманың башка бер ягын — «XVIII гасырның икенче яртысында Урта Идел буенда татар крестьяннары» дигән теманы тикшерү объекты итеп ала. Һәм 1983 елда шуның буенча кандидатлык диссертациясен яклый.

ТӘТИның 1963—1980 еллардагы уңышлары директор, тарих фәннәре докторы М.К. Мөхәррәмов исеме белән бәйле. Ул институтта 1951 — 1958 елларда гыйльми сәркатип, 1959 — 1963 елларда тарих бүлеге мөдире булып эшли, Татарстан җирлегендә Гражданнар сугышы барышын, Октябрь инкыйлабыннан соң милли дәүләтчелек төзелешен өйрәнә.

1982—1987 елларда ТАССРда бастырылган 10 томлык лениниаданың 6 сы бүлек хезмәткәрләре, бигрәк тә

М.А. Сәйдәшева тырышлыгы белән әзерләнде.

Милли тематика И.Г. Гыйззәтуллин тарафыннан совет хакимиятенең беренче елларында татар гаскәрләре һәм гаскәриләре буенча әзерләнгән монографиядә чагылыш таба [Гиззатуллин, 1977].

З.Г. Гарипова ТАССРда беренче бишьеллыктан алып дөнья күргән күп-кырлы мәдәни-агарту чаралары һәм аларның тәэсирен ачыклау буенча матур нәтиҗәләргә ирешә [Гарипова, 1985].

Тарихчыларның тагын да бер игелекле хезмәтләре — бүлек тарафыннан әзерләнгән күпсанлы документлар җыентыклары. Бу басмаларда күп кенә язма чыганаклар беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә, язылачак яңа темаларга нигез булдырыла [Воззвания..., 1988]. Аларның күбесе хронологик яктан XX гасырга карый. Документлар җыентыклары төбәктә совет хакимиятенең ныгуы, 1917 елгы вакыйгаларда катнашкан шәхесләрнең истәлекләре, ТАССР төзелү, 1917 — 1941 елларда ТАССР авыл хуҗалыгында коллективлаштыру, 1917 — 1941 һәм 1941 — 1970 елларда ТАССРда мәдәни революция һ.б. мәсьәләләргә багышлана. Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР халыкларының фронттагы һәм тылдагы батырлыкларын раслаучы документлардан дүрт җыентык бастырып чыгарыла.

В.И. Ленин темасы да шундый ук мөһим юнәлеш саналып, күпсанлы документлар җыентыклары төзелә.

Тарихчыларның башкарган эшләрен тулырак күз алдына китерү өчен, 2 томлы Казан тарихыннан тыш, башкаланың XX гасырның өченче чирегендә үсешенә багышланган «Молодость древнего города» (1978), «Рабочий класс Татарии (1961—1980)» (1981) кебек басмаларны да искә төшерергә кирәк.

Бөтен илдәге кебек ук, Татарстанда да сыйныфлар көрәше, Ленин шәхесе (М.А. Сәйдәшева), Октябрь инкыйлабы (А.А. Тарасов, М.К. Мөхәррәмов), крестьяннар (колхозчылар) һәм эш-чөләр (К.А. Нәҗипова), ТАССРда авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать үсешендә Коммунистлар партиясенең һәм комсомолның эшчәнлеге, мәдәният өлкәсендә яңарыш (Г.К. Вайда һ.б.) кебек мәсьәләләрне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Әйтик, 1954—1980 елларда ТӘТИда эшләгән А.М. Җәләлев сугышка кадәрге елларда ТАССР авыл хуҗалыгында социалистик үзгәртеп корулар турында монография язды, докторлык диссертациясе яклады [Залялов, 1971].

1964—1990 елларда тарих бүлеген җитәкләгән Җ.И. Гыйльманов (кандидатлык диссертациямнең фәнни җитәкчесе) кыска гына вакыт аралыгында Татарстанның һәм татарларның Бөек Ватан сугышында җиңүгә керткән өлешләре турында тирән эчтәлекле монографияләр язды, үзенең фәнни мәктәбен булдыруга иреште: аның укучылары шушы катлаулы теманың төрле аспектлары буенча диссертацияләр якладылар [Гильманов, 1977; 1981].

Һәрбер фән юнәлешенең үсешен әзерлекле кадрлар билгели. Басылып чыккан мәгълүматларга караганда [50 лет..., 1989, с. 229—239], тарихчылар арасында, аспирантура тәмамлагач, диссертацияләрен уңышлы яклаучылар саны буенча иң югары күрсәткеч археологларда һәм этнографларда иде. Бу, бәлки, тарихи темаларны аңлатудагы чикләүләр белән дә бәйледер.

Аспирантларга кагылышлы тагын бер кызыклы күзәтү ясап үтәсе килә. 1940 еллар ахыры — 1960 елларның беренче яртысында Институт үзенең аспирантурасы аша, шулай ук Мәскәү фәнни оешмалары һәм Ленинград университеты ярдәме белән, Татарстан (һәм шулай ук Мари автономияле рес-

публикасы) өчен галимнәр әзерләүгә зур өлеш кертте. Биредә төрле елларда аспирантура тәмамлап, үзләре сайлаган фән тармагында зур уңышларга ирешкән галимнәрне санап үтү мәслихәт булыр. Мәсәлән, археологлардан: Җ.Г. Мөхәммәтшин, А.М. Белавин, Г.Н. Белорыбкин, А.Ф. Кочкина, С.В. Кузьминых, М.Г. Косменко, В.С. Патрушев, В.В. Никитин, Б.С. Соловьев һ.б., этнографлар арасыннан гомер юлын Казан университеты белән бәйләүчеләрдән Р.Г. Кәшәфетдинов, Милли музей хезмәткәре М.К. Завьялова, күршеләребез Йошкар-Оладан Г.А. Сепеев, Чебоксардан П.В. Денисов, мордва-мукшы буенча белгеч В.П. Ежова һ.б.

Күрше республикаларга тарихчы-белгечләр әзерләүдә дә ТӘТИ аспирантурасының лаеклы өлеше бар. Чувашстанда, мәсәлән В.А. Нестеров, Г.И. Шумилов, С.Г. Русаков, Мари Республикасыннан А.С. Патрушев, А.В. Хлебников, М.М. Апраксин үзләренең республикалары һәм халыклары тарихын өйрәнүдә әйдәп баралар [50 лет..., 1989, с. 229—239].

Тарих фәне үсешенә башка бүлек галимнәре дә зур өлеш керттеләр. Тарихчыларның уңышы — телчеләрнең, әдәбиятчыларның, фәлсәфәчеләрнең, археологлар һәм этнографларның, күмәкләшеп, татар галимнәре, җәмәгать эшлеклеләренә, күренекле вакыйгаларга багышлап конференцияләр оештыруда, мәкаләләр җыентыклары бастыруда, ягъни өйрәнелә торган проблемага комплекслы якын килеп, аны төрле фән тармагы вәкилләре күзлегеннән бәяләүдә иде.

Археологларыбыз тырышлыгы белән экспедицияләр вакытында табылган материаллар халыкның матди һәм рухи мәдәниятен, Урта Иделдә тарихның борынгы һәм урта гасырлар чоры тормышын, анда барган иҗтимагый-сәяси процессларны реконструкцияләүдә мөһим чыганакларга әйләнәләр. Моңа нисбәтле, Н.Ф. Калинин, А.П. Смирнов, В.Ф. Генинг, Н.А. Халиков, Р.Г. Фәхретдинов, Е.П. Казаков, Т.А. Хлебникова, А.Г. Мөхәммәдиев, Ф.Ш. Хуҗин һ.б.ларның фәнни эшчәнлеге игътибарга лаек. Татарстанның 1945 елны башланып, 1988 елны төгәлләнгән алты томлык Археологик картасын төзү — чор казанышы дип саналырга лаек. Ул биш меңгә якын археология һәйкәленең тасвирламасын үзенә туплаган.

Х. Йосыпов, Ф.С. Хәкимҗанов, Җ.Г. Мөхәммәтшин хезмәтләрендә гарәп язулы эпитафик һәйкәлләр өйрәнелә һәм алар Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларының тарихи-мәдәни һәм рухи мирасы төсендә тәкъдим ителә.

Татарстанда Н.И. Воробьевтан башланган этнография фәне үсеше өчен ТӘТИ составындагы еллар «алтын чор» булды. Этнографлар тарафыннан әзерләнгән «Идел һәм Урал буе татарлары» («Татары Поволжья и Приуралья», 1967) дип аталган коллектив җыентык бу чор фәнендә аерым бер урын тота. Бу хезмәттә XIX — XX йөз башы татар традицион мәдәниятенә зур урын бирелгән. Ул, билгеле бер күләмдә, совет историографиясендә татарларның урнашу тәртибен һәм көнкүрешен, торак урыннарын, кием-салым һәм бизәнү әйберләрен, туклану, көнкүреш үзенчәлекләрен, йола-гадәтләрен һәм бәйрәмнәрен өйрәнү ягыннан яшәп килгән бушлыкны тулыландыра.

1970—1980 елларда, татар халкының тарихи-мәдәни атласын төзү барышында, татарлар яшәгән төбәкләргә күпсанлы экспедицияләр оештырылды, XIX гасыр азагы — XX гасыр башы татар көнкүреше, йолалары, тормыш рәвеше һ.б. турында искиткеч кыйммәтле материал тупланды.

1970—1980 елларда инде аерым тарихи-этнографик хезмәтләр язылa, аларда: Казан губернасы татар

крестьяннарының гаилә көнкүреше (Ә.А. Заһидуллин), Идел елгасының уң як ярында яшәгән татар-мишәрләр этнографиясе (Р.Г. Мөхәммәдова), керәшен татарлары һәм традицион торак мәдәнияте (Й.М. Мөхәммәтшин), орнамент (Ф.Х. Вәлиев), җәмгыяви һәм гаилә-көнкүреш бәйрәмнәре (Р.Г. Кәшәфетдинов, Р.К. Уразманова), казан татарларының бизәнү әйберләре (С.В. Суслова), XVIII—XIX гасырларда татарлардагы демографик үсеш (Д.М. Исхаков), тукучылык (Ф.Ш. Сафина), Идел — Урал төбәге татар крестьян хуҗалыклары (Н.А. Халиков), касыйм татарларының традицион мәдәнияте (Ф.Л. Шәрифуллина) һ.б. тикшерелә.

1980—1990 еллар башында этнографлар тарафыннан аерым төбәк татарлары (нагайбәкләр, Урал буе, Пермь төбәге һ.б.) тарихына һәм көнкүрешенә багышланган мәкаләләр җыентыклары басылды.

1986 елда лаборатория, 1990 елдан иҗтимагый фикер тарихы бүлеге булып оешкан фәлсәфәчеләр татар фикер ияләренең мирасын барлау, бастырып чыгару һәм өйрәнүдә зур хезмәт куйдылар. Я.Г. Абдуллин татар мәгърифәтчелегенә һәм җәдитчелегенә багышланган китаплары белән танылды, Ә.Г. Кәримуллин татар китабы тарихын, М.Х. Йосыпов Ш. Мәрҗанинең тарихи карашларын, Г.М. Дәүләтшин төркитатарларның Урта гасыр дәүләтчелек чоры рухи мирасын, Р.М. Әмирханов XIII—XVI гасырларда төрки-татар фәлсәфи фикере үсешен, А.Н. Юзеев татар мөселман реформаторларының әсәрләрен, Ф.М. Солтанов ислам дине һәм совет татар җәмгыяте мөнәсәбәтләрен, Р.Ф. Мөхәметдинов татарларда төркичелек идеяләренең таралышын, Р.М. Мөхәммәтшин Г. Ибраһимовның фәлсәфи карашларын өйрәнүдә, Ә.Н. Хәйруллин Ш. Мәрҗани һәи Р. Фәхретдиновның тарихи хезмәтләрен халыкка кайтаруда уңышка ирештеләр.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, 1980 еллар уртасына кадәр, илдә башланган сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр тәэсирендә тарих бүлегендә куелган бурычларны уңышлы хәл итә торган, максатчан эшләүче галимнәр коллективы тупланган иде. Әлбәттә, эзләнү темаларын сайлауга, вакыйгаларны бәяләүгә сыйнфый көрәш концепциясе, коммунистик идеология тәэсир итте. Бигрәк тә милли тарих һәм милли мәсьәләгә бәйле темаларга алыну мөмкин булмады.

Төбәк һәм төбәкара конференцияләр оештырып, СССРда уздырылган конференцияләрдә катнашып, мәкаләләр җыентыклары бастырып, республика вакытлы матбугатына русча һәм татарча мәкаләләр язып, бүлек хезмәткәрләре тарих фәнен үстерүгә һәм тарихи мирасны пропагандалауга үзләреннән зур өлеш кerттеләр.

1980 елларда бүлектәге галимнәр составы А.А. Арсланова, Ә.Г. Галләмова, Р.Г. Галләмов И.К. Заһидуллин һ.б. хезмәткәрләр хисабына яшәрде.

Илдә башланган үзгәрешләрнең уңай йогынтысы, беренче чиратта, татар тарихчыларының мирасын торгызуда чагылыш тапты. С.Х. Алишев күренекле татар тарихчылары Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласи тарихи хезмәтләрен халыкка кайтару буенча зур тырышлык куйды. Риза Фәхретдин, Зәки Вәлиди хезмәтләрен кириллицада заман укучына ирештерүдә Р.Г. Әмирханов игелекле хезмәт башкарды.

1980 елларда бүлек дүрт томлык «Татарстан тарихы»н язу эшен башлап җибәрде. Хәтерләвемчә, ул Татарстан чикләрендә булып узган вакыйгаларны соңгы дистә еллар эчендә тупланган материаллар буенча тикшереп-анализлап чыгуны күздә тота иде. ТӘТИ белән М.М. Зәкиев җитәкчелек иткән 1986—2000 еллар илдәге

«үзгәртеп кору» заманына һәм кризиска туры килде. Искергән карашлардан азат, заманча концепция, яңа чыганаклар һәм материаллар нигезендә күмәк көч белән «Татар халкы тарихы»н эшләү бурычы куелды. Аны оештыру 1989 елда тарих бүлегенә һәм аның яңа җитәкчесе С.Х. Алишевка йөкләнде. Эшләнеп бетмәгән дүрт томлы «Татарстан тарихы» материаллары да шушы яңа китапта файдаланылырга тиешле иде.

Бүгенге көннән торып якын килгәндә, 4 томлы академик «Татар тарих»ын язу омтылышын күчеш чоры проекты дип атарга мөмкин. Ул вакытта хезмәткәрләрнең темалары күмәк хезмәт планына тәңгәлләштереп үзгәртелде. Татар халкы тарихын киң масштабта, Евразия масштабында язу фикереннән чыгып, кайбер галимнәр өр-яңа темалар алдылар. Ләкин булачак хезмәтнең язу концепциясе табылмаган иде. 1995 елга үз темаларын язып бетергән бер төркем галимнәр текстларын «Материалы по истории татарского народа» [Материалы..., 1995] исемле мәкаләләр җыентыгына туплап бастырдылар.

1996 елда ТӘТИыннан мөстәкыйль Тарих институты аерылып чыккач, бүлекләр инерция рәвешендә шушы темаларны эшләвен дәвам итте. Мин Тарих институтында яңа оешкан урта гасырлар тарихы бүлегенә мөдир булып килгәч, ике ел эчендә дүрт томлы «Татар халкы тарихы» китабының баштагы ике томы эшләнеп бетте, бастырырга әзерләнде. Бу вакытта Тарих институты җитәкчелеге, әлеге проектка бәйсез рәвештә, 7 томлык «Татар тарихы»н әзерләү турында карар кабул иткән иде. Нәтиҗәдә бу проект татар тарихы историографиясендә бер мизгел булып кына калды. Дүрт томлык «Татарстан тарихы», «Татар халкы тарихы» проектлары кысаларында галимнәр язган мәкаләләрнең текстлары исә, дәреслекләр, монографияләр рәвешендә, укучыга барып иреште. Әйтик, әзер текстлар, беренче чиратта, галимнәр А.Г. Галләмова һәм Р.Г. Фәхретдинов тарафыннан Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча мәктәпләр өчен язылган уку-укыту ярдәмлекләрендә һәм дәреслекләрдә урын алды һәм, 1990 еллардан башлап, яңа буын татарстанлыларны тәрбияләүгә хезмәт итте. Г.Л. Фәйзрахманов, себер татарлары тарихы темасын үстереп, докторлык диссертациясе яклады, монографияләр бастырды, Н.С. Хәмитбаева, күмәк хезмәткә бүлекләр рәвешендә әзерләгән, XIX гасырның икенче яртысы — XX гасыр башында Урта Азиядә татарлар тарихына нисбәтле материалларын күләмле мәкаләләр итеп бастырды. К.А. Нәҗипова 1920—1930 еллар татар эшчеләре сыйныфына багышланган 700 битлек хезмәтен язып бетерде, аның кульъязмасын Тарих институты дирекциясенә тапшырды.

ТӘТИда аспирантура узып, фәндә беренче адымнарын ясаган хезмәткәрләр хәзер инде Тарих институтында үзләре өлкән буын галимнәр сафында. Алар фәнне оештыру өлкәсендә, көндәлек фәнни эшчәнлектә ТӘТИда алган уңай традицияләрне сакларга һәм үстерергә омтылалар. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының юбилее — безнең уртак бәйрәмебез, дип саныйм. Һәм барлык коллегаларымны Институтның бу күркәм бәйрәме белән котлап, яңа иҗат уңышлары теләп калам.

**Әдәбият**

*Алишев С.Х.* Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании / под ред. З.И. Гильманова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. 215 с.

*Алишев С.Х.* Каһарман бабайлар. Казан: Татар. кит. Нәшр., 1976. 126 б.

*Алишев С.Х.* Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. М.: Наука,1990. 269 с.

*Алишев С.Х.* Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV—XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 160 с.

*Алишев С.Х.* Тернистый путь борьбы за свободу: социальная и национально-освободительная борьба татарского народа (II половина XVI — XVIII вв.) / научн. ред. И.Р. Тагиров. Казань: Фэн, 1999. 158 с.

*Амирханов Р.У.* Татарская демократическая печать (1905—1907). М.: Наука, 1988. 191 с.

*Амирханов Р.У.* Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток — Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Таткнигоиздат, 2002. 240 с.

Воззвания и переписка вожаков пугачевского движения в Поволжье и Приуралье / сост. и ред.: С.Х. Алишев, Р.В. Овчинников, М.А. Усманов и др. Казань, 1988.

*Гарипова З.Г.* Культурно-просветительская работа в Татарии в годы первой пятилетки (1928—1932 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 160 с.

*Гиззатуллин И.Г.* Защищая завоевания Октября: центральная мусульманская военная коллегия: 1918—1920. М.: Наука, 1977. 159 с.

*Гильманов З.И.* Татарская АССР в Великой Отечественной войне (1941—1945 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 296 с

*Гильманов З.И.* Трудящиеся Татарии на фронтах Великой Отечественной войны. Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. 288.

*Гобәйдуллин Г.* Татар тарихы. Казан: Татарстан Социалистик Совет Җөмһүриятенең дәүләт нәшр., 1922. 126 б.

*Закиев М.З.* Начало составления академической истории татарского народа // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. А Вып.1. Казань, 2010. С.6—7.

*Залялов А.М.* Социалистическое преобразование сельского хозяйста в Татарии (1917—1937 гг.). Казань: Татар.кн. изд-во, 1971. 372 с.

История Татарской АССР. С древнейших времен до Великой Октябрьской социалистической революции. Казань, 1951. Т. I. 531 с.

История Татарской АССР. С древнейших времен до Великой Октябрьской социалистической революции. Казань, 1955. Т. I. 550 с.

История Татарской АССР / редкол.: Х.Г. Гимади, М.К. Мухарямов, Х.Х. Хасанов. Т.2. Казань: Татар. кн. изд-во, 1960. 584 с.

История Татарской АССР. С древнейших времен до наших дней. Казань, 1968. 701 с.

История Татарской АССР / под ред. М.К. Мухарямова. Казань, 1973. 289 с.

История Татарской АССР / под ред. М.К. Мухарямова. Казань, 1980. 140 с.

Материалы по истории татарского народа / редколл.: М.Х. Хасанов, М.З. Закиев, С.Х. Алишев и др.; АН РТ ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова. Казань, 1995.

*Мухамедьяров Ш.Ф.* Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV — первая половина XVI вв.) / сост. и отв. ред. Р.Г. Галлям. Казань: Ихлас; Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2012. 276 с.

50 лет поисков и открытий. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 240 с.

*Смыков Ю.И.* Крестьянство Среднего Поволжья в борьбе за землю и волю. 60—90-е годы XIX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. 270 с.

*Смыков Ю.И.* Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма: социально-экономическое исследование. М.: Наука, 1984. 232 с.

Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты (елы күрсәтелмәгән). 1 нче җилд: Борынгы дәвер. 240 б.

Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият. Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты, 1922. 1 нче җилд. 184 б.

Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. Казан: Татарстан Җөмһүрияте нәшрияты, 1922. 2 нче бүлек. 1 нче җилд. 240 б.

Указатель трудов ученых Института языка, литературы и истории Академии наук Республики Татарстан. 1939 — 1986 / под редакцией доктора филологических анук А.Г. Каримуллина. Казань, 1987.

*Файзрахманов Г.Л.* Развитие гуманитарных исследований в сороковые-восьмидесятые годы: к 50-летию Института языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова КФ АН ССР // Великий Октябрь и некоторые вопросы формирования татарской социалистической нации. Казань, 1989. С.96—122.

*Худяков М.* Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1923.

*Чернышев Е.И.* Татарская деревня второй половины XVI—XVII вв. // Ежегодник по аграрной истории Восточной Европы, 1961. Рига, 1963. С. 174—183.

*Чернышев Е.И.* Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Археология и этнография Татарии / отв. ред .А.Х. Халиков. Казань, 1971. Вып. 1. Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. С. 272—292.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,*** *тарих фәннәре докторы,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының*
*Урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе*

УДК 93/94

***Ф.Ш. Хуҗин***

# ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА ТАТАРСТАН АРХЕОЛОГИЯСЕ

В статье прослеживаются основные этапы развития археологии Татарстана в составе Института языка, литературы и истории за почти шестидесятилетний период его истории — до 1996 года, когда из ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ выделился самостоятельный Институт истории. Автор характеризует основные направления исследований археологов, отмечает достижения каждого этапа развития, определяя место казанской археологической школы, сложившейся в стенах ИЯЛИ КФАН СССР, в археологии России в целом.

**Ключевые слова:** археология Татарстана, Институт языка литературы и истории им. Г. Ибрагимова, сектор археологии и этнографии, отдел археологии, Национальный центр археологических исследований.

Татарстан археологиясенең — күренекле галимнәр Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиков исемнәрен йөртүче Казан археология мәктәбенең оешуы, археология фәненең ярты гасырдан артык, 1996 еллар уртасына кадәр дәвам иткән тотрыклы, алгарышлы үсеш чорлары, борынгы һәм Урта гасырлар тарихын өйрәнү юлында формалашып, бөтен Россиядә һәм чит илләрдә танылу алган олы ачышлары быел үзенең 75 еллык юбилеен бәйрәм итүче Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйләнгән.

Дөрес, Татарстан археологиясенең башлангыч чорлары турында сүз барганда 1878 елда Казан университеты каршында оешып, 1930 елларга кадәр эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеген дә онытырга ярамый. Татарстан җирлегендә беренче казу эшләрен нәкъ менә шушы җәмгыять әгъзалары — күбесе профессиональ археологиядән ерак торган кешеләр башлап җибәрәләр. С.М. Шпилевский, А.Ф. Лихачев, А.А. Штукенберг, Н.Ф. Высоцкий, П.А. Пономарев, Н.А. Толмачев, В.К. Савельев, Г. Әхмәрев, В.Ф. Смолин, М.Г. Худяков кебек галимнәрнең Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләре»ндә басылган фәнни мәкаләләре, казу эшләре вакытында, башлыча, очраклы рәвештә табылган борынгы әйберләр коллекцияләре Татарстан археологиясе үсешендә нигез ташлары ролен үтәделәр. Мәсәлән, А.А. Штукенберг һәм Н.Ф. Высоцкий таш, бронза, элгәреге тимер гасырында яшәгән кешеләрнең беренче торулыкларын табып тикшерделәр, В.Ф. Смолин Чувашиянең Абашево авылы янында урнашкан борынгы курганнарны казып, фәндә моңа кадәр билгеле булмаган яңа археологик культура ачты. Профессор С.М. Шпилевскийның «Казан губернасында борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар истәлекләре» дигән фундаменталь хезмәте (1877) әле бүген дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмады, 2012 елда аның репринт басмасы дөнья күрде.

1917 елгы октябрь инкыйлабыннан соң фәнне оештыру системасында яңа үзгәрешләр килеп чыга. ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты каршында төзелгән Гыйльми үзәк (1921—1930), Татарларны өйрәнү Гыйльми җәмгыяте (1923—1929), Татарстанны өйрәнү җәмгыяте (1928—1930) басмаларында, сирәк кенә булса да, архео-

логия һәйкәләрен өйрәнү һәм аларны саклау мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр дөнья күрә. Шул ук вакытта А.С. Башкиров, И.Н. Бороздин, Н.Ф. Калинин кебек галимнәр тарафыннан Биләр, Җүкәтау, Казан кремле, Иске Казанише болгар-татар калаларында зур булмаган, эзләнү, күзәтү (рекогносцировка) характерындагы казу эшләре үткәрелә.

1933 елда СССР Фәннәр академиясенең Матди культура тарихы Институты (Институт истории материальной культуры) оештырган археология экспедициясе, Дәүләт тарих музее һәм Татарстан Үзәк музее белән бергәләп, Республикабызда казу эшләре башлап җибәрә. Тиздән атаклы болгарчы-галим булып танылачак А.П. Смирнов җитәкчелегендәге экспедиция биш ел буена Сувар шәһәрлеген тикшерә, 1938 елда исә киң масштаблы һәм системалы казу эшләре Болгарда башланып китә. Бу эшләрдә Татарстан Үзәк музее хезмәткәрләре Н.Ф. Калинин, А.М. Ефимова, О.С. Хованская һәм З.А. Акчурина актив катнашалар.

Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институтында беренче археолог — Казан археология мәктәбенә нигез салучы олы галим Николай Филиппович Калинин 1942 елда эшли башлый, 1951 елда ул үзенең талантлы шәкерте А.Х. Халиковны лаборант сыйфатында эшкә урнаштыра, шулай итеп, Институтның тарих секторында археология төркеме барлыкка килә.

***Тарих секторы составындагы археология төркеме*** тиздән Т.А. Хлебникова[1], Һ.В. Йосыпов[2], Ф.Ф. Генинг[3] кебек яшь археологлар белән тулыландырыла.

1945 елда Институт каршына СССР Фәннәр академиясе тарафыннан Советлар Союзы халыкларының тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен исәпкә алу кысаларында Татарстанның Археологик картасын төзү бурычы куела. Берничә ел эчендә Республикабызның төрле районнарына экспедицияләр оештырыла, музей һәм архив фондлары тикшерелә. Үткәрелгән тикшеренүләрнең беренче нәтиҗәсе буларак, 1954 елда Н.Ф. Калининның А.Х. Халиков белән язылган китабы дөнья күрә. Бу китапта Татарстанның 21 районында урнашкан 447 археология һәйкәле исәпкә алынган һәм болгар-татар шәһәрлекләренең типологиясе тәкъдим ителгән [Калинин, Халиков, 1954, с. 63—126].

Сугыштан соңгы елларда, аз гына финанс мөмкинлекләре килеп чыгуга ук, борынгы археология һәйкәлләрендә стационар казу эшләре үткәрелә башлый, аерым алганда, Минзәлә районының Дәвек авылы янында палеолит (б.э.к. X—VIII меңьеллыклар), Апас районының Кабык Күпер авылы янында мезолит (б.э.к. VI—V меңьеллыклар), Казаннан ерак түгел Обсерватория поселогы янында неолит (б.э.к. IV—III меңьеллыклар) чоры кешеләре калдырган торулыклар казып өйрәнелә. Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләрендә моңарчы билгеле булмаган таш гасыры чорына караган гаять кыйммәтле археологик материаллар А.Х. Халиков хезмәтләрендә беренче мәртәбә киң фәнни әйләнешкә кертелә [Халиков, 1958; 1960]. Яшь галим, шулай ук беренче мәртәбә, бронза гасырында (б.э.к. II меңьеллык) яшәгән кабиләләрнең торулыкларын һәм каберлекләрен казып өйрәнә, шул материаллар нигезендә элгәреге тимер гасыры чорында ананьино культурасын формалаштыруга катнашкан Казан буе археологик культурасын ача [Калинин, Халиков, 1954 а; 1954 б; Халиков, 1962], баланово һәм абашево кабиләләренең курган каберлекләрен казый [Халиков, 1959; 1960]. Киң колач белән үткәрелгән тикшеренүләр вакытында тупланган өр-яңа археологик материаллар нигезендә А.Х. Халиков башта кандидатлык (1955), аннан соң

докторлык (1966) диссертацияләрен яклап, фән дөньясына таш һәм бронза дәверләрендә Төньяк-Көнчыгыш Европаның Урта Идел—Урал буе төбәкләрендә яшәгән күпсанлы борынгы кабиләләрнең катлаулы тарихын тәкъдим итте.

1953—1954 елларда Н.Ф. Калинин белән А.Х. Халиковның Лаеш районы Имән Кискә авылы янында урнашкан борынгы шәһәрлекне казыганда табылган материаллары фәндә моңа кадәр билгеле булмаган тагын бер археологик культура ачарга мөмкинлек бирде [Калинин, Халиков, 1960]. Бу культураны IV—VII гасырларда яшәгән кабиләләр калдырган, аларны шартлы рәвештә имәнкискәлеләр дип атыйлар. Кызганычка каршы, имәнкискәлеләрнең этник тамырлары әле һаман да ачыкланмаган (төркиләрме алар? Славяннармы? Сарматлармы?), болгарларның этник яктан формалашуында катнашу-катнашмау мәсьәләсе дә ныклап өйрәнелмәгән.

Тимер гасырына караган һәм бүгенге мари, удмурт халыкларының борынгы бабаларыннан саналган пьянобор (б.э.к. II — б.э.ның II гасырлары) һәм аларның дәвамчылары азелино (III—V гасырлар) кабиләләренә нисбәтле археологик истәлекләрне өйрәнү В.Ф. Генинг өлешенә туры килде [Генинг, 1959]. Ул шулай ук имәнкискә кабиләләренең Лаеш районы, Рождествено авылы янында урнашкан борынгы каберлекләрен [Генинг и др., 1962], Менделеев районының Турай авылы янында һуннарның хәрбиләре җирләнгән уникаль курганнарны казып тикшерде [Генинг, 1962]. Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләре халыкларының болгарларга кадәрге чордагы этник тарихына багышланган һәм фәнни кыйммәтен әле бүген дә югалтмаган беренче саллы хезмәтне дә В.Ф. Генинг язды [Генинг, 1959].

Азов, Кара диңгез далаларыннан безнең якларга VIII гасыр урталарында күчеп килгән болгарлар күмелгән Олы Тархан зираты (Республикабызның Тәтеш районында) 1957, 1960 елларда В.Ф. Генинг һәм А.Х. Халиков тарафыннан җентекләп өйрәнелгән иде. Аның материаллары 1964 елда Мәскәүнең «Фән» нәшриятында дөнья күрде [Генинг, Халиков, 1964]. Татар этногенезының болгар чорына караган этабын өйрәнү бүген дә Олы Тархан материалларыннан башлана.

Болгарда СССР Фәннәр академиясенең А.П. Смирнов җитәкчелегендәге Идел буе археологик экспедициясе сугыш вакытында өзелеп торган эшләрен дәвам итте. Шәһәрлекнең башлыча Куйбышев сусаклагычы астында калачак өлешләре казылды. 1957 елдан башлап экспедициядә Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Т.А. Хлебникова эшли.

Һ.В. Йосыповның 1960 елда басылып чыккан фундаменталь хезмәте болгар-татар эпиграфикасына багышланган иде. Биредә татар зиратларында башлыча XIV—XVI йөзләрдән сакланып калган 500 ләп каберташ язмалары тикшерелә [Юсупов, 1960]. Еллар үткән саен әлеге хезмәтнең фәнни әһәмияте күтәрелә генә бара.

1950 елларда безнең Институт, күрше республикалар һәм өлкәләр белән фәнни хезмәттәшлек традицияләрен башлап, Мари АССРның Тел, әдәбият, тарих һәм экономика фәнни-тикшеренү институты белән берлектә, А.Х. Халиков җитәкчелегендә Мари археологик экспедициясе оештыра. Әлеге экспедиция тарафыннан Мари республикасында һәм Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсендә борынгы фин-угыр кабиләләре калдырган дистәләгән археологик һәйкәлләр ачыла һәм казып тикшерелә [Никитин, 2007, с. 3—19].

***Археология һәм этнография секторы*** Тел, әдәбият һәм тарих институ-

ты составында 1962 елда оеша. 1965 елга кадәр профессор Н.И. Воробьев, аннан соң А.Х. Халиков җитәкләгән әлеге секторның археология төркемендә 4 археолог (сектор җитәкчесеннән башка Т.А. Хлебникова, Р.С. Габәшев, П.Н. Старостин) һәм эпиграфист-галим Һ.В. Йосыпов була. Соңгырак елларда секторга яшь археологлар Р.Г. Фәхретдинов (1966 елда), Е.П. Казаков (1967 елда) килеп өстәлә. 1970 елларда археологлар төркеменә М.Г. Косменко, Ф.Ш. Хуҗин, Р.Ф. Шәрифуллин, М.М. Кавиев, Г.И. Дроздова кабул ителә. Институт коллективында археозоология (А.Г. Петренко, 1966 елда) һәм антропология (Р.М. Фаттахов, 1977 елда) буенча югары квалификацияле белгечләр эшли башлый.

Археологларның фәнни-тикшеренү планнарында өстенлекле юнәлеш булып һаман да Татарстанның Археологик картасын төзү темасы кала бирде. Бу эш бары тик 1970 еллар ахырында гына тәмамланды. 4500 дән артык археология һәйкәлләренең тасвирламасын үз эченә алган хезмәт 1981—1990 елларда алты томлык китап булып басылып чыкты[4] [Археологическая ..., 1981; 1984; Археологические ..., 1988; 1989; 1990]. Мәскәүнең «Фән» нәшрияты чыгара торган «Археологик чыганаклар тупланмасы» сериясендә тематик карталары белән имәнкискә [Старостин, 1967], баланово [Бадер, Халиков, 1976], Казан тирәсе [Халиков, 1980] археологик культураларына багышланган китаплар дөнья күрде. Р.Г. Фәхретдиновның болгар-татар археологик һәйкәлләре тупланмасы фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды [Фахрутдинов, 1975].

1961 елдан Куйбышев сусаклагычының Татарстан зонасында (Идел белән Кама кушылган җирдә) башланып киткән һәм дулкыннар белән яисә су астында калып юылып юкка чыга язган 700 ләп археологик һәйкәлләрне саклау-коткару максатын күз алдында тоткан тикшеренүләр Казан археологлары эшчәнлегенең күп елларга исәпләнгән тагын бер фәнни юнәлешенә әверелде. Разведка һәм казу эшләре, башлыча, иртәнге яз һәм көз көннәрендә, сусаклагычта су кимегән чорда башкарылды [Габяшев и др., 1976].

1968—1972 елларда П.Н. Старостин, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков һәм М.Г. Косменко төзелеп килүче Түбән Кама сусаклагычы астында калачак археология һәйкәлләрен казыдылар. Әлеге эшләрнең нәтиҗәләре күп санлы мәкаләләрдә, фәнни җыентыкларда, китапларда чагылыш тапты [Древности, 1978; Казаков, 1978], тупланган материаллар М.Г. Косменконың Урта Идел мезолитына, Р.С. Габәшевның Түбән Кама неолитына багышланган кандидатлык диссертацияләрендә төп чыганак буларак кулланылды [Косменко, 1972; Габяшев, 1978].

Бронза һәм элгәреге тимер дәверләрен өйрәнү элеккечә А.Х. Халиков һәм аның коллегалары, шәкертләре тарафыннан дәвам ителде [1977а; 1980; Бадер, Халиков, 1976; Халиков, Патрушев, 1982]. А.Х. Халиковның таш һәм бронза гасырларында Урта Идел бассейнында яшәгән халыкларның тарихын өйрәнүгә багышланган монографиясе [Халиков, 1969] Россия һәм чит ил галимнәре тарафыннан, Татарстан археологларының чираттагы уңышы буларак, югары бәяләнде. Әйтергә кирәк, А.Х. Халиков тарафыннан тәкъдим ителгән фин-угыр халыкларының этногенезы концепциясе, асылда, бүген дә искермәде, яңа чыганаклар нигезендә ул һаман да камилләшә генә бара.

1960 елларның икенче — 1980 елларның беренче яртысында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре болгарларга кадәрге һәм, бигрәк тә, Идел Болгары чорына караган археология

һәйкәлләрен өйрәнүгә күбрәк игътибар итә башладылар. П.Н. Старостин бик актив рәвештә имәнкискә кабиләләренең әле хәзер дә серләртабышмаклар белән тулы тарихын язу белән шөгыльләнде [Старостин, 1967; 1981].

1961 елдан башлап Е.П. Казаков һәм Татарстан дәүләт музее хезмәткәре Е.А. Халикова IX гасырның икенче яртысында яшәгән элгәреге болгарларның Танкеевка некрополен (биредә якынча 6 мең чамасы кабер исәпләнелә) казып тикшерә башладылар. Яңа чыганаклар Идел болгарларының этногенезында, төркиләрдән кала, фин һәм угыр компонентларының да зур урын алып торуын расладылар [Казаков, 1971; Khalikova, Kazakov, 1977].

1970 елларның икенче яртысында Казан археологлары болгар этногенезын өйрәнүгә кагылышлы тагын бер уникаль археология һәйкәленә тап булдылар: А.Х. Халиков һәм Е.А. Халикова тарафыннан Республикабызның Алексеевский районы, Олы Тигәнәле авылы янында элгәреге венгр-мажарларның IX гасырда көнчыгыштан көнбатышка (Паннониягә) күчеп утырышлары вакытында калдырылган каберлекләре тикшерелде. Әлеге ачыш, аңлашыла ки, археология дөньясында, бигрәк тә Венгриядә, зур кызыксыну уятты. Венгр коллегаларыбыз Олы Тигәнәле ачышларына багышлап халыкара конференция дә үткәрделәр, казылмаларның материалларын да тулысынча бастырып чыгардылар [Halikova, Halikov, 1981]. Кызганыч, ни Танкеевка материалларын (бүгенге көндә биредә 1200 кабер өйрәнелгән), ни Олы Тигәнәлененекен һаман да үзебездә, рус телендә бастырып чыгара алмыйбыз әле.

1970—1980 елларда болгар шәһәрләрен археологик өйрәнү өлкәсендә зур уңышларга ирешелде. Болгарда казу эшләре дәвам итте, һәм, иң мөһиме, биредә Алтын Урда чорында төзелгән борынгы архитектура корылмаларына игътибар көчәйде [Город Болгар, 1987, с. 42 и сл.]. Т.А. Хлебникова болгарларның Танкеевка, Алексеевское, Җүкәтау һ.б. шәһәрлекләрендә казу эшләре алып барды [Хлебникова, 1971; 1975]. Р.Г. Фәхретдинов «Иске Казан» — XII гасыр ахырына — XVI гасыр башларына караган Камаево һәм Рус Урматы комплексын казый башлады [Фахрутдинов, 1984, с. 125—153]. Шул ук елларда А.Х. Халиков һәм аның хезмәттәшләре Казан кремлендә, башкалабызга нигез салыну вакытын ачыклау максатында, кызыклы тикшеренүләр үткәрде. Куелган максатка ирешелмәсә дә, әлеге тикшеренүләр нәтиҗәсендә башкалабызның монголларга кадәрге чорда ук яшәгәнлеген исбатлаучы материаллар, шул исәптән, иң борынгы саклану корылмалары табылды. Казан ханнары күмелгән төрбәләрне ачу исә киң җәмәгатьчелек тарафыннан олы бер сенсация буларак кабул ителде [Халиков, 1976; 1997].

Рус елъязмаларында олуг шәһәр саналган, әмма археологик яктан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән Биләрдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән экспедициясе профессор А.Х. Халиков җитәкчелегендә 1967 елда киң масштаблы казу эшләре башлап җибәрде. Көнчыгыш Европаның урман-дала киңлекләрендә беренче мәртәбә буларак Биләрне һәм аның тирә-юнен махсус приборлар белән аэрофотога төшерү, Урта Идел төбәгендә X гасырда ук салынган уникаль Җәмигъ мәчет хәрабәләрен, кирпеч архитектура биналарын («кәрван-сарай» мунчасы, «бай феодал йорты», эчке шәһәрдәге җәмәгать мунчасы) казып чыгарып консервацияләү, гомуми озынлыгы 40 чакрымга җитә торган саклану ди-

варларын, торак йорт һәм хуҗалык корылмаларын, болгар археологиясендә бүгенгәчә бердәнбер булып кала биргән юрта эзләрен, металл коючылар, тимерчеләр, чүлмәк ясаучылар яши торган һөнәрчелек бистәләрен, шәһәр зиратларын тикшерү, анда табылган материалларны, озакка сузмыйча, фәнни әйләнешкә кертү [Исследования ..., 1976; Новое ..., 1979; Культура ..., 1985 һ.б.] — болар барысы да Биләрне, территориясенең нибары 0,25% ы гына казылган булуга карамастан, археологик яктан яхшы ук өйрәнелгән болгар шәһәрләре рәтенә куйдылар. Һәрхәлдә Биләрдә эшләүче археологлар кулында Болгар дәүләтенең беренче башкаласына кагылышлы бәхәсле проблемаларны яңадан күтәрү өчен бай мәгълүмат тупланган иде [Биляр ..., 1991; Хузин, 1995].

1970 елларда археологиядәге яңа ачышлар Урта Идел регионында яшәүче фин-угыр һәм төрки халыкларның килеп чыгышы проблемаларын өйрәнүне актуальләштерде. Төрки халыкларның этногенезына багышланган мәкаләләр җыентыгын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты 1971 елда чыгарды [Вопросы..., 1971]. Әлеге җыентыкка кертелгән мәкаләләрнең кайберсе галимнәр арасында бәхәсләр тудырса да, ахыр чиктә ул әлеге өлкәдә алып барыла торган тикшеренүләрне җанландырып кына җибәрде [Кузеев, 1974; Болгары..., 1984]. Бу юнәлештә А.Х. Халиков бик актив эшләде [Халиков, 1972; 1978; 1985; 1989]. Кызганычка каршы, галимнең 1970 еллар уртасында ук тәмамланган монографиясе моннан берничә ел элек кенә дөнья күрә алды [Халиков, 2011].

Институтның сан ягыннан артык зур булмаган археологлар төркеме алып барган тикшеренүләрнең тематикасы җитәрлек дәрәҗәдә киң булып, әлеге «киңлек» авторлар коллективы әзерләп чыгарган фәнни җыентыкларда чагылыш таба иде [Об исторических..., 1981; Средневековые..., 1983; Военно-оборонительное..., 1985; Волжская..., 1986 и др.]. Әйтергә кирәк, шул тематика кысаларында планлаштырылган хезмәтләр, кагыйдә буларак, югары фәнни дәрәҗәдә башкарылалар иде. 1980 елларның беренче яртысында гына да Мәскәүнең «Фән» нәшриятында 5 индивидуаль монография [Халиков, 1980; Мухамадиев, 1983; Фахрутдинов, 1984; Петренко, 1984; Хлебникова, 1984] һәм 2 коллектив хезмәт [Археологическая..., 1981; Культура..., 1985] басылып чыгуы — әлеге фикерне куәтләүче ачык факт.

Казан археология мәктәбенең өлгергәнлеген күрсәтүче фактлар исәбенә галимнәребезнең еш кына Болгариядә, Венгриядә, Чехословакиядә, Финляндиядә һәм кайбер башка илләрдә үтә торган халыкара конференцияләрдә катнашуларын да өстәргә мөмкин.

1986 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтында чираттагы структур үзгәрешләр булды, аерым алганда, археология һәм этнография секторы икегә бүленде.

**Археология бүлегендә** 9 фәнни хезмәткәр (шул исәптән, 1 — фәннәр докторы, 5 — фәннәр кандидаты) һәм 4 лаборант эшли иде. Бүлек белән 1989 елга кадәр А.Х. Халиков, 1989—1990 елларда Ф.Ш. Хуҗин, 1990 елның октябреннән башлап П.Н. Старостин җитәкчелек иттеләр.

Фәнни тикшеренүләрнең тематикасы үзгәрмәде диярлек. Ел саен язын-көзен Идел-Кама сусаклагычлары зонасында калган һәм җимерелеп юкка чыгу куркынычы янаган борынгы объектларны саклауга, казулар үткәрүгә, һич югы, аунап яткан табылдыкларны җыеп алуга юнәлдерелгән эшләр алып барылды. Шундый эшләр нәтиҗәсендә тупланган материаллар-

ны өйрәнеп, Е.П. Казаков Каманың түбән агымында урнашкан болгар авыллары, халыкара сәүдә үзәкләре турында кызыклы монография язды [Казаков, 1991].

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары зонасында, башлыча, борынгы таш, бронза һәм элгәреге тимер гасырына караган археология һәйкәлләре өйрәнелде [Памятники..., 1988; Археологические 1989, 1992 и др.]. В.Н. Марков 1988 елда ананьино халкының этник компонентларын ачыклауга багышланган кандидатлык диссертациясен яклады [Марков, 1988]. П.Н. Старостинны соңгырак чорда яшәгән пьянобор, азелино һәм имәнкискә кабиләләренең тарихы кызыксындырды [Старостин, 1986; Старостин, Чижевский, 1993].

Элгәреге болгарлар археологиясен Н.Ф. Калининның тууына 100 ел тулуга багышлап үткәрелгән Бөтенроссия фәнни конференциясе җанландырып җибәрде. Е.П. Казаков үзенең күпьеллык һәм уңышлы тикшеренүләр нәтиҗәсен фәнни җәмәгатьчелеккә болгар археологисендә әһәмиятле вакыйга буларак кабул ителгән фундаменталь монография һәм докторлык диссертациясе рәвешендә тәкъдим итте [Казаков, 1992].

Болгар һәм Биләр шәһәрләрендә казу эшләре тукталып тормады. Г.А. Федоров-Давыдов һәм Т.А. Хлебникова редакциясендә «Шәһри Болгар» исемле коллектив монографиянең беренче томы дөнья күрде [Город..., 1987; 1988]. Биләр археологиясенә караган хезмәтләрдән Идел Болгарстанының X—XI йөзләрдәге башкаласы проблемасын чишүгә юнәлдерелгән мәкаләләр җыентыгын атарга була [Биляр..., 1991]. Әлеге җыентык 1972—1975 елларда «Советская археология» журналы оештырган фәнни дискуссиядә традицион караш тарафдарлары буларак чыгыш ясаган А.П. Смирнов, Р.Г. Фәхретдинов һәм Т.А. Хлебниковага җавап рәвешендәрәк әзерләнгән иде. Болгар дәүләтенең әүвәлге башкаласы белән бәйле проблемаларны мин Биләрнең культура катламы стратиграфиясенә һәм хронологиясенә багышланган монографиямдә дә күтәрдем [Хузин, 1995, с. 137 и сл.].

1990 еллар башында коллегаларым белән моңа кадәр археологларның игътибарыннан читтәрәк калып килгән Сувар, Җүкәтау, Чаллы ише болгар-татар калаларында да казу эшләре үткәрә алдык[5] [Хузин, Набиуллин, 1997; Хузин, Нигамаев, 1997; Хузин, Шарифуллин, 1999].

Украина ССР Фәннәр академиясенең Археология институты белән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты арасында 1988 елда төзелгән килешү кысаларында XII гасыр гарәп географы әл-Идриси язмаларында тасвирланган Болгар — Киев сәүдә юлын археологик яктан өйрәнү максатыннан, А.Х. Халиков һәм А.П. Моця җитәкчелегендәге экспедиция өч сезон буена (1989—1991 еллар) әлеге кәрван юлының көнбатыш (Русь) һәм көнчыгыш (Болгар) өлешләрендә җентекле разведка, ә кайбер пунктларда казу эшләре үткәрде. Тикшеренүләр нәтиҗәсе Воронежда һәм Казанда үткәрелгән конференцияләрдә чыгыш ясаучыларның докладларында [Путь ..., 1992] һәм махсус монографиядә бәян ителде [Моця, Халиков, 1997].

1994 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, «Казан кремле» музей тыюлыгы һәм Казан дәүләт университеты белән берлектә, Кремль территориясендә казу эшләре башлап җибәрде. Берләштерелгән археологик экспедицияне җитәкләү вазифасы миңа йөкләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 16 октябрендә чыккан 746 нчы номерлы

карары нигезендә Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология бүлеге Археологик тикшеренүләр милли үзәге (Национальный центр археологических исследований — НЦАИ) итеп үзгәртелә. Бер елдан әлеге Үзәк Татарстан Фәннәр академиясе составында яңа оешкан Тарих институтына күчә.

Шулай итеп, Тел, әдәбият һәм тарих институты составында археология фәне зур уңышларга иреште, халыкара танылу алды. Биредә үзенең илкүләм танылган галимнәре булган Казан археология мәктәбе барлыкка килде. Институт галимнәренең борынгы таш, бронза, элгәреге тимер һәм урта гасырлар, бигрәк тә болгар, Алтын Урда археологиясе өлкәсендә ясаган ачышлары археология фәненең киләчәктәге үсеше өчен нигез булып торалар.

**Әдәбият**

Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1981. 212 с.

Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1984. 116 с.

Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье / отв. ред. П.Н. Старостин. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1986. 110 с.

Археологические памятники Центрального Закамья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 98 с.

Археологические памятники Восточного Закамья / отв. ред. Е.П. Казаков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1989. 100 с.

Археологические памятники бассейна р. Черемшан / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1990. 112 с.

Археологические памятники зоны водохранилищ Волго-Камского каскада / отв. ред. П.Н. Старостин. Казань: ИЯЛИ КНЦ РАН, 1992. 143 с.

Археологические памятники Нижнего Прикамья. Сб ст. / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1984. 125 с.

Археология Волжской Булгарии: проблемы, поиски, решения / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1993. 138 с.

*Бадер О.Н., Халиков А.Х.* Памятники балановской культуры. Свод археологических источников. Вып. В 1—25. М.: Наука, 1976. 168 с.

Биляр — столица домонгольской Булгарии / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ КНЦ АН СССР, 1991. 139 с.

Болгары и чуваши. Чебоксары, 1984. 158 с.

Военно-оборонительное дело домонгольской Булгарии / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1985. 126 с.

Волжская Булгария и монгольское нашествие / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 126 с.

Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1971. 295 с.

*Габяшев Р.С.* Неолит Нижнего Прикамья. Автореф. дис. … канд. ист. наук. М.: Ин-т археологии АН СССР, 1978. 18 с.

*Габяшев Р.С., Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х., Хлебникова Т.А.* Археологические памятники Татарии в зоне Куйбышевского водохранилища // Из археологии Волго-Камья. Казань, 1976. С. 3— 34.

*Генинг В.Ф.* Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа // Тр. КФАН СССР, сер. гуманит. наук. Вып. 2. Казань, 1959. С. 157—219.

*Генинг В.Ф.* Тураевский курганный могильник в Нижнем Прикамье // Вопросы археологии Урала. Вып. 2. Свердловск, 1962. С. 72—80.

*Генинг В.Ф., Стоянов В.Е., Хлебникова Т.А., Вайнер И.С., Казаков Е.П., Валеев Р.К.* Археологические памятники у села Рождествено. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1962. 127 с.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге: Больше-Тарханский могильник / отв. ред. Н.Я. Мерперт. М.: Наука, 1964. 196 с., 11 л. илл.

Город Болгар: очерки истории и культуры / отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1987. 232 с.

Город Болгар: очерки ремесленной деятельности / отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1988. 280 с.

Древности Икско-Бельского междуречья: отчеты Нижнекамской археологической экспедиции АН СССР. Вып. 2. Работы Татарского отряда / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1978. 151 с.

Из археологии Волго-Камья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1976. 192 с.

Исследования Великого города / отв. ред. В.В. Седов. М.: Наука, 1976. 262 с.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Поселения эпохи бронзы в Приказанском Поволжье по раскопкам 1951—1952 гг. // МИА. 1954а. № 42. С. 157—246.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ за 1945—1952 гг. // Тр. КФАН СССР. Сер. истор. наук. Казань: Таткнигоиздат, 1954б. 126 с.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Именьковское городище // МИА. 1960. № 80. С. 226—250.

*Казаков Е.П.* Погребальный инвентарь Танкеевского могильника // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 94—155.

*Казаков Е.П.* Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1978. 130 с.

*Казаков Е.П.* Булгарское село X—XIII веков низовий реки Камы. Казань: Таткнигоиздат, 1990. 176 с.

*Казаков Е.П.* Культура ранней Волжской Болгарии / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1992. 335 с.

*Косменко М.Г.* Мезолит Среднего Поволжья. Автореф. дис. … канд. ист. наук. — М.: Ин-т археологии АН СССР, 1972. 18 с.

*Кузеев Р.Г.* Происхождение башкирского народа. М.: Наука, 1974. 571 с.

Культура Биляра: Булгарские орудия труда и оружие X—XIII вв. / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1985. 215 с.

*Марков В.Н.* Нижнее Прикамье в ананьинскую эпоху: об этнокультурных компонентах ананьинской общности. Автореф. дис. … канд. ист. наук. М., 1988. 18 с.

*Мухамадиев А.Г.* Булгаро-татарская монетная система XII—XV вв. / отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1983. 164 с., 21 табл.

*Никитин В.В.* Пятьдесят лет Марийской археологической экспедиции // Влияние природной среды на развитие древних сообществ: материалы науч. конф., посвящ. 50-летию Марийской археол. экспедиции. Йошкар-Ола, 2007. С. 3—17.

Новое в археологии Поволжья: археологическое изучение центра Билярского городища / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. 155 с.

Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1981. 143 с.

Памятники первобытной эпохи в Волго-Камье. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 130 с.

*Петренко А.Г.* Древнее и средневековое животноводство Среднего Поволжья и Предуралья / отв. ред. П.Н. Старостин. М.: Наука, 1984. 184 с.

Путь из Булгара в Киев / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КНЦ РАН, 1992. 133 с.

Средневековые археологические памятники Татарии / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1983. 168 с.

*Старостин П.Н.* Памятники именьковской культуры. Свод археологических источников. Вып. Д 1— 32. М.: Наука, 1967. 48 с.

*Старостин П.Н.* Памятники предболгарского времени в Нижнем Прикамье // Плиска — Преслав: прабългарската култура. Материали от българо-съветската среща, Шумен, 1976. София, 1981. С. 82—91.

*Старостин П.Н.* Именьковские могильники // Культуры Восточной Европы I тысячелетия. Куйбышев, 1986. С. 90—104.

*Старостин П.Н., Чижевский А.А.* Маклашеевский V могильник // Древние памятники приустьевого Закамья. Казань, 1993. С. 20—42.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: Таткнигоиздат, 1975. 219 с.

*Фахрутдинов Р.Г.* Очерки по истории Волжской Булгарии / отв. ред. С.А. Плетнева. М.: Наука, 1984. 215 с.

*Халиков А.Х.* История населения Казанского Поволжья в эпоху бронзы. Автореф. дис… канд. ист. наук. М.: ИА АН СССР, 1955. 18 с.

*Халиков А.Х.* Неолитические памятники в Казанском Поволжье // Материалы исследования по археологии СССР. М.: 1958. № 61. С. 11—44.

*Халиков А.Х.* Новые памятники абашевской культуры в Волго-Вятском междуречье // Советская археология. М.: 1959. № 2. С. 148—168.

*Халиков А.Х.* Материалы к изучению истории населения Среднего Поволжья и Нижнего Прикамья в эпоху неолита и бронзы. Тр. МарАЭ. Т. 1. Йошкар-Ола, 1960. 187 с.

*Халиков А.Х.* Очерки истории населения Марийского края в эпоху железа // Тр. МарАЭ. Т. 2. Йошкар-Ола, 1962. С. 7—187.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья / отв. ред. О.Н. Бадер. М.: Наука, 1969. 395 с.

*Халиков А.Х.* К вопросу о начале тюркизации населения Поволжья и Приуралья // Советская этнография. 1972. № 1. С. 100—109.

*Халиков А.Х.* О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976. С. 3—19.

*Халиков А.Х.* Волго-Камье в начале эпохи раннего железа (VIII—VI вв. до н.э.). М.: Наука, 1977а. 264 с.

*Халиков А.Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань: Таткнигоиздат, 1978. 160 с.

*Халиков А.Х.* Приказанская культура. Свод археологических источников. Вып. В I—24. М.: Наука, 1980. 128 с.

*Халиков А.Х.* К вопросу этнической территории буртасов во второй половине VIII — начале X в. // Советская этнография. М.: 1985. № 5. С. 161—164.

*Халиков А.Х.* Татарский народ и его предки. Казань: Таткнигоиздат, 1989. 221 с.

*Халиков А.Х.* Остатки ханских мавзолеев в Казанском кремле (по материалам раскопок 1977 года) // Мавзолеи Казанского кремля. Казань, 1997. С. 22—49.

*Халиков А.Х.* Основы этногенеза народов Среднего Поволжья и Приуралья / отв. ред. С.В. Кузьминых, Ф.Ш. Хузин. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2011. 336 с.

*Халиков А.Х., Патрушев В.С.* Волжские ананьинцы: Старший Ахмыловский могильник. М.: Наука, 1982. 277 с.

*Хлебникова Т.А.* Алексеевское городище: (к вопросу о своеобразии раннеболгарской культуры района Нижнего Прикамья) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 156—174.

*Хлебникова Т.А.* К истории Жукотина (Джуке-тау) домонгольской поры (по работам 1970—1972 гг.) // Советская археология. 1975. № 1. С. 234—251.

*Хлебникова Т.А.* Керамика памятников Волжской Болгарии: (к вопросу об этнокультурном составе населения) / отв. ред. Советская археология. Плетнева. М.: Наука, 1984. 240 с.

*Хузин Ф.Ш.* Великий город на Черемшане. Стратиграфия, хронология. Проблемы Биляра — Болгара / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. 223 с.

*Хузин Ф.Ш., Набиуллин Н.Г.* Булгарский город Джукетау на Каме (по материалам раскопа III 1991 и 1993 гг.) // Археологическое изучение булгарских городов. Казань, 1999. С. 90—103.

*Хузин Ф.Ш., Нигамаев А.З.* Раскопки на территории пригородов Чаллынского городища // Археологическое изучение булгарских городов. Казань, 1999. С. 114—142.

*Хузин Ф.Ш., Шарифуллин Р.Ф.* Город Сувар: некоторые итоги и задачи археологического исследования // Проблемы древней и средневековой археологии Волго-Камья. Казань, 1999. С. 85—100.

*Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / отв. ред. М.Х. Гайнуллин. — М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с., 77 табл.

*Khalikova E.A., Kazakov E.P.* Le cimetiere de Tankeevka // Les anciens hongrois et les ethnies voisines a l'Est. Budapest, 1977. P. 21—221.

*Halikova E.A., Halikov A.H.* Altungarn an der Kama und im Ural. (Das Gräberfeld von Bolschie Tigani) / Régészeti Füzetek, ser. II, No 21. Budapest: Maguar Nemzeti Múseum, 1981. 132 S.

***Искәрмәләр:***

[1]Проф. А.П. Смирновның шәкерте, Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң 1952—1955 елларда Дәүләт тарих музеенда (Мәскәү) аспирантура үтә һәм 1957 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлый.

[2]Казан дәүләт университетын 1941 елда тәмамлый, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклаганнан соң, СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында эшли. 1958—1968 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән гыйльми хезмәткәр. Галимнең фәнни мирасын, башлыча, болгар-татар эпиграфикасына, этнография һәм археология өлкәсенә караган хезмәтләр тәшкил итә.

[3]Н.Ф. Калининның шәкерте, Пермь университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, 1955—1958 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый.

[4]Әлеге хезмәтнең төп авторлары А.Х. Халиков, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков, П.Н. Старостин, Р.Г. Фәхретдинов, Ф.Ш. Хуҗин, Һ.В. Йосыпов 1994 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

[5]Ул вакыттагы авыр кризис шартларында әлеге экспедицияләрне оештыруда, аз булса да финанслауда Институт директоры М.З. Зәкиевның роле зур булуын рәхмәт хисләре белән махсус билгеләп үтәсем килә.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*Татарстан Фәннәр академиясе А.Х. Халиков исем. Археология институтының*
*Урта гасырлар археологиясе бүлеге җитәкчесе*

УДК 39

*Р.Н. Мусина, С.В. Суслова*

# ТАТАРСТАНДА ЭТНОЛОГИК ТИКШЕРЕНҮЛӘР ТАРИХЫННАН
## ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 75 еллыгына

В статье рассматриваются вопросы становления и развития академической этнографии в Республике Татарстан.

**Ключевые слова:** этнография татарского народа, татары Волго-Уралья, сектор археологии и этнографии ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова.

Бүгенге заман этнологиясе — дөнья халыклары турындагы катлаулы төзелешле, комплексы фән. Ул, этнография буларак, борынгы халыкларның көнкүрешен һәм мәдәниятен җанлы итеп тасвирлаган фән. Идел буе татарлары этнографиясе буенча тәүге фәнни хезмәтләр XIX йөзьеллыкта барлыкка килә, һәм ул күпмедер дәрәҗәдә Казан университеты һәм аның Көнчыгыш бүлеге тюрколог-галимнәре (1829—1855 еллар) белән бәйле. 1878 елда Университет каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте һәм 1895 елда Шәһәр музее оешканнан соң этнографик тикшеренүләр һәм алар хакында басылып чыккан хезмәтләр саны сизелерлек арта башлый. Әлеге һәм башка шундый фәнни учреждениеләрдә, җәмгыятьләрдә тегe яки бу күләмдә этнография проблемаларын күтәргән күп кенә галимнәр (Г. Әхмәров, К. Фукс, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Н. Катанов, Х. Фәесханов, Г. Гобәйдуллин һ.б.) эшлиләр яки хезмәттәшлек итәләр. Татар этнографиясе белемен нигез салучылар нәкъ менә шулар булалар да инде.

Татарстан этнографларын рәсми оештыру тарихы Октябрь инкыйлабыннан соңгы беренче елларда — Татарстан Халык Комиссарлары Советының Республикадагы фәнни кадрларны үзенә туплаган Академик үзәге (1921 ел), шулай ук Татарларны өйрәнү (Татароведение) җәмгыяте (1922 ел) һәм Татарстанны өйрәнү җәмгыяте (1925 ел) оешкач башлана.

1939 елдан татарларның мәдәниятен һәм көнкүрешен фәнни тикшеренүләр үзәге Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институтына күчә (1946 елдан ул СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы составына кертелә, 1967 елдан Институт Г. Ибраһимов исемен йөртә). Н.И. Воробьев белән Г.М. Хисаметдиновтан торган этнография төркеме тарих секторы составында булып, сугыштан соңгы елларда алар татарларның (нигездә авылларда яшәүчеләренең) этнографиясе буенча фәнни тикшеренүләрне җанландырып җибәрәләр. 1961 елда Институтта археолоия һәм этнография секторы оеша, аны җитәкләү Н.И. Воробьевка йөкләнә.

Республикада академик этнография формалашуның башлангыч этабы Н.И. Воробьев исеме белән бәйле. Профессор Н.И. Воробьевның казанышы шунда, татарлар этнографиясенә эпизодик характерда гына якын килгән тикшеренүче элгәрләреннән аермалы буларак, ул татарларның мәдәниятен һәм көнкүрешен системалы өйрәнүгә нигез сала. Аның мөһим хезмәтләре — «Материальная культура казанских татар», «Казанские татары» [Воробьев, 1930; Воробьев, 1953]. Автор аларда традицион матди куль-

тураны — Казан татарларының торулыкларын һәм торакларын, киемнәрен һәм бизәнү әйберләрен, ризыкларын җентекләп тасвирлый.

Н.И. Воробьев, тел һәм культуракөнкүрештәге шул чорга кадәр өйрәнелгән хезмәтләргә таянып, Идел-Урал татарларының этно-мәдәни үзенчәлекләрен шактый киңәйтеп һәм югары дәрәҗәдә нигезләп дифференциацияләгән беренче автор булып санала. Аның бу өлкәдәге тикшеренүләре татар историографиясенең үзәген тәшкил иткән монографиядә тулы хәлдә тәкъдим ителә [Татары..., 1967]. Бу монографияне басмага әзерләүдә 1960 елларда ТӘһТИдә эшләгән этнографлардан Г.М. Хисаметдинов (раздел «Общественные отношения»), Г.В. Йосыпов («Верования и их пережитки»), Р.Г. Кәшәфетдинов («Народные праздники»), Р.Г. Мөхәммәдова һәм Ә.А. Заһидуллин («Семейно-родственные отношения») катнашкан.

Н.И. Воробьев тарафыннан эшкәртелгән классификация күп еллар дәвамында этнографлар өчен нигез кулланма булып хезмәт итте. Галим үзенең хезмәтләрендә этносның терекләгеген (яшәешен) тәэмин итү (торак, кием, тукучылык һ.б. белән) системасын классификациянең типологик базасында өйрәнү мөһимлеген аңлауга җитди якын килә, бу аңа мәдәниятнең кайбер этноүзенчәлекләре эволюциясен күзәтергә, башка халыкларның аларга хас чыганакларын һәм аналогларын билгеләргә һәм, шулар нигезендә, татарларның традицион культурасы барлыкка килү турындагы мәсьәләне күтәрергә ярдәм итә. 1970—1990 елларда традицион культураны өйрәнүгә типологик якын килү галимнең шәкертләре тарафыннан эзлекле рәвештә һәм уңышлы тормышка ашырыла. Монда Р.Г. Мөхәммәдованың «Татары-мишари» [Мухамедова, 1972], Й.Г. Мөхәммәтшинның «Татары-кряшены» [Мухаметшин, 1977], С.В. Суслованың «Женские украшения казанских татар» [Суслова, 1980], Ф.Л. Шәрифуллинаның «Касимовские татары» [Шарифуллина, 1991] дигән мәгълүм хезмәтләрен мисал итеп китерергә була. Шулай ук татар халкының җирле традицион культурасын тасвирлау нигезендә төзелгән «Пермские татары» [Пермские...], «Астраханские татары» [Астраханские...], «Молькеевские татары» [Молькеевские...], «Нагайбаки» [Нагайбаки...], «Сибирские татары» [Сибирские...] дигән коллектив хезмәтләрне дә Н.И. Воробьев салган эзнең дәвамы дияргә кирәк.

Бу басмаларның һәркайсы, Идел—Урал татарларының матди һәм рухи культурасын фундаменталь нигездә тикшереп өйрәнү белән бәйле татар этнографик фәненең аеруча мөһим этаплары формалашуда үз урынын били; татар халкының 1970—1990 еллардагы тарихи-этнографик атласы (проект җитәкчесе Р.Г. Мөхәммәдова) өчен мәгълүматлар туплауның һәм аны нәшер итүгә әзерләүнең җирлеген тәшкил итә. Этнографлар төркеме, елдан-ел сан ягыннан арта баруы нәтиҗәсендә, 1987 елда этнография лабораториясенә бүленә, 1988 елдан ул ТӘһТИ этнография бүлеге дип атала башлый. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты этнография бүлеге хезмәткәрләре ул елларда татарлар күпләп яшәгән регионнарга — 500 ләп авылга 30 экспедиция оештырдылар, 30 музей һәм 20 архив фондлары өйрәнелеп, эш барышында гаҗәеп бай һәм уникаль материал туплана. Системага салып фәнни каталогларга урнаштырылган, этнология бүлеге фондында саклана торган ул материаллар бүгенге һәм киләчәктәге тикшеренүләр өчен зур фәнни кыйммәткә ия булган ныклы база санала.

Хәзерге тарихи-этнографик тик-

шеренүләр комплексында милли тарихи-этнографик атласлар төзү, мәгълүм булганча, зур хезмәт сорый торган, әмма бик мөһим һәм перспективалы звено булып санала. Фәнни күзлектән караганда, аларның төп максаты этнорегиональ чыганакларның киңәйтелгән һәм күрсәтмәлелеккә нигезләнгән (репрезентатив) корпусын төзүдән гыйбарәт; шуның җирлегендә традицион культураның төп категорияләрен типологик классификацияләү принципларын эшләү, аерып күрсәтелгән типларны картографияләү һәм региональ этномәдәни комплексларны бүлеп чыгару. Бу этап ТӘһТИдә башланып, 1996 елгы үзгәртеп корудан соң, ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты дәвам иткән Атлас томнары сериясен нәшер итү белән тәмамланды. Әлеге сериягә Н.А. Халиковның «Хозяйство татар Поволжья и Урала» [Халиков, 1995], Ф.Ш. Сафинаның «Ткачество татар Поволжья и Урала» [Сафина, 1996], С.В. Суслова белән Р.Г. Мөхәммәдованың «Народный костюм татар Поволжья и Урала» [Суслова, Мухамедова, 2000], Р.К. Уразманованың «Обряды и праздники татар Поволжья и Урала» [Уразманова, 2001] дигән монографияләре керде. Атласның йомгаклау томында («Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала») аңа хәтле басылып чыккан томнардагы типологик һәм картографик материаллар нигезендә авторлар тарафыннан традицион культураның җирле (локаль) комплексы аерып күрсәтелә, табигый, социаль-икътисади, конфессиональ факторларның тарихи-мәдәни ареалы барлыкка килүгә йогынтысы карала. Бу томда Идел — Урал татарларының этник классификациясе тагын да аныкланган һәм төгәлрәк нигезләнгән. Төрки (Тюркская) академиянең басма проектлары кысаларында, бераз соңрак, Й.Г. Мөхәммәтшин белән Н.А. Халиковның «Усадьба тюркских народов: сельское жилище татар Поволжья и Урала (конец XIX — нач. XX вв.): историко-этнографический Атлас татарского народа» [Мухаметшин, Халиков, 2011] дигән хезмәте басылып чыга.

Атлас материаллары, 2000 еллардан башлап, алдагы этнографик тикшеренүләрнең (татарларның традицион культурасы буенча диахрон һәм синхрон тикшеренү алымнары кулланып, тирәнтен этнорегиональ эзләнүләр белән бәйле тарихи этнографиянең) хәзерге этабында фундаменталь чыганак базасы булып тора. Этнорегиональ аспект, мәгълүм булганча, этносларның төрле структур төркемнәрендә халык культурасы формалашу һәм аның гамәлгә кертелүе үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә, бу исә этник тарихны һәм халык культурасы формалашу тарихын бөтен тирәнлеге белән өйрәнүдә мөһим шарт булып санала. Бүгенге тарихи-этнографик тикшеренүләр барышында әлеге аспект этно-мәдәни бәйләнеш векторларын, аларның юнәлеше үзгәрү сәбәпләрен ачыклауда, территориаль этно-мәдәни элементләрнең үзенчәлеген аныклауда, күчеш зоналарында үзара йогынты ясауның характерлы билгеләрен аерып күрсәтүдә, төп цивилизацион үзәкләрнең этник культураларга тәэсире дәрәҗәсен аңлауда өстенлекле урын били. С.В. Сусловaның 2010 елдагы Төрки (Тюркской) академия проектлары кысаларында басылып чыккан монографиясе шундый этнорегиональ тикшеренүләрдән саналырга хаклы [Суслова, 2011]. Тикшеренүләрнең мондый заманча этабы Казан тикшеренүчеләре тарафыннан кулланылуы һәм кайбер катнаш фәннәр, аерым алганда этноархеология ысулларын файдалану белән характерлана. Нәкъ менә этноархеологик (диахрон) тикшеренү кысала-

рында халыкның традицион культурасы формалашуын, аның этнотерриториаль комплекслары генезисы мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнеп ачыкларга мөмкин дә инде. Этноархеология ысуллары традицион культураның башлангыч һәм борынгы этнографик формаларын үзгәртеп кору белән бәйле мәсьәләләрне дә нәтиҗәле хәл итәргә мөмкинлек тудыра.

Тарих фәннәре докторы Д.М. Исхаковның татарларны һәм аларның борынгы бабаларының тарихи-демографик һәм статик планда өйрәнгән күпсанлы хезмәтләрен милли тарихи этнографиянең үзенә бер төрле векторы дип санарга була [Исхаков, 1983; 1993 һ.б.]. Аның тарафыннан (кайбер очракларда И.Л. Измайлов автордашлыгы белән) Җүчи олысы һәм Алтын Урда дәүләтенең соңгы дәверләрендә һәм XV—XVI гасырларда яшәгән төрки-татар дәүләтләрендә Урта гасыр татар этносы барлыкка килү һәм аның яшәешендәге төп үзенчәлекләр ачыклана, милли характердагы татар бердәмлеге оешуның этник аспектлары, шул процесстагы мөһим этаплар, аларга хас аерымлыклар өйрәнелә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Д.М. Исхаков, этнологик ысуллар ярдәмендә, Урта гасыр төрки-татар халкы тарихының үзенчәлекле тармакларын да (әйтик, Алтын Урдада һәм аның соңгы дәверләрендә хөкем сөргән кланлылык системасын) тикшереп өйрәнә [Исхаков, 1998; Исхаков, Измайлов, 2007; Исхаков, 2009; 2011 һ.б.].

ТӘһСИ галимнәре, традицион һәм тарихи этнографиядән тыш, бүгенге заман этносоциаль һәм этномәдәни процессларны өйрәнүгә бәйле, этнология белән социологияне тоташтырган яңа юнәлеш — этносоциология өлкәсендә дә нәтиҗәле эш алып баралар. Республикада бу юнәлештәге эшне «Быт рабочих-нефтяников татар юго-востока Татарстана (1950—1960 гг.)» дигән диссертацион хезмәте белән Р.К. Уразманова башлап җибәрде [Уразманова, 2002]. Россиядә этносоциологик институт оештыру мәсьәләсе СССР Фәннәр академиясе Этнография институты төгәл-социологик тикшеренүләр секторы хезмәткәрләре тарафыннан 1967—1968 елларда, Татарстан АССР җирлегендә уздырылган киң масштаблы тикшеренүләр базасында калкып чыкты. Этносоциологиянең шул вакытта нигез салынган методологик принцибы — үзара бәйләнештәге социаль һәм этник күренешләр җыелмасына системалы якын килү — татарларны тикшереп өйрәнү һәм Татарстандагы алда булачак барлык этносоциологик тикшеренүләр өчен дә төп нигез булып калачак. Р.Н. Мусинаның «Этносоциологические исследования в Татарстане» дигән хезмәтендә (ул «Этносоциология и этносоциологи. Исследования, поиски, воспоминания» җыентыгында басылып чыга), шулай ук Р.Н. Мусина белән Г.Ф. Габдрахманова тарафыннан әзерләнеп, «Социологические исследования» журналында дөнья күргән «Становление и развитие этносоциологии в Республике Татарстан» мәкаләсендә бу хакта тулы анализ ясала [Мусина, 2008, с. 262—278; Габдрахманова, Мусина, 2012, с. 83—93].

Этнография бүлеге этносоциологлары өчен «Современные этносоциальные и этнодемографические процессы в ТАССР. 1899—1990 гг.» дигән зур күләмле фәнни-тикшеренү проекты (җитәкчеләре — Л.М. Дробижева, Д.М. Исхаков, Р.Н. Мусина) мөһим чыганак ролен үти. Программа буенча һәм 1967—1968 еллардагы тикшеренүләр белән чагыштыру 1980—1990 еллар чигендәге этнодемографик, этномәдәни (шул исәптән этнотел, этноконфессиональ), этносоциаль вазгыятьне, татарларның этномилли үзаңы формалашуны һәм аның үсешен өйрәнү генә түгел, ә бу процесс һәм күренешләрнең динамикасын күзәтергә дә ярдәм итә [Со-

временные..., 1991]. Мондый хезмәт, «Этническая идентичность, национализм и разрешение конфликтов в Российской Федерации. 1993—1996 гг.» (җитәкчесе — Л.М. Дробижева) дип аталган регионара тикшеренү кебек үк, 1990—2000 елларда ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты этносоциологлары тарафыннан уздырылган тикшеренүләрнең базасын тәшкил итә.

Этносоциаль проблематика белән кызыксынуның яңа дулкыны безнең Республикада 1990 елларда, халыкның социаль-икътисади, сәяси, рухи тормышында зур үзгәрешләр килеп туган шартларда кузгалды. Региональ, гомум Россия һәм халыкара фәнни-тикшеренү проектларының кайберләрендә бүлек этносоциологлары хәзерге этносәяси, этнодемографик, этномәдәни, этнотел процессларын, Татарстандагы этникара һәм этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне, этномәдәни маркерларның бердәйлеге (үзара тәңгәллеге) эчтәлеген һәм аның тормышта кулланылуын тикшереп өйрәнделәр.

2000 еллардагы этносоциология үсеше, барыннан да бигрәк, 1990 елларда — 2000 еллар башында Татарстанда этник күрсәткечләр динамикасын дөрес аңлау һәм тикшеренүләрнең яңа юнәлешләрен билгеләү [Этносоциологические..., 2008], шул исәптән татар этносын барлыкка китерүдә төрле факторларның һәм объектив шартларның [Сагитова, 1998], бердәйлек формалаштыруда этномәдәни сәясәтнең роле [Макарова, 2010] бердәйлек структурасында һәм этникара мөнәсәбәтләрдә дин тоткан урын (диннең йогынтысын тикшереп өйрәнү) [Мусина, 2009, с. 86—100], этносның социаль-икътисади үсешендә этник культураның роле [Габдрахманова, 2010] белән характерлана.

Этносоциологлар эшенең мөһим юнәлеше этнотел өлкәсендәге хәзерге тенденцияләрне ачыклау, этник сыйфатлар барлыкка килүдә телнең ролен (этник үзаң формалашуга телнең йогынтысын, этнотел кыйммәтләрен конструкцияләү һәм трансляцияләүдә сәясәтнең, белемнең, гаиләнең әһәмиятен) ачыклау. Этнотел буенча тикшеренүләрнең нәтиҗәләре «Современные этнокультурные процессы в молодежной среде Татарстана: язык, религия, этничность» [Современые..., 2000], «Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования» [Языки..., 2011], «Язык и этнос на рубеже веков: этносоциологические очерки о языковой ситуации в Республике Татарстан [Язык..., 2002] дигән коллектив монографияләр сериясендә яктыртылган.

Традицион этнография белән бүгенге заман этнографиясен билгеле бер дәрәҗәдә гомумиләштерү Р.К. Уразманованың татарларда көнкүреш һәм бәйрәм культураларын трансформацияләү проблемаларын уңышлы күтәргән хезмәтләрендә чагылыш тапкан [Уразманова, 2013]. Р.К. Уразманованың хәзерге вакыттагы исламга нигезләнгән көнкүреш (йола, гадәт) культурасына җитди анализ ясаган кайбер мәкаләләре Россия үзәк теоретик-методологик басмаларының берсе — «Этнографическое обозрение» журналында урын алды.

ТР ФА Тарих институтының этнология бүлеге һәм этнографлары, этносоциологлар тарафыннан, мөстәкыйль рәвештә уздырылган этнографик тикшеренүләрдән тыш, комплекслы тикшеренүләр дә уздырыла. Мәсәлән, «Кряшены на пароге XXI века: этническая культура и проблема идентичности» (җитәкчесе — Р.Н. Мусина, 2003), Кырымга ясалган экспедиция буенча «Крымские татары: традиционная культура и современные этносоциальные, этнокультурные процессы» (җитәкчесе — Г.Ф. Габдрахманова, 2003) проект-

лары тормышка ашырылды. Республиканың академик этнологиясе өчен 2000 елларда мөһим саналган күләмле проектлардан «Халык һәм мәдәният» сериясе буенча басылып чыккан «Татары» [Татары, 2001] монографиясен һәм «Татарика. Этнография» атласын [Татарика..., 2008] санарга була. Аларда үзенең юбилеен билгеләп үтүче Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан юнәлеш алган Татарстан этнология фәне өлкәсендәге үсеш югарылыгы демонстрацияләнә.

**Әдәбият**


Астраханские татары / отв.ред. Д.М. Исхаков. Казань: Татполиграф, 1992.

*Воробьев Н.И.* Казанские татары. Казань: Татгосиздат. 1953. 381 с.

*Габдрахманова Г.Ф.* Этнокультурные ресурсы экономического развития. Казань: Казан.ун-т, 2010, 370 с.

*Габдрахманова Г.Ф., Мусина Р.Н.* Становление и развитие этносоциологии в Республике Татарстан // Социологические исследования, 2012, № 2. С. 83—93.

Историческая этнография татарского народа / Отв.ред. С.В. Суслова. Казань, 1990.

*Исхаков Д.М.* Институт сейидов в улусе Джучи и позднезолотоордынских тюрко-татарских государствах. Казань: ФЭН. 2011. 228 с.

*Исхаков Д.М.* Историческая демография татарского народа (XVII— начало XX в.). Казань: ИЯЛИ АН Татарстан. 1983. 143 с.

*Исхаков Д.М.* Исторические очерки. Казань: Фэн. 2009. 164 с.

*Исхаков Д.М.* От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV—XVII вв.). Научное издание. Казань: Мастер-Лайн. 1998. 276 с.

*Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона (принципы выделения, формирование, расселение и демография). Казань: ИЯЛИ АН Татарстан. 1993. 173 с.

*Исхаков Д.М., Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар (XIII— середина XVI вв.). Научное издание. Казань: РИЦ «Школа». 2007. 356 с.

*Макарова Г.И.* Идентичности татар и русских в контексте этнокультурной политики Российской Федерации и Республики Татарстан. Казань: Казан.ун-т. 2010. 248 с.

Молькеевские татары / Отв.ред. Д.М. Исхаков. Казань: Татполиграф, 1993.

*Мусина Р.Н.* Ислам и проблемы идентичности татар в постсоветский период // Конфессиональный фактор в развитии татар: концептуальные исследования. Казань. 2009. С. 86—100.

*Мусина Р.Н.* Этносоциологические исследования в Татарстане // Этносоциология и этносоциологи: исследования, поиски, воспоминания. М.: Старый сад. 2008. С. 262—278.

*Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: историко-этнографическое исследование материальной культуры (середина XIX — начало XX в.). М.: «Наука». 1977. 248 с.

*Мухаметшин Ю.Г.* Татары-кряшены: историко-этнографическое исследование материальной культуры (середина XIX — начало XX в.). М.: «Наука». 1977. 247 с.

Нагайбаки / Отв.ред. Д.М. Исхаков. Казань: Татполиграф, 1995.

Пермские татары / Отв.ред. А.Х. Халиков. Казань: Татполиграф, 1995.

*Сагитова Л.В.* Этничность в Татарстане. Казань: Татполиграф. 1998. 184 с.

*Сафина Ф.Ш.* Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX

в.). Историко-этнографический атлас татарского народа. / Отв.ред. Ю.И. Смыков. Казань: Фэн. 1996. 205 с.

Сибирские татары / Отв.ред. С.В. Суслова. Казань: Институт истории АН РТ, 2002.

Современные межнациональные процессы в ТАССР: программа исследования и инструментарий / Отв.ред. Р.Н. Мусина. Казань: Татполиграф, 1991. 158 с.

Современные этнокультурные процессы в молодежной среде Татарстана: язык, религия, этничность / Р.Н. Мусина, Я.З. Гарипов, Р.И. Зиннурова, Л.В. Сагитова. Казань: РИЦ «Школа», 2000. 138 с.

*Суслова С.В.* Женские украшения казанских татар середины XIX — начала XX в.: историко-этнографическое исследование. М.: Наука. 1980. 125 с.

*Суслова С.В.* История костюма тюркских народов: этнографическое исследование татарской народной одежды. Астана: «Сарыарка», 2011. 286 с. Татары Среднего Поволжья и Приуралья. / Отв.ред. Н.И. Воробьев, Г.М. Хисамутдинов. М.: Наука, 1967. 536 с.

*Суслова С.В., Мухамедова Р.Г.* Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). Историко-этнографический атлас татарского народа. / Отв.ред. Р.К. Уразманова. Казань: Фэн. 2000. 312 с.

Тартарика. Этнография / Отв.ред. р.Н. Мусина, Р.Р. Салихов, Р.Р. Хайрутдинов. М.:. Феория. 2008. 863 с.

Татары / Отв.ред. Р.К. Уразманова, С.В. Чешко. М.: Наука, 2001. 582 с.

Тюркские языки в условиях глобализации: этносоциологический анализ татарского языка / Сост. Габдрахманова Г.Ф., Исхакова З.А., Мусина Р.Н. Астана: Кантана-пресс. 2011. 396 с.

*Уразманова Р.К.* Быт рабочих-нефтяников татар юго-востока Татарстана (1950—1960 гг.): этносоциологическое исследование. Альметьевск. 2002. 158 с.

*Уразманова Р.К.* Обряды и праздники татар Поволжья и Урала. Годовой цикл (XIX — начало XX в.). Историко-этнографический атлас татарского народа / Отв. ред. С.В. Суслова. Казань: «ПИК» Дом печати. 2001. 197 с.

*Уразманова Р.К.* Праздничная культура и культура праздников татар. XIX — начало XXI в. Историко-этнографические очерки. Наб.Челны: Духовно-деловой центр «Ислам Нуры». 2013. 189 с.

*Халиков Н.А.* Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань, 1995. 276 с.

*Шарифуллина Ф.Л.* Касимовские татары. Казань: Татполиграф. 1991. 127 с. Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования / Ред. Р.К. Уразманова, Н.А. Халиков. Казань: Фэн. 2002. 248 с.

Этносоциологические исследования в Республике Татарстан / Сост. и ред. Р.Н. Мусина, Л.В. Сагитова. Казань: Институт истории АН РТ. 2008. 335 с.

Язык и этнос на рубеже веков: этносоциологические очерки о языковой ситуации в Республике Татарстан / Отв.ред. Р.Н. Мусина. Казань: Магариф, 2002. 208 с.

Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования. Казань: Татар.кн.изд-во. 2011. 158 с.

***Мусина Розалинда Нури кызы,*** *тарих фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;*

***Суслова Светлана Владимировна****, тарих фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94 (470.41):031

***Р.В.Шәйдуллин, Р.М.Вәлиев***

# XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА — XXI ГАСЫР БАШЫНДА РОССИЯДӘ ТАТАР МИЛЛИ ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКАСЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ

В статье рассматриваются особенности становления и развития татарской энциклопедистики, показывается значимость энциклопедических изданий для систематизации и аккумулирования научных знаний о татарском народе и Татарстане, а также анализируются работа коллектива и научно-практические перспективы деятельности Института Татарской энциклопедии Академии наук Республики Татарстан. Особое внимание уделяется исследованию проблем, связанных с подготовкой отраслевых энциклопедий в Татарстане и других национальных республиках России.

**Ключевые слова:** Россия, Татарстан, Институт Татарской энциклопедии Академии наук Республики Татарстан, Татарская энциклопедия, национально-региональные энциклопедии, отраслевые научно-справочные издания, энциклопедическое культуртрегерство.

Татарларның этномәдәни һәм этносәяси мәнфәгатьләренең идеологик нигезләре формалашкан тарихи шартлар татар халкы үсешенә хәлиткеч йогынты ясыйлар. XVI гасырның икенче яртысында — XVII гасырда этник дәүләти берләшмәләрнең (Казан, Әстерхан, Себер һәм Касыйм ханлыклары) юкка чыгарылуы һәм татарларның мәҗбүри рәвештә ят этномәдәни пространствога кертелүе, һичшиксез, аларның милли идеологиясе оешуга көчле тәэсир итәләр. Шул ук вакытта Россия дәүләтенең империячел идарә даирәләре тарафыннан татарларның этник потенциалын киметү һәм аны тәмам зәгыйфьләндерү максатында уздырылган сәясәтнең көчәюе татар халкының рус дәүләтчиркәү бөек державачылыгының «самодержавие, православие, халык» теориясенә нигезләнгән чынбарлыгына каршы күтәрелүенә китерә. XIX гасырның икенче яртысында — XX гасыр башында бай милли дәүләтчелек тарихы, мәдәнияте һәм менталь традицияләре булган татар халкы алдында тулы канлы этномәдәни һәм этносәяси үсешне тәэмин итәрлек этник яшәешнең яңа формасына ирешү мәсьәләсе кискен торган шартларда бу көрәш аеруча милли чагылыш ала. Татар җәмгыятенең демократик нигездә яңа гражданлык формалары оешуы Россия мөселманнарының дини мәнфәгатьләре суверенлашуы кысаларында бара, ул татар халкының милли мәнфәгатьләрен тормышка ашыруда төп, хәлиткеч тенденциягә әверелә. Мондый идеология һәм яңа бердәйлек барлыкка килүдә, аның үсешендә җәдитчелек идеяләре мөһим роль уйный. Татар иҗтимагый аңына җәдитчелек алгарышының беркадәр дәрәҗәдә генә үтеп керүе дә татар халкының мәдәният өлкәсендә яңа чынбарлыкка милли-дини энциклопедияләр барлыкка килүгә юл ача, әлеге энциклопедияләр татар җәмгыятендә барган этномәдәни һәм этносәяси үзгәрешләргә карата үзенчәлекле җавап рәвешендә туа. Шиһабетдин Мәрҗани («Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф»; «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар») һәм Ризаэддин Фәхретдиннең («Асәр»] фундаменталь энциклопедик хезмәтләрендә дөньядагы һәм Россиядәге күпмилләтле мөселман җәмгыятенең көндәлек тормы-

шындагы һәм тарихындагы аеручa мөһим социомәдәни вакыйгалар һәм күренешләр чагылыш таба. Ш.Мәрҗани — күпмиллионлы мөселманнар арасында татарларның этник бөтенлеген, Р.Фәхретдин татар халкының дөнья һәм Россия тарихындагы һәм мәдәниятендәге урынын һәм ролен аерып күрсәтүне төп максат итеп куялар. Аларның икесе өчен дә ислам (мөселман) традицияләренең һәм төрки-татар бердәйлегенең үзара дәвамлы бәйлелеге идеясе хас. Чынлыкта Ш:Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин Россия һәм дөнья халыкларының үзенчәлекле традицияләрен һәм этник мәдәниятләрен хөрмәт итүгә корылган яңа татар идеологиясен нигезләүчеләр булалар, бу исә урта гасырлардан сакланып килгән патриархаль искелек калдыкларын җимерүгә һәм милли гражданлык-хокукый җәмгыять төзүгә мөһим йогынты ясый.

1920 елларда Ш.Мәрҗанинең һәм Р.Фәхретдиннең энциклопедик традицияләре Исмәгыйль Рәмиев («Вакытлы татар матбугаты») һәм Әхмәтһади Максуди («Фәнни камус») тарафыннан дәвам иттерелә. Беренче татар энциклопедист галимнәреннән аермалы хәлдә, аларның хезмәтләренә тематик-тармаклылык хасияте хас була. Шул ук вакытта Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин һәм Ә.Максуди әсәрләренең күпчелеге кулъязма рәвешендә калып, киң татар җәмәгатьчелегенә барыпирешми. Шуңа да карамастан, аларның хезмәтләре яңа татар идеологиясен тудыру юлында, татарларның милли үзаңы формалашуда гына түгел, татар энциклопедистикасы барлыкка килүдә һәм аның үсешендә мөһим роль уйный. Бу чорны (XIX гасырның икенче яртысы — 1920 еллар) шартлы рәвештә татар энциклопедистикасы үсешенең беренче этабы дип атарга мөмкин. Шулай итеп, әлеге этапта татар милли яңарышы белән тыгыз бәйле җәдитчелек үзгәрешләре дулкынында яңа мәдәни-мәгърифәтчелек казанышы — Татар милли энциклопедиясе барлыкка килә. Иң мөһиме шул — татар халкының милли мәнфәгатьләрен материальләштерүдә ул җитди җирлеккә әверелә.

Татар энциклопедистикасы үсешенең икенче этабы 1980 елларның икенче яртысыннан башлана. Бу чорда СССР таркалу, Россия Федерациясендәге милли республикаларның «суверенлыклар парады» һәм административ берәмлекләрнең мөстәкыйльлеге үсеше белән бәйле үзгәртеп корулар дулкынында халыкларның үзаңы аларның тормыш рәвешендә, фикерләү калыпларында һәм дөньяны күзаллау алымнарында системалы үзгәрешләргә китергән кардиналь алгарыш кичерә. Бу үзгәрешләрдәге векторларның берсе Россия милли-төбәк энциклопедистикасы барлыкка килүдән гыйбарәт була. 1990 елларда милли яки төбәк энциклопедияләрен булдыру мәсьәләсе Россия халыкларының һәм төбәкләренең сәяси һәм этномәдәни тормышында үзәк урыннарны били башлый. Милли-төбәк энциклопедияләр эшләнүен хәзерге тикшеренүчеләр хаклы рәвештә идарәче даирәләрнең сәяси кызыксынуы белән бәйлиләр. Шул ук вакытта, алар фикеренчә, «яшь демократия» чорында халыкларның һәм төбәкләрнең этномәдәни мәнфәгатьләре икенче планда кала. 2003 елның 14—16 октябрендә Санкт-Петербургта Россия энциклопедистикасы мәсьәләләренә багышлап уздырылган Халыкара фәнни-гамәли семинарда катнашкан А.В.Кобакның, төбәк һәм милли энциклопедияләр бастыру — мәртәбәле гамәл, дигән, фәнни нигезләнгән фикере белән килешәбез. Ул: «Бу — сәяси бурыч. Һәр төбәкнең үзен танытасы, үзенең мөһимлеген күрсәтәсе килә. Әмма сәяси бурыч —

бердәнбер бурыч түгел. Икенче яктан караганда, әлбәттә, бу очракта мәгариф һәм агарту бурычлары да күздә тотыла. Өченче урынны (мөһимлелек буенча түгел) фәнни, тарихи һәм төбәкне өйрәнү бурычы били», — дигән иде [Проблемы ..., с.12]. Россия милли республикаларының сәяси һәм этномәдәни суверенялашуы күп яктан күпгасырлык этнотарихи һәм төбәк тәҗрибәсенә таяна, бу тәҗрибә исә тупланган рәвештә нәкъ менә энциклопедик басмаларда материальләшә.

XX гасыр ахырында — XXI гасыр башында Россиядә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә энциклопедик характердагы милли-төбәк басмаларының, чынлыкта, илнең барлык субъектларын колачлаган тулы бер китапханә системасы барлыкка килә. Россиянең Б.Н.Ельцин исемендәге милли китапханәсенең тарихи библиография бүлеге мөдире А.И.Раздорский исәпләүләре буенча, 2012 елга Россия Федерациясендәге 83 административ субъектның 73 е үзләренең төбәк һәм милли энциклопедияләрен бастырып чыгарды [Раздорский, б.11]. Россиядә дөнья күргән хәзерге энциклопедик әдәбият белән танышу нәтиҗәсендә территориаль тәгаенләнү һәм милли чагылыш тенденциясе ачыклана. Шулай итеп, 1990—2000 елларда Россиянең административ субъектларында булып узган энциклопедия шаукымының төп тенденциясе, җирле халыкның милли-төбәк мәнфәгатьләрен чагылдырудан бигрәк, төбәкләрдәге идарәче даирәләрнең сәяси ихтыяҗларыннан һәм дәгъваларыннан гыйбарәт иде.

Әлеге энциклопедияләрне шартлы рәвештә фундаменталь һәм фәнни-белешмәлек басмаларга бүләргә мөмкин. Беренчеләре кызыклы бәяләмә мәгълүмат (аеруча хәзерге чор шәхесләре хакында) бирсәләр, икенчеләрендә, башлыча, фәнни белешмәлек характерындагы мәгълүматларның өстенлек итүе күзгә ташлана. Болар барысы да теге яисә бу төбәктә фәнни белемнәрнең үсеш дәрәҗәсе, энциклопедик басмаларны эшләүче галимнәрнең профессиональлеге, өлешчә, төбәк сәясәтчеләренең дәгъвалары белән бәйле. Бу энциклопедияләр арасына Татарстан берничә басма — Татар энциклопедия сүзлеге, күптомлы Татар энциклопедиясе һ.б. белән керде. Төрле форумнарда һәм массачыл мәгълүмат чараларында татар энциклопедистикасы хакында төрле фикерләр белән очрашырга насыйп булды. Һичшиксез, андагы материалның киңлеге һәм объективлыгы, идеология һәм милли хисләр басымыннан азат булуы, мәкаләләрнең саллы библиография, кызыклы һәм эчтәлекле иллюстрацияләр белән тәэмин ителеше күпләрнең күңеленә хуш килде. Татар энциклопедистикасының дөнья һәм Россия энциклопедик традицияләренә эзлекле йөз тотуы да ассызыкланды.

Татар энциклопедистикасы үсешенең хәзерге этабы 1992 елда Татарстан Республикасы Президиумы каршында оештырылган Татар энциклопедиясе институты белән бәйле. 1994 елда Институт фәнни-тикшеренү һәм фәнни-нәшрият мәсьәләләре белән шөгыльләнүче мөстәкыйль академик учреждениегә әверелде. Әйтергә кирәк, Татар энциклопедиясен эшләү Ә.Максудиның 1920 еллар ахырында дөнья күргән татар энциклопедик басмасыннан соң, 60 елдан артык вакыт узгач кына башланды. Татар җәмәгатьчелегенең күп тапкырлар милли энциклопедиябезне төзү омтылышы җирле һәм үзәк җитәкчелекнең көчле каршылыгына дучар булды. Чынлыкта Институт тарихы 1990 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында оештырылган Та-

тар совет энциклопедиясе бүлегеннән башлангыч алды. Үзгәртеп корулар, Татарстанның дәүләт суверенлыгы өчен көрәш елларында ТАССР Министрлар Советының «Татар совет энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында»гы карары (1989) нигезендә Татар энциклопедиясенең 46 галимне, югары уку йортлары ректорларын һәм эре предприятиеләр җитәкчеләрен (М.Х.Хәсәнов (рәис), В.Е.Алемасов, М.З.Зәкиев, А.И.Коновалов, Р.А.Йосыпов һ.б.ларны) үз эченә алган фәнни-оештыру советы һәм составына 48 кеше (М.Х.Хәсәнов (рәис), Б.А.Арбузов, К.Ә.Вәлиев, Р.З.Сәгъдиев, И.А.Тарчевский, П.А.Кирпичников, В.Н.Пудовик, Ә.Р.Тенишев һ.б.) кергән баш фәнни-редакция коллегиясе оештырыла. 1990 елда Татар энциклопедиясе сүзлеген татар, рус һәм инглиз телләрендә эшләүне фәнни оештыру җәһәтендә СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында 13 кешедән торган Татар совет энциклопедиясе бүлеге (мөдире Ф.С. Хәкимҗанов) булдырыла. Ул 1992 елның 1 мартына татар телендә бастыру өчен Генераль лөгатьлекне һәм рус телендә мәкаләләрнең күпчелеген колачлаган Энциклопедия сүзлеген әзерләп җиткерә. Бүлек җирлегендә М.Х.Хәсәнов җитәкчелегендә 1992 елда Татар энциклопедиясе институты оештырылу нәтиҗәсендә Татар энциклопедиясенең аңа хәтле гамәлдә булган фәнни концепциясе тамырдан үзгәртелә һәм аның Генераль лөгатьлеге гаять баетыла, Татар энциклопедия сүзлеген рус һәм татар телләрендә әзерләү буенча планлы эш башлана. Татарстан Республикасы президенты М.Ш. Шәймиевнең «Татар энциклопедиясе турындагы программа» Указы һәм «Татар энциклопедиясенең баш мөхәррире турында нигезләмә» (1997 ел) [О программе...] басылгач Татар энциклопедиясен рус һәм татар телләрендә әзерләү башлангыч ала.

Татар энциклопедиясен эшләүнең беренче көннәреннән үк Институтның фәнни хезмәткәрләре алдына зур һәм җаваплы бурыч — универсаль, фундаменталь фәнни-белешмәлек басма әзерләү бурычы куелды, аны коллектив уңышлы рәвештә башкарып чыкты. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты көче белән дөнья күргән рус һәм татар телләрендәге Татар энциклопедия сүзлеге [Татарский..., 1999; Татар..., 2002], күптомлы Татар энциклопедиясе [Татарская..., Татар...] һ.б. фәнни белешмә продукция [Населенные...] бүген Россиянең киң татар җәмәгатьчелеге көтеп алган иң кирәкле китаплар рәтен били. Фәнни белемнәрнең татар халкы һәм Татарстан белән бәйле төрле тармаклары һәм көндәлек практика буенча кирәкле мәгълүматны тиз арада табып алу мөмкинлеге тудыруы сәбәпле милли энциклопедия Татарстан Республикасында һәм татарлар күпләп тупланып яшәгән төбәкләрдә хаклы рәвештә популярлык казанды.

Татар энциклопедиясенең, киң мәйданлы иҗтимагый-мәгариф мәдәниятенә үтеп кереп, төрки-татар цивилизациясенең меңьеллык тарихы һәм мәдәнияте турында комплекслы мәгълүмат бирүче, Татарстан Республикасы һәм аның халыклары турында бәян итүче фундаменталь, системалы хезмәт рәвешендә танылуы өчен күп еллар узуы кирәк булды. Ул, Татарстанның иҗтимагый, мәдәни һәм икътисади тормышында тулысынча катнашу сәләтенә ия булу өчен, Республиканың һәр гражданы үзләштерергә тиешле мәгълүматлар хәзинәсенә әверелде. Рус һәм татар телләрендәге Татар энциклопедиясе татар халкы һәм Татарстан тормышында барган катлаулы процессларның объектив ман-

зарасын күзаллау, Республиканың күпмилләтле җәмгыятендәге иҗтимагый-сәяси тетрәнүләрнең һәм социомәдәни үзгәрешләрнең асылына төшенү мөмкинлеге бирә. Татарстанның һәм гаять зур мәдәни цивилизацион киңлекләргә сибелгән татар этносының иҗтимагый үсешендәге хәлиткеч чорда барлыкка килүе сәбәпле, Энциклопедия җирле халыкларның этномәдәни һәм сәяси үзаңына тәэсир итүнең нәтиҗәле төре дә булып тора.

Татар энциклопедик басмаларының универсальлеге, фәннилек һәм мәртәбәлелек дәрәҗәсе турыдан-туры кеше факторы белән бәйле. ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләре Татар энциклопедиясен эшләүне төрки-татар цивилизациясенең күпгасырлык тарихын һәм мәдәниятен яңабаштан караудан башладылар. Гадәттә энциклопедик басмалар, үзләрен социомәдәни фактлар туплауның һәм проблемалы фәнни эзләнүләрнең ахыры буларак бәяләп, фән, мәдәният һәм җәмгыять үсешен өйрәнүнең билгеле бер этабының үзенчәлекле системалы нәтиҗәсен билгелиләр. Бу исә татар энциклопедистикасына кагылмый. Энциклопедик басмалар өчен мәкаләләр әзерләгәндә Институт хезмәткәрләре күп кенә проблемалар, шул исәптән төбәк историографиясенең «заман таләбенә» әзер булмавы белән очраштылар. Мәгълүм булганча, Татарстанда 1990 еллар башына кадәр күп кенә тармаклар буенча идеологик һәм фәнни кысаларда тиешенчә сыналган гомумиләштерүче хезмәтләр җитенкерәмәде. Татар халкы («Татары Поволжья и Приуралья») һәм Татарстан («История Татарской АССР с древнейших времен») тарихы [Татары..., 1960; История..., 1968] буенча соңгы гомумиләштерүче хезмәтләрнең 1950—1960 елларда дөнья күрүләрен искә алу да җитә.

Төрки-татар цивилизациясе тарихын, мәдәниятен һәм икътисадын өйрәнүгә заманча, камилрәк фәнни һәм методологик алымнар эзләү Институт хезмәткәрләре өчен, фәнни әйләнешкә кергән материалларны системага салу, алар буенча яңача фикер йөртү мөмкинлекләре тудырып кына калмыйча, элек мәгълүм булмаган яки онытылуга дучар ителгән фактларны, исемнәрне, Татарстанның һәм татар диаспорасының иҗтимагый, сәяси, мәдәни һәм икътисади тормышындагы вакыйгаларны һәм күренешләрне ачыклау максатында архивлар һәм китапханәләр фондларын комплекслы өйрәнүгә этәргеч бирде. Күптомлы Татар энциклопедиясенә кертелгән мәкаләләрнең зур өлеше төбәкнең иҗтимагый-сәяси тормышындагы аз өйрәнелгән мәсьәләләргә багышланган. Бу очракта гаять зур фактик материалны фәнни әйләнешкә керткән Татар энциклопедиясе һичбер арттырусыз, белемнәрнең төрле тармаклары буенча яңа массачыл һәм системалы мәгълүмат чыганагы буларак бәяләнергә хаклы.

Татар энциклопедиясе күпмилләтле Россия җәмгыятенең «үзәгенә» юнәлтелгән; аның максаты — басылган тарихи материалны, өлешчә архив документларын, шулай ук фән һәм мәдәният казанышларын барлап-туплап һәм системага салып, Татарстан һәм татар халкы белән бәйле шәхесләр, вакыйгалар һәм күренешләр турындагы мәгълүматны халыкка җиткерү. Татар энциклопедиясе мәкаләләренең яртысы диярлек сәяси, хәрби, иҗтимагый, фәнни, педагогик һәм иҗади эшчәнлекләре яки тормышларының аерым чорлары билгеле бер дәрәҗәдә Татарстан яки татар халкы белән бәйле дәүләт, җәмәгать, фән, хәрби өлкә эшлеклеләренә, дини фикер ияләренә, язучыларга һәм шагыйрьләргә, публицистларга, абруйлы руханиларга, төрле иҗтимагый фикер агымнары

һәм социаль тормыш идеологларына, сәяси партияләр һәм берләшмәләр лидерларына багышлана. Совет энциклопедияләреннән аермалы буларак, Татар энциклопедиясенең фәнни кыйммәте тарихка кереп калырга лаек шәхесләрнең, шул исәптән төрле иҗтимагый, фәнни, иҗади һәм икътисади эшчәнлек белән мәшгуль булган иң гади хезмәт кешеләренең дә биографияләре бирелүдән гыйбарәт. Совет заманында «кеше факторы» роле, бигрәк тә периферияда, түбәнсетелгән иде, гомумроссия, кайбер очракларда гомумсоюз күләмендә, аеруча идарәче даирәләр тарафыннан рәсми танылган затлар гына игътибарга лаек дип табылды. Татар энциклопедистикасы ярдәмендә татар җәмгыятенең революциягә кадәрге сәяси һәм интеллектуаль эшлеклеләре (Хәсәнгата Габәши, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдин, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Садри һәм Һади Максудилар, Йосыф Акчура, Әбүсогуд, Ибнеәмин һәм Ибраһим Әхтәмовлар, Сәетгәрәй һәм Ильяс Алкиннар, Закир Кадыйри, Зыя Камали, Габделбари Баттал, Муса Бигиев, Закир Аюханов, Әхмәт Тимер, Нигъмәт Курат, Вәли Мәңгәр һ.б.) турындагы мәгълүматлар киң җәмәгатьчелеккә барып иреште. Мәсьәләнең шул рәвешчә куелуы татар энциклопедистларына милләтнең бай интеллектуаль тарихи-мәдәни мирасын формалаштыручы мөһим хәзинәне кайтару, татар дөньясын киңәйтү мөмкинлеге бирде. Хәзерге татар энциклопедистикасының нигезен тәшкил иткән әлеге концептуаль юнәлеш, төрки-татар цивилизациясенең һәм Татарстанның тарихы һәм мәдәнияте буенча энциклопедик белемнәрнең төрле якларын бәйләүче буын гына булып калмыйча, Татарстан Республикасында һәм гомумән Россиядә мәдәни-мәгариф процессының фәнни-агарту һәм дидактик факторына дә әверелде.

Иҗат коллективының югары фәнни һәм профессиональ әзерлек дәрәҗәсеннән башка татар энциклопедик басмалары уңыш та, популярлык та казана алмас иде. Институт директоры академик М.Х.Хәсәнов һәм аның урынбасары Г.С. Сабирҗанов җитәкчелегендә үз алдында торган бурычларны һәм проблемаларны һич икеләнүсез хәл итәргә сәләтле коллектив оешты. Алар нигезләгән традицияләр яңа директор Р.М. Вәлиев тарафыннан дәвам иттерелә. Фәнни хезмәткәрләр В.Г.Авзалова, Л.М. һәм Р.А.Айнетдиновлар, Ф.Ә.Әхмәтшина, Ю.А. Благов, С.Г. Белов, Н.Д. Бобырев, Ф.Г. Борһанов, И.Р. Вәлиуллин, М.Җ. Гаитов, Е.Б. Долгов, Ф.С. Зыятдинов, Е.В. Липаков, Р.Р. Мусабәкова, А.И. Ногманов, Г.Г. Осокина, М.Г. Усманов, М.З. Хәбибуллин, Р.В. Шәйдуллин, методистлар А.В. Гарзавина, Р.И. Гурьянова, И.Г. Кадошникова, мөхәррирләр И.И. Барабанова, С.А. Ярмөхәммәтова, корректор Л.Т. Нигъмәтҗанова, энциклопедияләр текстларын татар теленә тәрҗемә итү бүлеге хезмәткәрләре Р.Н. Даутов, Ф.Ә. Шәрифуллин, Л.Х. Хәмидуллин, А.Г. Яруллина, С.С. Шәмси, И.Х. Хәлиуллин, Р.С. Вафина, В.А. Габдрахманова, Ф.Р. Бәдретдинова, Р.И. Раскулова, Ф.Г. Камалетдинова, Г.И. Каюмова, И.Г. Нигъмәтҗанов, Л.К.Галиева үз эшләренең чын осталары буларак танылдылар. Институт эшчәнлеген энциклопедик басмаларның иллюстрацияләрен басмага әзерләүчеләр Ф.Ә. Ибраһимова, Г.Р. Дәүләтьянова, Р.И. Шакиров, битләргә салучылар Р.Р. Сәлахиев, Г.Х. Галимуллина, библиографик мәгълүматларны тикшерүчеләр Р.Ф. Шәрәпова, Г.Р. Садриева, тармакларның фәнни-редакцион коллегияләре хезмәтеннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Институт коллективында яшьлек һәм тәҗрибәнең ныклы берлеге гәүдәләнә, бу исә үзенең югары нәтиҗәләрен бирә.

Бүгенге Россия җәмгыятендә милли-төбәк энциклопедияләр проблемалары тирәсендә барган бәхәсләр шартларында мәгариф, мәдәният, фән һәм гамәли тормышның көн кадагына суккан мәсьәләләрне хәл итүдә әлеге басмаларның мөһимлеге ачыграк күренә. Бу исә универсаль милли-төбәк энциклопедияләрен булдыру программаларын максатчан финанслауда да чагыла. Шул ук вакытта күп кенә төбәкләрнең җитәкчеләре белемнәрнең һәм фагыйлиятнең төрле өлкәләре буенча тармак энциклопедияләрен эшләү зарурлыгын яхшы аңласалар да, кризиска һәм бюджет кыенлыкларына сылтамалы рәвештә финанслау чыганаклары табылмый. Мәсәлән, Башкортстанда, Мари Эл, Мордовия, Удмуртия, Чувашиядә [Башкирская...], милли-төбәк энциклопедияләрен чыгару эшләре тәмамлангач, энциклопедия программалары ябылды, башка фәнни-белешмә басмаларны максатчыл финанслау туктатылды. Нәтиҗәдә, эшләнеп, басмага әзерләнгән тармак энциклопедияләре төрле ведомстволар һәм фондлар хисабына кечкенә тираж белән нәшер ителде. Югарыда искә алынган милли энциклопедия коллективлары арасында «Башкортстан энциклопедиясе» фәнни-нәшрият комплексы коллективының финанс хәлен, чагыштырмача, уңай бәяләргә мөмкин. Коллектив «Мостай Кәрим» персональ энциклопедиясен нәшер итүгә (2019 елга кадәр) дәүләт заказы, кайбер ведомстволарның фәнни-нәшрият заказлары белән тәэмин ителгән. Башкортстан Республикасының беренче президенты Мортаза Рәхимов фонды аңа шактый күләмдә финанс ярдәме күрсәтә: мәсәлән, 2013 елда фонд хисабына башкортларның хәрби тарихы буенча тармак энциклопедиясе басылып чыкты [Военная...].

Күтәрелгән мәсьәлә буенча соңгы елларда без тагын да күңелсезрәк гамәлләрнең шаһитлары булдык. Россиянең Европа өлешендәге кайбер республикаларның хакимиятләре тарафыннан рациональ булмаган адым ясалып, милли-төбәк энциклопедияләре өстендә уңышлы гына эшләп килгән коллективлар таркалды (мәсәлән: Мари Эл, Мордва, Удмурт, Чуваш Республикаларында). Татарстанда да, күптомлы Татар энциклопедиясен рус һәм татар телләрендә эшләү программасы тәмамланганчы ук, ТР Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләренең бер өлеше кыскартылды (109 хезмәткәрнең 72 се калды). Бу сәясәттә милли хәрәкәт дулкынында хакимияткә килгән төбәк җитәкчеләренең узгынчылык позициясе чагыла. Төбәкләрдә үз урыннарын ныгытканнан соң, алар фән, мәгариф, мәдәният, милли идея үсеше һәм төбәкне өйрәнү өчен аеруча мөһим милли-төбәк программалары «тәгәрмәченә» акрынлап «таяк тыга» башлыйлар. Милли-төбәк энциклопедияләрен эшләүче фәнни коллективлар, никадәр генә тырышсалар да, беренче талпынышта ук белемнәрнең барлык тармаклары һәм халык тормышы турында материалларны туплап бетерерлек, аларны тиешенчә гомумиләштерерлек, системага салырлык һәм энциклопедияләр сәхифәләрендә урнаштырырлык хәлдә түгел иделәр. Кыска вакытлы бер максатчыл программа кысаларында гына моны гамәлгә ашыруның мөмкин булмавы шик уятмый. Татарстан энциклопедистлары өчен бу эшне башкару тагын да кыенрак иде. Бер дәүләт программасы кысаларында алар алдына гаять киң колачлы бурыч куелды: Россия Федерациясенең барлык төбәкләрендә диярлек, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдә сибелеп яшәгән, исәбе алты миллионнан арткан татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, фәнни, сәяси һәм хуҗалык эшчәнлеге турында материаллар җыю-туплау, аларны гомумиләштерү һәм системага салу. Башка милли республикалар энциклопедияләреннән аерма-

лы буларак, Татарстанда параллель рәвештә рус һәм татар телләрендә энциклопедияләр нәшер ителә.

Татар җәмәгатьчелегендә дистәләгән еллар буе этнонигилизм хөкем сөрүен һәм татар теленең өй эчендә генә аралашу теленә әверелә баруын исәпкә алганда, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләре куйган хезмәтнең катлаулылыгы, колачы һәм әһәмияте ачыграк күзаллана. Шуңа да карамастан, Институт коллективы әлеге бурычны фидакарьләрчә башкара килә. Әмма, күптомлы Татар энциклопедиясенең фәнни, мәдәни танып белүне киңәйтүдәге роле, иллюстрация-бизәлеш ягы югары бәяләнсә дә, аны әлегә хәзерге чор татар энциклопедистикасының беренче уңышлы үрнәге дип кенә карарга кирәк. Кызганыч, бу энциклопедия барлык татар дөньясын, барча татар диаспорасын иңләп бетерә алмады, шул сәбәпле татар халкының дистәләгәнйөзләгән күренекле вәкиле турындагы мәгълүмат аннан читтә калды. Мисал өчен, Татар энциклопедиясенең 6 нчы томына «өстәмәләр» бүлегенә генә дә 1—5 томнарга кертелми калган 600 дән артык шәхес турында кыскача биографик мәгълүмат урнаштырылды. Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләренең күз уңына эләкми калганнарының исәбе билгесез.

Югарыдагы фикерләр күптомлы Татар энциклопедиясе чыгарылып тәмам ителгәннән соң, аның ныклы нигезендә тармак фәнни белешмә хезмәтләр өстендә эшләүне дәвам итү һәм аларны дөньяга чыгару буенча яңа максатчан хөкүмәт программасы кабул ителү зарурлыгын дәлилли. Ахыр чиктә бу, тармак энциклопедик басмалары мәгълүматларын файдаланып, милли-төбәк энциклопедияләрен кабат нәшер итү мөмкинлеге тудырачак. Татарстанда тармак энциклопедиясе бастырып чыгару тәҗрибәсе бар инде: Казанда узган XXVII Бөтендөнья җәйге студентлар уеннары — «Универсиада-2013» (6—17 июль) ачылышына күптомлы Татар энциклопедиясе базасында «Татарстан» иллюстрацияле энциклопедиясе эшләнеп дөнья күрде [Татарстан...]. Идел һәм Урал буеның башка милли республикаларында да моңа охшаш фәнни белешмә басмалар чыгарыла тора. Алар, кагыйдә буларак, хөкүмәт грантлары, төрле ведомство һәм фондлар хисабыннан бастырыла. Удмуртия сәнгатенә багышланган милли фәнни белешмәлек аерым игътибарга лаек [Удмуртская...]. 2014 елда, Татар энциклопедиясенең рус телендәге 6 нчы томы басылып чыкканнан соң, Татарстан Республикасының беренче президенты М.Шәймиев Указы нигезендә 1997 елда кабул ителгән «Татар энциклопедиясе» программасы тәмамлану этабына керә. Татар энциклопедиясенең татар телендәге соңгы 5 нче һәм 6 нчы томнары дөнья күрү белән әлеге программа буенча эш тәмамланачак.

Тармак энциклопедияләре турында сүз алып барганда алты миллионлы татар халкы өчен әһәмияте ягыннан тиңсез «Татар теле» энциклопедиясен аерып әйтергә кирәк. Мисал өчен, XXI йөз башында «Украин теле» энциклопедиясе 4 тапкыр кабатлап бастырыла (2000, 2004, 2007, 2011) [nado…]. XVIII йөздән башлап күпсанлы татар грамматикалары, дәреслекләр, аңлатмалы, орфографик һәм башка төрле сүзлекләр, хрестоматияләр чыгарыла килүгә карамастан, бүгенге көнгә татар халкының андый энциклопедиягә ирешкәне юк әле. Билгеле булганча, тел ул — халыкның җаны, меңьеллык мәдәниятенең тибеп торган йөрәге, ә тел турындагы фән — шул мәдәниятнең бер өлеше. Бер тасвирламада аерым, мөстәкыйль яшәүче тел турындагы мәгълүматларны фәннең хәзерге халәте белән кушу бурычын милли тел белеменә кагылышлы гыйлемнәрне гомумиләштерү һәм системага салуның фәкать энциклопедик

формасы аша гына хәл итәргә мөмкин. «Татар теле» энциклопедиясендә татар теле турындагы бүгенге фән бөтен тулылыгында тәкъдим ителәчәк: үсеш тарихы, язма ядкәрләр, аваз составы, грамматика, җөмлә типлары, диалектлар, әдәби тел, алфавит, хәреф үзлекләре, сүзлекләр, хрестоматияләр, дәреслекләр һ.б. Ул татар теле һәм татар тел белеме үсешенә җитди өлеш керткән галимнәр һәм язучыларга багышланган мәкаләләргә, шулай ук татар телен өйрәнү һәм пропагандалау белән шөгыльләнүче учреждениеләр, оешмалар, басма органнар турындагы материалларны барларга киң урын бирә. Әлеге басманың принципиаль яңалыгы шунда: татар тел белемен үсештә карау объект (тел) барлыкка килүнең һәм аның үсешенең тарихи этапларын барларга мөмкинлек тудыра, шул ук вакытта телнең үзгә, аны башка телләрдән аерып торучы сыйфатларын ачыклый һәм аның хәзерге халәтен тасвирлый. Димәк, бу энциклопедия билгеле бер күләмдә татар теле һәм телне яшәтүчеләр дөньясын да ача. Шулай итеп, «Татар теле» энциклопедиясен эшләү татар энциклопедиясе даирәсе вәкилләре өчен генә түгел, тел белеме фәне вәкилләре өчен дә беренче чираттагы бурыч булып тора, чөнки татар тел белеме өлкәсенә караган һәртөрле фәнни белемнәрне гомумиләштерү һәм системага салу юлы белән киләчәк буыннар өчен тулы канлы мәдәни-лингвистик тирәлек тудырырга һәм шуның аша халыкка татар теленең барлык байлыгын һәм лингвистик үзенчәлекләрен ачып салырга мөмкин булачак. Бу уңайдан Татарстан хөкүмәтенең инде ике дистә еллардан бирле Татарстан халыкларының телләрен үстерү программасы өчен шактый күләмдә акча бүлеп бирүен әйтергә кирәк. «2014—2020 елларга Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасы нигезендә әлеге максатлар өчен 1084,20 млн. сумнан артык акча бирелгән [Постановление..., с. 3]. Тик, шунысы кызганыч, әлеге Программаны төзүчеләр игътибарыннан көн кадагындагы мәсьәлә төшеп калган: программада «Татар теле» энциклопедиясен эшләү һәм бастырып чыгару өчен акча каралмаган. Укучы яшьләрне фән һәм практика тарихына тартуда, бәхәссез, төрле юнәлештәге фәнни белемнәр һәм практика буенча төзелгән тармак энциклопедияләре зур роль уйнаячак. Шул максаттан, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты җитәкчелеге 2006 елда ук тармак энциклопедияләре эшләп бастыру зарурлыгы мәсьәләсен күтәреп чынты. Тәкъдим ул чактагы премьер-министр Р.Н.Миңнеханов җитәкчелегендәге хөкүмәт тарафыннан яклау тапты һәм 2007 елның 29 декабрендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесенең перспектив эш планнарына түбәндәге тармак энциклопедияләрен кертү турында хөкүмәт күрсәтмәсе басылып чыкты: «Татарстан: тарихи энциклопедия» (ике томда), «Татарстан Республикасының торак пунктлары»; «Татарстан Республикасы: мәдәният һәм сәнгать», «Татарстан Республикасы: мәгариф һәм фән», «Татарстан Республикасы: сәнәгать, төзелеш, транспорт, авыл хуҗалыгы: кыскача энциклопедия» (ике томда), «Татарстан Республикасы: медицина һәм сәламәтлек саклау», «Татарстан Республикасы: физик культура һәм спорт», «Татар балалар энциклопедиясе: татарча һәм русча фәнни белешмә — уку ярдәмлеге» (өч томда) [Распоряжение...]. Энциклопедия чыгару эшендә бу, әлбәттә, төрле тармаклар буенча фундаменталь фәнни белешмәләр өчен материаллар җыю, аларны гомумиләштерү һәм систе-

малаштыру, шулай ук күптомлы Татар энциклопедиясенең яңа басмасын нәшер итү өчен фәнни-иллюстратив база әзерләргә мөмкинлек бирәчәк мөһим адым буларак кабул ителде. Кызганычка, әлеге башлангычның киләчәге анык билгеле түгел. Шулай булуга карамастан, Татар энциклопедиясе институтында «Казан» иллюстрацияле энциклопедиясе, «Татарстан Республикасының химия мәктәбе», «Татарстан республикасы: мәдәният һәм сәнгать», «Татарстан Республикасының торак пунктлары», «Казакъстан татарлары» һәм башка фәнни-белешмә басмалар әзерләү буенча тулы куәткә эш бара. Алдагы елларда аларның байтагы дөнья күрәчәк.

Хәзерге чор энциклопедик басмалар әзерләүчеләрнең өметләре милли-төбәк энциклопедистикасы өлкәсенә яңа мөнәсәбәтләр кертелү белән бәйләнгән. Безнең көннәрдә әлеге мөнәсәбәтләрнең, югары җитәкчелекнең сәяси мәнфәгатьләренә генә түгел, халык тарихи-мәдәни мирасының этномәдәни әһәмиятенә дә нигезләнгән булуы таләп ителә. Татар энциклопедиясе яшь буынны уйланырга, эзләнергә, иҗат итәргә фәнни-тикшеренү өлкәсендә башлангычлар белән чыгарга этәрүче көч — белемгә омтылу, кызыксыну көче. Нәкъ менә шундый максат белән 1991 елда М.Х.Хәсәнов җитәкчелегендә Фәннәр академиясе оештырылды һәм аның катнашында җирле гуманитар фәнни-тикшеренү институтлары һәм үзәкләре булдырылды. Бер үк вакытта Республика җитәкчелеге тарафыннан төрле тармакка караган фәнни белемнәр һәм хуҗалык практикасы тарихын өйрәнүне һәм шул нигездә монографияләр һәм фәнни белешмәлекләр рәвешендәге капиталь хезмәтләр барлыкка килүне тәэмин иткән законнар кабул ителде. Бу процессның тукталганы юк — авырлык белән, акрынлап булса да, ул тайпылышсыз югарыга, алга бара. Соңгы ике дистә ел эчендә белем һәм практиканың төрле тармакларында алып барылган эзләнүләргә караган йөзләгән саллы хезмәт дөнья күрде. Кызганыч, башлангычлар, еш кына, чиновникларның консерватизмы һәм бюрократлыгы кысасына килеп бәрелә, яңалык чаткылары, хаким даирәләр тарафыннан игътибар һәм ярдәм булмау сәбәпле, сүнә. Татар энциклопедиясе институты җитәкчелегенең тармак фәнни белешмәлекләре әзерләп чыгару өчен финанс ярдәме күрсәтү турындагы үтенечләренә хөкүмәт түрәләре юллаган күпсанлы битараф-тискәре җаваплар моңа иң ачык мисал. Шундый җавапларның берсендә: «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 25.11.2013, 142 нче номерлы мөрәҗәгатькә җавап хатында «ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014—2016 елларга чыгымнар системасында «Татарстанның авыл хуҗалыгы» энциклопедиясен бастырып чыгаруны финанслау каралмаган» диелгән (28.02.2014, министр урынбасары М.А.Җаббаров кул куйган 03/1—1233 номерлы хат). Ә шулай да, һичнинди каршылыкларга карамастан, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты галимнәре милли-төбәк һәм тармак энциклопедистикасына таба юл салуларын дәвам итәләр. Алар Институтның һәм үз фәнни эзләнүләренең яшәү куәте нык булуын, халыкка кирәклеген, гамәли файдасын эшләре белән исбатлыйлар.

Энциклопедия нәшер итү ул басма дөнья күрү белән тәмамлана торган акт түгел. Бу дәвамлы эш, процесс 2014 елда Татар энциклопедиясенең рус телендәге 6 нчы томы чыкканнан соң, күптомлы Татар энциклопедиясе программасы нигездә үтәлгән булып саналачак. 10—15 ел вакыт үтүгә, төрки-татар цивилизациясе һәм Татарстанның бүгенгесе һәм үткәне турында мәгълүмат бирүче

белешмәлек булган Татар энциклопедиясе тарихи-мәдәни мирас ядкәренә әвереләчәк, анда китерелгән статистик һәм биографик мәгълүматларның, фәнни фактологиянең беркадәр өлеше искерәчәк. Әлбәттә, моңа карап Татар энциклопедиясенең кадере китмәячәк һәм кулланыштан төшеп калмаячак, ләкин ул инде татарлар һәм Татарстанның шул чорына кагылышлы күп сорауларга җавап бирә алмаячак. Аны кабаттан бастыру мәсьәләсе күтәреләчәк, һәм менә шул чакта барысын өр-яңадан башларга туры киләчәк. Шуларны күз алдында тоткан хәлдә, мәгълүмат һәм иллюстрация базасын гына түгел, бигрәк тә Татарстанда һәм тулаем Россиядә бара торган процессларны исәпкә алып, Институт хезмәткәрләрен саклап калуны кайгырту да зарур, чөнки киләчәктә фәнни әзерлекле энциклопедистлар табу кыенга киләчәк. ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты хәзерге вакытта җитлеккән, тулы куәтенә эшләүче, төрле энциклопедияләр әзерләү белән мәшгуль даими структуралары булган фәнни организм тәшкил итә. Бүгенге көндә югары дәүләт һәм академик җитәкчелекне ераккарак карау, алдагы көнне уйлау, иң мөһиме — булганны саклау зарурлыгы турында искәртәсе килә. Татар энциклопедиясе институты портфеле тулы. Күптомлы Татар энциклопедиясенең һәм русча, һәм татарча электрон версияләре булдырылса, Татарстанның тарихы, фәне, мәгарифе, мәдәнияте, икътисады һәм табигатенә багышланган тармак энциклопедияләре һәм шулай ук татарлар тупланып яши торган төбәкләр турында энциклопедик белешмәлекләр, гомумән, туган якны өйрәнүгә яки танып белүгә караган башка темаларга уку ярдәмлекләре эшләнсә, безнең Республика моннан оттырыр идеме? Милли-төбәк тарихының, өстәмә уку-укыту компоненты буларак, мәктәп программасына кертелүен исәпкә алсак, югары фәнни-профессиональ дәрәҗәдә нәшер ителгән иллюстрацияле энциклопедияләр бик кирәк һәм урынлы булыр иде. Бүген Татарстан Республикасы һәм татар халкына кагылышлы барлык төр мәгълүматларны җыю, гомумиләштерү һәм системалаштыруга юнәлдерелгән комплекслы яңа дәүләт программасы таләп ителә. Бу, үз чиратында, фәнни белемнәрнең төрле тармакларында, шулай ук фәнни-гамәли даирәдә, мәдәният, мәгариф өлкәләрендә, хуҗалык итүдә яңа ыргылыш ясарга мөмкинлек бирәчәк.

**Әдәбият**

nado.znate.ru›Украинский язык (энциклопедия).

Башкирская энциклопедия. Уфа, 2005. Т.1:А—Б. 623 с.; 2006. Т.2:В—Ж. 623 с.; 2007. Т.3:З—К. 671 с.; 2008. Т.4:Л—О. 607 с.; 2009. Т. 5:П— Совет. 575 с.; 2010. Т.6:Советы народного хозяйства — У. 543 с.; 2011. Т.7:Ф—Я. 624 с.; Мордовия: энциклопедия. —Саранск, 2003. Т.1: А—М. 570 с.; 2004. Т.2:М—Я. 699 с.; Удмуртская Республика: энциклопедия. Ижевск, 2000. 799 с.; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2006. Т.1:А—Е. 587 с.; 2008. Т.2:Ж—Л. 491 с.; 2009. Т.3:М—Се. 683 с.; 2011. Т.4:Си—Я. 795 с.; Энциклопедия Республики Марий Эл. Йошкар-Ола, 2009. 872 с. и др.

Военная история башкир: энциклопедия. Уфа, 2013. 432 с.

Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник / Под ред. М.Х. Хасанова. Казань: Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ, 1997. 389 с.; Коноплев А.Ю., Салахиева М.Ю., Салахиев Р.Р. Я вечно помнить призываю: каталог

госпитальных воинских захоронений периода Великой Отечественной войны на территории Республики Татарстан. Казань, «Отечество», 2009. 320 с.; Центральные органы государственной власти и управления Татарстана (1920—2010 гг.): научно-справочное издание / Под ред Р.Ф. Муратова и др. Казань: Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ, Изд-во МОиН РТ, 2010. 312 с.; Татарстан: иллюстрированная энциклопедия. / Под ред. А.М. Мазгарова. — Казань: Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ, 2013. 816 с.; Айнутдинов Р.А., Гилазев З.З. За 200 лет: Пресса Татарстана и татарская периодика XIX—XXI вв. Библиографический сборник. — Казань: «Отечество», 2013. 368 с.; Айнутдинов Р.А., Айнутдинова Л.М., Гилазев З.З. Казанская научная пресса. Казань: «Отечество», 2013. 228 с.; Имена из солдатских медальонов. Т.6 / Сост.: Коноплев А.Ю., Салахиев Р.Р., Салахиева М.Ю. — Казань: «Отечество», 2013. 312 с. и др.

О программе «Татарская энциклопедия» и Положение о главном редакторе Татарской энциклопедии Указ президента РТ:

Постановление Кабинета Министров Республики Татарстан «Об утверждении государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014—2020 годы» от 25.10.2013 г. 25 с.; http://tatarstan.ru/rus/info.phpid=577559.

Проблемы создания региональных энциклопедий: материалы Международного научно-практического семинара (Санкт-Петербург, 14—16 октября. 2003 г.). СПб., 2004. 487 с.

Раздорский А.И. Отечественная региональная энциклопедистика на современном этапе // Исторический опыт, актуальные проблемы российской региональной энциклопедистики: материалы Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием (Уфа, 27—28 сентября 2012 г.). Уфа, 2012. 178 с.

Распоряжение Кабинета Министров Республики Татарстан №2329-р от 29.12.2007.

Татарская энциклопедия / Под ред. М.Х. Хасанова. Казань: Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ, 2002. Т.1:А—В. — 671 с.; 2005. Т.2:Г—Й. — 655 с.; 2006. Т.3:К—Л. 665 с.; 2008. — Т.4: М—П. 766 с.; 2010. Т.5:Р—Т. 734 с.; / Под ред. А.М. Мазгарова 2014. — Т.6:У—Я. 720 с.; Татар энциклопедиясе / Баш мөхәррир М.Х. Хәсәнов. Казан, ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-ты, 2008. Т.1:А—В. 719 б.; 2010. Т2:Г—Й. 655 б.; / Баш мөхәрир Ђ.М. Маскаров. 2012. Т.3:К—Л. 715 б.; 2014. Т.4:М—П . 632 б.

Татарский энциклопедический словарь / Под ред. М.Х. Хасанова. Казань: Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ, 1999. 703 с.; Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәрир М.Х. Хәсәнов. Казан, ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-ты, 2002. 830 б.

Татарстан: иллюстрированная энциклопедия. Казань, 2013. 816 с.

Татары Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1960. 537 с.; История Татарской АССР. Казань: Таткнигоиздат, 1968. 719 с.

Удмуртская Республика: культура и искусство: энциклопедия. Ижевск, 2012. 539 с.

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы****, тарих фәннәре докторы,*
*ТР ФА Татар энциклопедия институтының директор урынбасары;*

***Вәлиев Рәмил Миргасыйм улы****, тарих фәннәре докторы,*
*ТР ФА Татар энциклопедия институтының директоры*

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ РУХИ МИРАСЫ

Һәр халыкның рухи культурасының асылын аның фәлсәфи, этик һәм эстетик идеяләре, иҗтимагый карашлары тәшкил итә. Татар халкы тамырлары ерак гасырларга барып тоташа торган бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия, аның тирән эчтәлекле иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихы бар.

Әмма егерменче-утызынчы еллардан башлап милли республикаларда татар телен, әдәбиятен, тарихын, халык иҗатын өйрәнү юнәлешенә игътибар артса да, татар халкының бай иҗтимагый фикер тарихына махсус багышланган фәнни тикшеренүләр алып барылмый. Рухи мәдәният максатчан рәвештә өйрәнелмәгәч, халкыбызның бай мирасы игътибардан бераз читтәрәк калып килгән. Татар иҗтимагый фикеренең күпгасырлык тарихын, аның тарихи-фәлсәфи, социаль-сәяси, хокукый, әхлакый-этик аспектларын эзлекле рәвештә комплекслы тикшерү, белемнең бу өлкәдәге тикшеренүләрен координацияләү зарурлыгы гомуми үзәк булдыруга этәргеч ясый. Татарның фәлсәфи мирасын төрле яссылыкта максатчан өйрәнүне, бу өлкәгә галимнәрне җәлеп итү һәм туплауны күздә тотып, 1975 елда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты эчендә иҗтимагый фикер секторы оештырыла. Шунысын да ассызыклау кирәк — мондый сектор автономияле республикалар арасында бердәнбер була. Аны төзүнең инициаторы һәм беренче җитәкчесе фәлсәфә фәннәре докторы Яхья Абдуллин иде.

Атаклы галим, тәҗрибәле оештыручы Яхья Абдуллин җитәкләгән сектор каршында аспирантура ачыла, белгечләр туплана, 1986 елдан ул лаборатория итеп үзгәртелә, 1988 елдан иҗтимагый фикер тарихы бүлеге буларакэшчәнлеген дәвам итә, ә 1993 елдан «Иҗтимагый фикер тарихы һәм ислам белеме бүлеге» итеп үстерелә. Чөнки халкыбызның рухи мәдәниятенең иң зур өлеше ислам дине кыйммәтләре белән дә тыгыз бәйләнгән.

* * *

Бүлек формалашкан чорда фәнни-тикшеренү эшләренең үзәгендә XIX гасыр — XX гасыр башындагы рухи мирасны, аның фәлсәфи, идеологик, мәдәни эчтәлеген үзләштерү бурычы торган. Бигрәк тә мәгърифәтчелек, җәдитчелек проблемаларына, татар басма китабы тарихына, XIX гасырдагы татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре иҗатына, шулай ук XX гасырда татар иҗтимагый фикеренең революцион-демократик агымына игътибар зур булган. 80—90 нчы еллар чигендә — иҗтимагый тормышны демократияләштерү һәм милли мәдәниятне торгызу шартларында — бүлектә җәмәгать белеменең чыганак базасы һәм тематикасы күзгә күренеп киңәя. Ислам белеме проблематикасының мөстәкыйль фәнни юнәлешләрен билгеләүдә 1989 елда Идел Болгарстанында исламны рәсми кабул итүнең 1100 еллыган багышлап уздырылган фәнни конференция мөһим роль уйный. Туксанынчы елларда бүлекнең халыкара) фәнни элемтәләре көчәеп китә... Хәер, бүлекнең эшчәнлеге хакында аның җитәкчеләреннән дә төгәлрәк итеп кем сөйли алсын?!

Бүлек белән 1985 елга кадәр — Я.Г.Абдуллин, 1985 — 1993 елларда — Ф.М.Солтанов, 1993 — 1996 елга кадәр, ягъни, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты оешканчы Р.М.Әмирханов җитәкчелек итә.

Әйдәгез, бүлек тарихына аның җи-

тәкчеләре тарафыннан язылган мәкаләләре аша күз салыйк.

**Яхъя Абдуллин:**

«Сектор алдына Татариянең иҗтимагый фикере тарихында марксизм-ленинизм тәгълиматына таянган фәлсәфи һәм иҗтимагый-сәяси идеяләрнең торышын, татар мәгърифәтчелеге һәм революцион-демократик идеологиянең үзенчәлеген, рухи тормышыбызда ислам1 дине тоткан урынны һәм аның ролен, татар басма китабы тарихын өйрәнү бурычы куелды. Совет Татариясендә фәлсәфи һәм иҗтимагый-сәяси фикер үсеше өйрәнелеп, иҗтимагый фикер тарихын буржуаз фальсификацияләүчеләренең чын йөзен ача торган хезмәтләр дә язылырга тиеш иде».

«Галимнәребез тарафыннан иҗтимагый фикер тарихында атеизм идеяләренең үсеш проблемалары өйрәнелде».

«Сектор хезмәткәрләре катнашында «Ислам буенча сүзлек-белешмәлек» әзерләнде. Биредә Татариядә исламның таралуы һәм роле турында мәкаләләр тупланган, кайбер киң таралган дини терминнарга ачыклык кертелгән, революциягә кадәрге дин эшлеклеләренең социаль, сәяси, идеологик карашлары һ.б. бәян ителгән».

«Секторның фәнни эшчәнлегендә бер юнәлеш — татар китабы тарихы. Институтта бу юнәлештәге эзләнүләр сектор оешканчы ук башланган иде. 1971 елда Әбрар Кәримуллинның татар басма китабының барлыкка килүе һәм үсеш проблемаларын анализланган «У истоков татарской книги» исемле монографиясе басылды. Фәнни хезмәттә татар язуы һәм кульъязма китабы тарихы да каралган. Сектор ачылгач галим бу юнәлештәге эзләнүләрен дәвам итте».

«Соңгы елларда җәмәгатьчелеккә татар мәгърифәтчелегенең радикаль вәкиле, онытылуга дучар ителгән философ Шәмсетдин Күлтәси иҗади мирасын кайтара алдык. Г.Курсави һәм Х.Фәезханов кебек күренекле мәгърифәтчеләрнең иҗади мирасын өйрәнү буенча да уңышларыбыз бар.

Каюм Насыйри иҗатының басма әсәрләре опактый өйрәнелгән булып саналса да, фондларда аның кулъязма мирасы галимнәребезне көтә. Ш.Мәрҗанинең бай мирасын да өйрәнә генә башладык. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәтенең башында торган Г.Курсавиның иҗади мирасын да фәлсәфи анализлыйсыбыз бар. Соңгы елларда Г.Тукай, М.Гафури, Г.Коләхмәтов, Г.Ибраһимовларның иҗаты һәм дөньяга карашы эволюциясенең фәлсәфи-методологик нигезләрен яктырткан хезмәтләр барлыкка килде. Кыска гына вакыт эчендә иҗтимагый фикер тарихы бүлеге коллективы тарафыннан татар халкының рухи-мәдәни мирасының фәлсәфи һәм иҗтимагый аспектларын өйрәнү буенча шактый эш башкарылды».

«Әлегә халкыбызның борынгырак чорга караган рухи мирасын барлау юнәлешендәге эшләребез белән артык горурлана алмыйбыз. Татариядә суфыйчылык һәм аның үзенчәлекләрен дә! өстән-өстән генә күзаллыйбыз. Ә бит суфыйчылык татар иҗтимагый фикер тарихында тирән тамырлар җибәргән күренеш иде. Әлбәттә, бу юнәлештә эш бара. Г.М.Дәүләтшин «Духовная культура домонгольской культуры» темасы буенча эшли, Алтын Урда чоры Болгарстанында социаль-фәлсәфи фикер һәм рухи мәдәният буенча эзләнүләр бара. Бу юнәлештә эш дәвам итергә һәм киңәйтелергә тиеш...» («50 лет поисков и открытий», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1989)

*Белешмә*

*Философ, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, ТР ФАның шәрәфле әгъзасы, ТАССРның, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны Яхъя Габдулла улы Абдуллин тумышы белән Теләче*

*районының Олы Кибәхуҗа авылыннан. Казан юридик институтын һәм КПСС Үзәк комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен тәмамлый. 1945—1959 елларда партия эшендә, 1959 елдан — фәнни-педагогик хезмәттә. 1965 елдан фәнни эш белән шөгыльләнә башлый. 1979 елда ул докторлык диссертациясе яклый, 1980 елдан институт директоры урынбасары, 1982—1986 елларда институт директоры. 1986 елдан — өлкән фәнни хезмәткәр, 1997 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр. Шиһабетдин Мәрҗани, Габдерәхим Утыз-Имәни, Шәмсетдин Көлтәси, Хөсәен Фәезхановларның моңарчы «җиде кат йозак эчендә» булган, гарәп графикасында язылган әсәрләре галим өчен зур хәзинәгә тиң була. Татарларда иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсеше тарихына кагылган фәнни хезмәтләрендә татар мәгърифәтчелеге, җәдидчелек, танылган татар мәдәният эшлеклеләренең дөньяга карашы чагыла.*

**Фәрит Солтанов:**

«Бүлекнең фәнни-тикшеренү юнәлешләре күпкырлы иде. Татар мәгърифәтчелеге фикере, татар халык мифологиясендә һәм борынгы язма мираста фәлсәфи карашлар, татар китабы тарихы, татарның эстетик карашлары системасы, ислам һәм татар иҗтимагый фикере бәйләнешләре, Шиһабетдин Мәрҗани, Шәмсетдин Күлтәси, Садри һәм Һади Максудилар, Галимҗан Ибраһимов, Риза Фәхретдин эшчәнлекләре, пантюркизм һәм панисламизм, төркичелек мәсьәләләре, татар милли хәрәкәтенең социаль-философик асылы, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында иҗтимагый фикернең чагылышы, совет елларында милли үзаңның хәле кебек мәсьәләләргә фәлсәфи һәм тарихи күзлектән чыгып бәя бирелде, онытыла барган рухи мирас халыкның хәтеренә төшерелде, күп фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр язылды һәм бастырылды. Иҗтимагый фикер тарихы бүлеге республикабызга шактый фәнни кадрлар әзерләнде. Биредә эшләү дәверендә һәм аннан соң Я.Абдуллин, Ф.Солтанов, А.Юзиев фәлсәфә фәннәре докторлары, Р.Мөхәммәтшин сәясәт фәннәре докторы, Ә.Кәримуллин, Ә.Мәхмүтов филология фәннәре докторлары, Р.Әмирханов, М.Зарипов, А.Хәйретдинов, Л.Алмазова фәлсәфә фәннәре кандидатлары, М.Юсупов, Ф.Гаффарова, Р.Мөхәмәтдинов, Н.Гарипов, Л.Мөхәмәдиева тарих фәннәре кандидатлары дәрәҗәсенә ирештеләр. Бу бүлектә озак еллар танылган галим Әнвәр Хәйри эшләде. Иҗтимагый фикер тарихы бүлеге Г.ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты эчендә булган чорда ткл, әдәбият, археология, этнография, сәнгать, фольклор бүлекләре белән тыгыз элемтәдә торды, аларның хезмәтләренә таянды, фәнни һәм дустанә мохитне тоеп яшәде». (Галимнең истәлекләре Институт юбилеена махсус язылды).

*Белешмә: Солтанов Фәрит Мирза улы (1951) Философия фәннәре докторы, ТРнын атказанган фән эшлеклесе. 1977—93 елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1993—96 елларда РФ Мәгариф министрлыгы карамагындагы Милли мәгариф проблемалары институтының Татарстан филиалы мөдире, 1997 елдан Тарих институты директоры урынбасары. Хезмәтләре татар иҗтимагый фикер үсеше һәм татарларда милли хәрәкәт тарихына карый.*

**Рашат Әмирханов:**

«Бүлекнең фәнни эшчәнлегендә әһәмиятле юнәлеш булып иҗтимагый фикер һәм ислам белеме чыгана-

кларын бастырырга әзерләү тора. 1989 елда Ш.Мәрҗанинең «Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казань ва Булгар» әсәре кыскартылып заманча татар теленә күчерелеп бастырылды. Бүлекнең гарәп теле белгечләре, Петербургның шәрыкъ белгечләре белән берлектә, Мәрҗанинең алтытомлык «Вафийат ал-аслаф ва тахийат ал-ахлаф» дип аталган библиографик кульязмасын кыскартып рус телендә басарга әзерләделәр. Әсәрдә Идел буе мөселманнарының рухи мәдәнияте тарихы буенча гаҗәеп бай материал тупланган. Мөселман кульязмалары буенча каталог төзүебез дә шушы юнәлештәге эшебезнеңдәвамы.

Туксанынчы елларда бүлекнең халыкара фәнни багланышлары киңәйде, мәгълүмат алмашу, стажировкалар, уртак проектлар булдыру, Казанда иҗтимагый фикер тарихы һәм ислам дине фәне буенча халыкара фәнни форумнар оештыру һәм галимнәребезнең халыкара конференцияләрдә катнашу мөмкинлеге артты. Бүлекнең алдагы эш планында — татар халкының интеллектуаль тарихының моңарчы өйрәнелмәгән проблемаларын, шәхесләрен һәм чорларын тирәнтен өйрәнү, татар фәлсәфи фикере һәм төбәктә ислам тарихы буенча коллектив монографияләр әзерләү, Татарстанда бүгенге чорда иҗтимагый фикер үсешен һәм аның сәяси, социологик, идеологик аспектларын өйрәнү, татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча комплекслы хезмәтләрне әзерләүгә катнашу». («Духовное наследие народа», Институтның 60 еллыгына багышлап чыгарылган җыентыктан, 1999.)

*Белешмә: Рашат Мәхмүт улы Әмирханов (1939—2000), философ, 1974 елдан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми хезмәткәр, 1993 тән — бүлек мөдире, 1997 елдан — Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтында эшли.*

* * *

Халкыбызның рухи мәдәниятен өйрәнүдә якты эз калдырган Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Габдрахман Сәгъди кебек татар зыялыларының изге гамәлләрен танылган галимнәр Камил Фәсиев, Рәфыйк Нәфыйковһәм башкалар дәвам итсә, максатчан рәвештә ул бары тик Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты диварлары эчендә өйрәнелә башлады. Инде әйтеп үтелгәнчә, бүлек галимнәре моңарчы телебездә булып та, фәнни яктан өйрәнелмәгән шәхесләрне — Курсави, Мәрҗани, Күлтәсиләрнефәнни әйләнешкә кертеп җибәрүдә гаять зур роль уйнадылар. Татар иҗтимагый фикер тарихы юнәлеш буларак ике дистә ел дәвамында нәкъ менә биредә формалашты һәм системага салынды. Шунысы да игътибарга лаек: галимнәребез совет методикасы кысаларында килеш тә халкыбызның рухи мирасы, иҗтимагый фикер тарихы буенча җитди фәнни хезмәтләр әзерли алды, 1989 елда Казанда Татар иҗтимагый үзәгенең I корылтае уздыруда да алар актив катнашты. Сүз уңаеннан, Татарстанның бүгенге уңышларында бу корылтайның өлеше аз түгел. Чөнки нәкъ шушы корылтай татар милләтенең киләчәгенә зур өметләр уятуга этәргеч бирде.

Иҗтимагый фикер тарихы бүлеге, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән бергә, институтыбыздан аерылып чыкса да, татар халкының мәнфагатен кайгырту буенча уртак эш башкарган галимнәр, әлбәттә, хәзер дә актив хезмәттәшлек итәләр, уртак фәнни проектлар да һәрчак булып торачак.

*Материалны* ***Рузилә Мөхәммәтова***
*әзерләде*

УДК 812.512.145:372

***Ф.Ф. Хәсәнова***

# ТӘҺСИ ГАЛИМНӘРЕ ДӘРЕСЛЕК ЯЗА, ЯКИ ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫ ПРОГРАММАЛАШТЫРУ

В статье автор предлагает обзор истории создания учебников в ИЯЛИ, одновременно затрагивая проблемы преподавания предметов, изменения содержания обучения в области национального образования.

**Ключевые слова:** учебник по татарской литературе для средней школы, отдел литературоведения ИЯЛИ, татарское литературоведение, история татарской литературы.

Татар әдәбият белеме тарихы XIX гасырдан, Г.Утыз Имәни, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Р.Фәхретдинов хезмәтләреннән башланып китә һәм аның аерым юнәлешләре аеруча XX гасыр башында җанлану ала. Сәнгати сүзнең бөек осталары булган Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, галимнәрдән Г.Сәгъди, Җ.Вәлиди, Г.Рәхимнәр беренче әдәби тәнкыйтьчеләрдән санала. Әдәбиятчыларның хезмәте Татар фәнни-тикшеренү институтының эшчәнлегеннән аерып каралмый.

1939 елның 8 октябрендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институтында әдәбият бүлеге оештырыла. Аның беренче мөдире Казан педагогия училищесыннан эшкә чакырылган Я.Агишев, беренче әдәбиятчылар — В.Хаҗиев, А.Камский була. 1942 елда яшь галимнәрдән Б.Яфаров һәм Х.Хәйри эшли башлый. Х.Хәйри әдәбият бүлеге мөдире дә булып ала, аның эшен алга таба Г.Халит дәвам итә. Башлангыч чорда хезмәткәрләр арасында фәнни дәрәҗәсе булмаган галимнәр дә очрый. Шуңа карамастан, хезмәткәрләр монографияләр, дәреслекләр, коллек-тив җыентыклар эшләүгә алына. 1946 елдан соң бүлектә М.Гайнуллин, Х.Хисмәтуллин, Г.Кашшаф, М.Гали кебек галимнәр хезмәт итә. Аларга, татар әдәбияты тарихын тикшерү мәсьәләләре белән беррәттән, урта мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр төзү эше дә йөкләнә. Шул ук вакытта бу галимнәр классикларның томнарын әзерләп чыгару кебек олы бурычтан да читләшми.

Әдәбият белеме бүлегендә 50 нче еллардан алып 60 нчы еллар урталарына кадәр Урта гасырлар белән бәйле дәверне өйрәнү тенденциясе көчәя. Галимнәр коллектив җыентыклар эшләүгә басым ясый. Иң беренче чиратта алар югары уку йортлары өчен Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты буенча дәреслек эшләүгә керешә. Бу вакытта Казан университеты һәм Казан педагогия институты студентларына Борынгы әдәбияттан дәреслек-хрестоматияләр тәкъдим ителә. Бу эшнең башында М.Гайнуллин тора. Ул җитәкләгән төркемгә Х.Мөхәммәтев, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов, С.Исәнбаев, У.Беляев керә. 1947 елда М.Гайнуллин һәм Җ.Вәзиева авторлыгында югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләре өчен «Татар әдәбияты: XIX йөз — 1917 елга кадәр» исемле дәреслек-кулланма чыга. Дәреслекләр темасы алга таба да күз уңыннан төшми, әмма, башлыча, югары уку йорты дәреслекләренә басым ясала. 1963 елда Ф. Ганиев Казан университеты студентлары өчен «Ур-

та мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы»н тәкъдим итә [Ганиев].

Тел, әдәбият һәм тарих институтының 50 еллыгына багышлап чыгарылган китапта әдәбият белеме бүлегенең төп максаты ачык билгеләнгән. Бу максат — XX гасыр татар әдәбияты тарихын рус телендә 3 томда эшләп чыгу, югары уку йортлары өчен дәреслекләр язу. Әмма гомуми урта белем бирү мәктәбе өчен дәреслекләр әзерләү турында башкача телгә алынмый, гәрчә Л.Җәләй һәм С.Байков тарафыннан 1937—38 елларда ук 8 нче сыйныф өчен әдәбият буенча язылган дәреслек-хрестоматия булса да.

ТӘһСИдә эшләнгән иң беренче дәреслек булып, Г.Сәгъди һәм Л.Җәләй тарафыннан язылган «Систематик диктантлар җыентыгы» санала. Бу әсбап, башлангыч мәктәп укытучылары өчен кулланма форматында булып, 96 бит күләмендә төзелгән, 1939 елда чыккан. Әлеге методик кулланма, төзәтелеп, өстәлеп, баетылып, 1941, 1947 елларда яңадан чыгарыла. Исемлектә икенче мәктәп дәреслеге булып, Л.Җәләй һәм С.Байков тарафыннан 8 нче сыйныф өчен төзелгән әдәбияттан дәреслек-хрестоматия күрсәтелә. Ул 1940 елда 399 бит күләмендә булып чыга, яңадан 1953 елда бастырыла. Әмма инде авторлары үзгә: М.Гайнуллин һәм Х.Ярми. 1969 елда 8 нче сыйныф дәреслеге кабаттан М.Гайнуллин һәм М.Мәһдиев тарафыннан әзерләнә.

8 нче сыйныф дәреслегенә игътибарның күп булуын төп белем бирү баскычының тәмамлануы белән аңлатырга кирәктер. ТӘһСИ галимнәре гомумбелем бирүнең югары баскычына да игътибарын киметми: 9—10 нчы сыйныф дәреслекләрен төзүне дәвам итә. 1946 елда 9 нчы сыйныф өчен булган дәреслекне Х.Хәйри төзесә, 10 нчы сыйныфка татар совет әдәбиятыннан хрестоматияне Х.Хисмәтуллин һәм Б.Гыйззәт эшли. Ә «Совет әдәбияты» исемендәге 10 нчы сыйныф дәреслеген 1954 һәм 1969 елларда Г.Халит белән Г.Кашшаф чыгара. Бу дәреслекләр 7—9 ар тапкыр кабаттан басыла, эчтәлегенә үзгәрешләр дә кертелә, авторлар өстәлә, күләме зурая.

50—60 нчы елларда чыккан әдәбият дәреслекләренең эчтәлеге, бизәлеше хәзерге заман дәреслекләреннән бик нык аерыла. Беренчедән, дәреслек үзенә аерым, ә хрестоматия бары тик әдәби әсәрләрдән генә төзелгән. (Соңгы елларда, дәреслекнең авырлыгы 300 г нан артмау шарты белән, берләштерелгән дәреслек-хрестоматияләр чыга.) Мисал өчен М.Гайнуллин һәм Х.Ярми тарафыннан төзелгән 8 нче сыйныфның әдәбият дәреслегенә мөрәҗәгать итик [Әдәбият, 1954]. Әдәби материал төгәл академик стиль белән бирелгән. Хәзерге дәреслекләрдә, укучыларның туган телен белү һәм үзләштерү эшчәнлеге кимегәнлектән, хәтта әдәби текстлар адаптацияләп тәкъдим ителә. Билгеле, чор таләпләреннән чыгып, идеологик караш дәреслекнең һәр җөмләсендә чагылыш таба, В.Ленин һәм И.Сталинның әдәбият турындагы «аеруча әһәмиятле фикерләре» һәрдаим калкытып куела. Әмма, татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучы булып, барыбер, Г.Тукай исеме атала. Эчтәлегенә килгәндә, дәреслек әдәбият турында В.Ленин һәм И.Сталин «фикерләрен» тәфтишләп аңлаткан кереш белән башланып, татар халык авыз иҗатына, XIX йөзнең 60 нчы елларына кадәр булган татар әдәбиятына (ул В.Белинский һәм А.Герцен хезмәтләрен файдаланып, характеристика бирүгә кайтып кала), XIX йөзнең икенче яртысындагы татар әдәбияты (Н.Чернышевский, Н.Добролюбов, Н.Некрасов, М.Салтыков-Щедрин хезмәтләре хәтта эчтәлеккә үк чыгарыла), татар драматургиясенең беренче үрнәкләренә, Заһир Бигиев белән За-

кир Һади иҗатларын ачуга нигезләнә. Шунысы игътибарга лаек, дәреслектә бердәм академик стиль бер тапкыр да бозылмаган, шулай ук бер генә орфографик һәм пунктуацион хата да җибәрелмәгән, бит саен диярлек, астөшермәләр биреп барылган, һәрберсендә йә Ленин, йә Сталин хезмәтенә сылтама күрсәтелгән.

Х.Хәйри дәреслекләр төзү буенча зур эш башкара. Ул югары сыйныфлар өчен дәреслек һәм хрестоматияләр яза. Искәртеп үтик, ул М.Гайнуллиннан аермалы буларак, берүзе эшли. Мисалга аның 9 нчы сыйныф өчен төзелгән, 1959 елда чыккан хрестоматиясен алыйк. 348 бит күләмендәге китапта 6 автор карала. Биредә, XX йөз башы әдәбиятыннан башлап, 1930 елларга кадәр чор күз алдында тотыла. Язучылардан Г.Коләхмәтовның «Яшь гомер», Г.Тукайның 13 хезмәте (арада поэма, шигырь, публицистика да бар), Г.Камалның «Бәхетсез егет», М.Гафуриның 10 әсәре, Ф.Әмирханның «Яшьләр»е, М.Фәйзинең «Галиябану»ы кертелә. Һәр алты язучының тормыш юлына һәм иҗатына күзәтү ясала.

М.Гайнуллин әдәбият дәреслекләре төзү буенча аеруча күп эшли. Югары сыйныф дәреслекләренең һәрберсендә ул автор булып бара, бары икенче автор исеме генә үзгәрә. 1969 елда чыккан әдәбият дәреслеге [Татар..., 1969] «бөек юлбашчылар» исемен телгә алмыйча гына, «паразит руханилар»ны фаш итүгә юнәлдерелә. 8 нче сыйныф өчен дәреслек тә, 9 нчы сыйныфныкы да бер үк XIX йөз әдәбиятын өйрәнүне күз алдында тота. Әмма икенче китапта XX йөз башы әдәбияты да өстәлә. Китерелгән мисаллар совет чоры әдәбият дәреслекләрен төзүдә бердәм система сакланмавын күрсәтә.

Әлеге уңайдан шуны искәртеп үтү дөрес булыр, XXI гасырда төзелгән яңа дәреслекләр концентризм принцибына нигезләнү сәбәпле, аерым сыйныф дәреслегендәге материал әдәбиятның һәр чорына хас үрнәкләр белән үрелеп бара, ягъни һәр сыйныфта билге бер чор әдәбияты гына түгел, тулы бер әдәбият иңләп алына. Бу үзгәреш тулы мәктәп курсының 9 нчы сыйныф белән тәмамлануыннан килеп чыга. Ә югары сыйныфларда күбесенчә әдәбият тарихы, теориясе, иҗат методлары һәм зур күләмле әсәрләр тирәнрәк өйрәнелә.

Китерелгән мисаллардан ТӘһСИ галимнәре, аерым алганда әдәбиятчылары, дәреслекләр төзү эшен әйдәп баручылар булган, дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Бу эштә иң актив эшләүчеләр М.Гайнуллин, Х.Хәйри белән Х.Ярми була (алар 5нче сыйныфтан башлап әдәбият дәреслекләре яза), алардан тыш Х.Гали һәм М.Мәһдиев исемнәре дә кабатлана.

Билгеле, дәреслекләр әзер программага нигезләнеп төзелергә тиеш. ТӘһСИ галимнәре программаны да үзләре яза. Шул рәвешле «Сигезьеллык мәктәп программалары: Татар теле һәм әдәбияты (5—8 кл. өчен / төз. Б.Мифтахов, Б.Хафизова, Ф.Фасиев. Ш.Сайкин; ред.М.Зәкиев, Я.Агишев. 1960)» барлыкка килә.

Күренгәнчә, соңгы еллардан аермалы буларак, татар теле һәм әдәбияты программалары икесе бергә тәкъдим ителә. Дәреслекләр төзүдә бу бердәмлек бигрәк тә 8 нче сыйныфтан башлап ачык чагыла. 1989 елдан татар теле дәреслекләрен төзүдә М.Зәкиев исеме еш күренә башлый. Әдәбият фәне буенча дәреслек һәм хрестоматия тәкъдим ителгән булса, ягъни укучы өчен дәреслек эшләнсә, М.Зәкиев татар теленнән ул вакытта ук (1989) тулы уку-укыту комплектын булдыруга ирешә. Ул, берүзе эшләп, 6—8 нче сыйныфлар өчен дәреслек кенә түгел, укытучы өчен методик кулланма һәм дидактик материаллар да тәкъдим итә. Ә менә әдәбият дәресләренең методик кулланмасын эшләүне 90 нчы елларда Казан университеты галиме А.Яхин гына алып бара. Әдәбият дәресләренең

методикасын язу ТӘһСИ галимнәре өчен «каты чикләвек» була, күрәсең, библиографик исемлектә мәктәптә укытылган әдәбият буенча методик әсбап күрсәтелми.

Библиографик исемлектән күренгәнчә, 1939 — 2009 елларда ТӘһСИда 81 дәреслек эшләнгән. Шуларның 35е югары уку йортлары өчен дәреслек һәм программа, 46 сы мәктәп дәреслеге. 46ның 6сы башлангыч мәктәп өчен рус теле дәреслеге булса, 3се — тарих дәреслеге, 9ы — әдәбият, 28е — тел буенча дәреслек. Библиографик күрсәткеч буенча барганда, 70 елга 9 әдәбият дәреслеге язылган булып чыга. Әдәбият дәреслекләрен язу эше 90 нчы елларга таба кими бара. Бары тик Ф.Мусинның 11 нче сыйныф өчен булган әдәбият дәреслеген генә күрсәтергә була, шулай ук авторлар коллективында И.Нуруллин, Н.Юзиев булган дәреслекләр чыкканлыгы күренә. Әлеге галимнәр бу дөньядан киткәч, әдәбият буенча дәреслекләр эшләүдә ТӘһСИ галимнәренең катнашы бетә.

90 нчы елларда дәреслекләр төзүдә шактый гына үзгәрешләр барлыкка килә. Бу махсус «Мәгариф» нәшрияты ачылу белән дә аңлатыла. Моңа кадәр дәреслекләр татар мәктәбе, татар сыйныфы өчен генә язылса, 90 нчы елларда «рус мәктәбе», «рус мәктәбендә татар теле» төшенчәләре килеп керә. Шулай ук рус мәктәбендәге татар баласы өчен, әдәбият дәреслекләре төзү эше кызу темплар белән үсеп китә. Әмма бу эштән ТӘһСИ галимнәре читтә кала.

XXI гасырда Россия мәгариф системасында зур сикерешләр була. Перспективалы яңа проектлар тәкъдим ителә башлый. Федераль үзәктән регионнарга мәҗбүри үтәлергә тиешле карарлар килә. Шул ук вакытта уку планнарында инглиз теле, информатика, физкультура дәресләре саны арттырыла. Уку планнарына вариативлык кертелә. Мәктәпләргә уку планының төрле вариантларын сайлап алу хокукы бирелә. Бу елларда милли мәгарифнең вәкаләтләре кими бара. Болар барысы да татар теле һәм әдәбияты дәресләренең кимүенә китерә. Шулай да татар теле фәне артык зур югалтуга дучар булмый кала, чөнки Татарстанда рус һәм татар телләрен тигез күләмдә өйрәнүне тәэмин итә торган карар кабул ителә. Шуларга нисбәтле татар теле дәреслекләре күпләп языла башлый. Нигездә алар өч төрле юнәлештә бара. Татар мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыту, рус мәктәпләренең татар балаларына татар теле укыту һәм рус балаларын татар теленә өйрәтү юнәлешләре тормышка ашырыла. Бу эштән М.Зәкиев тә читтә калмый. Аның татар теле дәреслекләре даими рәвештә чыгып бара.

Нәкъ менә шушы чорда әдәбиятка игътибар кими. Бердәм дәүләт имтиханы кертелү нәтиҗәсендә, чыгарылыш сыйныфларда сочинение язу бетә. Сочинение язасы булмагач, әдәбиятны тирәнтен, фәнни яктан анализлап өйрәнү, аның эстетик әһәмиятенә төшенүнең кирәге калмый булса кирәк. Әдәбият, хезмәт, рәсем, җыр дәресләре кебек, атнасына бер сәгать укытыла башлый. Икенче төрле әйткәндә, әдәбиятның яшь буынны тәрбияләүгә, фикерләргә өйрәтүгә, кешедәге чын матурлыкны күрә белергә күнектерүгә хезмәт итә торган функциясе танылмый башлый. Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү, башлыча, тест формасына күчә бара. Төгәл фәннәр өчен бу уңай күренеш булса да, ул бәйләнешле сөйләм үстерүгә хезмәт итми инде. Инновацияле алымнар белән эшли торган мәктәпләр барлыкка килә. Аларда татар әдәбияты дәресе атнага бер тапкыр үткәрелә башлый, һәм бу бүленеш бүген дә шулай дәвам итә бирә.

Дөрес, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, ат-

нага бер сәгать укытып, чын татар җанлы кеше тәрбияләп булмаганын яхшы аңлый. Рәсми рәвештә әдәбият дәресләре атнага 2 сәгать булып язылып бара. Программалар шулай төзелә, дәреслекләр дә шуңа көйләнеп чыга. Укытучы 70 сәгатьлек материалдан 35 ен сайлап ала башлый. Моның өчен эш программасы сорала. Мәктәпләрдә башка предметлардан укытучыларга әзер эш программалары тәкъдим ителә. Бигрәк тә рус телле предметлар өчен эш программалары бик җентекләп төзелгән, аларны үзгәреш кертмичә дә кулланып була.

Менә шулар барысы дәреслекләр төзүдә үзгәрешләр китереп чыгара. Моннан тыш дәреслекләр аерым сыйныфлар өчен генә түгел, ә белем бирүне баскычлап (буынлап) иңләп алырга тиеш була. Аерым дәреслек кенә түгел, уку-укыту комплектын әзерләү бурычы да куела. Ә комплектка үрнәк программага нигезләнгән авторлык программасы, 2 кисәктән торган дәреслек, хрестоматия, укучы өчен эш дәфтәре, укытучы өчен дәреслек, ата-аналар өчен (алар өчен генә дә булмаган) электрон дәреслек, белем тикшерү өчен тестлар да сорала. Шулай итеп, бер уку-укыту комплекты 6—7 төрле әсбапны үз эченә алырга тиеш булып чыга. Болар белән генә дә чикләнмичә, 11 еллык мәктәпне тәмамлаган бала мәҗбүри рәвештә белергә тиешле 100 исемнән гыйбарәт булган әдәбият исемлеге, һәр сыйныф өчен 13—15 исемнән торган мәҗбүри уку минимумы булдырыла. Минимумга мәҗбүри укылырга тиешле әсәрләрнең исемлеге теркәлә, кайсы язучының тормыш юлы һәм иҗаты тирәнтен өйрәнелергә тиеш — барысы да күрсәтелә. Бер үк вакытта һәр предмет буенча Федераль дәүләт белем бирү стандартлары төзелә. Уку-укыту комплекты шуларның барысын да үз эченә алырга тиеш була. Ә әдәбият дәреслекләренең беркайчан да бу таләпләрнең барысын да исәпкә алып төзелгән үрнәге булмады (А.Яхинныкы да тулы түгел, аерым әсәрләрне анализлау методикасы формасында гына).

2011 елда ФГОС таләпләрен исәпкә алып эшләнгән шундый әсбап «Мәгариф-Вакыт» нәшриятында басыла. Әсбапны чыгару өчен, мәктәп укытучылары ел буе Мәскәүдә (РФА) профессор Р.Г.Чуракова җитәкчелегедә курслар үтә. Бу дәреслек, рус телендәге «Литературное чтение» китабына охшатып, «Әдәби уку» исемендә була, үз эченә дәреслек, хрестоматия, эш дәфтәре, һәр дәреснең план-конспектын һәм эш планын күрсәткән методик кулланма, электрон кушымтаны ала. Бу комплектта әдәбият дәреслекләрен төзү тарихында беренче тапкыр эш дәфтәре тәкъдим ителә. Әлеге комплектны тормышка ашыручы 4 кешелек төркемне мин үзем җитәклим. Шунысы үзенчәлекле, бу елларга кадәр дәреслекләрне, башлыча, галимнәр генә чыгара иде. Укытучылар — берән-сәрән генә, анда да югары сыйныф дәреслекләре төзүгә генә җәлеп ителде (киресенчә кирәк иде). Мәктәп укытучыларыннан дәреслек төзүдә Н.Гыймадиева, М.Гайфуллина һәм Х.Фәрдиевалар катнашып ала.

Ә 2011 елда татар мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен чыгарылган уку-укыту комплекты бер галим һәм 3 укытучы тарафыннан әзерләнә. Әлеге кулланма Республика укытучылары тарафыннан җылы кабул ителә. Шул рәвешле 2014 елга татар башлангыч мәктәбе өчен барысы 19 дәреслек һәм уку-укыту әсбабыннан торган, тагын 4 сыйныф өчен электрон кушымтасы эшләнгән дәреслекләр системасы әзерләнеп бетә. Болар белән бер үк вакытта альтернатив дәреслекләр дә яшәп килә. Әдәбият дәресләре саны кыскарган саен, дәреслекләр саны арта баруы күренә.

Дәресләкләргә таләпләр арттырыла бара. Мәскәүдә берничә төрле экспертиза үтеп, Федераль исемлеккә кергән дәреслекләр белән генә укытырга рөхсәт ителә башлый. Татар башлангыч мәктәбе өчен булган «Әдәби уку» әсбаплары системасы бу исемлеккә дә кертелә (исемлеккә Татарстаннан 51 комплект керә). Моны Татарстан Республикасы Мәгариф фән һәм министрлыгының 2013—2014 еллардагы зур уңышы дияргә кирәк.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы яңа дәреслекләр әзерләү эшен министр булып Э.Фәттахов килгәч аеруча көчәйтә. 2014 елда икенче буын өчен (5 нче — 7 нче сыйныфлар) дәреслекләр әзерләү боерыгы куела. Ярты ел тирәсе бу эшкә беркем дә алынмый. Әмма яз көне ихтыярый-мәҗбүри рәвештә әдәбият дәреслекләрен төзү башлана. 1 сентябрьгә 5 нче — 7 нче сыйныфлар өчен укыту комплекты булдырыла. ТӘһСИның әдәбият белеме бүлеге бу эштән читтә калмый. «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты алар катнашында эшләнгән дәреслекләрне яңа уку елына чыгарып та өлгертә. Бүгенге көндә алар мәктәпләрдә кулланышта йөри. Бу дәреслекләр рус мәктәбенең татар төркемнәре өчен булса, әдәбият белеме бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Д.Абдуллина җитәкчелегендәге 3 кешелек төркем татар мәктәпләренең 7 нче сыйныфы өчен әдәбият дәреслеген әзерли.

Дөрес, рус мәктәбендәге татар баласы өчен әзерләнгән дәреслек татар мәктәбе өчен булган дәреслектән күпкә аерыла. Беренчедән, рус мәктәбе өчен төзелгән дәреслек, Федераль исемлеккә кергән сурәттә, Россиянең татарлар яши торган төбәкләрендә дә кулланылыш алачак. Бу дәреслекләрдә шул сәбәпле күләме зур булмаган текстлар саны шактый күп бирелде. Әгәр моңа кадәр кулланышта йөргән дәреслекләрдә әдәби әсәрләр саны 15—20 дән артмаса, яңаларында 30—40 ка җиткерелде. Әсәрләрнең күләме кыскартылды, кыскартылган урыннарга резюме яки аннотация рәвешендә эчтәлек тәкъдим ителде. «Әгәр төркемнәр буенча эшләнгән дәреслекләргә күз салсак, татар мәктәбе төркемнәрендә әдәби материалның беренчеллеге сакланса да, рус мәктәпләре өчен әзерләнгән ике төркем дәреслекләренең дә тулысынча культурологик концепциягә нигезләнгәнен күрербез», — дип язуы белән Д.Заһидуллина хаклы [Заһидуллина, б. 13—18].

Әдәбият укытуны программалаштырып буламы? дигән сорау бер бүген генә тумаган. Америка галимнәре Б.Ф.Скиннер, Н.А.Краудер әлеге мәсьәләгә тискәре карашын белдерә. Ә менә Ж.М. Рейд бу сорауга уңай җавап итеп, үзе үк Р.Фрост шигырьләрен программалаштырып күрсәтә [The English...,1963. №4]. Сорауга уңай яки тискәре җавап бирү кешенең әдәбият һәм аны укытуга нинди караштa булуына бәйләнгән. Әдәбият дәресләрендә ике төрле материал белән эш ителә: әдәби әсәр һәм әдәбият белеме материалы. Әдәби әсәрне укудан туарга тиешле тәэсирләнү һәм дулкынлануны программалаштырырга мөмкин түгел. Язучы моны үзе эшләгән инде, дип кабул итәргә мөмкин. Ә менә әдәби әсәр турында фикер йөртүне программалаштырып була. Бүгенге көндә нәкъ менә шушы эш белән «Татармультфильм» берләшмәсе шөгыльләнә. Татар әдәбияты дәресләренең электрон варианты нәкъ менә шул принципка нигезләнә дә. Бу XXI гасыр дәреслекләренең зур гына үзгәреш кичерүе буларак карала.

ФГОСка нигезләнгән дәреслекләрдә тагын бер күзгә күренеп торган үзенчәлек бар, ул да булса укытучының вазифасы үзгәрү. Укытучы әсәрне анализламый, эчтәлеген аңлатмый, бары тик дөрес юлга этәреш кенә бирә. Яңа

дәреслекләрдә укытучыны консультант вазифасында тәкъдим итү аның эшен киметү буларак каралмый. Яңа шартларда укытучыдан киң эрудиция һәм хәбәрдарлык, өлгерлек сорала. Текстлардан соң 10—15—20 тирәсе бирем тәкъдим ителә. Укытучы аларны берәмберәм дә, сыйныфтагы укучыларның һәрберсенә, белем дәрәҗәсенә карап, үзенчә чамалап бүлеп бирә ала. Шартлы билгегә генә игътибар итәргә кирәк. Унлап сандагы шартлы билге укытучы сүзен алмаштырырга тиеш, дип уйланыла. Әмма җавапларны тыңлаганда, бирелгән тәртипне саклау таләбе куела. Сораулар җиңелдән катлаулыга таба бара. Араларында дөрес җавапка ишарә итү характерында булганнары да бар. Биремнәрнең һәрберсе сорау характерында түгел, араларында иҗади эш, текстны фәнни яктан тикшерү, аннотация, рецензияләр язу, презентация, импровизация, экскурсия, дискуссия дә бар.

«Татар мәдәнияте белән таныштыру, милли тәрбия нигезләрен салу, тулысы белән диярлек, татар әдәбияты предметы компетенциясенә керә. Шуңа күрә үрнәк программалар яссылыгында ук төп максатның беркадәр башкачарак аңлатылышы күзгә ташлана. Әдәби материал киңрәк — мәдәни материал эченә керә, культурологик, тәрбия функцияләре алга чыга», — дип язды Д.Заһидуллина [Заһидуллина]. Бу инде әдәбият дәреслекләре эчтәлегендәге сыйфат үзгәрешләрен күрсәтә. Әмма әлеге «программалаштыру»ның әдәбиятның эстетик ягына тискәре йогынтысы да барлыгын онытмыйк.

2011 елдан башлап, әдәбият белеме бүлеге хезмәткәрләре катнашында 28 исемдәге уку-укыту әсбабы, Д.Абдуллина тарафыннан татар мәктәбенең 7 нче сыйныфы өчен 2 кисәктән торган әдәбият дәреслеге төзелде. Бер үк вакытта безнең галимнәребез дәреслекләрне экспертизалау эшендә дә актив катнаша.

Димәк, ТӘһСИда Х.Ярми, Л.Җәләй, Г.Халит, Х.Хәйри, М.Гайнуллин, М.Зәкиев тарафыннан башлап җибәрелгән мәктәп дәреслекләре төзү традициясе бүген дә яши, хәтта уңышлы гына дәвам итә, дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**

*Ганиев Ф.А.* Программа для студентов КГУ: методика преподавания татарской литературы в средней школе / Ф.А.Ганиев. Казан: Татар.кн.изд-во, 1963. 12 с.

Әдәбият. 8 нче класс өчен дәреслек. Төзәтелгән икенче басма / М.Гайнуллин, Х.Ярми. Казан: Таткнигоиздат (Укыту-педагогик әдәбият редакциясе), 1954. — 218 б.

Татар әдәбияты. 9 нчы класс өчен дәреслек / М.Гайнуллин, Ш.Әхмәтов. Казан: Татар.кит.нәшр., 1969. 234 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Төп гомуми белем бирү баскычында татар әдәбияты: заман таләпләре һәм яңа мөмкинлекләр // Мәгариф, 2014. № 10. Б. 13—18.

The English journal. 1963. №4. An, Adveture in Programing Literature, James M.Reid.

***Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге җитәкчесе*

УДК 929

*Д.М. Абдуллина, Л.Ш. Бәдертдинова*

## МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИН — ГАЛИМ ҺӘМ ОСТАЗ

Статья является кратким обзором научно-педагогической деятельности литературоведа М. Гайнуллина. Долгие годы исследований ученый посвятил изучению татарской литературы XIX и начала XX веков, зарождения и становления журналистики и литературной критики. Более десяти лет М. Гайнуллин руководил Институтом языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, текстология, ученые Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова, М. Гайнуллин.

Бер караганда, җитмеш биш ел — олы тарихы, бай мәдәнияте булган татар халкының телен, рухи мирасын барлау, фәнни өйрәнү юнәлешендә эш алып баручы оешма өчен әллә ни зур сан да түгел. Әмма әлеге гыйлем йортының халкыбызга күрсәткән хезмәтен, фәнни эшчәнлекләрен, аның тарихы белән тыгыз үрелгән олы галимнәребезне барлый башласак, бу елларның нинди бай кыйммәткә ия булуы ачыла.

Институтның тәүге елларыннан ук күп юнәлешләрне бердәй колачлап, уңышлы эшләп китүенең сәбәпләренә берьяклы гына бәя кую дөрес түгел, әлбәттә. Тик монда Институтны җитәкләгән шәхесләрнең роле зур булуы да бәхәссез. Әлеге гыйльми институтның татар халкының үткәнен өйрәнүдә генә түгел, киләчәген хәл итүдә дә төп терәк булачагын аңлап эш иткән хөкүмәтебез бу урынга җитәкчеләрне һәрьяктан сынап, җиз иләктән үткәреп сайлап куя.

Ил-халык тормышының катлаулы чорында дистә елдан артык әлеге институт директоры булган Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин (1903—1985) да әлеге таләпләргә туры килерлек киң эрудицияле зур галим, авырлыклар алдында куркып калмастай көчле ихтыярлы, зирәк, тормышның һәр өлкәсеннән хәбәрдар, үз халкына хезмәт итүне намус эше итеп таныган, эзләнүчән, тырыш һәм зыялы затларның берсе.

Иҗат, фән өчен мөмкинлекләр сайгеккан, фаҗигале Бөек Ватан сугышы елларында йөкләнә аңа бу вазифа. Яшьлеге, кеше язмышында гына түгел, кешелектә гаять катлаулы үзгәрешләр барган чорга туры килгәнлектән, тормыш сынаулары алдында бирешмәскә күнеккән Мөхәммәт ага өчен бу тагын бер җитди адым, тормышында яңа бер баскыч буларак кабул ителгәндер. Әлеге җаваплы вазифага керешкәнче үк инде ул татар әдәбияты фәнендә үз урынын тапкан, танылган галим булып җитешә.

Ул 1903 елның 18 (яңа стиль белән — 31) августында хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы, Кызыл Тау (әүвәлге исеме — Коллар) авылында крәстиян гаиләсендә туган. Әтисе Хәйрулла балаларын кечкенәдән үк укытырга, һөнәрле итәргә тырышкан. Мөхәммәт белем алуны, инкыйлабка кадәрге чорга хас булганча, авылның гап-гади мәктәп-мәдрәсәсеннән башлый. Октябрь инкыйлабыннан соң, Тәтеш шәһәренә барып, укытучылар әзерли торган берьеллык курсларда укып, үзе дә мөгаллим булып китә. Белем бирү,

мәдәни агарту эшләре яңа совет власте йөкләгән төрле вазифалар белән бергә үрелә. Аңа белемен күтәрүне дә хезмәт белән бәйләп алып барырга туры килә. 1924 елның сентябреннән 1925 елның июленә кадәр Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты оештырган «Татар телен гамәлгә кую курслары»нда белем ала. Казанда яшәгән бу вакыт эчендә ул фән дөньясына якыная, язучылар, галимнәр белән аралаша, үзе дә мәкаләләр яза, әдәби темаларга докладлар укый.

Курсларны тәмамлап, Тәтештә авыл кредитпромсоюзында эшләгән елларында да әдәби эзләнүләреннән читләшми, бу кызыксынуы аны 1928 елда Казан педагогия институтының филология факультетына алып килә. Биредә ул төпле белем, фән юлында беренче чыныгу ала. Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, Г. Шәрәф кебек күренекле галимнәрнең лекцияләрен тыңлау, алар белән якыннан аралашу, мәртәбәле галим Г. Нигъмәти җитәкчелегендә аспирантура үтү аңа гыйлем һәм тәҗрибә туплау юлында олы тормыш мәктәбе була. Аспирантурада укыган елларында ук ул үзе укыган институтта татар әдәбияты тарихы һәм әдәбият теориясеннән лекцияләр укый. Бу аңа алган белемнәрен ныгытырга гына түгел, әлеге өлкәдә җитешмәгән якларны күрергә, шул өлкәдә эзләнергә, киләчәккә эш юнәлешләрен билгеләргә дә этәргеч була. Югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләре өчен дәреслекләр төзергә алынуының сәбәбе дә шуның белән бәйле. Дәреслекләр төзү өчен күп эзләнергә, материалны эшкәртеп, бастырып чыгарырга озак вакыт сарыф итәргә кирәк, ә укучыга мәгълүмат вакытында җиткерелергә тиеш. Шуны күздә тотыптыр, утызынчы-кырыгынчы елларда яшь галим үзенең эзләнүләренең нәтиҗәләрен мәкаләләр рәвешендә бастырып килә. Аларда татар әдәбиятының XIX — XX гасырларына караган материаллар, татар-рус әдәби багланышлары мәсьәләләре карала. Мәкаләләрдә Г. Тукай, К. Насыйриларның иҗаты һәм эшчәнлеге төрле яклап һәм тирәнтен өйрәнелә, шулай ук Ш. Мәрҗани, З. Бигиев, Г. Коләхмәтов һ.б. эшчәнлегенә багышланган хезмәтләрендә яңа фикер әйтүгә ирешә. Алда искәрткәнчә, М. Гайнуллин милли әдәбиятларга рус әдәбиятының уңай йогынтысын бәяләү юнәлешендә дә шактый ук эзлекле эш алып бара. Татар әдәбиятына В.Г. Белинский, А.С. Пушкин, А.М. Горький кебек бөек шәхесләрнең һәм, гомумән, рус әдәбиятының тәэсире белән кызыксына. Шул җирлектә 1944 елда «Горький һәм татар әдәбияты» (рус телендә) дип аталган китабы дөнья күрә. «Совет әдәбияты» журналында «Толстой һәм татар әдәбияты» (1945), «Чынлык көче. Татар әдәбиятының реализм сызыгында үсүенә бөек рус язучылары һәм революцион демократик тәнкыйтьчеләрнең йогынтысы» (1948), «Пушкин һәм татар әдәбияты» (1949), «Кызыл Татарстан» газетасында «В.Г. Белинский һәм татар әдәби тәнкыйте» (1948), «Пушкин һәм Тукай» (1949) мәкаләләре басыла. Бу фәнни эзләнүләр татар әдәбияты өчен генә яңалык булып калмый. «Горький һәм татар әдәбияты» китабы басылып чыккач, СССР Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, профессор Н.К. Пиксанов: «Горький һәм Советлар Союзының тугандаш әдәбиятлары» дигән хезмәтемдә аңа бер генә мәртәбә мөрәҗәгать итмәм дип уйлыйм», — дип яза.

Чыннан да, алдагы елларда М. Гайнуллинның әдәби багланышларга караган хезмәтләре «Горький и литература народов Советского Союза» (1969), «Некрасов и литература народов Советского Союза» (1972), «Пушкин и литература народов Советского Союза» (1975), «Лермонтовская энциклопедия» (1976) кебек коллектив хезмәтләрдә урын ала. 1973 елда

«Дуслыкта көч» исемле җыентыгында аның шул юнәлештәге хезмәтләре туплап нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышы елларында М. Гайнуллин Татарстан дәүләт нәшриятының директоры булып эшли, шул ук вакытта ул фән белән шөгыльләнергә дә, педагогия институтында лекцияләр укырга да вакыт таба.

1944 елда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институтына (бу статус институтка 1941 елда бирелә) директор итеп билгеләнгәндә, М. Гайнуллин инде һәрьяктан әзерлекле, тәҗрибәле, танылган шәхес, җитлеккән галим була. Алга таба да ул фән өлкәсендә дә, җитәкче буларак та вазифасын намус белән башкара. 1944—1953 һәм 1959—1961 елларда — институт директоры, 1953—1956 елларда шул ук институтта әдәбият секторын җитәкли.

1946 елда ул «XIX гасыр ахырындагы һәм XX йөз башындагы татар әдәбияты турында тикшеренүләр» дигән темага кандидатлык диссертациясе, ә 1958 елда СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында «Россиядәге беренче революция чорында татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Н.А. Баскаков, И.С. Брагинский, Л. Җәләй, М. Богданова кебек абруйлы галимнәр аның хезмәтен татар әдәбият белеменең җитди казанышы дип билгелиләр.

1946 елда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институты СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына кертелә, әдәбият секторы исә 1961 елга кадәр халык иҗаты секторы белән берләштерелгән була. Шул ук вакытта ул яңа фәнни кадрлар хисабына күпмедер дәрәҗәдә үстерелә дә. Эзләнүләрнең тематикасы һәм проблематикасы киңәйтелә. Әдәбият белгечләренә татар әдәбияты тарихының актуаль проблемаларын тикшерү, милли әдәбият тарихын булдыру, урта мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр әзерләү, татар әдәбияты классикларының томнарын туплау һәм бастыру кебек вазифалар йөкләнә.

1947 елда М. Гайнуллин югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләре өчен инде 1940 елда ук әзерләп нәшриятка тапшырган «XX йөз әдәбияты» дәреслеген Җ.Вәзиева белән кабат яңартып, бастырып чыгара.

Бу чорның үзенчәлекле якларыннан берсе — коллектив хезмәтләр әзерләү. Беренче чиратта биредә югары уку йортлары өчен татар әдәбиятының борынгы һәм урта гасыр чоры буенча дәреслекләр төзү күздә тотыла. М. Гайнуллин җитәкчелегендәге әдәбият секторы үз эченә XIII—XVIII йөз әдәбиятларын туплаган «Борынгы әдәбият тарихы» дәреслек-хрестоматиясен эшләп чыгаруга керешә. Әлеге хезмәт 1963 елда дөнья күрә (төзүчеләре: Х. Мөхәммәтов, Х. Хисмәтуллин, Ш. Абилов, Ү. Беляева, С. Исәнбаев). Китапта аерым тарихи чорлардагы әдәби хәрәкәтләргә, язучыларга һәм аларның әсәрләренә бәйләнешле күзәтү мәкаләләре, халык авыз иҗаты һәм язма әдәбият үрнәкләре бирелгән. «Дәреслектә яңалык шактый, шулай да аның төп кыйммәте әдәбият тарихына карата яңа концепция тудырудан гыйбарәт. Әдәбият белеме белгечләре Идел—Кама буе татарларының этногенезы мәсьәләсендә тарихчыларның соңгы эзләнүләренә таянып эш итәләр. Татар әдәбияты тарихын алар Идел—Кама буе Болгар дәүләтеннән (IX—XIII) башлый» [Юзеев, с. 69]. Хезмәттә беренче тапкыр Кол Гали иҗаты борынгы татар әдәбиятының аерылгысыз өлеше буларак карала. Төп игътибар язма әдәбиятны барлауга юнәлтелгән.

50 нче елларда әдәбият секторы хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән XX йөз башы буенча коллектив монографияне бу чорның бер уңышы дип карарга кирәк [XX йөз башында татар

әдәбияты]. «Бу XX гасыр башы татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен билгеләү, әлеге чорның идея-эстетик байлыгын ачу, чорның танылган язучыларының әдәбият үсешенә керткән өлешен бәяләү юлында беренче талпыныш була» [Юзеев, с. 69]. Шулар белән беррәттән, әлеге хезмәттә чагылган чор идеологиясен дә онытмаска кирәк. Нәтиҗә буларак, XX гасыр башы әдәбияты шактый берьяклы яктыртыла. Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Н. Думави, Дәрдемәнд кебек язучыларның иҗаты бәяләмәләрендә вульгар-социологик күзаллаулар сизелә, аларның әдәби процесстагы роле түбәнсетелә. Иҗат портретлары арасында Ф. Әмирханга да урын табылмый [Юзеев, с. 70]. Шуңа да карамастан, XX йөз башы әдәбиятын киң планда күрсәтү М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева тарафыннан чыгарылган дәреслек-хрестоматиядә күзәтелә. Биредә Дәрдемәнд һәм С. Рәмиев иҗатларына тиешле урын бирелә. Чор тәнкыйтенең басымы астында, икенче басмада төп игътибар Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатларына юнәлтелә.

XX гасырның 60—70 нче елларында әдәбият тарихы һәм теориясенең актуаль проблемаларын яктырткан монографияләр барлыкка килә. Биредә бигрәк тә XIX йөз әдәбиятын өйрәнүгә үз өлешен керткән М. Гайнуллин хезмәтләре аерым урын алып тора [Гайнуллин, 1975, 1979].

XIX йөз татар әдәбиятын өйрәнү барышында М. Гайнуллин күп кенә чыганакларга таянган. Публикацияләрдән тыш, галим Ленинград һәм Мәскәү үзәк архивларында, Казан дәүләт университетының китапханәсендә, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих, Башкорт филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтлары архивларында сакланган татар әдәбиятының бай кулъязма мирасына мөрәҗәгать итә. XIX гасыр әдәбиятын М. Гайнуллин төп дүрт юнәлеш аркылы күз алдына китерә: XIX йөз татар әдәбиятының төп үсеш этаплары; поэзия; проза; драматургия. Аларның һәрберсе аерым бүлекчәләрдән тора. Шунысын да ассызыклап әйтү кирәк: китап, нигездә, әдәбият тарихы мәсьәләләрен яктыртуга багышланса да, аның авторы һәрбер иҗат портретына үзенчә якын килә. Мисал өчен, китапта К. Насыйриның татар тел гыйлеменә керткән өлешенә, аерым мәгърифәтче-язучыларның сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенә, аларның тел байлыгына да игътибар ителә. Ягъни галим үзен чын мәгънәсендә тирәнтен эзләнүче итеп таныта.

М. Гайнуллинның XIX йөз әдәбияты өлкәсендәге казанышлары, табигый рәвештә, XX гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасын өйрәнүгә дә этәргеч биргәндер, чөнки нәкъ менә шушы вакыт аралыгы татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә зур үзгәрешләр чоры булып теркәлгән. «XX гасыр татар әдәбияты һәм публицистикасы» дип исемләнгән хезмәт — галимнең зур уңышы. Монографиядә татар журналистикасының, публицистикасының, әдәби тәнкыйтенең барлыкка килүе һәм формалашуы, беренче рус инкыйлабы һәм аннан соңгы чор татар матур әдәбиятының үсеше тикшерелә. Хезмәттә кулъязма фонд материаллары һәм шулай ук аерым язучыларның автограф язмалары китерелә, заманның иҗтимагый-тарихи вакыйгалары тергезелә.

Галим «Большая советская энциклопедия»нең өченче басмасында (1970—1978 еллар, 30 нчы том) һәм «Краткая литературная энциклопедия» томнарында (1962—1978 еллар, 9 нчы том) татар әдәбияты тарихын яктырту буенча фәнни консультант буларак зур хезмәт куя. Озак еллар дәвамында туплаган материаллары белән энциклопедия томнарында татар әдәбиятын шактый тулы һәм заманындагы әдәбият фәне ирешкән

югарылыкта яктыртуга ирешә. Аның тырышлыгы белән белешмәләрдә әлегә кадәр кертелмәгән күп кенә әдипләребез урын ала.

1971 елдан Институтның әдәбият белгечләре «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгын әзерләү эшенә керешәләр. Томнарның баш редколлегиясе составында М. Гайнуллин исеме дә бар. Шулай ук ул II томның җаваплы редакторы хезмәтен дә үти. Аның авторлыгында томда Каюм Насыйри, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Шакир Мөхәммәдев, Драматургия, Йомгак кебек бүлекчәләр язылган, чорга иҗтимагый-тарихи вакыйгалар һәм культура хәрәкәте аша бәя бирүдә дә ул катнаша. Томга кереш сүздә М. Гайнуллин XIX гасыр әдәбиятының өйрәнелү тарихына туктала. Биредә бу өлкәдә үз хезмәтләре белән чыгыш ясаган Б. Дорн, В. Смирнов, А. Соловьев, Н. Ашмарин, И. Березин, В. Григорьев, Н. Катанов, П.И. Пашино, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, К. Насыйри исемнәре атап үтелә; «татар әдәбияты үсешен тарихи җирлектә алып, халык тормышына һәм демократик җәмәгатьчелек фикеренә бәйләп өйрәнү мәсьәләләре Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Ибраһимовларның мәкаләләре аша күрсәтелә»; Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, Л. Җәләй һәм соңгырак дәвер галимнәренең хезмәтләре аша XIX гасыр әдәбияты төрле яклап күз алдына китерелә [Гайнуллин, 1985, б. 7]. М. Гайнуллин язганча, «авторлар Мәскәү һәм Ленинград үзәк архивларында, Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар бүлегендә, СССР Фәннәр академиясенең Казан һәм Башкорт филиаллары архивында сакланган материаллардан киң файдаландылар» [Гайнуллин, 1985, б. 9].

«Галимнең үз иҗат эшчәнлеге дә тугандаш әдәбият вәкилләре белән тыгыз аралашуның ачык мисалы була ала. 1973 елда ул Ленинград университетында чуваш галиме Владимировның докторлык диссертациясе яклавында оппонент булып катнашты. Финляндиянең Хельсинки университеты алтаистика кафедрасы профессоры Гомәр Таһир белән даими бәйләнештә торды, «Тукай җәмгыятенең чакыруы буенча Финляндиядә булды. Аның шәхси архивында күренекле рус әдәбиятчылары Е. Бертельс, И. Брагинский, Н. Баскаков, С. Касторский, Н. Пиксанов, азәрбайҗан академиклары Мамед Ариф, Гамид Араслы, чуваш, мари галимнәре белән аралашуны раслаган байтак документлар саклана» [Юзиев].

Күрүебезчә, М. Гайнуллинның эшчәнлеге гаять киң колачлы. Шуңа күрә бу шәхес турында сүз алып барганда чордашлары да, шәкертләре дә, галимнәребез дә аның төрле өлкәдәге хезмәтләренә игътибар итәләр. Мәсәлән, М. Госманов: «Профессор Гайнуллинның гыйльми эшчәнлегендә төп ике юнәлеш аерата нәтиҗәле иде. Аларның беренчесен мин иң элек татар филологиясе белеме буенча кадрлар әзерләүгә, аларны «аякка бастыруга» керткән өлеше дип билгеләр идем» [Госманов, б. 153]. «Аспирант җитәкчеләре дә, җитәкләнүчеләрнең үзләре дә беренче оппонент сыйфатында күбрәк М. Гайнуллинны чакырырга тырышалар иде... Әдәбият тарихына, хәзерге әдәби процесс мәсьәләләренә, тел белеменә, хәтта фольклорга багышланган диссертацияләр хакында да төп рәсми хөкемне Мөхәммәт ага Гайнуллин чыгарып килде. Ә ул, һәрвакыт диярлек, яклана торган диссертацияне чамалы гына тәнкыйтьләп, эшлекле тәкъдимнәр дә ясап һәм, иң мөһиме, әйбәт кенә мактап, «бу хезмәтнең авторы дәгъва ителә торган гыйльми дәрәҗәгә һичшиксез лаек», дип йомгаклап куя иде» [Госманов, б. 153].

«Галим эшчәнлегенең икенче төп юнәлеше һәм зур нәтиҗәлесе сыйфа-

тында мин аның тарафыннан югары уку йортлары өчен төзелгән дәреслек һәм хрестоматияләрне күрсәтер идем. Төгәлрәк әйткәндә, монда мин татар әдәбияты тарихы буенча әзерләнгән, күп еллар уку әсбабы буларак хезмәт иткән китапларны күз уңында тотам», — дип искәртә галим [Госманов, б.153]. Һәм «XIX йөз — XX гасыр башы иҗтимагый, мәдәни тормышыбызда, бигрәк тә әдәби фикеребез тәрәккъыятендә билгеле урын биләгән, моңарчы мираслары тигез дәрәҗәдә өйрәнелмәгән әдипләребезнең мирасларын барлау, алар белән киңрәк җәмәгатьчелекне таныштыру галим хезмәтләренең төп өлешен тәшкил итә.

Хатын-кыз әдипләребездән Газизә Сәмитова, Маһруй Мозаффария, Гыйффәт туташ, Мәхүбҗамал Акчурина иҗатларын, эшчәнлекләрен өйрәнүен дә мин махсус билгеләп үтүне кирәк табам. Шунысы да билгеле булсын: бездәге хатын-кызларның иҗтимагый активлыгы бер татар дөньясында гына түгел, бәлки Русиядәге, Көнбатыш Кытайдагы башка мөселман төркиләр өчен дә гыйбрәтле, шунысы белән тарихи зур әһәмияткә ия хәрәкәт, хәтта төгәл бер күренеш иде», — дип нәтиҗә ясый ул [Госманов, б. 154—155].

Миркасыйм ага шунда ук Мөхәммәт Гайнуллин сөйләгән бер «сер» белән дә уртаклаша: «Альберт Яхиннан шуны да ишетергә туры килде: «Бер көнне, М. Гайнуллин белән очрашкач, сүздән сүз чыгып, ул болайрак әйткән иде: «Мин үз китапларымны утызынчы елларда репрессияләнгән галимнәребезнең хезмәтләреннән файдаланып, хәтта алардан күчереп яздым. Тагын сәяси гарасатлар чыгып, аларның калган әйберләрен дә җыеп яндырсалар, бөтенләй югалу ихтималыннан куркып, ичмасам, фикерләре минем китапларда сакланыр дип уйладым. Тик билгеле сәбәпләр аркасында исемнәрен генә атый алмадым. Әйтче, зинһар, болай эшләп мин дөрес иттемме, әллә җинаять кылдыммы?» Мин ул мәлдә Мөхәммәт агага өздереп кенә җавап бирә алмадым, әлбәттә», — диде Альберт сүзен йомгаклап» [Госманов, б. 157].

Халкыбыз кулында булырга тиешле мирасны түкми-чәчми саклау юлында намус белән хезмәт куйган галимгә һәр адым эзәрлекләнгән елларны имин үтү җиңел булмагандыр, билгеле. Күңелендәге кайбер сорауларга җавап таба алмаса да, иманына тугрылыклы булуына, башкаларны рәнҗетмәвенә шиге булмагандыр аның. Укытучылар белән булган әңгәмәләрнең берсендә: «Гомерем буена бер генә әләк тә язмадым, бер генә әләккә дә кул куймадым», — ди ул [Зиннәтова, б. 138].

Мөхәммәт ага Гайнуллинның гомер юлы озын, бәрәкәтле була. Аның хезмәтләренең үз вакытында да, бүген дә әдәбият тарихы өчен зур әһәмияткә ия булулары турында озак тәфсилләп сөйләп булыр иде. Галимнең татар әдәбияты үсешенә керткән өлешен Ә. Нәҗип, Ш. Абилов, Ф. Мусин, М. Зәкиев, Ф. Ганиев, Н. Хисамов, Ф. Гарипова, Ф. Галимуллин һәм башка бик күп галимнәребез таный. Сүзебезне йомгаклар алдыннан галим эшчәнлегенә язучы-галим М. Мәһдиев биргән бәяләмәне китерү дөрес булыр: «Сүзләремдә һич арттыру юк, Мөхәммәт ага Гайнуллин әдәбият тарихының моңарчы укучылар массасына мәгълүм булмаган катлауларын ача. Ул прогрессив әдәбиятка үзләреннән кайчандыр файдалы өлеш керткән, ләкин безнең игътибарсызлыгыбыз аркасында күмелеп калган шәхесләрне, фактларны күтәрә, әдәбият тарихындагы «ак таплар»га төс бирә. Аның фикеренчә, XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы әдәбиятларында зурзур шәхесләр янында шул демократик әдәбиятка хезмәт иткән йөзләгән баш-

ка шәхесләр булган. Әнә шуларның да хезмәтен өйрәнми, әдәбият тарихының ярдәмчел факторларын белми торып, бөтен бер әдәби процесс турында сүз алып бару мөмкин түгел. Ул әдәбият тарихы битләрендә тәрҗемәче Габделмән һәм Солтан Рахманкуловлар, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче Г. Кәрам, хатын-кыз шагыйрәләр һәм әдәбиятчылар З. Сәгыйдә, М. Мозаффария, З. Бурнашева, М. Акчурина кебек шәхесләрне күтәрә» [Мәһдиев, б. 16—17].

Галимнең фәнни эшчәнлеге хөкүмәтебез тарафыннан да югары бәяләнә. Бу өлкәдәге казанышлары өчен Совет хөкүмәте аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкли, ул РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә М. Гайнуллинның фонды бар, ул әлегә тасвирланмаган. Димәк, олуг галимнең эшчәнлеге турында әле киләчәктә дә яңа сүз әйтелер.

**Әдәбият**

Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз. Р.Ф. Рахмани, Р.Н. Даутов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. I том. Б. 308—309.

*Гайнуллин М.* Каюм Насыри и просветительское движение среди татар. Казань, 1955.

*Гайнуллин М.* Кереш // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. II том. XIX йөз татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 5—10.

*Гайнуллин М.* Татарская литература XIX века. Казань, 1975; Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. Казан, 1979.

*Госманов М.* Сират күперендәге уйлар // Казан утлары. 2006. № 12. Б. 149—161.

*Зиннәтова М.* «Сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын...» // Мөхәммәт Гайнуллин — олуг галим һәм язучы (М.Х. Гайнуллин — видный ученый и писатель). Автор һәм китапны төзүче — Х.А. Гайнуллин. Казан: ДУП ПИК «Идел-Пресс», 2003. Б. 137—139.

*Мәһдиев М.* Мөхәммәт Гайнуллин һәм татар филологиясе // Мөхәммәт Гайнуллин — олуг галим һәм язучы (М.Х. Гайнуллин — видный ученый и писатель). Автор һәм китапны төзүче — Х.А. Гайнуллин. Казан: ДУП ПИК «Идел-Пресс», 2003. Б. 13—18.

XX йөз башында татар әдәбияты. (Редколлегия: Х. Хәйруллин — председатель, М. Гайнуллин, Г. Халитов; авторлар коллективы: Г. Халитов, Б. Гыйззәт, Х. Хисмәтуллин). Казан, 1954. 386 б.

*Юзеев Н.* Литературоведение и археография // 50 лет поисков и открытий. Казань: Татарское кн. изд-во, 1989. С. 64—95.

*Юзиев Н.* Мөхәммәт Гайнуллин // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. V том. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941—1960). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 491— 500.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;*

***Бәдертдинова Ләйсән Шәүкәт кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 929

***Ш.Н. Асылгәрәев***

# ПРОФЕССОР Л. ҖӘЛӘЙ — ТАТАР ОРФОЭПИЯСЕН НИГЕЗЛӘҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Статья посвящена научной деятельности известного татарского языковеда Л. Заляя в области орфоэпии. Считается, что научно-теоретические основы изучения орфоэпических норм современного татарского литературного языка были заложены в трудах данного ученого.

**Ключевые слова**: звуковой строй татарского языка, фонетика, орфоэпия, орфоэпические нормы.

Татар теле төрки телләр арасында фәнни яктан иң нык өйрәнелгән телләрдән санала. Аны өйрәнү белән бик күп күренекле галимнәр, тел белгечләре, татарның зыялылары шөгыльләнгән һәм хәзер дә шөгыльләнә. Шулар арасында профессор Л. Җәләй эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Фәнгә шактый соң килүенә карамастан, ул татар тел белеменең төрле тармакларына караган күп санлы фәнни хезмәтләр язып калдырган. Менә аларның кайберләре: «Татар диалектологиясе» (1947), «Татар теленең урта диалекты» (докторлык диссертациясе, кульъязма. 1954), «Диалектологик сүзлек» (I т. —1948; II т. — 1957), «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» (1954), «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» (2000), «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953).

«Татар теленең орфоэпик нигезләре» китабы татар милли әдәби тел әйтелеш нормаларының, ягъни кагыйдәләренең урнашуын өйрәнүгә багышланган беренче монографик хезмәт. Дәрес, татар сөйләм авазларының дөрес әйтелешенә Л. Җәләйгә кадәр дә игътибар итүчеләр булган. Мәсәлән, укучы сөйләм авазлары үзгәрешенә караган материалларны К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» (1895), Ш.Иманаевның «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» (1910), Җ. Вәлидинең «Татар теленең грамматикасы» (1919), Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) хезмәтләрендә таба ала. Әйтергә кирәк, соңгы өч хезмәттә татар сөйләм авазларының үзгәрү сәбәпләре җентекле күрсәтелгән, алар бик күп мисаллар белән дәлилләнгән дә. Шуңа да карамастан, китапның авторы Ш. Иманаев һәм Җ. Вәлиди хезмәтләрен бер урында да телгә алмый. Күрәсең, бу — чор белән бәйледер. Чөнки узган гасырның 40—50 нче елларында репрессиягә эләккән әдипләрнең, галимнәрнең һәм башка зыялыларның исемен әйтергә ярамаган. Ш. Иманаев белән Җ. Вәлиди фамилияләре дә шул исемлеккә кертелгән булган. Бу урында шунысын әйтү дә урынлы булыр: исемнәре аталган хезмәтләрнең авторлары орфоэпик нормаларны өйрәнү белән махсус шөгыльләнмәгәннәр. Алар сөйләм авазлары үзгәрешенә фонетика бүлегендә аваз төзелешен, аларның бер-берсенә тәэсирен, йогынтысын өйрәнү уңаеннан гына тукталып үтәләр. Чыннан да, татар теленең орфоэпик нигезләре Л. Җәләйгә кадәр фәнни нигездә өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсе булып кала. Моңа В. Хангилдинның «Совет мәктәбе» журналында басылган «Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе» исемле мәкаләсе дә дәлил булып тора. Галим бу турыда болай яза: «Сөйләмә әдәби телнең әһәмиятенә, роленә һәм киң кулланылышына караганда, аның кайбер өлкәләрен өйрәнү һәм тагын да культуралаштыру буенча безнең гыйльми һәм методик эшләребез җитәрлек түгел әле. Шундый аз эшләнгән өлкәләрдән берсе булып, татар теленең әдәби әйтелеше (орфоэпиясе)

мәсьәләсе тора» [Хангилдин, б. 16]. В. Хангилдин сүзләрен Л. Җәләй үзе дә куәтли: «Татар теленең орфографиясен юлга салу, аны шушы телнең үзенә хас законлылыкка лаеклы итеп беркетү, фәнни-нигезләү кирәклеген беренче башлап күтәрүче Каюм Насыйри була. Һәм, әйтергә кирәк, ул кайбер сүзләрнең ничек әйтелергә тиешлеге турында да күрсәтмәләр ясый, ягъни орфоэпия мәсьәләсен дә кузгата. Ләкин орфография өстендә байтак кына эш күрелсә дә, Бөек Октябрь Социалистик революциясенә чаклы татарның орфоэпиясе өстендә эшләүче кеше булмый, һәм, шул рәвешчә, Каюм Насыйри күтәргән мәсьәлә йомылып, капланып кала. Безнең чорда, ягъни совет культурасы шартларында, татар теленең орфоэпиясен эшкәртергә, тәртипкә салырга кирәк, дигән мәсьәлә 1939—40 елларда гына көн тәртибенә куела, һәм бу эш Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институтына тапшырыла» [Җәләй, б. 11—12].

Бу урында искәрмә ясап шуны әйтергә кирәк: Л. Җәләй исемен телгә алган Институт үзе дә 1939 елның октябрь аенда гына төзелә. Озак та үтми, Бөек Ватан сугышы башлана, фәнни хезмәткәрләрнең күбесе фронтка китә. Институтта бөтен гуманитар фәннәрне өйрәнү белән 3—5 кеше шөгыльләнә. Л.Җәләй үзе дөрес күрсәткәнчә, бу эш белән нигездә Татар академия театры артистлары, Радио комитеты хезмәткәрләре һәм мәктәп укытучылары шөгыльләнә, һәм бу өлкәдә тупланган тәҗрибә Л.Җәләй китабының нигезенә ята. Бу турыда ул үзе болай ди: «Кыскасы, хәзерге татар теленең орфоэпик төзелешен өйрәнү өстендә тупланган беркадәр тәҗрибә бар дип әйтергә мөмкин. Безнең түбәндә теркәлгән материалларыбыз әнә шуны өйрәнү, тикшеренүләрнең сөземтәсе булып тора» [Җәләй, б. 12].

Хәзер Л.Җәләй әйткән сөземтәләрне карауга күчик. Галим башта, ул вакытта урнашкан гадәт буенча, марксизм-ленинизм, бигрәк тә И.В. Сталинның тел турындагы өйрәтүләренә нигезләнеп, милли әдәби телгә билгеләмә бирә, аның ике төрле кулланылышы: язма формасы һәм сөйләмә формасы булуын искәртә. «Бу ике төрнең беренчесе, гадәттә, язма әдәби тел, икенчесе сөйләмә әдәби тел дип йөртелә» [Җәләй, б. 5], — дип яза ул. Милли әдәби телнең формалашу һәм үсеш дәвамында аның язу һәм әйтелеш нормалары да урнаша. Әдәби телнең язма нормалары орфография кагыйдәләре сөйләмә (әйтелеш) нормалары, ягъни сөйләмә тел кагыйдәләре исә орфоэпия кагыйдәләре белән беркетеләләр, системалаштырылалар, дип күрсәтә галим.

Л. Җәләй орфография һәм орфоэпия сүзләренең татар теленә грекътан кергән булуын исәпкә алып, аларның мәгънәләрен дә аңлатып бирә: орфография — туры, дөрес язам, орфоэпия — туры, дөрес сөйлим мәгънәсендәге сүзләр, ягъни орфография дөрес язу кагыйдәләрен, орфоэпия дөрес әйтелеш, сүзләрнең әдәби әйтелеш кагыйдәләрен билгеләү дигән сүз. Фикерен дәвам итеп, автор бу кагыйдәләрнең икесе дә шушы телнең әйтелешендәге үзенчәлекләрдән, аның эчке законнарыннан чыгып билгеләнүен әйтә. «Күп очракларда, — дип яза ул, — теге яки бу сүзләрнең орфографик (дөрес язылыш) нормалары белән орфоэпик (дөрес әйтелеш) кагыйдәләре, ягъни әдәби язылышлары белән әдәби әйтелеш нормалары берләшәләр. Бу момент сүзләрнең тамыр килеш торышларында ачык сизелә: мин, сез, без, кеше, авыл, урам, урман, күңел» [Җәләй, б. 6].

Дөрес, сүзләрнең язылышлары белән әйтелешләре һәр очракта да туры килеп бетмиләр, алар арасында аерма барлыкка килә. Әдип бу

аерманың барлыкка килү сәбәпләрен ике шартка бәйләп аңлата: а) сүзнең, кушымчалар алып басымы күчү белән. Мәсәлән, кеше → кешеләр, күңел → күңле, авыл → авлы; б) сүзләрнең үзара бәйләнешкә керүләре — сүз тезмәләрендә килүләре белән. Мәсәлән, ул безгә килэйде ... (Һ. Такташ), һәр нәрсәдән миңа син кыйбат ич (Г. Тукай). Укыла: Һәр нәрсә дөм миңа сиң кыйбат ич [Җәләй, б.6]. Шул рәвешчә, галим сүзләрнең язылыш нормалары (орфографиясе) белән әйтелеш нормалары (орфоэпиясе) арасында һәм уртаклык, һәм аерма булуын, бу аерманың барлыкка килү сәбәпләрен күрсәтеп бирә.

Л. Җәләй хәзерге татар әдәби теленең орфографиясе фонетик, морфологик, график принципларга нигезләнгән булуын һәм алар арасында фонетик принципның төп урын тотуын әйтә. Фонетик принципның өстенлек алуы татар милли әдәби теле орфографиясенең гомумхалык сөйләм теленә якынлаштырылган булуы турында сөйли, ди ул.

Галим, хәзерге татар әдәби теленең орфоэпиясе, ягъни дөрес әйтелеш нормалары түбәндәге дүрт принципка корылган булырга тиеш, дип саный:

1. «Яшәп килә торган орфографиябез кебек үк, орфоэпиябез дә гомумхалык телендәге әйтелеш формаларына нигезләнә» [Җәләй, б. 12], — дип яза ул. Л. Җәләй бу очракта гомумхалык теле, гомуммилли тел төшенчәсен нинди дә булса бер диалектны үзәкләштерүче, калганнарын исә аңа буйсынган, аның тирәсенә урнашкан килеш, бердәм тел эчендә эрүчеләр итеп аңларга чакыра, һәм татар орфоэпиясенең төп нормалары урта диалектның Казан арты сөйләшенә нигезләнгән булуын әйтә. Шул ук вакытта ул урынлы бер кисәтү дә ясый, ягъни урта диалектның үзенең дә бик чуар булуын истә тотарга куша. Фикерен дәлилләү өчен *өй, у, и* (дом); *сөйли, сили, сүләй* (говорит); *миңа, миа, миңгарга, мәңа* (мне); *печән, песчән* (сено) кебек төрлечә әйтелеп йөрүче сүзләрне мисалга китерә. Урта диалект нигез итеп алына, дигән сүзне андагы барлык төр әйтелешләр дә әдәби булалар икән дип аңларга ярамавын искәртә.

2. Орфоэпиянең икенче төп принцибын дөрес аңлау өчен Л. Җәләйнең үзен тыңлап карыйк: «Орфоэпиянең төп принципларының икенчесе сүзләр әйтелешендәге көчлелек, гармониялелек һәм мәгънә ачыклыгы белән бергә, теге яки бу формаларның моңарчы әдәбиятта беркетелгән булуларын бик нык исәпкә алудан тора» [Җәләй, б. 13], — дип яза галим. Биредә ул әдәби әйтелеш нормалары белән диалект, сөйләш һәм урынчылык арасында зур аерма барлыгын күрсәтә, мисаллар китерә. Әгәр дә «... акыл күп, мин әйтәм, алып кайт, килә алмады... кебек сүз тезмәләрен *апкил // әпкил; мәтәм // мәйтәм, апкайт, киләлмәде*... дип әйтүгә күчсәк, телебезне җимерү, аның һәм эчтәлек, һәм формасын бозу юлына баскан булыр идек» [Җәләй, б. 13—14], — дип искәртә автор.

3. Л. Җәләй фикеренчә, «Әдәби телнең орфографиясендә морфологик нигездә язылыш формаларының орфоэпиядә дә саклануы өченче төп принцип булып санала ала» [Җәләй, б. 14]. Бу түбәндәге кушымчалар язылышында һәм әйтелешендә чагыла:

а) сыйфат ясагыч *лы-ле* кушымчасы; б) рәвеш ясагыч *лай-ләй, лайләйә, лап-ләп, лаган-ләгән* кушымчалары; в) исем һәм сыйфат ясагыч *лык-лек*; г) фигыль ясагыч *ла-лә, латләт* кушымчалары борын авазларына беткән сүзләргә ялганып килгәндә, орфоэпия кагыйдәсе нигезендә, ассимиляциягә (охшашлануга) буйсындырылмый әйтелергә тиешләр. Мәсәлән, аңлы, белемле, урманлы (җирләр); бөтенләй, бөтенләйгә, унлап, меңләп; меңләгән, миллионлаган, урманлык,

утынлык, ашамлык, тыңла, тыңлап (тора), аңлап һ.б. [шунда ук, б. 14].

Мисаллардан күренгәнчә, «л» авазыннан башланган ясагыч кушымчалар тамыр яки нигездәге борын авазларына йоттырылмыйча әйтеләләр. Бу мәгънә, эчтәлек ачыклыгын тәэмин итә һәм сөйләмнең монотонлыгын (бертөрлелеген) булдырмый. Димәк, боларның әйтелеше белән язылышы арасында аерма юк. Шул рәвешчә, бу кушымчаларның әйтелеше орфоэпик норма булып санала.

4. Галим рус теленнән һәм аның аша башка телләрдән (биредә Л. Җәләй Европа халыклары телләрен күз алдында тота) кергән сүзләрнең әйтелешләре рус орфоэпиясендәге формаларында алуны орфоэпиянең дүртенче төп принцибы итеп карый. Ләкин Л. Җәләй бу уңайдан бер искәрмә дә ясый. Мәсәлән, рус теленнән безнең телгә бик күптәннән кереп, фонетик төзелешләре үзгәреп урнашкан *сука, мич, камыт, буразна*, *мичкә, эшләпә* кебек сүзләрнең әйтелешләрен һәм язылышларын шул формаларында саклау дөрес дип саный.

Әдип, орфоэпиянең төп принципларын күрсәтеп биргәннән соң, турыдан-туры аваз үзгәрешләре һәм аларның дөрес әйтелеш мәсьәләләрен карауга күчә. Сүзне сузыклар, анда да дифтонглар орфоэпиясеннән башлый.

Кушык (дифтонг) сузыкларның орфоэпиясе турында сөйләүгә күчкәнче, галим кушык сузыкның нәрсә икәнен аңлатып китә. «Кушык сузык яки дифтонг дип, гадәттә, бер-берсенә бик нык кушылып, бер иҗек эчендә килә торган ике сузыкны атыйлар» [Җәләй, б. 16], — дип, кушык сузыкка билгеләмә бирә. Татар телендә кушык сузыкларның чагыштырмача күп булуын әйтә һәм татар әдәби телендә 24 кушык сузык саный. Аларны ике төргә бүлеп карый: күтәрелмә (восходящие), төшерелмә (нисходящие) кушыклар.

Күтәрелмә кушыклар составына кергән ике сузыкның беренчесе көчсезләнә, икенчесе сузылыш тулылыгын саклый, дип күрсәтә автор. Сузылыш тулылыгын саклаган сузык, ягъни икенче сузык аваз иҗек ясаучы була. Күтәрелмә кушыклар (дифтонглар) составында түбәндәге кушыкларны күрсәтә: *йа-йә (я); йу-йү (ю); йо-йө; йы-йэ (е); уа-үә; уы-үэ* (тауык, Дәүэш авылы). Йарма, йарма сүзләрендәге «йа» кушыгында «а» авазының озын (сузылып), «й» авазының кыска ишетелүен искәртә, шуңа күрә «а» авазы иҗек ясаучы аваз булып тора; «уакыт, уатык» сүзләрендәге «уа» кушыгында да шулай ук «у» кыска, «а» озын әйтелә» [шунда ук].

Төшерелмә кушыкларда, киресенчә, беренче сузык тулы әйтелә, ә икенчесе кыскара. Мисалга автор *ай-әй, уй-үй; ой-өй; ый-ий; ау-әү; ыу-эү* кушык сузыкларын китерә. Болардан тыш, татар теле фонетикасында трифтонг, ягъни өч сузык кушылмасыннан торган кушык сузыклар да булуын күрсәтә: *йау-йәү, уай-иәй*.

(Искәрмә: татар телендә саф дифтонг юк. Л. Җәләй күрсәткән дифтонглар сузык һәм тартык авазлар кушылмасыннан торалар. Мәсәлән, ай=а+й.)

Галим кушык сузыкларның һәм трифтонгларның төрле авазлар тирәлегенә керү белән, әйтелешләрен үзгәртүләре турында яза, шуларга кыскача күзәтү ясый:

а) *йа-йә* кушыклары бер сүз күләмендә генә булганда, төрле комбинацияләргә керүләренә карамастан, үзгәрми, үз әйтелешләрен саклый. Мисаллар: йар-йарым, йарык; ойа, ойала, ойат, Санийә, Санийәсе, Санийәгә, йәш, йәшен, йәм, йәмсез;

б) *йу-йү* кушыклары, икенче бер сузыклардан алда килгәндә, у-ү сузыклары йөгерек әйтелеш алалар [Җәләй, б.17], — дип күрсәтә автор: кер йу -> кер йуу (йуыу түгел, йуу);

в) *йо-йө* кушыклары, гадәттә, сүзнең беренче, икенче иҗекләрендә килүчән булалар, — ди галим. Мисалга түбәндәге сүзләрне китерә: йоко, йотом (языла: йокы, йотым), ойок (языла: оек, оегы); койо (языла: кое); бөйөк (языла: бөек). Күренә, *йо-йө* дифтонглары, сүзнең кай җирендә килүләренә карап, үзләренең бөтенлекләрен үзгәртәләр, мәсәлән, той → то-йу [Җәләй, б.17—18].

Кызганыч, галим бу урында кечкенә бер төгәлсезлек җибәргән. Сүз *йо-йө* күтәрелмә кушыклары турында бара. Автор мисалга, ни өчендер, төшерелмә дифтонг кергән той сүзен китерә һәм аның ахырына «у» сузыгы ялгангач, «ой» кушыгы үзенең бөтенлеген югалткан — той+у → то+йу.

Л. Җәләй күтәрелмә кушыкларның бер сүз күләмендә генә булганда, төрле комбинацияләргә керүләренә карамастан, бөтенлекләрен үзгәртми, гадәттә үз әйтелешләрен саклаулары турында дөрес фикер әйтә. Төшерелмә дифтонглар кергән сүзләрдә эш башкачарак тора, ягъни төшерелмә дифтонгка беткән сүзгә сузык аваздан башланган кушымча ялганганда «й» авазы аңа кушылып икенче бер дифтонг ясала. Моңа мисал итеп галим түбәндәге мисалларны китерә: «ай — март а-йы (языла: ае); бай (кояш) — байый (языла: байый); ба+йу (языла: баю); тай → та-йа (языла: тая)» [Җәләй, б. 19].

Укучыда «Ни өчен мондый үзгәреш барлыкка килә?» дигән законлы сорау туарга мөмкин. Л. Җәләй үзе дә бу сорауны җавапсыз калдырган. Мәгълүм булганча, бу үзгәрешләрнең сәбәбен инде узган гасыр башларында ук Ш. Иманаев белән Җ. Вәлидиләр аңлатып биргән булганнар. Әлеге галимнәр икесе дә аваз үзгәрү, иҗек ясалу процессларын сөйләм органнары эшчәнлегенә бәйләп аңлаталар. Мәсәлән, Ш. Иманаев иҗек ясалу күренешен болай тасвирлый: «Тавышавазлы (сузык — *А.Ш.*) булсын, авазсыз (тартык — *А.Ш.*) булсын — аны әйткәндә тавыш кораллары өч хәлгә төшә: әүвәл — тавыш коралы тыныч, хәрәкәтсез хәленнән тавышны әйтер өчен кирәк булган хәлгә таба хәрәкәтләнә башлый. Икенче — ул хәлгә җиткәч, берничә микъдар тавыш чыккан арада тик тора, ягъни хәлен үзгәртми. Өченче — кораллар, тавыш әйтелгәннән соң, тыныч хәлгә төшәләр, кире әүвәлге хәлләренә кайталар (хәзерге тел белемендә аваз артикуляциясендәге бу өч этапны экскурсия, экспозиция, рекурсия терминнары белән атап йөртәләр. — *А.Ш.*). Әгәр авазсыз тавыш артыннан авазлы тавыш барса, ул чагында җамдәнең (тартык авазның. — *А.Ш.*) өченче хәлендәге тыныч хәлгә кайтуы булмый, ләкин саутиянең (сузык авазның. — *А.Ш.*) әүвәлге хәлендәге хәрәкәсе белән бергә кушыла һәм җамдә саутия белән тыгыз тоташлы әйтелә һәм бу гадәд мотәһәррәк (хәрәкәтләр саны буенча) җамдәдән гыйбарәт булган сауте пәйда була. Ошбу берничә тоташкан һәм берсе-берсе белән нык бәйләнгән авазны һәҗа яисә гавам телендә иҗек дип әйтәләр» [Иманаев, б. 20—21].

Шушы ук күренешне Җ. Вәлиди түбәндәгечә сурәтли: «... Әгәр без авазны ялгыз көенчә генә әйтсәк, шуны тәләффыз итүче әгъзалар иң элек тиешле вазгыять алыр өчен хәрәкәткә киләләр вә яхуд эшкә чыгалар. Соңра тәләффыз эшен эшләп (ягъни авазны әйтеп) янә үзләренең әүвәлге эшсез хәлләренә кайталар. Күзге алдына килегез дә бик дикъкать белән «т» авазын әйтеп карагыз. Шул вакытта күрерсез ки, иң элек (тел авазны әйтмәс борын) сезнең телегез кыймылдап, алга таба килер һәм үзенең алгы кыйсеме белән өске тешкә килеп терәлер. Менә аның шушы хәле хезмәткә чыгу вә яки «экскурсия» дип атала. Соңра «т» авазы әйтелер дә сезнең телегез янә үзенең әүвәлге хәленә кайтыр. Бусы аның

хезмәттән кайтуы яки «рекурсия» дип атала. Әгәр сузынкы авазлардан берсе, мәсәлән, «а»ны әйтеп карасагыз, монда да шушы өч төрле хәлне (экскурсия, тәләффыз, рекурсия) сизәрсез.

Әгәр инде без «т»ны үзен генә әйтмичә, аннан соң бер сузынкы аваз, мәсәлән, «а» ны китереп «та» дип әйтсәк, күрербез ки, «т»ның рекурсиясе белән «а»ның экскурсиясе берләшер, ягъни тел «т» авазын әйткәннән соң үзенең асыл хәленә кайтып, туктап тормыйча, турыдантуры «а»ны әйткән вакыттагы хәлгә таба килер, ягъни түбән таба төшеп китәр. Шуның өчен «а» авазын үзен генә әйтү белән аны икенче бер тартык авазның соңына китереп әйтү арасында аерма бар. Әгәр инде «та»ның ахырына тагын бер тартык авазны китерсәк, мәсәлән, «таб» дисәк, монда янә «а»ның рекурсиясе белән «б»ның экскурсиясе бергә катышканын күрербез. Әмма әгәр моның ахырына янә бер «а» кушып «таба» дип әйтсәк, монда «та» белән «ба» бер-берсеннән аерым әйтелер, ягъни әүвәлге «а»ның рекурсиясе белән «б»ның экскурсиясе бергә катышмый. Без сүзләрнең бу рәвештә аерылуларын, иҗеккә аерылу, дибез. Димәк ки, бу җәһәттән бер үк авазның төрлечә әйтелүе аларның сүздә торткан урыннарына «карап түгел, бәлки иҗектә торткан урынnарына карап була, ягъни иҗекнең башында килсә, бер төрлерәк булып, ахырында яки уртасында килсә, икенче төрлерәк булып ишетелә» [Вәлиди, 1919, б. 21—22; 2007, б. 34].

Төшерелмә дифтонгларның үзгәрешен күрсәтү өчен Л. Җәләй тарафыннан китерелгән «ай», «тай» сүзләренең үзгәрешләре дә шул ук закончалык нигезендә баралар. Әгәр бу сүзләрнең ахырына тартык аваздан башланган кушымча ялганса, дифтонг үз бөтенлеген саклый, үзгәреш булмый: ай → ай-га, тай → тай-га, ай-ны, тай-ны.

Шул рәвешчә, галим кушык сузыкларның әдәби телдә һәм диалектларда әйтелешләрен карап чыга, фикерен конкрет мисаллар белән дәлилли. Аннан соң мөстәкыйль сузыкларның дөрес әйтелешен карауга күчә.

«А» авазының дөрес әйтелеше. Бу турыда фәнни әдәбиятта күп язылган. Үз чиратында Л.Җәләй дә аңа игътибар иткән. Шуларны хәзер укучыларга тәкъдим итәм:

а) сүзнең баш өлешендә килеп, басым алмаган «а» авазы, язуда «а» белән күрсәтелүенә карамастан, «о» (рус «о» сына якын ишетелә) авазы булып әйтелә. (Бу урында «о» авазы булып әйтелә дип әйтү бик үк дөрес булмас, бераз «о» лаштырып әйтелә дип әйтү дөресрәк булыр — *А.Ш.*);

б) кушма тамырлы сүзләрдә очрашкан а+а тезмәләрендәге бер «а» йотыла. Мисаллар: ата-ана → атана, алма агач → алмагач, таба агач → табагач;

в) шулай ук сөйләмдә синтаксик мөнәсәбәткә кереп бәйләнешкән сүзләр арасындагы а+а тезмәсеннән бер «а» югала. Мисаллар: Кама аркылы, кара алды, тасма алдым... кебек сүз тезмәләре *Камаркылы* йөзеп чыкты бу егет; бер савыт *каралды* да *язустәленә* илтеп куйды; ефәк *тасмалдым...;*

г) «а» авазына беткән сүзләрдән соң «ал» ярдәмче фигыль, «әле» яки «әллә» сүзләре килгәндә, а+а, а+ә тезмәләре шулай ук кыскартылалар, һәм бу очракта беренче сүздәге «а» саклана. Мисаллар: бара алмыйм → *баралмыйм*; яза алмыйм → *язалмыйм*, Сафа әллә кая киткән → Саф*алләкая* киткән;

д) борынгы «ир» тамырыннан ясалган *иде, икән, имеш* ярдәмче фигыле «а» яки «ә» авазына беткән сүзләрдән соң килгәндә «и» авазы кыскарып, «й»ләнеп, ай-әй кушыгы барлыкка килә. Мисаллар: бара иде, килә иде тезмәләрендә без *барайде, киләйде* дип әйтәбез.

Хәзерге тел белемендә сузыкка тәмамланган сүз сузыкка башланган икенче сүз белән бер синтагмада әйтелгәндә янәшә килгән әлеге авазларның тәэсир итешүен *сандхи* дип атыйлар. Ике бер төрле сузык очрашканда аларның берсе генә кала. Бу — *элизия* була.

Галим, грамматик бәйләнеш сәбәпле, бер-беренә кушылып әйтелә торган сүзләр арасындагы сузык авазлар үзгәрешен җентекләп карап чыккан, бу үзгәрешнең сәбәпләрен күрсәткән, дөреслеген мисаллар китереп дәлилләгән. Ләкин ул күренешләрне хәзерге тел белемендә кабул ителгән терминнар белән атамаган.

**Тартыклар орфоэпиясе.** Кеше сөйләгәндә, аның сөйләмендә һәрвакыт ниндидер аваз үзгәрешләре булып тора. Бу үзгәрешне еш кына сөйләүче үзе дә, тыңлаучы да сизмәскә мөмкин. Чөнки ул үзгәрешләр сүзләрне дөрес аңлауга комачауламый. Әмма бу әйтелешләрнең кайберләрен язуда билгеләү моментлары да күзәтелә. Л. Җәләй үзенең хезмәтләрендә әнә шундый моментларны күрсәтеп биргән:

а) *б-п* күчеше. Мисаллар: кап → кабам, яп → ябармын, китапны улым табып бирде;

б) *к-г* күчеше. Мисаллар: так → тагылма (термин), як (май) → ягымлы; йок →йогынты;

в) *д-н* күчеше. Мисаллар: урамдай → нан, урмандай → нан. Галим бу төр күчешләрнең барысының да язуда күрсәтелүен әйтә, шунлыктан аларның язылышлары белән әйтелешләре арасында аерма булмавын искәртә.

Шуннан соң Л. Җәләй язу чаралары белән күрсәтелми торган тартыклар әйтелешенә *күчә* (боларны ул саф орфоэпик моментлар дип атый):

а) *з+с* тезмәсенең с+с тезмәсенә күчеме. Мисаллар: күзсез (языла) → *күссес* (әйтелә); тозсыз (языла) → *тоссос* (әйтелә);

б) *н+б* тезмәсенең м+б булып ишетелеше. Мисаллар: *умбер* көн эчендә *умбиш* хат язды (языла: унбер, унбиш); *кәмбатыштан* (языла: көнбатыш) дымлы җил исә;

в) *н+м* тезмәсенең м+м булып ишетелеше. Мисаллар: *баргаммы* (языла: барганмы). Сезне күрергә мөмки*нмме*? (язылa: мөмкинме). *Мим монда* укып ятам (языла: мин монда);

г) *н+к* һәм *н+г* тезмәләренең *ң+к*, *н+г* булып ишетелешләре. Мисаллар: *имән кайрысы* (языла) → *имәң кайрысы* (әйтелә). *Төнге смена* (язылa) → *төңге смена* (әйтелә). Син генә (языла) → *сиң генә* (әйтелә).

Галим шул рәвешле тартыклар орфоэпиясен, ягъни тартык авазлар үзгәрешен, аларның бер-берсенә күчешен сурәтләп биргән. Әмма күчеш сәбәпләрен аңлатуны кирәк санамаган. Бу урында шуны искәртергә кирәк: ул сәбәпләр Җ. Вәлидинең 1919 елда дөнья күргән «Татар теленең грамматикасы» исемле хезмәтендә яхшы чагылыш тапкан. Мәсәлән, «д» авазы белән борын авазлары арасындагы мөнәсәбәт (үзгәреш) болай аңлатыла: «Дан һәм дар тагылмаларында «д» авазы борын авазларыннан (ягъни — ң-н һәм м авазларыннан) соң килсә, «н»га әйләнәдер. Мәсәлән, Казандан — Казаннан, андан — аннан. Монда да шул ук сәбәп, мәзкүр өч борын авазы «д»ны үзләре шикелле булган «н»га әйләндерәләр. Ләкин ни өчен монда «д» «н»га әйләнә, башка борын авазларына әйләнми. Моның бик табигый сәбәбе бар: «д»дан элек килгән борын авазларының үзләренең генә «д»ны «н» га әйләндерергә көчләре җитми. Шуның өчен «дә», «ди» кушымталарында «д» борын авазларыннан соң килсә дә, сәламәт саклана. Казанда, таңда, урманда. Әмма «дан»ның үзенең ахырында да борын авазы бар, шуңа күрә бу хәлдә андагы «д» авазына һәр ике яктан борын авазлары белән чорналырга ту-

ры килә вә шуның өчен дә ул җиңелә, ягъни «н»га әйләнә» [Вәлиди, б. 32]. Шулай итеп, Җ. Вәлиди тартык авазлар арасында булган үзгәрешләрне мәхрәҗләренең якын булуы белән аңлата.

**Кушымчалар орфоэпиясе.** Л.Җәләй, кушымчаларның татар теленең фонетик законы буенча, тамыр һәм нигез гармониясенә килештерелүләрен әйтә. «Шушы хәл, нигездә, орфографиянең фонетик принцибын күрсәтә» [Җәләй, б. 36], — ди автор.

Галим кушымчаларның уңай охшашлану (прогрессив ассимиляция) таләбе белән сүзләрнең тамыр һәм нигезенә охшашлануларын мисаллар ярдәмендә раслый. Мисаллар: ул → дан → аннан; мин → миннән; син → синнән, кем → кемнән. Сүзнең тамыр яки нигезендәге авазлар таләбенә буйсындырылган кушымчалар әйтелеше, нигездә, орфоэпик норма булып тора һәм алар язылышларынча әйтеләләр.

Галим теркәгеч, бәйлек һәм кисәкчә кебек ярдәмче сүз төркемнәренең орфоэпиясен дә читләтеп үтмәгән. Орфоэпиядә ярдәмлекләрнең үзләре караган сүзләргә әйтелеш мөнәсәбәтләре ике төрле чагылыш алуы турында әйтә.

1. Аларның бер төрлеләре һәр урында да үзләренең басымнарын саклап, икенче бер сүзләргә кушылмый әйтеләләр. Алар, башлыча, түбәндәгеләр: *һәм, да-дә (та-тә), янә, тагын (тагы), ни, ләкин, ә, бәлки, тик, яки, яисә, йә, чөнки, әгәр, гәрчә, гүя, төсле, шикелле... чаклы, шулай да, әмма.*

Мисаллар: Торып әйтә шул арада өлкән бүре,

Картайган һәм күбэшләрне күргәм бүре, Кайтмый бүре, эзе дә юк, исе дә юк... (Г. Тукай).

2. Үзләре караган сүзләргә кушылып, алар белән уртак басым астына кереп әйтелә торган ярдәмлекләр. Алар: *өчен, саен, бирле*. Мисаллар:

— Күп тырыштык без аныңчөн шар салып (Г. Тукай)

— *Айсаен, кәнсаен,* сине сагынган саен... (Халык җыры)

Бу урында галим бер моментны искәртеп китүне кирәк таба. «... ярдәмлекләрнең үзләре караган сүзләргә кушылулары тик уртак басым астына керүдән генә тора, ягъни алар әйтелеш гармонияләрен, ягъни калынлык, нечкәлекләрен югалтмыйлар» [Җәләй, б. 38]. Мисаллар: саен (калын әйтелүле) көн сүзенә кушылганда да, ай сүзенә тоташканда да, үзенең аваз төзелешен, калынлыгын саклый. Көчәйткечләр дә шушы кагыйдәгә буйсына. Мисаллар. Җыелыш башландымы? *Югәле*, башланмады. Бакчаны *бигәйбәтләп* эшкәрттеләр. Эшкә тотынган *баргачук*.

Л. Җәләй сингармонизмның авазлар үзгәрешендәге роленә шактый киң урын бирә. Ләкин ул аңа сузык һәм тартык авазларның үзгәрешләрен караганнан соң гына туктала. Безнең карашыбызча, сузыклар гармониясен сингармонизм законына бәйләп алып китү дә уңышлырак булыр иде. Чөнки сингармонизм законы татар сөйләм авазларының дөрес әйтелешен тәэмин итә. Шуңа күрә ул татар тел белемендә шактый киң яктырту тапкан да. Профессор В.А. Богородицкий сингармонизмны «сузыклар гармониясе» дип бик дөрес эшли. «Сузыклар гармониясе яки сингармонизм төрки телләрнең иң характерлы якларыннан берсе булып тора» [Богородицкий, б. 117], — дип яза галим. Ул характерлы як шуннан гыйбарәт: тамырдагы сузыклар кушымчаларның сузыкларын билгеле рәвештә үзгәртәләр [шунда ук]. В.А. Богородицкий сингармонизмның ике төрен күрсәтә: а) сузыкларның калынлык яки нечкәлектә (аңкаулашу яки аңкаулашмауда, икенче төрле әйтсәк, палатальләшү яки палатальләшмәүдә) охшашланулары; б) иренләшү яки иренләшмәүдә (лабиальләшү яки

лабиальләшмәүдә) ярашулары. Л. Җәләй В.А. Богородицкийның югарыда әйткән фикерен тулысынча кабул итсә дә, аның сингармонизмны бары тик сузык авазларга гына хас күренеш дип әйтүе белән килешми. Бу мәсьәләдә ул профессор Н.К. Дмитриев фикерен кулай күрә. Мәсәлән, Н.К. Дмитриев, беренчедән, авазларның сингармоник мөнәсәбәтләрен ассимиляциянең бер төре итеп саный. Шул нигездә галим сингармонизмны сузыклар гармониясенә һәм тартыклар гармониясенә бүлә. Сузыклар гармониясен, үз чиратында, тагын ике төркемгә: аңкау һәм ирен гармонияләренә аерып карый. Профессор Л. Җәләй Н.К. Дмитриев схемасын тулысынча кабул иткән хәлдә, ул аны тагын да киңәйтергә, детальләштерергә тәкъдим итә. «Безнең уебызча, — дип яза ул — а) сузыклар белән тартыклар гармониясе; б) кушма сүзләр гармониясе, дигән ике пункт өстәргә кирәк» [Җәләй, б. 52]. Бу ике пунктны өстәгәннән соң сингармонизмның төре дүрткә җитә: 1) сузыклар гармониясе. Бу үзе ике төрле була: а) аңкаулашу гармониясе; б) иренләшү гармониясе; 2) тартыклар гармониясе; 3) сузык-тартыклар гармониясе; 4) кушма сүзләр гармониясе.

Галим үзе тәкъдим иткән ике моментка аеруча җентекле туктала.

Сузык-тартыклар гармониясе, ягъни сузыклар белән тартыклар арасындагы гармоник ипләшү, ярашу. «Бу ярашу шуннан гыйбарәт, — дип аңлата галим, — татар телендә (әдәби телдә) тартык авазлар үзалларына торганда, калын һәм нечкәгә бүленмиләр... бу момент буенча алар тулысынча сузыклар гармониясенә буйсыналар. Калын сузык янында килгән тартык калын әйтелә, нечкә сузык янында килгән тартык нечкә әйтелә» [Җәләй, б. 52]. Фикерен дәлилләү өчен мисаллар да китерә. Мәсәлән: ал, ул, ыл, ол, ыйл тезмәләрендәге «л» — калын, эл, үл, эл, өл тезмәләрендәге «л» — нечкә. Автор барлык тартыкларның да шул законга буйсынуын искәртә һәм моны сингармоник күренеш буларак танырга хаклы дип саный. Бу урында шуны да искәртү урынлы булыр. Профессор Л. Җәләй сингармонизм составына кергән «сузык-тартыклар гармониясе» хәзерге тел фәнендә аккомодация күренеше итеп карала. Дөрестән дә, аккомодация ике төрле авазлар, ягъни сузыклар белән тартыклар, ә сингармонизм бер үк төрдәге авазлар, ягъни сузыклар белән сузыклар арасында бара. Чыннан да, татар әдәби телендә тартыклар калын сузыклар янәшәсендә калын, нечкә сузыклар янында нечкә әйтеләләр.

Башка телләрдә, мәсәлән, рус телендә тартык авазлар һәрвакытта да бу законга буйсынмыйлар. Галим рус телендә дә палаталь тартыклар булуы турында әйтә. Ләкин рус һәм татар телләрендәге палаталь тартыклар арасында зур аерма бар. Чөнки рус телендә палатальлек, беренчедән, көчлерәк, икенчедән, мөстәкыйль, ягъни ул күршесендә нинди сузык булуга бәйле түгел. Л. Җәләй рус телендә, мәсәлән, «л» авазының ике варианты — калын һәм нечкә вариантларының мөстәкыйль фонемалар булып йөрүләрен мисаллар белән дәлилли: «*был* һәм *быль* сүзләренең икесе ике мәгънәне аңлатуы «л» авазының ике төрле (л, ль) — калын һәм нечкә әйтелүләренә бәйле» [Җәләй, б. 56], — ди автор. Димәк, рус телендә тартыкларның палатальлегe фонематик роль уйный.

Галимнең сингармонизм күренешен артык киңәйтүе белән килешеп булмый, әлбәттә. Бу очракта В.А. Богородицкий хаклы. Чөнки сингармонизм, ягъни сузыклар гармониясе, ассимиляциянең бер төре буларак, татар телендә ике төрле чагылыш таба. Беренчесе, сузыкларның сүз эчендә рәт буенча охшашлануы. Бер сүз эчендә тамырда да, кушымчаларда да бер үк рәт сузыклары гына килә ала. Бу — рәт гармониясе, дип атала.

Татар телендә рәт гармониясенең булуына татар телчеләреннән беренче булып Ш. Иманаев игътибар иткән. Ул «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» исемле хезмәтендә бу турыда болай яза: «Әгәр бер сүзнең әүвәлге иҗеге йомшак булса һәм калган иҗекләре дә йомшак булыр. Сүзнең әүвәлге иҗеге каты булса һәм калган иҗекләре дә каты булыр. Ошбу галәмәт татар лөгатенең табигатеннән булып, мәсәлән, гарәп лөгатендә булмас һәм гарәп лөгатендә әүвәлге иҗек, мәсәлән, каты булып, икенче иҗек йомшак булуы мөмкин» [Иманаев, б. 23].

Рәт гармониясе Җ.Вәлиди игътибарыннан да читтә калмаган. Сүзләрнең йә калын, йә нечкә ишетелүләре турында сөйләгәндә ул: «Татарчада да бер сүздә булган авазлар арасында калынлык нечкәлектә камил гармония (аһәң) бар, ягъни бер сүз йә гел калын авазлардан, йә гел нечкә авазлардан җыела» [Вәлиди, 1953, б. 36].

Сингармонизмның икенче төре — ирен гармониясе. Бу очракта сүзнең беренче иҗегендә о, ө авазлары килсә, шуннан соңгы иҗекләрдәге ы, э сузыклары иренләшә, ягъни о, ө сузыклары ы, э сузыкларын үзләренә тулысынча охшашландыралар.

Татар телендә сингармонизмның ике төре дә танылган һәм яхшы өйрәнелгән. Мәсәлән, профессор Г. Алпаров «Сингармонизм телебезнең иң төп табигатеннән берсе, авазлар янәшә тезелеп сүзләр хасил иткән чагында, аларның барысы да калынлык, нечкәлектә бер-берсенә ярашып әйтелүләредер» [Алпаров, б. 40] — дип яза. Галим шунда ук фикерен болай дип дәвам итә: «Авазларның калынлык һәм нечкәлеге, тамыр кисәкләрендә, төп сүзләрдә генә калмыйча, кушымчаларга да күчә. Төп сүзнең азагына ничаклы, ничә рәт кушымча тоташса да, алар бары да калынлык, нечкәлектә төп сүзнең әйтелешенә ияреләр. Мәсәлән, ал, алды, алдылар, алдыгызмы, алганнарыгыздан; кил, килде, килделәр, килдегезме, килгәннәрегездән... кебек» [шунда ук]. Ләкин профессор Л. Җәләй Г. Алпаровның сингармонизм турында әйткән фикерләре белән тулысынча килешеп бетми. Чөнки ул авазларның калынлык һәм нечкәлектә ярашу табигатен, сүзнең мәгънәсе һәм сөйләүченең башындагы тәсаувыр белән бәйләнгән, дип аңлата. Г. Алпаров фикеренчә, «зур һәм эре нәрсәләр бездә күбрәк калын әйтелүчән, кечкенә һәм вак нәрсәләр күбрәк нечкә әйтелүчән була» [Алпаров, б. 40].

Профессор Л. Җәләй, Г. Алпаров белән бәхәскә кереп: «Аңлашыла: Г.Алпаров сингармоник төзелешне татар теленең иң характерлы үзенчәлеге итеп саный. Монысы белән килешәбез. Ләкин теге яки бу сүзләрдәге калын яки нечкә әйтелешне шул сүзләр белән аталган әйберләрнең зур яки кечкенә булуыннан һәм сөйләүченең ул әйберләрне ничек күзаллавыннан килә, дип аңлатуы фәннилектән бик ерак тора. Чөнки бу карашның реаль чынбарлык бәлән бернинди дә бәйләнеше юк һәм була да алмый» [Җәләй, б. 50], — дип язды, һәм ул болай дип язуы белән хаклы иде. Чөнки татар кешесе *җир, күк, диңгез, көн, төн. ил, фил* кебек зур, эре әйберләрне һәм күренешләрне нечкә авазлы, *валчык, бармак, борын, кырмыска* кебек кечкенә әйберләрне калын авазлы сүзләр белән атаган һәм бу калынлык, нечкәлек аларның әйтелешендә дә саклана. Шулай итеп, Г. Алпаров сингармонизм күренешен аңлатканда каршылыклы фикерләр дә әйтә. Шуңа күрә Л. Җәләй Г. Алпаровның түбәндәге фикере белән дә килешмәвен белдерә. Чөнки ул үзенең алда әйткән сүзләренә каршы килеп: «Калынлык, нечкәлек сүзнең башындагы яки тамырындагы бер авазга (йә бер хәрефкә) карап йөрми. Сөйләүче, бер сүзне әйтергә теләп, авызын ача башлаганда ук (экскурсия чагында) аваз эчендә үзенең телен, үзенең тасвирына муафыйк рәвештә йә калынга, йә нечкәгә ипләп куйган була; гүя телгә: «Син тел, бу

сүзне менә шул көе торып кына әйт, урыныңнан күп кузгалма!» — дип боерык бирелә» [Алпаров, б. 41], — дип белдерә. Л. Җәләй Г. Алпаров фикерләренең каршылыклы булуын аның концепциясенең субъектив идеализмга нигезләнгән булуы белән аңлата.

Хәзерге тел белгечләре, шулай ук Л. Җәләй концепциясе белән дә килешеп бетмиләр. Чөнки ул (бу турыда югарыда әйтелгән иде инде) сингармонизм күренешен артык киңәйтә. Сузыкларның рәт һәм иренләшү гармонияләренә тагын өчне: а) тартыклар, б) сузыклар-тартыклар гармониясен һәм в) кушма сүзләр гармониясен өсти. Әйтергә кирәк, галимнең бу өйрәтүләре мәктәп дәреслекләрендә дә урын алды. Анда сингармонизм ассимиляциясенең бер төре итеп күрсәтелде. Шуның өстәвенә аның бер генә ягы — рәт гармониясе генә искә алынды. Тартыклар ассимиляциясен сингармонизмга кертеп карау белән һич тә килешеп булмый. Дөрес, соңгы вакытта фонетика өлкәсендә үткәрелгән тикшеренүләр аваз үзгәрешләрен, аларның орфоэпиясен фәнни нигездә аңларга һәм аңлатырга мөмкинлек бирде. Бүгенге көн татар әдәби телендә урнашкан сөйләм нормалары, ягъни әйтелеш кагыйдәләре бик яхшы өйрәнелгән. Матбугатта аваз үзгәрешләренә, авазлар орфоэпиясенә багышланган фәнни мәкаләләр дөнья күрде. Мәсәлән, Х. Курбатовның «Татар теленең әдәби әйтелеше», Х. Сәлимов һәм Д. Салиховаларның «Татар телендә аваз үзгәрешләре» исемле мәкаләләре Совет мәктәбе журналында басылып чыкты. Бу мәкаләләр аваз үзгәрешләрен дөрес аңлауда һәм аңлатуда аеруча зур роль уйнадылар. 1995 елда Х. Сәлимов «Татар теленең орфоэпик сүзлеге»н төзеп бастырды. Орфоэпия турындагы өйрәтүләр мәктәп, махсус урта белем һәм югары уку йортларының ана теле дәреслекләренә дә кертелде. Анда урын алган материаллар барысы да галим, филология фәннәре докторы, профессор Л. Җәләй хезмәтләренә нигезләнгән.

**Әдәбият**


*Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр. Казан: Татгосиздат, 1945. 340 б.

*Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание. Казань: Татгосиздат, 1953. 219 с.

*Вәлиди Җ.* Сайланма хезмәтләр. Казан: «Мәгариф» нәшр. 2007. Б. 34.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең грамматикасы. Казань: Миллять (Курултай), 1919. Б.4—52.

*Җәләй Л.* Татар теленең орфоэпик нигезләре. Казан: Татгосиздат, 1953. 71 б.

*Заляй Л.З.* Основы татарской орфоэпии (в порядке обсуждения) // Известия АПН РСФСР, вып. 40. М.: 1952. С. 84—95.

*Иманаев Шәехгаттар*. Татар теленең нәхүе вә сарыфы. Казань: Типография газеты «Баянульхакъ», 1910. 102 б.

*Киекбаев Җ.Г.* Башкорт әдәби теленең дөрес әйтелеше. Өфө: Башкортстан китап нәшрияте, 1964. 87 б.

*Курбатов Х.* Татар теленең әдәби әйтелеше (орфоэпия) // Сов. мәкт., 1962. №2. Б. 25—31.

*Насыйри Каюм.* Әнмүзәҗ. Казан: 1975. Б. 3—110.

*Хангилдин В.* Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе // Сов. мәкт., 1941. № 5. Б. 15—17.



***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 929

*И.И. Ямалтдинов*

# ХАЛЫК АКЫЛЫНА СОКЛАНГАН, ГОМЕРЕН АНЫ ӨЙРӘНҮГӘ БАГЫШЛАГАН ГАЛИМ

Статья посвящена анализу научной и научно-организационной деятельности выдающего татарского фольклориста Хамита Ярми.

**Ключевые слова**: татарская фольклористика, Хамит Ярми, отдел народного творчества ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова.

2014 елның 5 маенда күренекле фольклорчы галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең (Габделхәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтевнең) тууына 110 ел тулды.

Хәмит Ярми Төмән өлкәсе, Кырынкүл авылында 1904 елда туып, башлангыч белемне әтисеннән — Стәрлетамак, Мәчкәрә авылы мәдрәсәләрендә белем алган, заманының мәгърифәтле, прогрессив карашлы кешесе саналган Хөснетдин мулладан ала, соңрак атаклы Нигъмәтулла хаҗи Кармышаков улы Сәйдүков исемендәге Ямбай авылындагы мәктәптә укый. Төмәндә педагогия училищесын тәмамлый, төрле авылларда уку өе мөдире, авыл советы рәисе урынбасары булып эшли.

1930—1933 елларда Казан педагогия институтында белем ала. Институтны тәмамлаганнан соң татар теле һәм әдәбияты кафедрасында аспирантурада укырга калдырыла. 1934—1939 елларда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә мәдәният бүлеге җитәкчесе, Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы сәркәтип, Татарстан китап нәшриятендә тәрҗемәче булып эшли.

1939 елда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты (хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) ачыла. Бу урында шуны да әйтеп үтәргә кирәк, 2014 ел аеруча истәлекле: мәшһүр галимебез Хәмит Ярминең тууына 110 ел булды, ә Институт оешуга 75 ел. Хәмит Ярми милләтебезнең йөзек кашы булган Институтның үсешенә өлеш керткән зат булса, Институт Хәмит Ярми кебек күренекле шәхес язмышында шулай ук зур роль уйнаган [Миннуллин, 2014, с. 5].

Институт оешу белән Х.Ярмөхәммәтев өлкән фәнни хезмәткәр, фольклор секторы мөдире булып эшли башлый. Фольклорчы буларак формалашкан Хәмит Ярми (аны фольклор өлкәсенә алып кереп китүче остазы — XX гасырның 20 нче еллары ахыры — 30 нчы елларында фольклор мәсьәләләре, проблемалары буенча актив тикшеренүләр алып баручы, язучы, фольклорчы галим Гомәр Толымбай булса кирәк, чөнки Хәмит Хөснетдин улы төзегән «Кемнәр турында язарга?» дигән исемлекнең 13 нче саны астында әлеге шәхес күрсәтелгән) [Хәмит Ярми, 2004, б. 80] сектор эшчәнлегенең төп юнәлешләрен, гомумән, фольклористикада кабул ителгәнчә, дөрес итеп, түбәндәгечә билгели: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен фәнни экспедицияләр оештыру; фольклор текстларын әзерләп бастыру; халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү.

Күрсәтелгән өч юнәлешне тормышка ашыру буенча планлы рәвештә эшен башлап җибәрә.

### Оештырылган фәнни фольклор экспедицияләр (XX йөзнең 40—60 нчы еллары)

Билгеле булганча, XX гасырның 30 нчы еллары ахырына хәтле татар халык иҗаты әсәрләрен халыктан җыю, аларны фәнни өйрәнү һәм бастырып чыгару эше, нигездә, стихиячел рәвештә башкарыла. 1921 елда Татарстан АССР Халык мәгарифе комиссариаты (Татнаркомпрос) каршында төзелгән беренче фәнни оешма — Академүзәк 1933 елда ябыла. Әлеге эшләрне планлы рәвештә алып бару өчен махсус фәнни үзәк булмый. Ниһаять, 1939 елда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты ачыла һәм анда, Хәмит Ярми тырышлыгы белән, фольклор секторы төзелә.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен халыктан җыюның төп методы булып фәнни экспедицияләр тора. Һәм, бу юнәлештә беренче адым буларак 1940 елда Х.Ярми җитәкчелегендә Себергә «Академик В.В. Радлов эзләреннән» беренче комплекслы экспедиция оештырыла. Экспедиция вакытында 80 көйнең ноталары, 4 эпос, 136 әкият, 18 бәет, 1500 җыр һәм 200 мәкаль язып алына.

Танылган фольклорчы галим Ф.И.Урманче, бу беренче экспедициянең иң җитди нәтиҗәләреннән берсе дип, мәшһүр «Идегәй» дастанының аерым вариантларын язып алуны ассызыклап үтә [Урманче, б. 9].

Шул ук 1940 елны эшчеләр фольклорын өйрәнү өчен Татарстанның Бондюг, Красный бор һәм Әгерҗе районнарына Х.Ярми җитәкчелегендә фольклор экспедициясе җибәрелә.

1942—1944 елларда Х.Ярмөхәммәтев Институт директоры вазыйфаларын башкара, ләкин, милли характердагы «җитди хаталар» җибәрүе сәбәпле, әлеге вазыйфадан азат ителә. Галимнең татар халкының «Идегәй» дастанын өйрәнә башлавы дәүләт тарафыннан шулай бәяләнә һәм декабрь аеннан ул Институтта татар фольклоры буенча өлкән фәнни хезмәткәр буларак эшли башлый (1961 елдан фольклор һәм сәнгать тарихы секторы мөдире итеп билгеләнә).

Халык иҗатын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эше 1946 елдан, Тел, әдәбият һәм тарих институты СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына кертелгәч, башлана.

1945—1950 елларда Институт тарафыннан 11 фольклор экспедициясе оештырыла. Фольклорчылар 200 дән артык торак пунктта булып, барлыгы 243 әкият, 20 меңнән артык җыр-такмаклар, 96 бәет, меңгә якын мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар, 362 җыр текстлары белән халык уеннары язып алалар [Ярмухаметов, 1957, с. 173—181].

1951—1955 елларда татар фольклоры фондын баету эше тагын да киңәя. Татарстан районнарына яңадан 5 фольклор экспедициясе һәм 4 махсус сәфәр оештырыла, шуның белән Республика районнарында сакланган рухи мирасны туплау эше тукталып кала. Әлеге экспедицияләр вакытында галимнәр 38 меңнән артык җыр һәм такмак, 233 әкият, 515 мәкаль һәм әйтем, 87 бәет, 126 җыр текстлары белән халык уеннары һәм 200 берәмлектән артык төрле характердагы материаллар (сөйләкләр, истәлекләр һ.б.) язып алып кайталар.

Татарстанда халык авыз иҗатын барлау, аларны язып алу эше нигездә бер тәртипкә салынгач, фольклорчыларга РСФСРның татар халкы яши торган башка өлкәләренә экспедицияләр оештырырга мөмкинлек ачыла. Һәм алар Х.Ярми җитәкчелегендә 4 республикада (Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Мари Эл) һәм 13 өлкәдә (Киров, Пенза, Рязань, Оренбург, Әстерхан һ.б.) булалар.

Татар фольклорын өйрәнү белән беррәттән, Тел, әдәбият һәм тарих институты рус фольклорын җыю буен-

ча да эш алып бара. Бу юнәлештәге эшне фольклор төркеменең фәнни хезмәткәре В.Ф.Павлова башкара, ул соңрак рус халкы такмаклары (частушки) буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Рус авылларына беренче фольклор экспедициясе 1946 елда оештырыла, ә 1950 елдан бу юнәлештәге эш планлы рәвештә алып барыла. Монда, М.Ф.Малкина (Юдино), М.Д. Гирдасова (Бондюг районы), Н.А. Ерохина (Алабуга районы) кебек талантлы җыр осталары репертуарларының язып алынуы игътибарга лаек, дип ассызыклый Х. Ярми [Ярми, 1940].

Шулай итеп, Хәмит Ярми 30дан артык фольклор экспедициясе оештыра һәм аларның җитәкчесе була, 100дән артык районда һәм 500гә якын авылларда була. 1920—1960 елларда планлы рәвештә халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю нәтиҗәсендә Институтның бай фольклор фонды булдырыла һәм төрле типтагы җыентыклар дөнья күрә башлый.

### Татар фольклоры буенча фәнни җыентыклар (XX гасырның 40—60 нчы еллары

Фольклор әсәрләрен системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү нәтиҗәсендә 1940 еллар башыннан аерым оешмалар һәм язучылар, сәнгать әһелләре тарафыннан күпсанлы җыентыклар тупланып, басылып чыга башлый. Шулар рәтенә Х. Ярмөхәммәтев һәм А. Әхмәт тарафыннан төзелгән һәм татар халык иҗатының төрле жанрларын үз эченә алган «Халык иҗаты» [Ярми, 1938] китабының икенче басмасы [Ярми, 1940] дөнья күрә. Бу басмага карата үзенең тәнкыйть мәкаләсендә С. Гарипов кайбер кимчелекләрне күрсәтә, ә, гомумән алганда, әлеге җыентыкны уңай бәяли [Гарипов, б. 80—83].

1940 елның уртасында ук Х. Ярми белән Г. Бәширов ике томлы «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын басмага әзерләп бетерәләр, 1946 елда ул дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышыннан соң Х. Ярми югарыда күрсәтелгән басмага яңадан әйләнеп кайта һәм ул 1951 елны нәшер ителә. Бу китапка төп фольклор жанрларына караган халык иҗаты әсәрләренең үрнәкләре керә һәм ул үзенә күрә югары уку йортларының филология факультетлары өчен дәреслек-хрестоматия ролен үти башлый, чөнки моңа кадәр татар фольклор жанрларының характеры, үзенчәлеге турында тулы мәгълүмат бирердәй җыентык булмый.

Беренчедән, китапта Хәмит Ярминең тулаем татар халык иҗатына багышланган зур күләмле мәкаләсе урын алган. Аның беренче өлеше татар фольклористикасы тарихына багышланган. Анда автор шул елларга хәтле фольклорчыларның игътибарыннан читтә калып килгән чыганакларга мөрәҗәгать итә. Аннан соң Х. Ярми татар фольклорының төп жанрларының һәркайсына (әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар), Совет чоры фольклоры кебек моңа кадәр өйрәнелмәгән проблемага фәнни анализ ясый. Җыентыкның төп өлешендә санап үтелгән жанр төрләренең иң яхшы үрнәкләре урын алган. Фәнни фольклор җыентыгына куела торган мөһим таләпләрнең берсе булып, аның тиешле дәрәҗәдә эшләнгән фәнни аппараты булуы санала.

Әлеге антология шул чор вакытлы матбугатында югары бәя ала һәм тиз арада халыкка таралып бетә [Фәттах, 1951, №10, б. 119—125].

1954 елда Х. Ярми (баш редактор), Г. Бәширов, Х. Госман һәм А. Шамов тарафыннан әзерләнгән «Татар халык иҗаты» антологиясенең икенче басмасы дөнья күрә. Әлеге җыентык ярты гасырдан артык милли мәктәпләр, педагогия училищелары, югары уку йортлары өчен дәреслек һәм хрестоматия ролен үти.

1956 елда ике томлы «Татар халык әкиятләре»нең икенче китабы басылып чыга [Ярмухаметов, 1956]. Фольклорчы галим Ф. Урманче фикеренчә, әлеге басмалар татар фольклористикасында принципиаль яңа төр җыентыклар булып, үзләренең фәнни әһәмиятләрен әле бүген дә югалтканнары юк [Урманче, б. 11].

Халык иҗаты әсәрләре үрнәкләреннән торган җынтыклар әзерләүне Х.Ярми алга таба да дәвам итә. Шундыйларның берсе — 1960 елда басылган «Бәетләр» җыентыгы.

Фольклорчы галим Х. Мәхмүтов язганча, Х. Ярми бәет жанрының теориясенә һәм тарихына караган бик күп мөһим фикерләр әйтеп калдыра [Мәхмүтов, б. 52—53].

Х. Ярмөхәммәтев тарафыннан рус телендә әзерләнеп, Мәскәүдә бастырылган (1952, 1957, 1964, 1976 елларда) татар әкиятләре җыентыклары («Гульчечек», «Татарские народные сказки», «Находчивый джигит») кытай, венгр, словен, әрмән, литва, украин, узбәк, төркмән, казакъ һәм башка халыкларның телләренә дә тәрҗемә ителеп бастырылган [Ахметова, 1984, с. 100—101].

Х.Ярмөхәммәтев халык иҗаты әсәрләрен бастырып, аны яңадан халыкка кайтаруга бик күп көч куйган шәхес. Аның тарафыннан яисә аның катнашында төзелеп бастырылган җыентыкларның саны 20дән артык [Надиров, 2004, б. 19].

Шулай итеп, Х.Ярми тарафыннан әзерләнеп бастырылган фәнни җыентыклар 2 типта булган. Беренчесе — татар фольклорының төп жанрларының барысын да үз эченә алса, икенчесе — бер жанрга гына багышланган. Бу җыентыклар Х. Ярминең зур һәм төпле фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәсе һәм алар барысы да фольклор җыентыгына куела торган мөһим таләпләргә туры киләләр: кереш һәм искәрмә-комментарийлары бар, фәнни аппараты тиешле дәрәҗәдә эшләнгән.

Материаллар җыю, алар өстендә киң пландагы теоретик тикшеренүләр алып бару, җыентыклар төзү һәм бастырып чыгару тәҗрибәсе академик күптомлыклар әзерли башлауга мөмкинлек тудыра. 1960 еллар ахырында зур коллектив хезмәт — күптомлы татар фольклоры җыелмасын төзү проекты эшләнә [Ямалтдинов, 2012]. 12 томлык «Татар халык иҗаты»ның 3 китаптан торган әкият томнарының баштагы икесен Х.Ярми белән бөтен гомере буена секторда эшләп, күпсанлы экспедицияләр вакытында да, шулай ук бихисап җыентыклар әзерләгәндә дә аның ярдәмчесе булган фольклор белгече, хәләл җефете Халидә Гатина төзиләр. 1989 елда әлеге фундаменталь басманы әзерләүдә катнашкан бер төркем галимнәр, шул исәптән Х. Ярми дә (вафатыннан соң), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булалар.

### Татар фольклорының беренче тарихчысы

Фольклористиканың фән буларак өйрәнелергә тиешле өлешен аның тарихы тәшкил итә. Татар фольклорына һәм фольклористика тарихына озак еллар дәвамында безнең филологлар артык игътибар итмиләр. Татар фольклоры тарихын беренче өйрәнүче дип, бик хаклы рәвештә, аны профессиональ дәрәҗәдәге тикшеренүче Хәмит Ярмине атарга була. Әлеге мәсьәләләр аның кандидатлык диссертациясендә күтәрелә [Ярмухаметов, 1947]. Аны анализлауга шушы юллар авторының махсус мәкаләсе багышланган [Ямалетдинов, 2009, с. 91—92].

Фольклорчы галим Х.Мәхмүтов халык иҗатын өйрәнүгә 40 ел гомерен багышлаган Хәмит Ярмине универсаль фольклорчы дип атый [Мәхмүтов, б. 52—53]. Элгәрләреннән аермалы буларак, ул барлык жанрлар, татар фольклористиканың бар-

лык юнәлешләре буенча системалы тикшеренүләр алып бара.

Х.Ярмөхәммәтевнең фәнни кызыксынулар диапазоны киң була, әмма галим төп игътибарын фольклорга юнәлтә. Ул гомере буена ару-талуны белмичә халык җәүһәрләрен җыючы, бастырып, аларны халыкка яңадан кайтаручы һәм аларны тикшерүче була.

Хәмит Ярми бу өлкәне әзерлекле кадрлар белән тәэмин итүгә дә зур көч куя. 1950 еллар ахыры — 1960 елларда аның йогынтысы-ярдәме белән татар халык иҗатының аерым жанрларын, фольклор һәм әдәбият бәйләнешләрен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертацияләре яклана.

1960 еллар ахырына кадәр татар халык иҗатының барлык жанрларын тикшерүне колачлаган теоретик хезмәт булмый. Һәм 1967 елда Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» [Ярми, 1967] монографиясе дөнья күрә. Әлеге хезмәт татар фольклорын монографик планда беренче тикшерү була.

Хәмит Хөснетдин улы үзенең фольклористик эшчәнлеген халык авыз иҗатын җыю, язып алу эшеннән башлап, масштаблы тикшеренүгә таба бара, җыелган материалларны өйрәнеп һәм гомумиләштереп, билгеле бер фәнни нәтиҗәләргә килә. 1969 елны, татар фольклорчыларыннан беренче булып, Казакъстан Фәннәр академиясендә, алда күрсәтелгән тема буенча докторлык диссертациясе яклый һәм аның хезмәте фольклористика фәненә саллы өлеш кертү буларак бәяләнә [Ямалтдинов, 2012, №1, с. 136—139].

Хәмит Ярми татар фольклоры фәнен киң ачышлар дөньясына алып чыккан галим. Язган хезмәтләре — бүгенге көндә татар фольклорчыларының инде өч-дүрт буынны берләштергән академик мәктәбе — галимнең иң зур мирасы. Һәрьяклап та беренче булган Хәмит ага Ярминең татар фәненә багышланган нәтиҗәле хезмәтләре һичкайчан үзенең кыйммәтен югалтмаячак.

**Әдәбият**

*Ахметова Ф.В.* Фольклор и современная татарская проза: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1968. 24 с.

*Ахметова Ф.В., Галиуллин Т.Н.* Хамид Хуснутдинович Ярмухаметов. К восьмидесятилетию со дня рождения // Советская тюркология. 1984. № 3. С. 100—101.

*Галиуллин Т.Н.* Современная татарская поэзия и народное творчество: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1968. 30 с.

*Гарипов С.* Халык иҗаты: шул исемдәге җыентык турында // Совет әдәбияты. 1941. № 4. Б. 80—83.

*Касимов Э.* Сатира и юмор в татарских народных сказках: автореф. дис. ...канд. филол. наук. Казань. 1966. 27 с.

*Махмутов Х.Ш.* Татарские народные загадки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1969. 31 с.

*Мәхмүтов Х.* Беренче профессиональ фольклорчыбыз // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр. 2004. Б.52—53.

*Миңнуллин К.М.* Вступительное слово // Фольклор в системе национальных и общечеловеческих ценностей: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Хамида Хуснутдиновича Ярмухаметова (Хамида Ярми) / под ред. И.Закировой. Казань: ИЯЛИ. 2014.

*Надиров И.* Олуг галим, хөрмәтле остаз // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр. 2004.

*Надиров И.* Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр. 1961. 192 б.

О назначении Ярмухаметова Х.Х. зав. кабинетом фольклора с 15.12.1939 г.: приказ № 10 от 14.12.1939 г. // Музейный комплекс им. И.Я. Словцова Тюменской области. Отдел учета. Папка № 31.

Сведения о количестве фольклорных экспедиций, организованных с участием Х.Х. Ярмухаметова (1922–1964 гг.) // Музейный комплекс им. И.Я. Словцова Тюменской области. Отдел учета. Папка № 29, 31.

Статьи, труды Х.Х. Ярмухаметова // Музейный комплекс им. И.Я. Словцова Тюменской области. Отдел учета. Папки № 25, 28, 29, 31.

*Урманче Ф.* Хәмит Ярми һәм бүгенге татар фольклористикасы // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит.нәшр. 2004.

*Урманчеев Ф.И.* Пути развития жанров татарского советского народно-поэтического творчества: дис. … канд. филол. наук. Казань. 1968.

*Фәттах Н.* Татар халык иҗаты җыентыгы // Совет әдәбияты. 1951. № 10. Б. 119—125.

*Хәмит Ярми.* Кемнәр турында язарга? // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр. 2004.

*Ямалтдинов И.И.* Весомый вклад в фольклористику (60-е гг. XX века) // Научный Татарстан. 2012. № 1. С. 136—139.

*Ямалтдинов И.И.* Первый историограф татарской фольклористики // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 29 июня 2009 г.). Казань. 2009. С. 91—92.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20 — 60-х гг. XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 30 с.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967. 307 б.

*Ярми Х., Әхмәт А.* Халык иҗаты. Казан: Татгосиздат, 1938. 167 б.

*Ярми Х., Әхмәт А.* Халык иҗаты. Икенче басма. Казан: Татгосиздат, 1940. 270 б.

*Ярмухаметов Х.Х.* История собирания татарского фольклора: дис. ... канд. филол наук. Казань. 1947.

*Ярмухаметов Х.Х.* Татарская советская фольклористика за 40 лет // Известия Казанского филиала АН СССР. Юбилейный сборник. Казань, 1957. С. 173—181.

*Ярмөхәммәтев Х., Бәширов Г.* Татар халык әкиятләре. Казан: Таткнигоиздат. 1956. 396 б.

*Мәкалә Татарстан Республикасы яшьләр гранты кысаларында язылды.*
*Проект номеры: 18-173г/Г2014.*

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге җитәкчесе*

УДК 303

***Ф.С. Баязитова***

## ИНСТИТУТ ТАРИХЫНДА ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР

Научные экспедиции — это страницы «живой» истории языка и культуры. Практически с первых дней образования Института самое серьезное внимание обращалось целенаправленным полевым научным экспедициям. В настоящее время проводятся тематические и комплексные экспедиции с целью всестороннего изучения тех или иных районов, областей, в которых принимают участие многие специалисты: языковеды-диалектологи, искусствоведы, фольклористы и др. Научные экспедиции, полевые исследования включают в себя не только выявление, фиксацию языковых, культурных ценностей, но и обработку, публикацию материалов в виде отдельных сборников.

**Ключевые слова:** экспедиция, археография, диалектология, этнография, лексикология, этнография, искусство, топонимы.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты — гуманитар тикшеренүләрне әйдәп баручы эре гыйльми үзәкләрнең берсе. Институт 1939 елның 7 октябрендә ачыла. Ул чагында «Татар теле һәм әдәбияты фәнни тикшеренү институты» дип атала, ә 1941 елның февраленнән башлап, «Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институты» статусын ала.

1946 елда Институт СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына, 1993 елдан Татарстан Фәннәр академиясенә карый. 1967 елда Институтка татар әдәбияты классигы, күренекле язучы һәм дәүләт эшлеклесе Г.Ибраһимов исеме бирелә. Институтны хезмәтләре белән фәнгә зур өлеш керткән, халык арасында киң танылган галимнәр: М.Х. Гайнуллин, Х.Х. Ярми, Х.Ф. Хәйри, К.Ф. Фасиев, М.К. Мөхәррәмов, Я.Г. Абдуллин, М.З. Зәкиев, Н.Ш. Хисамов җитәкли, бүгенге көндә К.М. Миңнуллин бу авыр һәм җаваплы эшнең башында тора. Институтның беренче ачылган көннәреннән башлап, татар халкын төрле яклап өйрәнү бурычы куела. Татар телен, әдәбиятын, тарихын тикшерү буенча күп төрле бүлекләр ачыла: археография, этнография, фольклор, диалектология, лексикология, сәнгать, кульъязмалар һ.б. Соңрак, тарих, археология һәм этнография бүлекләре нигезендә Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, Татар энциклопедиясе институты эшли башлый.

Институтта күп кырлы, киң профильле фәнни эшчәнлек алып барыла, шуның өчен халык белән турыдан-туры аралашып, экспедицияләргә, ягъни фәнни сәяхәтләргә чыгып материаллар туплау, иң әһәмиятле метод булараk, алгы планга куела.

*Экспедиция* — [<лат. *expeditio*] бер төркем яки аерым кешеләрнең, отрядның махсус задание, максат белән чыккан сәяхәте, походы. Экспедицияләргә чыгып халыкны төрле яклап өйрәнү Россия тарихында күптән башланган. 1725 елда Петр I тарафыннан Россия Фәннәр Академиясенә нигез салынгач, фәнни экспедицияләр Себер, Ерак көнчыгыш, Урал, Урта Азия, Оренбург, Казакъстан һ.б. якларга оештырыла. Бу экспедицияләрдә, нигездә, фәнни максатлар куелган булса да, патша хөкүмәтенең рус булмаган халыкларны тикшерү, барлау, төрле са-

лымнар җыю кебек эшләренә дә юл ачкан. Әлеге экспедицияләрдә катнашучы тарихи шәхесләр: Г.Ф. Миллер, И.Г. Георги, И.И. Лепехин, П.И. Рычков, В.В. Радлов хезмәтләрендә бүгенге көн фәне өчен дә кыйммәтле мәгълүматлар табыла. Төрки халыкларга (шул исәптән татар теленә дә) мөнәсәбәтле хезмәтләрдән борынгы сәяхәтнамәләрне, юлъязмаларны, М.Кашгариның XI йөздә чыккан мәшһүр «Диване — лөгатет төрк» сүзлеген, соңгырак чорларда К.Насыйри хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Институтта турыдан-туры экспедицияләр белән бәйле булган күп кенә бүлекләр эшләп килә. Шуларга кыскача күзәтү ясап китик.

*Археология* [<*архайос* ’борынгы’, ’*логос* ’сүз, фән] — казылып табылган әйберләр, сакланып калган тарихи истәлекләр буенча кешелек җәмгыятенең үткәнен өйрәнә торган фән. Бу терминны беренче мәртәбә безнең эрага кадәр 427—347 елларда борынгы грек галиме, философ Платон кулланган. Бик күп археологик экспедицияләрдә катнашып, аларның җитәкчеләре булып, күренекле хезмәтләр калдырган Н. Калинин, А. Халиков, Р. Габдрахманов, Ф.Хуҗин, П. Старостин кебек галимнәрнең эшчәнлеге безнең Институтның да горурлыгы булып тора. Археологлар һәм тарихчылар тырышлыгы белән фәнни өйрәнеп тикшерелгән һәм Татарстан хөкүмәте ярдәме белән торгызылып килә торган борынгы Болгар шәһәренең «Юнеско» тарафыннан сакланырга тиешле әһәмиятле истәлекләр исемлегенә кертелүе дә күп нәрсә турында сөйли.

*Этнография* [< грек. *этнос* ’халык’, *графо* язу] — халыкларның матди һәм рухи культурасын, аларның мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган фән; нинди дә булса халыкның, урынчылыкның тормышкөнкүреше, әхлакый, мәдәни үзенчәлекләре җыелмасы. Этнография башка фәннәр — археология, антропология, география, тарих, тел белеме белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Этнографиядә һәм аның белән бәйле булган башка фәннәрдә дә *культура* [<лат. *cultura*] термины киң кулланыла: матди культура, рухи культура. Хезмәтләре, китаплары белән халыкка киң танылган этнографлардан Н.И. Воробьев, Р.Г. Мөхәммәтова, Р.К. Уразманова, Д.М. Исхаков, С.В. Суслова, Й.Г. Мөхәммәтшин, Ф.Ш. Сафина һ.б. эшчәнлеге дә Институт тарихы белән тыгыз бәйләнештә алып барылган.

*Фольклор* [<англ. *folk — lore*; *folk* — халык, *lore — белем, акыл*] — халык авыз иҗаты — җырлары, әкиятләре, гореф-гадәтләре һ.б. җыелмасы. Фәнни экспедицияләр ярдәмендә татар авылларында халыкның сурәтле сүз байлыгын җыйнау эше фольклор өлкәсендәге эшчәнлекнең бик тә әһәмиятле бер тармагын тәшкил итә. Әгәр үз заманында Каюм Насыйри, Василий Радлов, Хуҗа Бәдигый, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Илбарис Надиров, Флора Әхмәтова, Хәлидә Гатина, Рәшит Ягъфәров, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Фатих Урманче, Ленар Җамалетдинов кебек мәшһүр галимнәребез һәм язучыларыбыз халык иҗат иткән әсәрләрне халык авызыннан үз куллары белән язып алып, китаплар рәвешендә бастырып калдырмаган булсалар, фольклористика дигән фәнебез шактый ярлы булып күренер иде. Бәхетебезгә күрә, татар халкының әле генә искә алынган шәхесләре һәм бу өлкәдә элегрәк эшләп киткән, шулай ук бүгенге көндә эш алып баручы Айсылу Садыйкова, Илсөяр Закирова, Илмир Ямалтдинов, Лилия Мөхәммәтҗанова кебек галимнәр тарафыннан тупланган фольклор хәзинәсе гаять бай.

Татар фольклористикасы фәненең тамырлары бик ерактан килә. X һәм

XII йөзләрдә Борынгы Болгарда Әхмәд бине Фазлан (X йөз) белән әл-Гарнати (1080—1169), XIII йөздә Европа сәяхәтче-галиме Рубрук (1215 яки 1220 еллар тирәсе — 1293), XVI—XVIII йөзләрдә шулай ук Көнбатыш Европа һәм рус галимнәре татар халкының тормышы, гореф-гадәтләре һәм йолалары, әкиятләре, бәетләре, җырлары, мәкаль, әйтемнәре һәм табышмаклары буенча бай конкрет материаллар туплыйлар. Шулар арасында академик В.В. Радловның (1837—1918) себер татарлары фольклорына багышланган зур күләмле томнарын, венгр галимнәре Габор Балинтның (1844—1913) керәшен татарлары иҗаты әсәрләрен туплаган саллы китабын, фин галиме Хейкки Паасонен (1865—1919) җыентыкларын күрсәтеп китәргә мөмкин.

Татар фольклористикасының фән буларак оешуы бөек мәгърифәтче, энциклопедист-галим Каюм Насыйри (1825—1902) эшчәнлеге белән бәйләнгән. XX гасыр башына татар фольклор фәне шактый бай тәҗрибә туплаган, гуманитар фәннәрнең тулысынча формалашкан бик тә мөһим бер юнәлеше буларак килеп җитә. Табигый, бу фәннең алга таба үсешендә бөек әдипләр Габдулла Тукай (1886—1913), Галимҗан Ибраһимов (1887—1938), Фатих Әмирхан (1886—1926), шул чорларда ук киң танылган галимнәр: әдәбиятчы һәм фольклорчы-теоретик Гали Рәхим (1892—1943), Хуҗа Бәдигый (1887—1940), Фазыл Туйкин (1887—1938) һәм соңыннан олы галим, шагыйрь, драматург буларак танылган Нәкый Исәнбәтләр (1899—1992) зур роль уйныйлар.

Татар халык иҗаты бүлегенең тарихын тәфсилләп күзәткәндә, бик тә үзенчәлекле фактка тап буласың: 51 ел, ягъни ярты гасыр буена, бу бүлекне нибары ике кеше — ике зур галим җитәкләгән: 1939—1972 елларда — Хәмит Ярми; 1972—1990 елларда — Илбарис Надиров.

Фольклористика фәнендәге күпьяклы эшчәнлекнең матур үрнәген без Хәмит Ярми мисалында күрә алабыз. Институт төзелгән 1939 елдан башлап 1973 елга кадәр ул халык авыз иҗаты бүлегенең мөдире һәм өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли, 30 дан артык фольклор экспедицияләренә җитәкчелек итә, хезмәттәшләре һәм шәкертләре белән бергә Россиянең төрле республикаларында һәм өлкәләрендә сибелеп утырган 500 ләп татар авылында була. Хәмит Ярми оештырган экспедицияләрнең географиясе бик киң, ул татар халкының төрле этник төркемнәрен фронталь төстә өйрәнүне максат итеп куя. Татарстан һәм күрше өлкә-республикалардагы татар авылларын тулысынча йөреп чыкканнан соң, Хәмит Ярми, хезмәттәшләренең игътибарын Татарстаннан ераграк төбәкләрдә яшәүче татарлар иҗатын өйрәнүгә юнәлтә. Галимнең бу инициативасы әйтеп бетергесез мөһим һәм перспективалы булып чыга. Чөнки татар халкының дүрттән өч өлеше, мәгълүм булганча, Татарстаннан читтә яши. Академик В.В. Радловтан соң бер гасыр вакыт узгач, татар фольклорчылары алдында халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен бөтенләй диярлек күтәрелмәгән, бик тә уңдырышлы «чирәм җирләр» ачыла. Күп санлы экспедицияләр нәтиҗәсендә фольклорчыларның татар халык иҗаты, аның байлыгы, жанр төрләре турындагы карашлары да үзгәрешләр кичерә: татар халык эпосы, бәетләр, туй йоласы җырлары (себер татарлары, керәшеннәр, мишәрләр), тарихи җырлар кебек фундаменталь фольклор әсәрләре җыелып, әлеге проблемаларны яңа фәнни югарылыкка күтәрү мөмкинлеге туа.

Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлегендә халык сәнгатенең

төрле тармакларына һәм традицион һөнәрчелеккә караган фәннитикшеренү эшләре алып барыла. Бүлекнең җитәкчесе Рауза Рифкат кызы Солтанова үзе һәм фәнни хезмәткәрләр халык белән аралашып, экспедицияләргә чыгып материал туплануның әһәмиятен аңлап эш итәләр. Бу бүлек хезмәткәрләре катнашкан экспедицияләрнең географиясе Татарстан белән генә чикләнми, чит төбәкләр, шулай ук чит илләр белән дә фәнни багланышлар, сәяхәтләр өстәлеп тора. Мәсәлән, 2009 елда Р.Р. Солтанова киез сәнгатен өйрәнү өчен Казакъстанга бара, андагы музейларда була һәм шәхси коллекцияләрне өйрәнә. Аспирант Илтубаева Лариса Татарстанның мари авылларындагы сәнгать үзенчәлекләрен, Түбән Новгород һәм Кукмара төбәге татарларының сәнгать һәм архитектура үзенчәлекләрен, бүлек хезмәткәре Людмила Михайловна Шкляева Казандагы Иске татар бистәсен, Яңа бистәне һәм Бишбалта бистәләрен, сәнгать һәм архитектура истәлекләрен өйрәнә, Апас, Кукмара районнарына, Удмуртиянең татарлар яши торган төбәкләренә оештырылган фәнни сәяхәтләрдә катнаша. 2014 елда Самара өлкәсенә оештырылган экспедициядә фәннәр докторы Рөстәм Зәки улы Мөхәммәтшин тырышлыгы белән архитектура һәм сәнгать үзенчәлекләрен чагылдырган бик күп фотолар туплана. Бүлек аспиранты Илүсә Фәррәхова Удмуртиягә (2012 ел), Мамадышка (2013) оештырылган экспедицияләрдә катнаша, Әстерхан өлкәсенә (2013 ел) Исимбитьева Айгөл, Омск өлкәсенә (2014) Хисамова Рәзилә фәнни сәяхәтләргә чыгалар.

*Археографик* [<*архайос* борынгы', уraphike' язу] экспедицияләр вакытында халыкта сакланган борынгы китаплар, кулъязмалар тупланып бара, әлеге кыйммәтле табылдыклар Институтның Кулъязмалар һәм музыкаль мирас үзәгендә фәнни архив фондын тәшкил итә. Бу бүлекне 2009 елга кадәр күренекле галим-археограф М.И. Әхмәтҗанов, соңрак Р.Ф. Исламов җитәклиләр.

Әлеге бүлек фондында татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә язылган, халыктан тупланган күп санлы борынгы китаплар, кулъязмалар, фәнни экспедиция материаллары, фотокопияләр, язучылар һәм сәнгать белгечләренең шәхси архивлары саклана.

*Эпиграфика* [др. греч. *epigraphe; graphike*]. Борынгы кабер ташлары буенча безнең Институтның башлангыч чорларыннан ук эшләп, зур хезмәтләр һәм олы фәнни мирас калдырган Һ.В. Йосыпов фонды да шушы Үзәктә саклана.

Кулъязма китаплар фондында Әхмәт Ясәви (XII), Сөләйман Бакыргани (XII), Кол Галинең «Кысса-и Йосыф» (XIII), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә Солтан» (XIV), Мәхмүт Болгариның «Нәһҗел фәрадис» (XIV), Мөхәммәдьярның «Нуры содур» һәм «Төхфәи Мәрдан» (XVI), Саядиның (XVII) «Бабахан дастаны», Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә (XVIII), Өмми Камал (XV) Мифтахетдин Акмулла (XIX) Мәүлә Колый (XVII), Габдрахим Утыз Имәни (XVIII) язмалары һәм дастаннар саклана.

Мирасханә фонды ел саен үткәрелә торган археографик экспедиция материаллары белән байый бара. Алар белән Россиянең төрле шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килгән күп галимнәр кызыксына, үзләренә кирәкле мәгълүматларны табалар.

*Диалектология һәм лексикология* бүлегендә татарлар яши торган барлык регионнар буенча тел материаллары туплау һәм фәнни эшкәртү эшләре алып барыла. Бу бүлектә диалектология, тарихи грамматика, фонетика, лексикология, этнолингвистика һ.б. проблемалар буенча фәнни

эшләр башкарыла, күп санлы фәнни сәяхәтләр, экспедицияләр оештырыла.

*Диалект* [<гр**.** *dialektos*] — телнең җирле формасы, гомумхалык теленнән аермалы булган бер төркем сөйләшләрне берләштерә.

*Диалектология* — тел фәненең диалектларны өйрәнә торган тармагы. Диалектология мәсьәләләрен өйрәнүнең башлангыч чорлары В.В. Радлов, А.Г. Бессонов, Г.Н. Ахмаров, С.Е. Малов, Н.Д. Катанов, Җ.Җ. Вәлиди, Л.Җ. Җәләй исемнәре белән бәйле.

Октябрь инкыйлабыннан соң татар диалектологиясе белән күренекле тел галиме Җамал Вәлиди шөгыльләнә һәм бу өлкәдә шактый күп эшләр башкара. Аннан эстафетаны Латыйф ага Җәләй ала һәм шуннан башлап татар диалектлары эзлекле рәвештә, бөтен киңлеге һәм тирәнлеге белән өйрәнелә башлый. Турыдан-туры Латыйф ага Җәләй катнашлыгында һәм җитәкчелегендә татарлар яшәгән Идел буе һәм Урал төбәкләренә җирле сөйләшләрне өйрәнү-тикшерену өчен бик күп экспедицияләр оештырыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1947 елда галимнең «Татар диалектологиясе» дигән монографиясе басылып чыга. Галим бу хезмәтендә татар диалектларының өйрәнелү тарихын, аларның классификациясен һәм диалектларның төп үзенчәлекләрен ача.

1956 елда «Татар теле белеме алдында торган бурычлар» исемле мәкаләсендә Латыйф ага Җәләй татар теленең диалектологик атласын, тулы диалектологик сүзлеген һәм татар теленең аңлатмалы сүзлекләрен, татар теле белеме буенча тулы библиография төзүнең кирәклеген, бу проблемаларның көн тәртибенә басканлыкларын күрсәтеп чыга. Әйтергә кирәк, Латыйф ага Җәләй инциативасы белән башланган бу зур эшләр күп еллар буе тел бүлегенең һәм диалектология төркеменең җитәкчесе булган Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова, Латыйф аганың яраткан шәкерте булган Наҗия апа Борһанова һәм инде аларның да шәкертләре булган бер төркем диалектологлар тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә. Татар диалектологлары, төрки халыклардан беренче буларак, «Татар теленең диалектологик атласы» өчен материал туплый башлыйлар. Атлас өчен программа-сораулыкны Н.Б. Борһанова төзи, ике дистә ел эчендә йөзләгән экспедицияләр оештырыла, бик күп диалектологлар үсеп чыга: Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Ф.Й. Йосыпов — фән докторлары, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова фән кандидатлары исеменә лаек булалар. Диалектология фәнендә озак еллар экспедицияләрдә йөреп кенә уңышларга ирешергә мөмкин: мин үзем — 1960 елдан, студент чакларымнан, Д.Б. Рамазанова 1964 елдан — аспирант чакларыннан ук фәнни сәяхәтләрдә актив катнаша башладык.

1961—1986 елларда тел бүлеген җитәкләгән Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова — мишәр диалекты буенча язылган фәнни монография авторы (аның төп фәнни-тикшеренү эшләре диалектология белән бәйле). Ул үзе һәм аның җитәкчелегендәге диалектологлар Пенза, Самара, Саратов, Киров өлкәләренә, Мордовия, Удмуртия, Башкортстан, Оренбург һ.б. төбәкләргә фәнни сәяхәтләргә чыгып, «Диалектологик атлас» өчен материаллар туплыйлар. Атласның ике томы 1989 елда дөнья күрә, 2008 елда көнчыгыш диалекты (Себер регионы) һәм Түбән Иделне (Әстерхан, Волгоград) эченә алган өченче том төзелеп бетә.

Фәнни экспедицияләрдә йөреп тупланган һәм системага салынган материаллар зур фәнни хезмәтләр булып дөньяга чыга тордылар. 2008 елда «Татар халык сөйләшләре» дигән ике томлык зур хезмәт, 2009 елда «Татар теленең зур диалектологик

сүзлеге» (төзүчеләр: Ф.С. Баязитова, Д.Б.Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова) дөнья күрде.

*Лексикология* [< гр.*lexsikos* <*lexis сүз, сүзтезмә; logos сүзләр турындагы фән*] — тел белеменең лексиканы, сүзлек байлыгын өйрәнә торган тармагы. Диалектолог-лексикологлар тарафыннан лексиканың төрле тематик, лексик-семантик төркемнәре: ашсу, кием-салым, йорт-җир, хуҗалык-көнкүреш, табигать күренешләре, үсемлекләр һ.б. фәнни өйрәнелеп, монографияләр һәм диссертацияләр буларак фәнни әйләнешкә кертелә торалар. Лексикологиянең үзенчәлекле тармагына караган халык йолалары лексикасын: туй, бала туу, соңгы туй (җеназа), шулай ук бәйрәмнәр, ел фасыллары, борынгы ышанулар һ.б. тел, фольклор, этнография синтезында карап реконструкцияләү, торгызу буенча да күп хезмәтләр языла. Экспедицияләргә чыгып халыктан тупланган диалектологик, этнолингвистик мәгълүматлар лексикологик хезмәтләрнең иң төп казанышы, уңышы булып санала.

*Ономастика* [гр. *onoma* ’исем’] — ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган фән. Ономастика фәне ике тармакка бүленә: **топонимика** һәм **антропонимика**. Фәнни терминологиянең эчтәлегенә игътибар итик.

*Топонимика* [< гр. *topos* ’урын’, *onoma* ’исем*’* ] — лингвистиканың топонимнарны өйрәнә торган тармагы. *Топоним* — нинди дә булса төбәк, урын атамалары. Антропоним — кеше исемнәре, фамилияләр һәм кушаматлар. *Микротопонимия* — шунда яшәүче җирле халыкка гына билгеле булган авыл яки шәһәр, шулар тирәсендәге халыкка гына билгеле булган объектларның атамалары; метафорик атамалар. Гидроним [<гр. hydör ’су’] — су чыганаклары: елгалар, күлләр, чишмәләр, диңгезләр һ.б. атамалар. Топонимика буенча халыктан туплап, китаплар, сүзлекләр итеп чыгаруда галимә Фирдәвес Гарипова фәндә киң танылу яулады. Антропонимика тармагын хәзер яшь галимә Гүзәлия Хаҗиева-Демирбаш алып бара.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Институтта гуманитар фәннәрнең төрле тармакларына караган экспедицияләр даими рәвештә оештырылып торган. 2009 елдан Институт директоры К.М. Миңнуллин инициативасы белән экспедицияләр тарихында яңа этап башланып китте. Глобальләшү чорында халкыбызның тел байлыгы һәм рухи культурасы, милли үзенчәлекләре зур тизлек белән югала баруны истә тотып, теге яки бу төбәкне, районны тирәнрәк өйрәнү өчен күп галимнәр, аспирантлар катнашында ел саен комплекслы экспедицияләр уздырыла башлады. Бу экспедицияләрдә фольклор һәм музыка белгечләре, тел галимнәре, диалектологлар, археографлар, сәнгатьчеләр, фотографлар һ.б. халык белән якыннан аралашып, сөйләшеп фәнни мәгълүматлар туплыйлар. Үзенең туган ягы, авылы яки районына караган мәгълүматлар шул якларда яшәүчеләр өчен дә кызыклы һәм бик кирәкле булуны истә тотып, бөртекләп җыйналган рухи җәүһәрләребезне китаплар итеп чыгарып, халыкка кайтарып бирү бурычы да куела. Мәсәлән, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән», сериясе белән түбәндәге китаплар дөнья күрде:

Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Беренче китап). Казан, 2010.

— Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Икенче китап). Казан, 2011

Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Өченче китап). Казан, 2011.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Дүртенче китап). Казан, 2012.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Бишенче китап). Казан, 2013.

Татарстанның Чүпрәле, Кукмара, Мамадыш төбәкләренә, шулай ук Әстерхан, Омск, Самара өлкәләренә, Пермь краена оештырылган комплекслы экспедиция материаллары да китаплар итеп халыкка кайтарылу алдында торалар.

***Баязитова Флера Сәет кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының лексикология*
*һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 78:79

*М.Г. Арсланов*

# РУХИ БАЙЛЫК САГЫНДА

В статье рассматриваются вопросы становления и развития татарского искусствознания посредством анализа деятельности сектора, затем отдела искусствоведения ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** татарское искусствоведение, отдел искусствоведения ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, отдел театра и музыки ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова.

Татар халкының меңнәрчә еллык сәнгате, мәдәнияте бар. Бу искиткеч зур байлыкны өйрәнү бик борынгы заманнардан ук башланган. Әйтик, сакланып калган урта гасыр әдәбияты һәйкәлләренең иң элгәреләреннән булган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, соңгырак чорларга караган Сәиф Сараи, Котби, Мөхәммәдьяр әсәрләрендә, XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри хезмәтләрендә ул чорлардагы сәнгать әсәрләре, аларның халык тормышындагы урыны турында җитди күзәтүләр табарга була. Сәнгать әсәрләре турында системалы фикер йөртү, даими эзләнүләр XX йөз башында аеруча алга китә һәм бу хәл сәнгатьне өйрәнә торган фәннәр туугa җирлек әзерли.

Гомумән алганда, сәнгать фәннәре төп өч компоненттан формалаша: оператив тәнкыйть, сәнгать тарихы һәм теория. Шушылар арасыннан иң элек тәнкыйди фикерләү дөньяга килә. Әйтик, татар театрының туган вакытын 1906 ел дип билгеләсәк, театр тәнкыйте дә шул ук елны мәйданга чыга. Шул чордан татарның беренче театр тәнкыйтьчеләре Габдрахман Кәрам, Гыймад Нугайбәк, Заһид Нуркин, Ибраһим Биккулов — Казанда, Кәбир Бәкер — Ырынбурда, Сәгыйть Рәмиев — Әстерханда, Самат Шәрәфетдинов Уфада үзләренең тәнкыйди-иҗтимагый эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. Аларның көндәлек матбугат битләрендә урын алган мәкаләләрендә бу сәнгать төренең аерым әсәрләре, узган театраль сезон йомгаклары нәтиҗәләре чагылыш таба. 20 нче елларда татар театрының 20 еллыгы белән бәйле рәвештә, бу төр сәнгатьнең тарихы, үсеш тенденцияләре, проблемалары, узган юлы турында шактый төпле, фактик материалга бай булган В.Мортазин-Иманский һәм Т.Ченәкәй язган «Татар театры тарихыннан» һәм коллектив авторлар тарафыннан төзелгән «Татар театры (1906—1926)» китаплары басылып чыга. Әлеге хезмәтләр безнең театр фәненең нигез ташлары, беренче нәтиҗәләре булып саналырга хаклы. Әмма аннан соңгы елларда М.Мәһдиевның «Уен һәм сүз техникасы», «Театр эше», «Театр», Г.Айдарскийның «Театр сәнгате» исемле гомуми театр сәнгате теориясен пропагандалаучы китаплары басылып чыкса да, татар театр фәне алга таба зур үсеш ала алмый. 40 нчы еллар башында З.Солтанов, К.Шамил, Н.Исәнбәт, Г.Кутуй кебек әдәбият һәм сәнгать әһелләре татар театры тарихын язарга омтылыш ясап карыйлар, тик башлаган эш ахырга кадәр барып җитми. 1950—1960 елларда Р.Усманова, Х.Гобәйдуллин, Х.Кумысников язган кандидатлык

диссертацияләре театр сәнгате турындагы фәннең алга таба үсеш баскычы була.

Бүгенге көндә Татарстанда шактый гына алга киткән музыка, рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгать фәннәрендә дә шундый ук үсеш юлы күзәтелә. Октябрь инкыйлабына кадәр һәм аннан соңгы елларда музыкаль фольклористика өлкәсендә Гайса Еникеев, Гата Исхакый, Гыйлаҗ Сәйфуллин, Солтан Габәши, сынлы, гамәли сәнгать буенча П.Дульский, А.Девишев, Л.Поздеева хезмәтләре билгеле булса да, бу төр сәнгать фәннәре бары тик 60 нчы елларда гына ныклап гамәлгә куела.

1968 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында сәнгать секторы оешу Татарстан сәнгать фәне үсешендә әйтеп бетергесез зур һәм мөһим адым булып тора. Шушы чордан башлап татар халкының сәнгате Республикада системалы, планлы рәвештә өйрәнелә башлый. Сәнгать секторының җитәкчесе итеп әдәбият һәм театр белгече, филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт билгеләнә.

**Гыйззәтуллин Фәтхелбәян Нурлыгаян улы** (16.07.1918, Башкортстанның Кушнаренко р-ны, Талбазы ав. — 25.05.1991, Казан), әдәбият галиме, театр тәнкыйтьчесе, филология фәннәре кандидиты (1951), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1989). Институтта 1949—1983 елларда эшли. Бөек Ватан сугышы ветераны. 1934 елда авыл мәктәбенең алтынчы сыйныфын тәмамлаганнан соң, Уфага барып, медицина рабфагына укырга керә. Әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт аны Казан дәүләт педагогика институтына алып килә. 1941 елда укуын уңышлы тәмамлагач, аны аспирантурада калдыралар. 1941 елның декабрендә Бәян Гыйззәт Ватанны саклаучылар сафына баса. Ул сугышта яралана, госпитальдә дәваланып чыккач, хәрби училищега укырга җибәрелә. Аннан — янә фронтка. Фронттагы батырлыклары өчен Б.Гыйззәт ике мәртәбә Кызыл Йолдыз ордены һәм берничә медаль белән бүләкләнә. 1945 елда армиядән кайткач, Б.Гыйззәт Татар дәүләт академия театрына әдәби бүлек мөдире булып эшкә керә. Шул ук елларда ул СССР Фәннәр академиясенең Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасында да укый һәм 1951 елда «Гафур Коләхмәтовның иҗаты» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1953—1983 елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1968—1981 елларда сәнгать секторы мөдире) эшли. Әдәби-фәнни эшчәнлеге тулысынча диярлек татар драматургиясе һәм татар театр сәнгате белән бәйле. Аның бу өлкәдәге тикшеренүләре «Егерменче йөз башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960), «Заман сулышын тоеп» (1967), «Татар совет театры» (1975), Мәскәүдә рус телендә чыккан «История татарской советской литературы» (1965), «История многонациональной советской литературы» (1972) исемле китапларда урын алган. Тажи Гыйззәт иҗатын яктырткан монографиясе 1957 елда аерым китап булып басылып чыга. Мәскәүдә Сәнгатьләр тарихы институтында әзерләнгән «История советского драматического театра» исемле алты томлык коллектив хезмәттә ул, авторларның берсе һәм редколлегия әгъзасы буларак, татар театрының үсеш этапларын яктырткан фәнни очерклары белән катнаша. Болардан тыш, Б.Гыйззәтнең драматургия һәм театр сәнгате турындагы мәкалә һәм очерклары төрле җыентыкларда, әдәбият һәм театрга бәйле белешмә-энциклопедияләрдә, көндәлек матбугат битләрендә күпләп басылган. Г. Камал, Г. Коләхмәтов,

Г. Кариев, К. Тинчурин, М. Фәйзи, Х. Әбҗәлилов, Г. Кутуй, Һ. Такташ, Г.Насрый һ.б. бик күпләргә багышланган иҗади портретлар, аерым әсәр яки спектакльләр турында рецензияләр, сәнгатьнең актуаль мәсьәләләрен күтәргән тәнкыйть мәкаләләре — болар һәммәсе Бәян Гыйззәтнең, галим һәм тәнкыйтьче буларак, иҗат активлыгын, диапазонын дәлилләр.

Б.Гыйззәт җитәкчелегендә сектор сәнгать фәненең театр, музыка, рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгать юнәлешләре буенча җитди эш башлап җибәрә һәм бүгенге көнгә кадәр Татарстанда, Россиянең төрле өлкәләрендә, БДБ илләрендә, ерак чит илләрдә яшәгән милләттәшләребезнең сәнгатен өйрәнә.

Сәнгать бүлегендә беренчеләрдән булып эшләгән хезмәткәрләрне, алар арасындагы театр, музыка белгечләренә — республикада танылган галимнәрнең исемнәренә аерым тукталып үтәргә кирәктер.

**Гобәйдуллин Хәсән Хәйрулла улы** (28.12.1913,Уфа — 09.07.1992,Казан), театр белгече, сәнгать фәннәре кандидаты(1964), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1990).1937 елда Казан дәүләт университетының математика бүлеген тәмамлый. Мәктәптә укыта. 1940—1959 елларда Татар опера театры хоры җырчысы, Бөтенроссия театр җәмгыяте хезмәткәре, музыка мәктәбе директоры. 1959—1977 елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече, өлкән фәнни хезмәткәр. Татар театр сәнгатенең Октябрьга кадәрге өлешен өйрәнә. Гомумән алганда, киң җәмәгатьчелеккә Х.Гобәйдуллин татар театрының Октябрьга кадәрге чорын өйрәнүче җитди галим, шул чорга караган бай материал җыйган актив эзтабар, Г.Кариев, Ш.Шамилский, С.Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр туплаган һәм китап итеп бастырып чыгарган автор буларак мәгълүм.

**Илялова Ильтани Исхак кызы** (08.02.1932, Екатеринбург ш.), театр белгече, сәнгать фәннәре кандидаты (1965), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1983,2000). 1950 елда Ташкент театр сәнгате институтына укырга керә. 1958—1961 елларда И.Илялова Мәскәүдә Театр сәнгате институтының (ГИТИС) чит илләр театры кафедрасы каршындагы аспирантурада укый. 1963 елда И.Илялова Казанга күчеп килә һәм СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече фәнни хезмәткәр, 1964—1968 елларда Татарстан Мәдәният министрлыгында сәнгать бүлеге җитәкчесе булып эшли. 1965 елда ул «Хәмзә исемендәге Үзбәк театры сәхнәсендә чит илләр драматургиясе (1918—1962)» дигән темага диссертация яклый һәм сәнгать фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1968 елдан 1989 елга кадәр Илялова, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының хезмәткәре буларак, татар театр сәнгатенең тарихына, бүгенге хәленә бәйле проблемаларны тикшерә. СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров иҗаты турындагы очеркын («Труд актера» җыентыгы, Мәскәү, 1974) һәм «Бүгенге татар театрында актерлык осталыгы» (1978) исемле хезмәтен бастыра. Институтта эшләү чорында авторның «Бөек Ватан сугышы чорында Татар дәүләт академия театры», «Хәзерге Татар дәүләт академия театры» исемле хезмәтләре «Татар совет театры» китабында (Казан, 1975) дөнья күрә. «Халык артистлары» («Народные артисты», Казан, 1980) дигән җыентыкны әзерләүдә катнаша. Биредә аның аерым шәхесләргә багышланган мәкаләләре дә урын ала.

**Мәхмүтов Һәнүз Котдус улы (**15.07.1933, Башкортстанның Янавыл р-ны, Таш-елга ав. — 17.12.1996,

Казан), әдәбият һәм театр белгече. Өч дистә ярым елга сузылган катлаулы иҗат эшчәнлеге дәверендә Һ.Мәхмүтов театр сәнгатен өйрәнү өлкәсендә шактый тирән эз калдыра алды. Ул язган күп санлы фәнни мәкалә, рецензия, иҗат портретлары, библиографик белешмәләр әле бүген дә үз кыйммәтләрен югалтмый. Казан дәүләт университетының чыгарылыш курсы студенты Һ.Мәхмүтов «Татар драматургиясендә трагедия жанры» дигән темага диплом эше яза. 1965 елда ул аерым китап булып басылып та чыга. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында 1966—1996 елларда эшли. Анда аспирантурада укыганда Әстерхан татар дәүләт драма театры турында хезмәт яза. Ул, соңрак, «Мирас» журналында тулысы белән басыла. Аның катнашында чыгарылган «Татар совет театры» (Казан, 1975), «Татар сәхнәсе әдәбият күрсәткече (1917—1967) (Казан, 1979), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (Казан, 1988) китаплары әле бүген дә әһәмиятләрен югалтмыйлар. Һ. Мәхмүтов классик әдибебез Гаяз Исхакый иҗатын халкыбызга кире кайтару өлкәсендә дә актив эшләде.

**Гыйммранова Дания Әхәт кызы** (23.10.1937, Казан — 27.10.2014, Казан), театр белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1997). 1962 елда А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтын (ГИТИС) тәмамлый, Б.Алперс, С.Ростоцкий кебек танылган театр белгечләре җитәкчелегендә белем ала. 1964 елдан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институтында фәнни хезмәткәр булып эшли башлый. Минзәлә, Әлмәт, Чаллы, Республика күчмә театрлары буенча хезмәтләр яза. Аның тарафыннан язылган һәм китап булып дөнья күргән «Гөлсем Болгарская», «Габдулла Шамуков» кебек күләмле монографияләр Дания Гыйммранованың татар театрының күренекле шәхесләре галереясен булдыру өлкәсендә зур өлеше булдылар.

Болардан тыш Д.Гыймранова Институтта сәнгать секторы чыгарган «Татар совет театры» китабы өчен «Мәскәү эшче һәм Республика дәүләт күчмә театрлары» бүлеген яза. «Сугыштан соңгы татар режиссура сәнгате», «Октябрьгә кадәрге татар театры актерлык осталыгы мәктәбе», «Татар театр энциклопедиясе» кебек темалар өстендә эшли. Авторның иң соңгы китабы «Минзәлә татар дәүләт драма театры» дип атала. Ул 2007 елда басылып чыкты. Дания Гыймранованың Татарстан Республикасы театрларының көндәлек эшчәнлегенә багышланган күпсанлы мәкаләләре, рецензия, иҗат портретлары татар театры һәм мәдәниятебез тарихын өйрәнүдә сизелерлек өлеш булдылар.

Сәнгать бүлегенең беренче буын театр белгечләре эшен алга таба Г.Арсланов, А.Салихова, А.Садирова, Д.Фәрдиева кебек фәнни хезмәткәрләр дәвам итте һәм итә.

**Арсланов Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы** (6.10.1947, Актаныш районы, Түмерҗә ав.), театр белгече, сәнгать фәннәре докторы (1993), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1997), Халыкара Төрки Академия академигы (1997), Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (2007). 1975 елдан ТР ФА Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1997 елдан Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) аспирант, кече, өлкән, әйдәп баручы, баш фәнни хезмәткәр. 1984 елда — кандидатлык, 1993 елда докторлык диссертацияләрен яклый. 1993 елдан — сәнгать, 2007 елдан театр һәм музыка бүлеге мөдире. Милли театр сәнгатенең төрле өлкәләрен — актерлык осталыгы, драматургия, сценография, режиссура проблемала-

рын өйрәнә, татар сәхнәсенең үткәне, бүгенге көне, киләчәгенә багышланган 400 гә якын фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Алар арасында бигрәк тә «Хөсәен Уразиков» (Казан, 1986), «Татар режиссура сәнгате (1906—1941)» (1992), «Татар режиссура сәнгате (1941 — 1956)» (1997), «Татар режиссура сәнгате (1957—1990)» (2002), «Режиссер Ширияздан Сарымсаков» (2004), «Режиссер. Актер. Драматург. Педагог» (2006) «Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар» (2008), кебек зур күләмле монографияләр, «Галиәсгар Камал: әдип һәм заман» (2005), «XX гасыр мәдәнияте һәм татар театры: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары» (2007), «Габдулла Кариев: тарихи-документаль җыентык» (2011) кебек татар театрының күренекле шәхесләренә (Г. Кариев, Г.Камал, В. Мортазин-Иманский, М. Мутин, К. Тинчурин, Г. Исмәгыйлев, Г. Девишевка һ.б.га) багышланган күләмле китаплары, мәкаләләре зур ачыш буларак кабул ителделәр. Киңрәк алганда, галимнең эзләнү-тикшеренү өлкәләре булып татар халкының рухи мәдәнияте, милли сәнгатебез тарихы һәм аның теоретик нигезләре, театр сәнгате проблемалары тора. Аның хезмәтләреннән сәнгать, әдәбият белгечләре генә түгел, тарихчылар, мәдәният хезмәткәрләре дә файдалана. Шулай ук алар югары театраль уку йортларында театр тарихы (татар театры) укытканда, халык театрлары, драма коллективлары һәм студияләр эшендә дә кулланыла.

**Салихова Айгөл Рөстәм кызы** (Айгөл Габәши) (19.10.1968, Казан), әдәбият, театр белгече, филология фәннәре кандидаты (1999). 1993 елда КДУның филология факультетын, соңрак Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантураны тәмамлый. «Татарский театр в литературно-критическом наследии Габдрахмана Карама» китабы (2003) һәм татар театрының тарихына, бүгенге көненә багышланган күпсанлы мәкаләләр, рецензияләр авторы. Театр һәм музыка бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. «Татар театры энциклопедиясе», «Татар театры елъязмасы» хезмәтләренең аерым бүлекләрен язды, татар театр сәнгатендә жанрлар һәм стильләр проблемасына караган монография тәмамлады.

**Фәрдиева Динара Радий кызы** (10.03.1984, Казан), әдәбият, театр белгече, филология фәннәре кандидаты (2010). 2006 елда КДУның филология факультетын, соңрак Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы аспирантураны тәмамлый. «Г.Камал исемендәге театрда милли прозаның куелышы» дигән темага диссертация яклый. 2014 елда хезмәт аерым китап булып басыла. «Татар театры елъязмасы» хезмәтенең аерым бүлеген язды.

**Сәйдәшева Земфира Нурмөхәммәт кызы** (20.05.1938. Казан), музыка белгече, педагог, сәнгать фәннәре докторы (1998), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе(1989), профессор (2000), Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең Композиторлар берлеге әгъзасы. Институтта 1970—76 елларда эшли. Өйрәнү өлкәсе — татар халкының җыр культурасы, милли музыканың тел һәм язма традицияләре. «Татарско-мишарские песни. Из коллекции фольклориста». (в соавт.), (1979) «Татарская советская песня» (1984), «В мире татарской музыки» (1995), «Современные татарские бытовые песни» (1997) һ.б. китаплар авторы. Татар халкының музыкаль культурасын Институт кысаларында өйрәнүне беренчеләрдән булып башлап җибәрүчеләрнең берсе.

**Нигъмәтҗанов Мәхмүт Нигъмәтҗанович** (10 .05. 1930, Татарстанның Саба р-ны З.Арташ ав.), музыка белгече, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979), сәнгать

фәннәре кандидаты (1973), профессор (1990), ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1985). Институтта 1960—1967, 1974—1984 елларда эшли. Күп санлы экспедицияләрдә катнашып, Идел буе, Урал алды, Төмән өлкәсе татарларының дүрт меңгә якын җырын һәм инструменталь әсәрләренең ноталарын язып алган фольклорист-эзләнүче. «Татарская народная песня в обработке композиторов» (1964), «Начальные уроки игры на аккордеоне» (1966), «Татарские народные песни» (1970), «Музыкальный Татарстан» (1970), «Татарские народные песни» (1976) китапларының авторы, төзүчесе.

Өлкән музыка белгечләреннән эстафетаны сәнгать фәннәре кандидатлары А.Алмазова, Н.Әлмиева, Г.Гобәйдуллина, Г.Сәйфуллина, Г.Макаров, Э.Каюмова, Э.Галимовалар кабул итеп алалар. Ә архитектура һәм гамәли сәнгать белгече, сәнгать фәннәре докторы Ф.Вәлиев башлаган эшне сәнгать фәннәре кандидатлары Д. Вәлиева, Г. Вәлиева-Сөләйманова, Р.Шәмсутов кебек киң эрудицияле, тырыш сәнгатькәрләр рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгатьне өйрәнү өлкәсендә дәвам итәләр.

Сәнгать бүлегенең биш дистәгә якын елга сузылган эшчәнлеге нәтиҗәсе зур-зур монографияләрдә, газета-журнал, төрле җыентыкларда басылган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләрдә, иҗат портретларында, рецензияләрдә, докладларда чагылыш тапты. Алар арасында күмәкләшеп язылган «Татар совет театры» (Казан, 1975), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (Казан, 1988), И.Илялованың «Хәзерге татар театрының актерлык сәнгате» (Казан, 1978), «Татар театрының милләтара элемтәләре» (Казан, 1980), Д.Гыймрановaның «Гөлсем Болгарская» (Казан, 1976), «Габдулла Шамуков» (Казан, 1985), «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры», М.Арслановның «Хөсәен Уразиков» (Казан, 1986), «Татар режиссерлык сәнгате (1906—1941)» (Казан, 1992), «Татар режиссерлык сәнгате (1941—1956)» (Казан, 1997), «Татар режиссерлык сәнгате (1957—1990)» (Казан, 2002), М.Нигъмәтҗановның «Татар халык җырлары» (Мәскәү, 1970; Казан, 1984), «Идел татарларының халык җырлары» (Мәскәү, 1982), З.Сәйдәшева һәм Х.Ярминең «Татар-мишәр җырлары» (Мәскәү, 1979), А.Алмазованың «Фәрит Яруллин һәм татар балеты» (Казан, 1987), Ф.Сәлитованың «Салих Сәйдәшевнең музыкаль драмалары» (Казан, 1988), Ф.Вәлиевнең «Урта Идел һәм Урал алдының борынгы һәм урта гасыр сәнгате» (Йошкар-Ола, 1975), Д.Вәлиеваның «Идел болгарлары сәнгате (X—XIII)» (Казан, 1983) Г.Вәлиева-Сөләймановaның «Совет Татарстанының монументаль-декоратив сәнгате» (Казан, 1984), «Татарстанның декоратив сәнгате (1920—1990 еллар башы)» (Казан, 1995), Ф.Гулованың «Татар халык чигү сәнгате» (Казан, 1980), «Татар милли аяк киеме» (Казан, 1983) кебек, киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнгән, хуплау тапкан зур хезмәтләр дә бар.

Соңгы елларда сәнгать бүлеге хезмәткәрләре «Рухи мәдәниятнең үсеш һәм кабул ителеш проблемалары» дигән гомуми тема буенча эшли. Бу зур тема өч юнәлеш буенча кечерәк проблемаларга бүленә. Театр белгечләре — «Татар театр энциклопедиясе», «Татар театры елъязмасы», музыка белгечләре «Татар музыкасы гомумтөрки традицияләр тукымасында» дигән уртак проблемалар буенча эзләнүләр алып баралар. 2007 елда рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгатьне өйрәнүче галимнәрдән аерым бүлек оештырылды һәм бүгенге көндә алар мөстәкыйль фәнни берәмлек тәшкил итәләр.

Моннан тыш, бүлек галимнәре аерым җыентыкларда, газета, журнал битләрендә фәнни мәкалә, рецензияләр, иҗат портретлары белән чыгыш ясыйлар. Татарстанда, чит илләрдә уздырылган конференцияләрдә докладлар белән катнашалар. Безнең хезмәткәрләр шулай ук татар халкының бай рухи мирасын, театр, музыка сәнгатен популярлаштыру өлкәсендә дә зур эш алып баралар, төрле аудиторияләрдә лекцияләр укыйлар, радио, телевидение аша чыгышлар ясыйлар. Боларга өстәп, тагын бүлек галимнәренең Мәдәният министрлыгы, төрле иҗат берлекләре комиссияләрендә яңа концерт программалары, спектакльләр кабул итү, музыкаль әсәрләр тыңлау, аларга бәя бирү, фикер әйтү буенча эшләүләрен дә билгеләп үтү кирәктер.

Бүлек хезмәткәрләре, соңгы вакытта финанс мәсьәләләренең катлаулы булуына да карамастан, төрле мөмкинлекләр табып, иҗат оешмалары, иганәчеләр ярдәме белән Татарстаннан читтәге авыл, шәһәрләрдә булырга, төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез белән аралашырга, архив-музейларда эшләргә, фәнни хезмәт өчен кирәк булган материаллар тупларга да вакыт табалар. Экспедиция, командировка материаллары Институтта махсус фондларда саклана. Мәсәлән, этномузыкологиягә караган материаллар гына да 6 меңгә якын берәмлек тәшкил итә.

Бүлек яшь фәнни алмаш әзерләү бабында да җитди эшчәнлек алып бара. Бүгенге көнгә бүлектә ике төр сәнгать белгечлеге буенча егермегә якын кеше белем алды, бер докторлык һәм дистәгә якын кандидатлык диссертациясе якланды. Күренекле шәхесләребезнең иҗади мирасын барлау буенча, сәнгатьнең аерым проблемаларына багышланган фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр дә киң җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына. Әйтик, Г. Кариев, К. Тинчурин, С. Габәши, Б. Урманче, С. Садыйкова, Р. Ваһапов юбилейларына тәгаенләнгән фәнни конференцияләр катнашучыларны идеологик басымнан азат фикерләр, әле фәнни әдәбиятка кермәгән өр-яңа мәгълүмат белән баеттылар. Галимнәребез шулай ук Г. Исхакый, Ш. Мәрҗани, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш кебек әдип һәм галимнәребезгә багышланган конференцияләрдә дә докладлар белән чыгыш ясадылар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, сәнгать бүлеге татар халкының сәнгатен, рухи мирасын барлау, туплау, системалаштыру һәм анализлау буенча купьяклы һәм нәтиҗәле зур эш алып бара. Бүгенге көндә дистәгә дә тулмаган хезмәткәрдән торган бүлек куйган мондый хезмәтне Казакъстан, Үзбәкстан кебек мөстәкыйль дәүләтләрдә зур фәнни-тикшеренү институтлары башкара. Киләчәктә, әлбәттә, Татарстанда да аерым Татар сәнгатен өйрәнү институты булырга тиешле.

***Арсланов Мөхәммәдгали Гыйльмегали улы,***
*сәнгать фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*театр һәм музыка бүлеге җитәкчесе*

УДК 74/76

*Р.Р. Солтанова*

# ТАСВИРЫЙ ҺӘМ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ БҮЛЕГЕ

В статье раскрывается деятельность отдела изобразительного и декоративно-прикладного искусства со дня его основания (2007). Даётся краткий обзор научных изысканий в области искусствоведения, обозначаются приоритетные направления и перспективы развития отдела.

**Ключевые слова:** искусствоведение, изобразительное, декоративно-прикладное искусство, архитектура, традиции, художественный проект.

2007 елдан мөстәкыйльлек алган тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге (бу юнәлеш сәнгать белеме бүлеге составында 1968 елдан эшли. Аның беренче җитәкчесе Ф.Х. Вәлиев була) үз эшчәнлеген комплекслы тарихи-сәнгати тикшеренүләр ысулына нигезләнгән яңа фәнни концепциягә тәңгәлләштереп, «Тарихи-мәдәни контекстларда татарларның милли-сәнгати фикерләү формалары» (2007—2012), 2013 елдан «Татарстан халкының художестволы мәдәнияте һәм сәнгате: теория һәм тарих» дигән гомум тема кысаларында алып бара. Бүлекнең киләчәккә концептуаль планы тасвирлана торган материалны фәлсәфи, эстетик идеяләр, контекстуаль-мәдәни анализ белән нигезләүне күздә тота. Төп өйрәнү предметын тарихи (Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Казан губернасы, совет чоры һәм аннан соңгы еллар), мәдәни (мөселман сәнгате, төрки дөнья, сәнгатьтә бүгенге дөнья, Россиянең Идел—Урал регионындагы этно-милли даирәдә заман традицияләре) контекстлардагы милли-сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен ачыклау тәшкил итә.

Мондый колачлылыкның максаты — сәнгати иҗатның киң күләмле (күп санлы төрләргә һәм жанрларга ия тасвирый сәнгать, декоративгамәли сәнгать, сәхнә сәнгате [сценография], архитектура) материалына таянып, татарларда сәнгати-пластик фикерләүнең үзенчәлеген башка халыкларның культуралары белән диалогта өйрәнү.

Бу юнәлештә тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгатьнең бөтен формаларын һәм төрләрен берләштергән дизайнны (тирәлек бизәлешен) анализлау аеруча перспективалы булып санала. Әлеге фундаменталь программаны тормышка ашыру өчен бүлектә, фәннең төрле өлкәләреннән (тарих, фәлсәфә, мәдәният, социология) художестволы сәнгать үсешенең төрле этаплары буенча куелган таләпләрне үтәргә сәләтле белгечләрне сайлап, консультатив совет төзелде.

Бүлек тарафыннан педагог-мәгърифәтче һәм рәссам Ш.Таһировның тууына 150 ел тулу уңае белән «Төрки халыкларның сәнгати мәдәнияте чыганаклары һәм эволюциясе» (2008), шулай ук «Төрки дөньяда киез сәнгате: тарих һәм бүгенге заман» (2009), «Бакый Урманче иҗаты һәм милли сәнгатьнең актуаль проблемалары» (2012) дигән темаларга уздырылган халыкара фәнни-гамәли чаралар Идел—Урал регионында гына түгел, ә бөтен төрки дөнья тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгате өлкәсендә эшләүче белгечләрнең берләшүенә тәүге адым булды.

Бүлек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү йөзеннән һәм алда торган яңа максатларны истә тотып, хезмәткәрләребез фәнни тикшеренүләрне берничә юнәлештә алып баралар.

Борынгы сәнгать, шулай ук тасвирый сәнгатьнең бүгенге торышы безнең элеккеге өлкән фәнни хезмәткәребез, сәнгать фәннәре кандидаты Д.К. Вәлиеваның «Искусство Волжской Булгарии периода Золотой Орды» (2003) хезмәтендә тәфсилле яктыртылган. Автор бу хезмәтендә, Әстерхан, Казан регионнарында табылган археологик казылмалар, яңа язма чыганаклар, музей коллекцияләрен киң файдаланып, Идел Болгарстаны сәнгатен Алтын Урда сәнгате контекстына тоташтыра. Үзенең «Искусство города Булгар» дигән очеркында (2008) ул, беренче булып, Болгар шәһәре сәнгатенең монголларга хәтле чорындагы һәм Алтын Урда дәверенә кадәрге үсешен киң планда сурәтли. Д.К. Вәлиеваның «Искусство Татарстана XX века» дигән китабы (1999) бүгенге заман татар сәнгатендә реализмның стилистик төрлелегенең киң спектрын чагылдыра.

Шәхсән мин үзем «Искусство новых городов Республики Татарстан» дигән китабымда (2001) соңгы ике дистә елда Республикабызның сәнгати, мәдәни һәм социаль юнәлешләрен берләштергән тасвирый сәнгать буенча фәнни тикшеренүләремнең нәтиҗәләрен яктыртырга тырыштым. Анда тасвирый сәнгатьнең барлык төрләре һәм жанрлары үсешендәге мөһим этаплар билгеләнә, һәр этапның төп тенденцияләре ачыклана, стильгә бәйле һәр юнәлешенең милли үзенчәлекләре чагылыш таба.

«Татар театры сәхнә бизәлеше сәнгате. Аның барлыкка килүе һәм үсеше проблемалары» дигән тема буенча алып барган комплекслы фәнни тикшернүләремдә мин татар театр-декорация сәнгате проблемаларына тукталдым, сәнгатьнең берничә төрен (тасвирый сәнгать, архитектура, гамәли сәнгать, костюмнар, сәхнә бизәү һ.б.) берләштергән сәхнә бизәлеше сәнгате (сценография) феномены өлкәсендә фәнни тикшеренүләрем әле дә дәвам итә. Татар театры оешкан көннән башлап бүгенге чорга хәтле вакыт аралыгында дәвам иткән сәхнә бизәү (сценография) тарихы билгеле бер системага салынып тәкъдим ителә.

Р.И. Шәмсутовның 2007—2011 елларда алып барган тикшеренүләре «Урта Идел һәм Урал буе татар-мөселманнарының гыйбадәтханәләре бизәлеше»н колачлый. Аның максаты — архитектур корылмаларның (каллиграфик язмаларны да кертеп) гомуми күренеше фонында, гыйбадәтханәләр интерьерында бизәлеш (декоратив) элементларының функциональ ролен билгеләү, сәнгать төрләренең (витраж, мозаика, уеп-сырлап бизәү һ.б) синтезы проблемаларын ачыклау.

Көнчыгыш халыклары сәнгате дәүләт музеенда (Мәскәү) Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 70 еллык юбилеена багышлап оештырылган гарәп графикасы күргәзмәсе өчен, Р.И. Шәмсутов тарафыннан махсус төзелгән каталогны татар шамаиле сәнгатен фәнни өйрәнүнең чираттагы мөһим бер баскычы дип санарга кирәк. Анда революциягә кадәрге басмалар да, хәзерге заман авторлары әсәрләре дә урын алган.

Бүлек эшендә әһәмиятле юнәлешләрне берсе — борынгы чордан алып XXI гасыр башына хәтле дәвердәге Татарстан графикасы сәнгатен бөтен төрлелеге белән: каллиграфиясен, китап бизәү сәнгатен, татар графикасының иң тәүге формаларын (ярлыклар, шәҗәрәләр һ.б) фәнни яктан тикшереп өйрәнү; шулай ук Европа графикасының XIX гасырда Татарстанда үсеш алган юнәлешләренә, төрле этаплардагы үсеш закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен истә тоткан хәлдә, бербөтен күренеш буларак якын килеп, аларның үзенә бер стиль эволюциясе кичерүләрен исәпкә алып,

сәнгати мәдәнияттә тоткан урыннарын билгеләү.

Татарстан графикасы тарихи үсешенең тоташ картинасын гәүдәләндерүдә О.Л. Улемнованың «Казанская графика 1920 — 20-х годов» дигән кандидатлык диссертациясе сизелерлек өлеш булып тора. Анда Республикабыз милли тасвирый сәнгате барлыкка килүнең башлангыч, мөһим бер чоры фәнни яктан тикшерелгән; рус, Көнбатыш Европа осталарының классик формалары, авангардистик сәнгате, татар милли традицияләре кушылмасыннан гыйбарәт, катлаулы, үсеш юлы үткән станок графикасы (рәсем, гравюра), калыпка салынган (производственная) графика, плакат, китап һәм журнал графикасы анализланган.

Ф.Г. Ваһапованың «Художественное оформление татарской книги в дореволюционный период» дигән хезмәтендә стиль эволюциясе карала, Россиядә, Урта Азия илләрендә, Төркия, Иранда дөнья күргән гарәп графикасындагы басмалар системасында татар китабының урыны билгеләнә. Автор эзләнүләренең төп бурычы — татар рәссам-бизәүчеләрне, каллиграфист-күчереп язучыларны барлау.

О.Л. Улемнова белән Ф.Г. Ваһапова тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып «Искусство книги Татарстана» (2 томда, беренче томында — XX гасырга кадәр татар китапларының бизәлеше, аның чыганаклары һәм үсеше, икенче томында 1917 елдан XXI гасыр башына хәтле татар китапларының бизәлеше яктыртыла) дигән, рәссамнарның сүзлекләре урын алган һәм бай иллюстратив материаллар белән тулыландырылган китап басылып чыгарга тиеш. Татар китабын бизәү сәнгатенә багышланган, милли традицияләре ерак үткәннәргә барып тоташкан, әлегә хәтле махсус өйрәнеп тикшеренүләр предметы була алмаган бу хезмәтнең актуальлеге XXI гасыр башында Татарстанда полиграфиянең көчле үсеш алуы (гәрчә аңа стиль төрлелеге һәм эзлексезлек хас булса да) белән бәйле.

Сәнгать фәннәре кандидаты (2007—2011 елларда Институтның өлкән фәнни хезмәткәре) Л.Н. Донинаның «Татар театрында татар милли киемнәрен интерпретацияләү»гә багышланган фәнни тикшеренүләрен дә (бу темага ул 2010 елда Мәскәүдә кандидатлык диссертациясе яклады) бүлек эшчәнлегенең яңа юнәлеше дияргә кирәк. Ул төрле фәннәрнең — сәнгать белеме, театр белеме, эстетика, семиотека, этнография, филологиянең үзара бәйләнешләре яссылыгында тикшерелә. Бу теманың актуальлеге шуннан гыйбарәт: әлегә хәтле милли киемнәр фәкать тарихи-этнографик аспектта гына өйрәнелде. Л.Н. Донинаның максаты — традицион киемнәргә, гадәти күзаллау белән генә чикләнмичә, театр мәйданында контекстуаль әһәмият ялаган тема буларак якын килү. Шушы ук автор тарафыннан әзерләнеп, нәшер ителгән «П.Т. Сперанский, Л.Л. Сперанская. От эскиза к спектаклю» альбомы исә, үз укучыларын, беренчеләрдән булып, М.Җәлил исемендәге татар дәүләт академия опера һәм балет театры рәссамнарының иҗат лабораториясе белән таныштыра.

Тасвирый сәнгатьнең бер төре булган скульптура тарихи вакыт аралыгында — башлангыч чорыннан бүгенге көнгә кадәр — тикшерелә. Бу өлкәдә сәнгать фәннәре кандидатлары Д.Д. Хисамова белән Т.Н. Кривошеева хезмәтләре игътибарга лаек. Т.Н. Кривошееваның кандидатлык диссертациясенә нигезләнгән «Скульптура Татарстана: Истоки. Становление. Традиции» дигән китабында (2013) автор скульптура үсешен, беренче мәртәбә, киңәйтелгән хронологик планда күрсәтергә омтыла. Ул әлеге сәнгать төренең татарларның урта гасырларда

яшәгән элгәрләреннән үк калган чыганакларына юл таба, аларның алга таба, үзләреннән шактый ерак этапларындагы үсешен күзәтә һәм, шуларга нигезләп, Татарстан скульптурасының, XIX — XX гасырлардан алып, бүгенге көннәргә хәтле дәвам иткән үсеш үзенчәлекләрен ачыклый.

Д.Д. Хисамованың «XX гасырның икенче яртысында — XXI гасыр башында Татарстан скульптура үсеше проблемалары» хакындагы тикшеренүләре Татарстанда скульптураның, Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы еллардан башлап, бүгенге көнгә хәтле чорын колачлый. Автор сайлаган теманың мөһимлеге шуның белән билгеләнә: нәкъ менә шушы чорда Республикабызда скульптурага үз иҗатларында Казан сәнгать (художество) мәктәбе рус скульптурасы традицияләрен дәвам итүче профессиональ осталар килә. Д.Д. Хисамовның «XX гасырның икенче яртысында — XXI гасыр башында Татарстан монументаль скульптурасында художество процесслары» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясен (фәнни җитәкчесе — Р.Р. Солтанова. 2012) Республикабызда монументаль скульптура үсешенең тоташ бер системасын тудыруда беренче омтылыш дияргә кирәк. Өйрәнеп тупланган һәм системага салынган материаллар нигезендә сайланган тема буенча стиль юнәлешләре аерып күрсәтелгән, аларның үсеш эволюциясе яктыртылган, туган ягыбыздагы монументаль пластика үсешенең киң панорамасы фонында аларның үзенчәлекләре, төбәгебезнең скульптура сәнгате үсеше ачыкланган.

Бүлек хезмәткәрләренең фәнни тикшеренүләреннән архитектура һәм шәһәр төзелешен өйрәнүне дә соңгы дистә елларда гына башланган эш дияргә кирәк.

Сәнгать фәннәре кандидаты Г.Г. Ногманованың «Россия империясе дәверендә (XVIII—XX гасыр башы) Казан губернасы архитектурасы һәм шәһәр төзелеше» буенча фәнни тикшеренүләре, теоретик характерда гына булмыйча, бүгенге архитектура һәм шәһәр төзелеше, реставрация эшен киңәйтеп җибәрү өчен дә практик әһәмияткә ия. Бу хезмәттә Россия империясе шартларында Идел—Кама регионындагы архитектура, шәһәр төзелеше үзенчәлекләре тасвирлана. Хронологик кысаларны сайлау зарурлыгы — регионда архитектура һәм шәһәр төзелеше үсешенең тарихын фәнни торгызырга, республикада тарихи-мәдәни мирасны реконструкцияләү һәм реставрацияләү буенча кабул ителгән проект карарларын нигезләргә ярдәм итүче архив документларының шактый күп булуыннан килеп туган чара.

Институтыбыз аспиранты Н.Н. Халитованың фәнни тикшереп өйрәнү предметы — Алтын Урда чоры татар архитектурасы орнаментлары. Алар башка халыклар культурасы һәм җирле үзенчәлекләр белән бәйләнештә карала. Әлеге фәнни хезмәтнең яңалыгы шунда — ул татарларның һәм аларның борынгы бабаларының күчмә тормышына җайланып эшләнгән (күчерелмә) орнаментларны өйрәнүгә багышланган. (Н.Н. Халитованың кандидатлык диссертациясе — «Татарский архитектурный орнамент периода Золотой Орды (вторая треть XIII — первая половина XV вв.). Истоки. Типология. Закономерности стиле- и формообразования» дигән темага.)

Бүлекнең өлкән фәнни хезмәтләре Д.И. Әхмәтова заманыбызның сәнгати мәдәният юнәлешләрендәге стиль төрлелеге проблемасын өйрәнә. Бу теманы ул теоретик (фәлсәфи-мәдәни, сәнгати) аспектта да, Татарстан тасвирый сәнгатенең тарихы һәм бүгенге торышыннан чыгып та ачыклау бурычы өстендә эшли. Аның та-

рафыннан әзерләнгән «Бүгенге заман сәнгати мәдәният шартларында стиль төрлелеге» дигән монография дә инде басмага әзер. Бу хезмәттә тасвирый сәнгать үсешенең заманча тикшеренүләргә нигезләнгән, шулай ук дөньякүләм тенденцияләр яктылыгындагы проблемалары чагылдырыла. Д.И. Әхмәтова тикшеренүләренең тагын бер тармагы — Татарстандагы фотография сәнгатен өйрәнү.

Бүлек эшчәнлеге структурасындагы сәнгати педагогика өлкәсен фәнни яктан өйрәнеп тикшерү бурычы О.А. Гыйльметдиновага йөкләнде. Ул аны төрле аспектларда: шушы иҗат белән шөгыльләнүчеләрне (Казан сәнгать көллияте рәссам-педагогларын) барлау, Н.И. Фешин исемендәге КСКдә гомум һөнәри һәм махсус фәннәрне укыту методикасы, традицияләр, сәнгати педагогиканы үстерү тенденцияләре һәм аның үзенчәлекләре (Н.И. Фешин исемендәге КСК мисалында) юнәлешләре буенча алып бара. Белем бирү процессында, беренче тапкыр буларак, сәнгати традицияләрнең дәвам ителүе (варислык) мәсьәләләре карала. Сәнгать үсешенең бүгенге этабында ул аеруча көнүзәк темалардан санала. Академик дәрәҗәдәге сәнгати белем бирү традицияләрен саклау, шул ук вакытта аны үстерү хәзер өстенлекле бурычларның берсе.

Бүлекнең яшь хезмәткәрләре тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгатьнең актуаль проблемалары буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып баралар. А.Р. Исимбитьева (Институтта 2012 елдан эшли), мәсәлән, Республикада монументаль сынлы сәнгатьнең бүгенге торышын өйрәнә М.Р.Газизова (бүлектә 2012 елдан эшли) республикада чыга торган «Чаян» журналының сатирик графикасын өйрәнү-тикшерү белән шөгыльләнә. Л.М. Шкляеваның (бездә 2014 елда эшли башлады) фәнни эзләнүләре XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында Урта Идел татарларының агачны традицион уеп бизәкләү традицияләрен өйрәнүгә юнәлгән.

Бүлектә яңа серияләр буенча фәнни басмалар әзерләү дәвам итә. Монда без Татарстан, Россия, якын һәм ерак чит илләрдәге фәнни-тикшеренү учреждениеләре галимнәрен дә җәлеп итәргә тырышабыз. Ш. Мәрҗани исемендәге фәнни һәм мәдәни программаларны яклау һәм үстерү фонды (Мәскәү) матди ярдәме белән «Искусство тюркского мира» сериясеннән планлаштырылган басмаларның Казанда өч томы: 1. «Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов» (2009); 2. «Творчество Баки Урманче и актуальные проблемы национального искусства» (2012); 3. «Искусство войлока в тюркском мире: история и современность» (2013) дөнья күрде. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университеты галимнәре белән бергәләп, «История татарского искусства» сериясеннән бастырып чыгару өчен, «Художественная культура и искусство ранних булгар и Волжской Булгарии VIII—XIII веков», «Искусство периода Золотой Орды», «Искусство Казанского ханства» дигән китаплар әзерләнә.

Ф.Г. Ваһапованың «Термины изобразительного искусства, архитектуры и искусства книги: Толковый словарь = Тасвирый сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек» (2010) хезмәтендә кешелекнең һәр дәверенә караган тасвирый сәнгать терминнарының татар телендәге аңлатмасы беренче мәртәбә бирелде.

Бүлек хезмәткәрләре тарафыннан Сәнгаткярләр ассоциациясе белән хезмәттәшлектә әзерләнә торган «Искусствоведение Татарстана — Санаигэ нафиса» альманахы республикабызның хәзерге заман

сәнгати тормышындагы мөһим аспектларны яктыртуны, сәнгать белеме фәннәренең горизонтын киңәйтүне, ягъни фәннәрара тикшеренүләрнең төрле алымнарын, методологиясен, перспективаларын ачыклауны, шушы өлкәләрдәге күренекле иҗатчыларның һәм яшь талантларның яңа хезмәтләре белән таныштыруны күздә тота.

2011 елдан башлап бүлек «Татарстан рәссамнары. XX гасыр» дигән күптомлы белешмәлек әзерләү өстендә эшли. Энциклопедик характердагы биобиблиографик бу басма Татарстанның һәм бездән читтә яшәүче татар диаспораларының төрле тарихи этаплардагы сәнгати дөньясын (тасвирый һәм декоратив-гамәли һәм фотография сәнгатен), аның күпкырлы палитрасын күрсәтергә ярдәм итәчәк.

XX гасырда һәм XXI гасыр башында Татарстанда яшәп иҗат иткән рәссамнарның басмага әзерләнгән библиографик сүзлегенә өстәп, лөгатьлек (словник) эшләнә (төзүчесе: Д.И. Әхмәтова). Ул, үзебезнең республикадагы гына түгел, ә Татарстаннан читтәге сәнгаткярләрне дә кертеп, 1000 чамасы рәссам, скульптор, декоратив-гамәли сәнгать осталары, фоторәссамнар, шулай ук сәнгать белгечләре турында гаҗәеп бай мәгълүмат чыганагы булачак.

Сәнгать әсәрләреннән оештырылган күргәзмәләр Республиканың хәзерге чор тасвирый сәнгать процессларын өйрәнүгә һәм аларга, заман таләпләреннән чыгып, тәнкыйди бәя бирергә мөмкинлек тудыра. Шундый күргәзмәләр оештыруны үз күзәтчелегебезгә алуыбыз да бүлек эшчәнлегенең мөһим бер юнәлешен тәшкил итә.

Милли үзенчәлекләрне, региональ аерымлыкларны чагылдырган өстенлекле юнәлешләрне билгеләү, Татарстан тасвирый сәнгатенең үзебездәге һәм чит өлкәләрдәге казанышларын халыкка җиткерү дә бүлекнең төп бурычларыннан санала. Шуларны тормышка ашыру буенча билгеләнгән сәнгати проектларыбызның шактые гамәлгә куелды инде. Мәсәлән: ТР Милли музеенда «Татарстан китабы сәнгате» дип аталган, I Республикакүләм күргәзмә; Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында «Яр-Чаллы театры сәхнә бизәлеше» (2008); «Хәзинә» милли галереясында «Бүгенге заман киез сәнгате» күргәзмәсе (2009); 2009 елның апрель—июнь айларында Мәскәүнең Көнчыгыш халыклары сәнгате дәүләт музеенда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 70 еллык юбилеена багышлап уздырылган «Шамаил сәнгате: сүз һәм образ» күргәзмәсе.

Институтыбызның 75 еллык юбилеен билгеләп үткән көннәрдә (2014 елның декабрендә) тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге «Россия һәм БДБ илләрендә сәнгать белеме үсешенең көнүзәк мәсьәләләре» дигән тема буенча Халыкара фәнни конференция уздырды. Ул Казанның танылган сәнгать белгече, педагог, рәссам Петр Максимилианович Дульскийның (1879—1956) тууына 135 ел тулуга багышланды.

**Әдәбият**

*Ахметова Д.И.* Проблема стилевого многообразия в ситуации современной художественной культуры. Казань: ИЯЛИ, 2014. 184 с.

*Вагапова Ф.Г.* Термины изобразительного искусства, архитектуры и искусства книги: толковый словарь = Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек. Казань: Магариф — Вакыт, 2010. 231 с.

*Донина Л.Н.* Татарский костюм в театре: проблемы интерпретации и реконструкции. автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2010. 27 с.

*Донина Л.Н.* П.Т. Сперанский, Л.Л. Сперанская-Штейн. От эскиза к спектаклю. Казань: Татар. кн. из-во, 2010. 464 с.

*Донина Л.Н., Рамазанова Д.Б.* Словник названий элементов татарского костюма: учеб. пособие. Казань, 2007. 120 с.

*Кривошеева Т.Н.* Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. Казань, 2013. 254 с.

*Султанова Р.Р.* Рифкат Вахитов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 148 с.

*Султанова Р.Р.* Художники Татарстана: справочник посвящается 75-летию Союза художников Татарстана / авт.-сост., авт.вст.ст. и разделов Р.Р. Султанова, др. разделов А.Р. Ильясова, Э.Ш. Салимзянова и др. Казань: Заман, 2011. 308 с.

*Улемнова О.Л..* АРХУМАС: казан. авангард 20-х: [каталог выставки] / авт.-сост. и авт.вст.ст. И.И. Галеев, О.Л. Улемнова. М.: Скорпион, 2005.

Графком. Неформальное творческое объединение: [альбом] / вст. ст. О.Л. Улемновой. Казань, 2014.

*Халитов Н.Х., Халитова Н.Д.* Стили и форма средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казан: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Хисамова Д.Д.* Художественные процессы в монументальной скульптуре Татарстана второй половины XX — начала XXI в.: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2012. 30 с.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,*** *сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе;*

**А.Ә. ТИМЕРХАНОВ, С.Ф. ГАРИФУЛЛИН.**
**ТАТАРЧА-РУСЧА-ИНГЛИЗЧӘ МӘКТӘП СҮЗЛЕГЕ**

Агымдагы елда «Мәгариф — Вакыт» нәшриятында яңа лексикографик басма — «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге» (Казан, 2014, 512 б.) басылып чыкты. Аны төзүче авторлар — Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы А.Ә. Тимерханов һәм шул ук институтның элеккеге хезмәткәре филология фәннәре кандидаты С.Ф. Гарифуллин.

Сүзлек төзү эше күп вакыт һәм киң эрудиция, тирән белем таләп итә торган бик вак, четерекле хезмәт. Кайчак, еллар буена сузылган хезмәтебезнең нәтиҗәсен дистә еллардан соң гына күрергә дә туры килә. Мондый эчтәлектәге әлеге өчтелле сүзлекне 15 ел буе барган максатчан эшчәнлекнең зур нәтиҗәсе дияргә кирәк. Сүзлек 1993 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Татарча-русча уку-укыту сүзлеге»нең сүзлекчәсенә һәм аның төп лексикографик принципларына таянып төзелгән.

Әлбәттә, «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге»н эшләү бөтенләй үк яңа бер өлкә түгел. Соңгы елларда мәктәпләр, югары уку йортлары өчен төзелгән, күләмнәре ягыннан зур булмаган икетелле, күптелле сүзлекләр басылып тора. Мәсәлән: «Татарча-немецчә сүзлек» (Казан, 1989). «Инглизчә-русча-татарча физика терминнары сүзлеге» (Казан, 1996), «Инглизчә-татарча-русча гомумтөзелеш лексикасы сүзлеге» (Казан, 1996), «Инглизчә-татарча уку-укыту минимумы сүзлеге» (Казан, 1999), Информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары: «Инглизчә-татарча аңлатмалы сүзлек» (Казан, 2006) һ.б. Шулай ук чит һәм төрле төрки республикаларда нәшер ителгән инглиз теленә бәйле башка икетелле сүзлекләр дә дөнья күрде.

«Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге»нең нигезен хәзерге татар әдәби теленең гомумкулланылыштагы лексикасы тәшкил итә, аңа 12 меңгә якын сүз һәм сүзтезмә кертелгән. Аның максаты — татар сүзләренең рус һәм инглиз телләрендә мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү. Сүзлектә татар теленең хәзерге вакыттагы үсешенә хас үзенчәлекләр (татар, рус һәм инглиз телләренә хас конверсия күренеше, ягъни, исемнең сыйфат буларак кулланылышы, фигыльнең исемгә күчүе; татар фигыленең төп формасы итеп *-ырга / -ергә* инфинитив формасы алыну һ.б. очраклар) теркәлгән. Шулай ук телнең лексик составында барлыкка килгән, яисә башка телләрдән кереп үзләштерелгән күп кенә яңа берәмлекләр (*локатор, лекало, метеорит* һ.б.) исәпкә алынган. Шунысы үзенчәлекле, бу басмага инглиз теленең америка сөйләшенә хас берәмлекләрен һәм стилистик төсмере белән аерылып торган сүзләрен кертү өчтелле сүзлек төзү юнәлешендә беренче тәҗрибә буларак тәкъдим ителә. Теләсә кайсы телне камил үзләштерү, аның бар нечкәлекләрен оста файдалану өчен шушы телләрдәге афористик хәзинәне яхшы белү зарур. Шуны истә тотып сүзлекне төзүчеләр 1000ләп актуаль булган фразеологик берәмлек һәм аларның рус, инглиз телләрендә төгәл тәңгәлләрен биргәннәр. Рус һәм инглиз телләрендә эквиваленты булмаган очракта, татар сүзләре тасвирлау юлы белән тәрҗемә ителгән. Бу исә, үз чиратында, сүзлекнең татар-

ча лөгатьлеген берникадәр яңартуга китергән.

Теге яки бу телнең байлыгы, анда булган сүзләр саны белән генә исәпләнмичә, лексик мәгънәләрнең күптөрлелеге белән дә бәяләнә. Сүзлекне төзүчеләр күп кенә сүзләрнең мәгънәләрен тулысынча бирергә тырышсалар да, кайбер очракларда сүзләрнең мәгънәләре күрсәтелеп бетмәгән урыннар очрый. Мәсәлән, *йөгертергә* фигыленең — хайваннарда: *малларны җенси кушылдыру, каплату* мәгънәсе дә бар бит. Сүзлектә *баскетбол, волейбол, хоккей, чемпион, тренер* сүзләрен биргәч, *теннис, матч, футбол, джунгли* сүзләрен дә аерым сүз берәмлеге итеп бирергә кирәк булгандыр. Сүзлекнең яңа басмасында аның сүзлек составын, һичшиксез, тулыландырырга кирәк булачак.

Сүзлектән файдаланучыларга уңайлыклар тудыру, туган тел аша чит телне өйрәнү процессын җиңеләйтү максатыннан, китапка өстәмә материал итеп инглиз теле грамматикасы турында кыскача белешмә дә бирелгән. Бу кушымта әлеге сүзлекнең гамәли әһәмиятен тагын да арттыра.

Сүзлек киң катлау укучыларга, мәктәп укытучылары, студентлар, аспирантлар, югары уку йортлары укытучылары, тәрҗемәчеләр, масса-күләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә эшләүчеләргә, инглиз телен өйрәнүче яки һөнәри эшчәнлегенә бәйле рәвештә чит телдән файдаланучыларның һәркайсына гамәли кулланма була ала.

Сүзлекләрне бүген теләге булган һәркем яза, төзи, бастыра алса да, тиешле югарылыктагы академик басмаларны фәнни институт кына тәкъдим итә. Үз вакытында Татарстан Мәгариф министрлыгы соравы буенча 17 мең тираж җыйса да, ни гаҗәп, әлеге сүзлек нибары 1000 данә тираж белән басылып чыккан. Татарстандагы мәктәпләргә берәр данә тия микән бу?.. Якын араларда 2020 елга кадәр туризм һәм кунакчыллыкны үстерү буенча Республика программасы кабул ителәчәк. Анда Татарстанның туристлык потенциалын күтәрү каралган. Хәзер бөтен дөнья инглиз телен өйрәнүгә йөз тота. Шуңа күрә әлеге сүзлекне зур тираж белән иреклe сатуга чыгарсаң, ул аны алырга теләгән һәркем кулына барып җитә алыр иде.

***Саберова Гөлзада Гарафетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## Д.Р. ФАРДЕЕВА.
## НАЦИОНАЛЬНАЯ ПРОЗА НА СЦЕНЕ ТАТАРСКОГО ГОСУДАРСТВЕННОГО АКАДЕМИЧЕСКОГО ТЕАТРА им. Г. КАМАЛА

XX гасырның 20 нче елларыннан татар театры милли прозаны бик актив үзләштерә башлый. Театр драмада конфликт чикләрен киңәйтергә һәм тирәнәйтергә тели, иң яхшы классик әсәрләрдәге көчлелеге яки башка яклары белән аерылып торган образларга тиң геройны сәхнәдә дә гәүдәләндерергә омтыла. Сугыштан соңгы чордагы сәнгатьтә кешенең рухи кичерешләр тирәнлеген ачу, заман героеның йөзен күрсәтү җитмәү, тематик һәм жанр бертөрлелеге борчу сәбәпле, театр «зур проза»га, танылган татар язучыларының тарихи-революцион романнарына мөрәҗәгать итә.

Шул чордан алып, бүгенге көнгә хәтле, татар мәдәнияте эшлеклеләре ярдәмендә язучыларның роман, повесть, хикәяләреннән туган дистәләгән спектакльләр куела. Әмма моңа кадәр татар әдәбиятында һәм театр өлкәсендә Д.Фәрдиева күтәргән проблемага караган хезмәт юк иде әле. Шулай да, театр сәнгатен һәм әдәбиятны өйрәнүче галимнәрнең (Б.Гыйззәт, А.Әхмәдуллин, Ф.Галимуллин, Т.Галиуллин, М.Гайнуллин, М.Арсланов, И.Илялова, Һ.Мәхмүтов, Д.Гыймранова һ.б.) гомуми характердагы кайбер хезмәтләрендә билгеле бер дәрәҗәдә фактик материал, әһәмиятле күзәтүләр бар.

Китап авторы татар прозасының театр сәнгате белән бәйләнеш төрләрен билгеләүне максат итеп куйган. Эшенең яңалыгы — татар проза әсәрләрен сәхнәләштерү үзенчәлекләрен ачу. Д.Фәрдиева сәхнәгә кую өчен эшкәртелгән әдәби әсәрләргә чагыштырма анализ үткәргән һәм татар театрында милли прозаны үзләштерү барышының уртак закончалыкларын күрсәтергә тырышкан.

Яшь галимә күренекле язучыларыбыз — Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, М.Әмир, А.Гыйләҗев, К.Нәҗми, Г.Әпсәләмов, Г.Ахуновның проза әсәрләрен һәм аларның XX гасыр дәвамында Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында куелган сәхнә версияләрен өйрәнеп язган.

Д.Фәрдиева сәхнәләштерелгән әсәрләрнең төрләрен ачыклый. Беренче төр — авторның роман яки повестен шәхсән үзе сәхнә әсәре итеп эшкәртүе; икенче төр — режиссер сәхнәләштерүе; өченче төр — драматург-арадашчы ярдәмендә уртак иҗат җимеше булып әверелгән сәхнә әсәре. Бу сәхнә төрләре Г.Камал исемендәге театрда тамашачылар күңелен яулаган спектакльләр мисалында китапның аерым бүлекләрендә карала.

Хезмәтнең беренче бүлеге кайбер проза әсәрләрен язучының үзе тарафыннан пьеса итеп яңадан эшкәртелүенә багышланган. Монда Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», М.Әмирнең «Агыйдел», А.Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестьләре һәм Ш.Камалның «Козгыннар оясында» хикәясенең сәхнәләштерү үзенчәлекләре анализлана. Әйе, бу прозаик әсәрләр заманында авторларның үзләреннән сәхнә варианты итеп яздырыла, ул вакыттагы тамашачылар алдында алар шактый зур уңышка ия була, татар театры сәнгате үсешенә мәгълүм бер өлеш кертә.

Д.Фәрдиева проза әсәрләреннән иң беренче булып сәхнәдә уйналганы Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте икәнен ассызыклап уза, аңа тулы анализ ясый. Сәхнә әсәрләрен өйрәнгәндә ул төрле авторлар һәм белгечләр (Ф.Бурнаш, Г.Кашшаф, Б.Гыйззәт, А.Әхмәдуллин, Ф.Хатыйпов һ.б) фикерләренә дә таянып эш итә. Бу, үз чиратында, хезмәтнең караш гаделлеген чагылдыра һәм аның фәнни дәрәҗәсен күтәрә.

Икенче бүлектә автор проза әсәрләренең театр режиссерлары Ш.Са-

рымсаков, Х. Уразиков, Ә.Зарипов һәм Р.Хаҗиәхмәтов тарафыннан сәхнәләштерелгән вариантларына туктала. Монда К.Нәҗминең «Язгы җилләр» (сәхнәләштерелгән исеме «Сәүбәневләр») романы, Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» (Ш.Сарымсаковның сәхнәләштерелгән варианты «Хәерле юл!») романы һәм Г.Ахуновның «Чикләвек төше» повесте фәнни күзлектән тикшерелә.

Әдәби әсәрнең режиссерларның үзләре тарафыннан пьеса итеп эшкәртелүе аларны сәхнәгә куюны җиңелләштерә булса кирәк. Спектакльдә артистлар тарафыннан уйналган образлар да югары дәрәҗәдә килеп чыга. Д.Фәрдиеваның күренекле белгечләр һәм режиссерлар хатирәләренә таянып ясалган нәтиҗәсе дә шуңа килеп тоташа.

Өченче бүлектә традицион инсценировкалар тикшерелә. Моны икенче төрле — «татар әдәбиятының классик әсәрләренең сәхнәләштерелүе» дип тә әйтеп була. Монда Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар», Ш. Камалның «Акчарлаклар», А.Гыйләҗевнең «Яра» әсәрләре нигезендә барлыкка килгән спектакльләр анализлана. Традицион сәхнәләштерү дигәндә, элегрәк прозаик әсәрне пьесага әйләндерү белән авторлар шөгыльләнмәгән, режиссерлар да булмаган, шуңа күрә бу эшне актерлар, драматурглар, йә булмаса башка язучылар башкарган. Мәсәлән, Ш. Камалның «Акчарлаклар» повесте прозаик һәм драматург Г.Ахунов тарафыннан сәхнә әсәре итеп кабат эшләнә; Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестен һәм «Тирән тамырлар» романын әлеге театрның артисты Х. Сәлимҗанов сәхнә теленә күчерә.

Шулай итеп, Д. Фәрдиева татар классик прозасының 11 әсәрен һәм алар нигезендә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында, 1922 елдан башлап, хәзерге көнгә хәтле куелган спектакльләрне сайлаган. Аларга анализ нәтиҗәсендә китап авторының Г. Камал театры актерлары белән әңгәмә материалларын куллануы, театрның архив фондында сакланган бай чыганакларга таянып ихлас эш итүе күренә. Автор татар режиссурасының проза әсәрләрен сәхнәләштерү юллары үзенчәлеге турында эчтәлекле күзәтүләр ясый, театрның роман һәм повестьларгә аеруча игътибар күрсәтүен билгели; һәр әсәрнең эпик асылын ачып, әйтеп узылган спектакльләрне җентекләп анализлый.

Д. Фәрдиева татар язучыларының проза әсәрләре Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының репертуарын баетуын һәм аларның татар сәхнә сәнгатен үстерүгә зур йогынты ясавын күрсәтә алган. Татар театрының нәкъ әлеге әсәрләргә мөрәҗәгать итү сәбәпләрен, аларның сәхнәгә куелуы тарихын, режиссер һәм аерым башкаручылар эшен тәфсилле һәм эзлекле итеп тасвирлаган.

Китаби басма буларак, әлеге монографиянең тагын бер «сер»ен чишәргә туры килә. «Фәнни Татарстан» журналы гамәлгә куелгач, Институт җитәкчелеге яшь галимнәрнең хезмәтләрен журналга кушымта итеп чыгару башлангычы белән чыкты. Д.Фәрдиева китабы, шул кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе буларак, әлеге сериянең беренче карлыгачларыннан.

Бу хезмәт әдәбиятыбыз, театрыбыз тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә, хәзерге татар театрының әһәмиятле хезмәтенә бәя булып та тора. Милләтебезне тәрбияләү һәм иң мөһиме халкыбызны берләштерү көченә ия булган мондый юнәлештәге эзләнүләр алга таба да һичшиксез дәвам итәчәк.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

## БЕЗ — БЕР ТАМЫРДАН
## КОРНИ НАШИ ЕДИНЫ
## KÖKLERİMİZ ORTAK

«Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы — 2014» программасы кысаларында нәшер ителгән бу китап Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының яшь буын галимнәре тарафыннан әзерләнгән. Тышлыгындагы ТҮРКСОЙ мөһере (логотибы) аның төрки халыкларны изге максатларда бергә туплау бурычын үз өстенә алган мәгълүм халыкара оешма белән хезмәттәшлек нәтиҗәсе икәнлегенә дә ишарәли.

Әлеге затлы басманың төп үзенчәлеге шунда ки, тугандаш халыкларны дөньяга таныткан авыз иҗаты җәүһәрләре һәм төрле чорлардагы күренекле шагыйрьләрьнең шаһ әсәрләре биредә, «үзләренең янәшә торуларына шаккатырлык итеп», бер төпкә җыелган. Аларны төрле илларда басылган китаплардан, журнал төпләмәләреннән Л.М. Бәдретдинова, Г.Н.Зәйниева һәм Ф.Х.Миңнуллина сайлап-«сөзеп» алган. Урнаштыру тәртибе дә ачык: беренче итеп әсәрнең оригинал телендәгесе куелган. Аннары — татар һәм рус телләренә тәрҗемә вариантлары. Тагын шунысы игътибарга лаек, якут халкының «Нүргун Батыр», кыргызларның «Манас» дастаны, башкорт кобайыры «Урал Батыр»дан өзекләр (шул ук вакытта аларербөтен әсәр булып та кабул ителә), моннан тыш Харәзми һәм Мәхтүмколыйның шигыре шушы басма өчен беренче тапкыр әзерләнгән өр-яңа тәрҗемәләр буларак тәкъдим ителә.

Һәр әсәрне яки аерым шагыйрьләрнең тормыш һәм иҗат юлын кыска, тыгыз җөмләләр белән, әмма шактый тулы итеп чор, мохит җирлегендә ачарга омтылган, аларның өйрәнелү тарихын һәм дәрәҗәсен күрсәткән мәкаләләр (авторы — И.Г. Гомәров) басманың аерым уңышы дип әйтергә мөмкин. Текстларны русчага — Л.Ш. Дәүләтшина, Б.Ю. Хәйретдинов, Г.М. Хәсәнова, төрек теленә Б.К. Миңнуллин һәм Р.Ф. Мирхаев күчергән. Китапның редактор-корректоры Я.М. Абдулкадыйрова, бизәлеш авторы Э.Ф. Нурмөхәммәтова (Бәшәрова) булуын да әйтеп узу урынлы булыр: бинаһая зур хезмәт башкарылган бит. Иллюстратив материал белән купшыландырылган басманың күләме дә саллы гына — зур оригиналь форматтагы 311 бит.

«Хәзерге төрки халыклар һәм аларның әби-бабалары инде менә мең еллар, күп гасырлар дәвамында Евразиянең Ерак Көнчыгышыннан алып Балкангача, төньяк диңгезләрдән алып Урта диңгезгәчә сузылган гаять зур мәйданда гомер кичерәләр. ...Безнең борынгы әби-бабаларыбыз төрле империя-мәмләкәтләр (Төрки, Уйгур, Хәзәр каганлыклары, Караханый, Сәлҗүк, Кимәк, Болгар, Кыпчак... дәүләтләре, Чыңгыз олыслары, Госманлы империясе...) төзегәннәр... Кайбер башка халыклар кебек үк, төркиләр дә дөнья сүз сәнгатендә лаеклы урын алырлык бай фольклор һәм язма әдәбият тудырганнар... Төрки сүз сәнгате аның үзен тудырган халыкның рухи ихтыяҗлары белән тыгыз бәйләнештә үсә, төрки дөньяның чагыштырмача берлеген, бөтенлеген саклауга хезмәт итә.» — менә шундый рухтагы киң колачлы, тирән мәгънәле кереш сүз белән ачыла бу тупланма (авторлары — басманың фәнни редакторы, танылган галим-тюрколог, филология фәннәре докторы Х.Й.Миңнегулов һәм Институт директоры, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы К.М. Миңнулллин).

Беренче сәхифәләрне, табигый ки, рун-чөй (Күлтәгин кабер ташъязмасы) һәм уйгур язулы («Алтун ярук»), ягъни

борынгыдан — VII—VIII гасырлардан килүче ядкәрләрнең өзек-үрнәкләре, Мәхмүт Кашгарыйның атаклы «Диване лөгатет-түрк» хезмәтеннән (XI гасыр) мисаллар били. Алга таба саф-саф булып таныш исемнәр тезелеп китә: Йосыф Баласагуни («Котадгу белек»), Әхмәд Ясәви («Диване хикмәт»), Сөләйман Бакыргани («Бакырган китабы»), Әхмәд Йүгнәки («Һибәтел-хәкаик»), Кол Гали («Кыйссаи Йосыф»), Юныс Әмрә («Диван» тупланмасы), Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбиятының гүзәл бер үрнәге булган «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасын иҗат иткән Сәйф Сараи... Ниһаять, чират алда исемнәре телгә алынган дастаннарга җитә. Алар арасында, әлбәттә, татар халык иҗатының йөзек кашы — «Идегәй» дә бар. Инде укучыны, ничә буыннарны илһамландырган «Мәхәббәтнамә» җырчысы Харәзмидән (XIV гасыр) алып, XIX гасыр ахыры — XX гасыр башындагы Абай белән Тукайга, чуваш әдәбияты классигы, халкын дөньяга таныткан «Нарспи» поэмасының авторы Константин Ивановка кадәр сәламли. Әле алар арасында — тагын ун мәшһүр шагыйрь һәм аларның туган әдәбиятларының «визит карточкасы» булган әсәрләре. Билгеле, һәммәсен барлап- санап үтү үзмаксат түгел. Алда телгә алынган «Диване лөгатет-түрк» мисалында, мәгълүм «Кодекс Куманикус» җыелмасыннан, Лейпцигта 1612 елда нәшер ителгән, беренче төрки басма китаплардан саналган «Institutionum linguae Turcicae libri quatuor» («Төрки тел нигезләре») дигән хезмәттән халык җәүһәрләрен сайлап алып бирү шулай ук нур өстенә нур өсти, бу фикер төзүчеләрнең уңышы-табышы дип бәяләнергә лаеклы.

Бәхеткә, уртак рухи хәзинәбез, китапка кереш сүздә үк әйтелгәнчә, «авторларның күплеге, идея-тематик байлыгы, жанрлар һәм әдәби формаларның төрлелеге, сәнгати яктан югары торулары белән сыйфатлана». Әйе, тамырларыбыз тирән, күкләребез биек, уртак байлыгыбыз — гасырлар басымын тоеп алмазга әверелгән зирәк сүз бүгенге әдәби мохитка да зур тәэсир ясый. Тик... Әлеге хәзинә, нафталинлы сандыкларда бикләнеп, караңгы шүрлекләрдә тузан җыеп ятмыйча, хәтта фәнни өйрәнү һәм югары уку йортларында лекция булып яңгырау белән генә дә чикләнмичә, мәктәп программаларына һәм дәреслекләргә кереп, яшьтән үк милли горурлык хисләрен тәрбияләүгә, ныгытуга хезмәт итсен иде. Шулай ук соңгы егерме-егерме биш елда салкын көл астына күмелеп калган тәрҗемә учагын да дөрләтергә кирәклеген искәртә бу китап. Татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак шагыйрь улы Акмулланың «Урысча укып кына түгел белмәк — / Халь килсә, французча белгән яхшы!» дигән сүзләре бүген дә актуальлеген югалтмый, әмма, рус яки чит тел аша аралашудан бигрәк, кан-кардәшләр үзара «кан теле»ндә яхшырак аңлаша алырлар иде кебек тоела. XXI гасыр башы татар әдәбияты һәм фәненең төрек теле «күпер»еннән Европага чыга башлавы шул өметне көчәйтә, кардәш халыкларның киләчәгенә ышанычны арттыра.

***Вәлиев Мөдәррис Харис улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге җитәкчесе*

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**2—3 октябрьдә** Бакуда IV Халыкара гуманитар форум уздырылды. Аның максаты дөньякүләм глобальләшү яссылыгында XXI гасыр гуманитар проблемаларны, аларның перспективаларын билгеләү иде. Форум кысаларында түгәрәк өстәл артында түбәндәге юнәлешләр буенча фикер алышулар үткәрелде: а) мультикультурализмны чагыштырма — теориядән гуманистик практикага күчә барып тикшерү; ә) цифрлы дәвердә медианы трансформацияләү: үсешнең яңа трендлы; б) инновацион үсеш процессында фәннәрара интергрцияләрнең роле; в) тотрыклы үсеш һәм экологик цивилизация; г) глобальләшү чагылышы: традицияләрдә, трансформацияләүдә һ.б.ларда.

**20—25 октябрьдә** Казанда археологларның IV Бөтенроссия съезды булды. Анда Россиянең иң эре фәнни үзәкләре вәкилләре, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдән килгән кунаклар катнашты. Россия ФАнең Себер бүлеге археология һәм этнография институты академигы Анатолий Деревянко, пленар утырышта ясаган чыгышында, бу форумның Казанда үткәрелүе очраклы түгел икәнлеген, Татарстанда археология фәне казанышларының югары булуын билгеләп үтте. Ул моны, Казан һәм Алабуга шәһәрләренең меңьеллык тарихын фәнни нигезләү, шулай ук Республикада яңа археологик экспедицияләр һәм, тиз арада, ТР Фәннәр академиясе структурасында Археология институты белән Болгарда Археологик тикшеренүләрнең халыкара үзәге кебек, ике көчле фәнни үзәк оештырылу белән раслады, республикада мәдәни мирасны саклауга игътибарның зур булуын ассызыклады.

**2014 ел** — ЮНЕСКО тарафыннан Исмәгыйль Гаспринскийны искә алу елы, дип игълан ителгән иде. Шул уңай белән **5—17 октябрьдә** Истанбулда төрки-татар дөньясының күренекле шәхесе Исмәгыйль Гаспринскийның үлүенә 100 тулуга багышланган симпозиум уздырылды. Халыкара дәрәҗәдә оештырылган бу форумда үзләренең фәнни хезмәтләрендә Казан татарларының да иҗтимагый һәм мәдәни тормышын әйдәүче җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, педагог һәм нашир И.Гаспринскийның ролен яктырткан татар галимнәре дә катнашты. Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты профессоры Ә.Сибгатуллина (Мәскәү) доклад белән чыгыш ясап, татар әдәбиятында И.Гаспринский образы эволюциясен тасвирлады. КФУ профессоры Д.Госманова (Казан) үзенең чыгышында төрки-татар интеллектуаль фикер ияләре И.Гаспринский, Ф.Кәрими һәм С.Максуди хезмәтләренең форма-эчтәлекләрен чагыштырма планда анализлады. КФУ доценты Д.Мостафина (Казан) Гаспринскийның үлеме Россия мөселманнары тарафыннан гомуммилли фаҗига буларак кабул ителүе вакыйгаларына тукталды.

**7 октябрдә** Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 75 еллыгын билгеләп үтте. 1939 елда Татарстан АССР Халык комиссарлары Советы карары нигезендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты оештырыла. Шуннан бирле Институт татар халкының тарихын, мәгарифен һәм мәдәниятен тикшереп өйрәнү буенча татар гуманитар фәненең иң күркәм традицияләрен дәвам итә, аларны киңәйтә һәм камилләштерә. 1967 елдан башлап татар әдәбияты классигы, күренекле энциклопедист-галим, танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Иб-

рaһимов исемен йөрткән бу Институт хәзер инде Татарстанда гына түгел, ә Россиядә татар филологиясе һәм сәнгать белеме өлкәсендә киң колачлы тикшеренүләр алып баручы бердәнбер академик фән үзәге санала.

**22 октябрьдә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә күренекле тарихчы, Татарстанда һәм аннан читтә, аерым алганда Төркиядә һәм Ерак Көнчыгышта яшәүче төрки халыкларның һәм татарларның тарихы, мәдәнияте өлкәсендә олуг галим, Истанбулның Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләт белән очрашу уздырылды. Хөрмәтле кунагыбызга 70 яшь тулу хөрмәтенә оештырылган әлеге чарада Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Р.И. Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Р.З.Закиров һ.б. зыялыларыбыз катнашып, юбилярга иң җылы теләкләрен җиткерделәр. Академик Ә.М. Мазһаров Надир Дәүләткә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең көмеш медален тапшырды. 21 октябрьдә Надир Дәүләт ТӘһСИ галимнәре белән аерым очрашып фикер алышкан иде.

**13 ноябрьдә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Төрекмәнстан Фәннәр академиясе баш гыйльми сәркатибе Й.К. Хәкимов белән очрашу булды. Йосыф Корбан улы Татарстанга рәсми делегация составында килгән булган. Й.К. Рәхимов үзен каршы алган А.Л. Абдуллин (ТР ФА вице президенты), Ә.М. Мазһаров (ТР ФА президиумы киңәшчесе), Д.Ф. Заһидуллина (ТР ФА баш гыйльми сәркатибе) һәм башка вәкилләр каршында Төрекмәнстан Фәннәр академиясе һәм аның институтларының фәнни эшчәнлеге турында сөйләде. Шулай ук Төрекмәнстандагы һәм Татарстандагы Фәннәр академияләренең нано-биотехнологияләр, химия, гуманитар фәннәр өлкәсендәге уртак эшләре белән кызыксынуын белдерде.

**19 ноябрьдә** ТР ФАнең кече залында «Шәхесләребез» сериясеннән, «Җыен» нәшриятында басылып чыккан «Миркасыйм Госманов: тарихи-биографик, фәнни-документаль җыентык» китабын тәкъдим итү булды. Бу чарада ТР Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе Р.И. Вәлиев, ТР ФА президенты М.Х. Сәлахов, милли китапханә директоры Н.А. Камбиев, Лобачевский исем. китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Җ.С. Миңнуллин, КФУ профессоры Д.М. Госманова (галимнең кызы), Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты директоры Р.С. Хәкимов һ.б. зыялылар катнашты.

1804 елның 17 (5) ноябрендә император Александр I тарафыннан имзаланган Раслау грамотасы һәм Устав нигезендә Россиянең укуукыту һәм фән үзәкләре сафына Казан университеты да кушыла. Бу көнне һәр елны бирегә университетның зур гаиләсе, күп санлы дуслар һәм кунаклар җыелып, Alma mater туган көнен бәйрәм итәләр. Ә **2014 елда Казан университеты үзенең 210 еллыгын билгеләп үтте**. Юбилей тантанасы 6 декабрьдә уздырылды, ә дата белән бәйле фәнни форумнар, конференцияләр, флешмоб, спорт ярышлары, концертлар инде ел дәвамында оештырылды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2014. № 4

Бизәлеш авторы
*Э. Бәшәрова*

Басарга кул куелды: 15.12.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 18,1. Тираж 500. Заказ К-18

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында нәшер ителде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru